# казан утлары

11
НОЯБРЬ-1976

# Казан утлары

**АЙЛЫК ӘДӘБИ һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ**
**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ**
**1922 елның май аеннан башлап чыга**

**11**

**НОЯБРЬ**
**1976**


## Бу санда


**Г. БӘШИРОВ.** Җидегән чишмә. Роман . . . . 3
**Р. ХАРИС.** Рәссам. Поэма . . . . . . . . . . 81
**Ә. МОХТАР.** Чинар. Романнан өзек . . . . . . . 90
**Г. ЛАТЫЙП.** Яңгыр. Шигырьләр . . . . . . . 122

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . . 125
**Р. МАКСУДОВ.** Үлемне җиңгән батыр . . . . . 128

ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

**Ф. ШӘРӘФИЕВ.** Күркәм иҗат, бәхетле язмыш . 145

ПУБЛИЦИСТИКА

Сатлык җан-артык җан
**А. ЯХИН.** [redacted] . 151

ТӨРЛЕСЕННӘН

**Н. ФӘТТАХ.** Ерак гасырлар авазы . . . . . . 156

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ш. ХАММАТОВ.** Төп юнәлеш, төп маяк . . . . 171

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**А. РАСИХ.** Яңа үрләргә . . . . . . . . . . 182

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189



**КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА һӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ КАЗАН**

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: Зәки Нури

Редколлегия: Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 30/VII-1976 ел. Басарга кул куелды 7/X-1976 ел. ПФ 09034. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 90744 экз. Заказ К-280. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1976 ел.

**Гомәр Бәширов**

# ҖИДЕГӘН ЧИШМӘ

РОМАН

## I



Бөгелмәдә автобуска утырырга җыенучылар арасында Гайнанның зәңгәр күлмәкле яшьрәк кенә бер кызга күзе төште. Ул кыз, зур гына кәрзинен күтәреп, алдагы ишеккә барган иде, анда утыра алмады.

Кызый як-ягына карангалап торды да, «ярар, өлгерермен әле» дигәндәй, Гайнан янына килеп утырды.

Бу кыз төсе-бите белән дә бу як кешесенә охшамый иде. Озынчарак битле булса да, янак калкыннары ярыйсы ук бүлтәеп торалар. Күзләре өстендәге чем-кара кашлары хәтсез киң, алар икесе бергә кушыла язган. Кызыйның бабайларымы, әллә үзе үкме Урал таулары арасында башкорт илендә тумадымы икән? Әллә аннан да арыракмы?

Бу кызның сөйкемле сөяге бар идеме, әллә башка берәр ягы тарттымы, әмма аңа нигәдер карыйсы килә иде.

Зур бер автобус күргәч, кызый кинәт телгә килде.

— Әсә-ем! Ай, исәвән!..

Ул да түгел, кәрзинен элеп алды да йөгереп тә китте.

Гайнан, автобус ишегенә асылынган кешеләрне ыра-ера үтеп, кызыйга кәрзинен сөйрәп кертергә ярдәм итә башлады. Тик шунда кемдер аның пинжәгеннән тартып артка сөйрәргә, кычкырырга тотынды.

— Әй, кәрзин! Кәрзинне!..

Кемдер Гайнанны җилкәсеннән каптырып сөйрәп төшерде. Кемдер кәрзинне автобуска алды. Аның өстенә берсеннән-берсе әшәкерәк сүгенү сүзләре ява башлады.

---

Әсәр журналда кыскартылып басыла.

— Кара син аны, җир бит! Көпә-көндез кеше таларга, ә?
— Изеп ташларга кирәк үзен!
— Милиция нәрсә карый, милиция!..
— Сызгырт, сызгырт!
— Нигә җыеп алмыйлар шул паразитларны!..

Гайнан, башына күсәк белән суккандай, катып калды, аннары аңа бурлат төсе керде. Төрле җилкәләр, юанлы-нечкәле муеннар, мыеклар арасыннан кызыйның гаҗәпләнүдән, куркудан зур ачылган кара күзләре генә елтырап күренде.

Гайнанның: «Ялгышасыз! Дөрес түгел, нахак!» — дип кычкырасы килде. Тик ул авызын ачарга өлгермәде, ишек ябылды. Автобус, тычкан кергән умарта эчедәй гөжләп, бусарып китеп тә барды.

Әле генә көн аяз, һава аксыл-зәңгәр хрусталь төсендә иде. Кинәт барлык нурлар сүнде, бөтен дөнья берьюлы тагын ямьсезләнеп калды. Әле генә якты чырай күрсәтеп гөжләп кенә сөйләшеп утырган кешеләр хәзер аңа, без белән чәнечкәндәй, тиштереп карый башладылар.

Аның тагын күңеле сүрелде. Бу дөньяның кайсы ягына барып чыксаң да, бар җирдә дә шундый шыксыздыр, кайда да шундый ук гаделсезлек, рәхимсезлек тулып ятадыр кебек тоела башлады.

Гайнан үзенә-үзе «ахмак» диде. «Яхшылык итә, имеш. Алдыңмы кирәгеңне?» Ул, җәне чыгып, ачу белән төкереп куйды.

Автобуста Гайнан нindидер төсе-бите таныш кеше белән янәшә туры килде. Аның өстендә агара башлаган чәче төсле яңа соры костюм, аягында тишекле туфли иде. Ул Гайнанга күптәнге белеше кебек елмаеп баш иде.

— Менә, юлдаш булдык, бергә-бергә күңелле булыр,— дип сөйләнде.

Гайнанның әле генә исенә төште: бу абый аның теге кызыйга булышам дип, хур булуын күреп торды шикелле. Ул хакта берни дә әйтмәсә дә, күзләренә карагаңда, егетнең нахакка сүгелүен белә, аны кызгана иде шикелле. Гомумән, бу кеше бүтәннәрдән үзенең ягымлылыгы, игътибарлырак булуы белән аерыла иде. Һади Такташныкы кебек артка тарала торган куе чәче, бер үк вакытта ягымлы да, сыный да карый белә торган күз карашы һәммәсен берьюлы исенә төшерде: язучы абый бит бу! Былтыр мәктәпкә очрашуга килгән иде. Портретлары да бар. Кеше күзенә артык чалынасы килмәгәндәй, тәрәзәгә борылып утыруга, чибәр генә киенгән бер яшь кеше аның янына килеп баш иде.

— Исәнмесез, Камил абый!
— Саумысыз, сәламәтмесез!..

Әйе, Камил Дусаев дигән язучы бит бу! Теге яшь ир кеше:

— Камил абый, машина соратасыгыз калган, болай уңайсыз бит! — диде.

— Нигә уңайсыз? Бик уңай! Мин дә кеше күк, кеше дә минем күк! — Камил теге егеткә елмаеп сүзен бетерде.

Яшь кеше, «мәйлегез» дигәндәй, иңбашларын җыерды. Язучының хәзер сөйләшәсе килмәвен, тыныч кына карап барырга теләвен сизеп, теге егет тә бүтән сүз катмады, Гайнан да читкәрәк елышып тын гына карап утырды.

Иген басуларын, тын утырган урманнарны, ак күгәрчен булып тау итәкләренә кунаклаган нефть чаннарын Камил рәхәтләнеп карап барды. Аңа инеш буйларындагы яшел тугайлар да, саргылт кояш нуры белән мөлдерәмә тулган урман аланнары да, аларга кереп баручы чуп-чуар бала-чага, хатын-кыз төркеме дә — һәммәсе дә якын, газиз, күңелдә җылы тойгы уяталар. Инеш буена тезелеп утырган җыйнак авыллар, алардагы калай һәм шифер түбәле яңа йортлар, болын буйлары, анда сибелгән каз-үрдәк — барчасы күңелен күтәрде. Болар һәммәсе дә аның

туган иле, туган халкы иде. Ул үзе дә әнә шундый тугайларда печән чабып, басуларда иген игеп, шушындый ук авылда үскән кеше. Болар аның булачак китабының язылачак манзаралары. Аның каһарманнары әнә шунда яшәячәкләр — шушы сөйкемле якта, шушы матур елгалар буенда. Аның сугыштан соңгы чор кешеләре турында, үз буынының балалык, яшьлек еллары хакында язган әсәрләре бар. Менә хәзер бүгенге көн авылы белән хыяллана. Хәтта төшендә дә яңа әсәре белән саташа. Хәзерге заман кешесе, бүгенге авыл! Аның нечкә шигърияте, нәзберек табигате, шуның белән янәшә үк куәтле тракторлар, агрегатлар, комплекслар. Бу тыштан гына шулай ансат мәсьәлә кебек күренә. Ә уйлана башласаң, болар һәркайсы кеше язмышына барып тоташа. Алар хакында роман да, поэма да, докторлык диссертациясе дә язарга була. Үткәнне, хәзергене, киләчәкне бер фокуска җыеп күрсәтергә иде. Шуна көчең җитсен иде! Китапка кирәсе төрле вакыйгалар, газиз истәлекләр, гыйбрәтле дөнья хәлләре күңел түрендә тынгысызлана, язганны көтеп болгана. Яшь чагында Камилнең сөйгән яры бар иде. Алма кебек пешкән чагы: матурлыгы, яшьлек дәрте — һәммәсе үзендә, һәммәсе мулдан. Инде кавышабыз дигәндә генә китте дә югалды, җир упкандай булды. Нинди язмыш, нинди явыз җилләр аны сөйгәненнән аерган? Аннары менә халык тәнендәге сугыш яралары. Фаҗига бу! Ләкин ул туган илгә ялкынлы мәхәббәт чаткысы кабызсын! Уйлар, истәлекләр, кичерешләр, хыялда туа башлаган төрле манзаралар...

Җәйнең бик матур бер кояшлы көнендә бал кортлары дулап, ярсып умартадан чыгалар да, кая барасын белмичә, арлы-бирле сугылып, чәч тә баш килеп бетәләр. Шул вакыт яшь корт анасы эшлекле кыяфәт белән сабыр гына кирәкле урынга килеп кундымы, бөтен корт иле шундук тынычланып бер йомарлам гаиләгә туплана. Язылачак романга да шундый бер корт анасы кирәк. Камил бу чыгуында шул корт анасын читлеккә ябачагына да ышана иде.

Яңа әсәрнең сюжетына оеткы булырдай тормышчан материал аның кесәсендә үк килә иде инде. Шушы районнан җибәрелгән сайлаучылар хатын Камил тагын бер мәртәбә күздән кичерде. Ул хатта Ык буендагы тугайны сөреп ташларга җыенулары, чишмәләр өстендәге урманны теләсә кем менеп кисүе, Әверләп инешенең саегып бетүе хакында язганнар, депутаттан чара күрүен үтенгәннәр иде.

Камил бу хатны җибәргән Җидегән авылына иртәгә үк барып чыгарга булды.

Ташлы яр авылы турысында автобуска тагын берничә пассажир керде. Шулардан берсе, зур кара күзлек кигән, таякка таянганы килеп керүгә, Гайнан торып урын бирде. Ул сугыш елларында я танкта яна башлаган, я бүтән шундый хәвефле хәлгә дучар булган яралы кешегә охшаган иде. Аның йөзенең тиресе күп урыннарда янудан саргылт целлофан төсенә кереп ялтырап калган, җөйләнгән, имәнеч хәлгә килгән иде. Камил, аны күргәч үк, хәтеренә төшерде. Кара күзлеге аша карангалый торгач, инвалидның да йөзе яктырып китте.

— Исәнмесез, депутат иптәш, киләсезме? — диде.

Камил аңа ихтирам белән баш иде.

— Саумы сез, сәламәтме сез! Әйе, менә килеп яту...

Яралы кеше кыенлык белән генә йөри иде шикелле, тиргә баткан йөзен, муенын сөртеп алганнан соң, яулыгы белән җилләнә бирен сүзгә керешә.

— Менә бит нинди бәхет! «Теләгән колына — чыгарып куяр юлына» дигәнме? Без сезнең белән былтыр да нәкъ шушындый автобуста очрашкан идек. Хәтерлисезме?

Бу кешенең менә шундый гөрелдәп сөйләвен дә, яралы битен дә онытуы мөмкин түгел иде.

— Ә, әйе, шулай, узган җәй...

Ләкин исемен, кем булуын Камил һич кенә дә хәтерли алмый иде. Теге кеше, калын портфелен алдына куеп, җайлырак утырды да бик тәмләп кенә тезеп китте:

— Мин сезгә ике-өч кешенең башыннан узган гыйбрәтле хәлләрне сөйләгән идем — язучыга ярап куяр, китабында файдаланыр дип. Шәт, онытмагансыз? Бәлки берәр әсәрегездә язып та куйгансыз әле. Шулаймы?

— Әйе, дөрес, сөйләдегез. Исемдә...

Әйе, Бухенвальдтан котылган укытучы хакында. Ләкин, кызганычка каршы, кайсы авылныкы ул, исеме ничек, язмышы ниндирәк? Анысы Камилнең һич хәтерендә сакланмаган икән.

— Мин сез язганнарны, берсен бер калдырмыйча, укып барам. Үзебез сайлаган депутат бит! Әдәбият укыткач, бигрәк тә...

Камил уңайсызланып башын иягә ашыкты.

— Бик рәхмәт инде, рәхмәт.

— Ләкин мин сөйләгәннәр нигәдер килеп чыкмый әле. Әллә сезнең язарга вакыт булмады, әллә бүтән сәбәбе бар. Тыңлавын ифрат яратып тыңладыгыз да бит.

— Әйе, әйе, бик кызык фактлар иде, гыйбрәтле фактлар.

Камил кыенсынып як-ягына каранды. Күршеләрнең күбесе кызыксынып тыңлыйлар иде. Камил тәрәзәгә борылды. Болайга киткәч, бу кешенең нинди гыйбрәтле вакыйгалар сөйләвен дә, исем-фамилиясен дә искә төшерергә кирәк иде бит. Ничек кенә булса да! Нәрсә генә булса да, бер генә детален булса да!.. Камил, тәрәзәдән карап барган булып, узган елгы очрашуны күз алдына китерергә тырышты. Әһә! Тагын бакчачы хакында! Бакчачы... аны кемдер рәнҗеткән. Ул йортын ташлап киткән, шулай да аның буш йортына беркем дә кермәгән. Аны соңыннан, ялынып, колхозга кире кайтарганнар...

Укытучы тагын да җентеклэбрәк төпченергә кереште.

— Мин сөйләгәннәр бик оригиналь вакыйгалар иде. Икесе дә! Нинди кешенең үз йортын бушлай ташлап киткәне бар? Юк, андый, юк! Димәк, бик гадел, бик горур кеше булган. Аның намусына кагылдылармы — бетте! Бернәрсә дә җәл түгел! Хатынын җитәкли дә чыга да китә! Төкерим мин сезнең ишеләргә дип! Исегезгә төштеме? Шуның өстенә, ул әле Ленинны күргән кеше!

— Әйе, әйе, бар истә, бар!.. Менә анысын хәтерлим!

Камил вакытны сузу өчен генә булса да, кесәләрен капшарга тотынды. Ник кенә бер куен дәфтәре эләгеп чыксын! Һаман да шул ахмак гадәтенең җәзасы бу! Һәр эшне тәмам актык минутына кадәр сузу, астыңа су кепә башлагач кына кузгалу! Бу юлы да шулай булды бит! Шофер килеп кергәнче язып утырды да ут капкандай ашыгып әзерләнде, өеннән сыңар ручка белән ярым буш чемодан гына эләгеп чыкты.

— Гафу итегез... Куен дәфтәрендә бар да бит, йортын ташлап китүен хәтерлим. Әмма ни сәбәп?

Укытучы кәефсезләнеп бот чабып куйды.

— Их, җәл, материалы җәл!.. Ә мин тагын әдәбиятта чыгуын көтәм!

Камил, бик уфтанып, бу кешене кадәри хәл йомшартырга тырышты.

— Бик тә баш әйләнгән чак иде бит, иптәш, сайлау ыгы-зыгысы... Ничектер истән чыгыбрак китә язган. Дәфтәрдә бар ул барын, бар!.. Мөмкин булса, тагын берәрсен әйтеп карагызчы!

Юлдашы аңа шигәебрәк карап торды да бармакларын портфель өстендә уйнатты.

— Ярый! Крематорий газабыннан исән чыккан укытучыны сөйләгән идем. Исегезгә төштеме? Уникаль вакыйга! Татар укытучысы үзен газ камерасына ташларга җыенучы карт немецларга аларның үз телендә яттан Шиллер шигырен укый! Кешелек хакында, кешенең бөеклеге хакында! Ә?! Дүрт юллык шигырь үлемнән көчлерәк булып чыга! Хәтерегездәме?

Камил җанланып китеп башын күтәрде.

— Әһә! Әйе, исемә төште! Аны камерага салмыйча, үлекләр белән бергә лагерьдан чыгарып ташлыйлар. Соңыннан ул авылына кайтып күренергә кыенсынган, күпмедер вакыт читтә йөргән.

— Шулай анысы. Ә аның идән аска иңә башлагач, битен ялкын ялап алуы, бер минут эчендә чәче агаруы?

Кызганычка каршы, әдип башка әллә ни хәтерли алмады. Укытучының моңа тагын кәефе китте.

— Ул турыда мин үзем дә язып чыккан булыр идем. Болай буласын белсәм... Көчем житенкерәмәс дип шүрләдем. Язучы каләме кирәк иде моңарга. Әнә Мусалар, Алишлар фидакарьлеге кебек, безнең совет кешесенә генә хас бөеклеге белән күрсәтәсе иде моны! Тәрбияви роле зур булачак иде... Бигрәк тә яшьләргә. Онытыла бит, әрәм була бит! Андый батырларга һәйкәл салырга кирәк! Андыйны онытырга ярыймыни? Их-ма!

Камил малайлар шикелле кызарды. Хаклы иде укытучы. Гәрчә ул уйлаганча андый бер-ике вакыйгадан тына әдәби әсәр тумаса да, укытучының үпкәсе урынсыз түгел иде.

Укытучы хәзер аңа юньләп күтәрелеп тә карамый, аның тәмам кәефе кырылган. Бара торгач, ул, үзенә-үзе сөйләгәндәй, тагын әйтеп куйды:

— Сугыш хакында шаять мең китап язылгандыр, ә мондыйның очраганы юк әле. Ул бит чирле кеше. Аның үлеп китүе дә бик ихтимал...

Камилнең аңа: «Бәлки бу сез үзегездер?!» дип әйтәсе килде. Ләкин нигәдер кыюлыгы җитмәде.

Кайсыдыр авылга җитәрәк укытучы, өстен-башын, галстугын төзәткәләп, төшәргә җыена башлады. Портфелен култык астына кыстырып Камилгә карар-карамас урыныннан кузгалды.

— Шулай инде ул, дәрәҗәнә күрә исем, исемеңә күрә игътибар. Сез минем исем-фамилияне дә онытkансыз шикелле. Шулай сизелә.

Камил: «Юк, онытмадым», дип кистереп әйтә алмады. Гаеп анда иде.

— Зинһар, гафу итегез инде. Мин ифрат таркау кеше. Язып алганмын, дәфтәремдә бардыр анысы, тәгаен бардыр. Табармын мин аны, мөгаен, бардыр. Табармын мин аны, мөгаен, табармын!

— Мин бит әле гыйбрәтле вакыйгалар сөйләүче генә түгел. Сез сайланганда без сезнең белән өч-дүрт кәррә очраштык. Мин сезне укучыларга таныштырдым.

Оялудан Камил үзен кая куярга белмичә кызарынып аягүрә басты.

— Аһ, егетләр! Шул кадәр оятка калыр көнем бар икән! Зинһар, үпкәләмәгез инде, зинһар!

Укытучы портфеленнән болонья плащын алып беләгенә салды, таягын кулына тотты.

— Үпкәләп нишлисең?! Әгәр дә мин, әйтик, берәр генерал, я булмаса, Верховный Совет председателе, я райком секретаре булсам, сез мине, мөгаен, онытмаган булыр идегез. Шулаймы?

Аһ, шул таркаулыкны, шул хыялыйлыкны!

— Алай түгел түгелен! Шунда да бәхәсләшеп тормыйм, иптәшкәй. Гаеп миндә, бу миңа сабак булсын, мин аны төзәтермен. Тик рәнҗемәгез генә!

Әллә гафу итүе булды, әллә саубуллашуы, укытучы, башын сизелерсизелмәс иеп:

— Хушыгыз,— диде дә чыгып та китте.

Камил байтак вакыт кәефсезләнеп барды. Автобустагылар моның һәммәсен дә ишеттеләр, хәзер аңа ничектер кырын карыйлар кебек иде.

Камилне иң рәнҗеткәне — укытучының аны борын чөя, үзен эре тотып, гади кешеләр белән исәпләшми-санашмый дип уйлавы иде. Алай түгел бит, түгел! Камил җаны-тәне белән дошман андыйга! Ләкин бөтен бәла шунда ки, укытучының андый нәтиҗәгә килергә нигезе бар иде. Ул бит бу гыйбрәтле хәлне, күрәсең, аңа үзе сайлаган депутат итеп, наказ рәвешендәрәк тә сөйләгән булса кирәк. Ә менә депутат иптәш нишләгән? Каһәр генә төшсен иде шул таркаулыкка, шул харап итә аны!

Депутат булып сайланганнан бирле Камил үзен сайлаучылар каршында түгел, бәлки бөтен әдәбият һәм язучылар алдында да җаваплы итеп хис итә башлады. Чөнки язучылар вәкиле итеп сайланган икән, әдәбиятның лаеклы дәрәҗәсенә, әдип һәм шагыйрьләрнең яхшы намына кечкенә генә тап төшерсә дә, ул үзен гафу итәчәк түгел иде.

Бара торгач, Камил, әсәрләнеп, утырган урыныннан сикереп тора язды. Тукта әле, бу укытучы үз башыннан узганнарны сөйләде түгелме соң? Мөгаен, шулайдыр. Боларны бит яңа әсәрдә файдаланырга мөмкин! Әйе! «Нет худа без добра!» ди рус агай.

Әлеге укытучы сөйләгәннәргә ялганып, тере килеш бозга катырылган батыр генерал Карбышев күз алдына килеп басты. Аннары Муса Җәлил, Алиш, Курмашлар язмышы... Нинди сокландыгыч каһарманнар үстерде безнең ил!

Бу эпизодны әсәргә кертеп, теге укытучы каршында да гаепне йолырга мөмкин булачак.

Гайнанның үз кайгысы кайгы иде. Үз авылына кайтса да кайтты, кайтмаса да. Иң кыены анасына күренү...

Шулай да укытучының язучы абыйга үпкәсе Гайнанның да колагына кергәләде. Бакчачы мажарасы умартачы Минһаҗ башыннан үткәннәргә охшаган иде. Җөйле битле укытучы Сәет тә болар авылында укытып киткән иде бит. Гайнан яңадан Камил янына барып утырды. Язучы Гайнанны үз итеп, гүя аннан да уңайсызланган һәм гафу үтенгәндәй:

— Эшләр менә шулай булып тора бит әле, кем... исемең ничек? — диде.

— Гайнан.

— Кайсы авылдан?

— Җидегәннән.

— Гайнан энекәш «Җидегәнле»...

Төшәр алдыннан чемоданын алып ишеккә таба китте дә егет, зур күзләре белән ялт-йолт каранып, ашыгыч кына кире килде.

— Абый, Сәет Үтәганов райүзәктә укыта. Ул сөйләгән бакчачы безнең авылның Минһаҗ абзый түгелме икән? Шулайдыр күк тия,— диде.

Камил торып егетнең беләгеннән кысты.

— Ай, рәхмәт, энекәш! Алайса, икесен дә табабыз. Өмет бар икән! Мин килеп чыгармын әле, алайса! Ярыймы?

— Рәхим итегез.

Автобус кузгалды. Язучы кесәләреннән эзләнде-эзләнде дә, кәгазь кисәге таба алмагач, вак кына хәрефләр белән, автобус билетына нидер язып маташты.

## II

Тышта игенченең җилегенә тия, ашлыкны черетә торган бәйләнчек вак яңгыр ява иде. Гайнан күптән үк торган булса да, бернигә кулы бармыйча, үзен кая куярга белми, тәрәзә каршысына килеп басты. Өсләренә плащ бөркәнгән, целлофан япкан авылдашлары, чыпыр-чыпыр пычрак ерып, каядыр баралар, ашыгалар. Ә Гайнанның барыр җире дә, ашыгыр урыны да юк.

Казаннан кайткач, анасы Җәүһәриянең борчылып, җәберләнеп кенә түгел, хурлыгыннан елап каршы алуы Гайнанның күз алдыннан китмичә, бәгырен кимереп тора. Атасы Гайнанны үзе белән алып китеп, Бакуда укытмакчы иде. Ә анасы монда алып калды: «Үзем укытам, үзем инженер итәм!» диде. Булмады бит, анасының матур хыяллары җимерелеп төште. Атасы бер кайтыр, кайтмыйча булмас. Шул хурлыкны анасы ничек күтәрер?!

Моңа Гайнан бары үзен генә гаепле саный иде. Әле моннан бер ай гына элек һәммәсе ап-ачык иде: имтихан, аттестат, тагын имтихан, аннары вуз. Ә хәзер? Башында буталчык, күңелендә бушлык. Кәефе нәкъ әнә шул черек томанмы, вак яңгырмы каплап торган шыксыз, пычрак һава төсле — өметсез.

Капка төбенә ишетелер-ишетелмәс кенә мыгырданыпниндидер машина килеп туктады. Кечкенә капкадан егетләрчә киенеп йөрүче Гайшә-малайша килеп керде. Башында зур козыреклы зәңгәр кепка, өстендә шуның төсле үк нейлон куртка, аягында итек. Өсте-башы малайларча, ә тешләре нәкъ кызлар теше кебек вак, ап-ак. Тәрәзә аша елмаеп, үз итеп дәште:

— Нихәл, скубент!.. Әллә студент түгелме? Менә шуны белергә җибәрделәр. — Матур тешләрен күрсәтеп, күз кырые белән егетнең ачык изүенә, таралмаган бөдрә чәченә карап торды да көлеп куйды.— Я, рәхим итеп әйтәсеңме, әллә мин моны әйтмичә генә белергә тиешлеме? Синең моңсу күзләреңнән. Ә?!

Гайнанның бу кыланчык белән сөйләшәсе килми иде. Ул икенче тәрәзә каршысына барып басты. Ничек хурланмыйча әйтәсең?!

Гайшә-малайша, бармагында машина ачкычын әйләндерә биреп, көтеп карады да, җавап булмагач, йөзен чытып авызын кыйшайтты.

— Вакланмыйсың инде, әйеме? Мәйлең! Миңа нәрсә?! Мин кушканны гына эшләүче. Әле ни, керми кайткан булсаң да гаеп түгел. Ул чагында Минһаҗ янына умарталыкка менәсең, диделәр. Бүген үк, диделәр. Чурмантай үзе кушты. Салют!..

Шофер ике бармагын козырегына күтәреп китеп барды.

Өстәл янына килеп утыруга, әнисенең караңгы белән үк торып, аны кайгыртып йөрүе Гайнанның күңелен йомшатып җибәрде. Ул аңа йомырка пешергән дә, ашаганчы суынмасын дип, кат-кат тастымалга төреп калдырган. Баздан салкын каймак белән эремчек алып менгән дә, тәмле килеш ашасын дип, аларны салкын суга утырткан. Ак күмәч калдырган, шакмаклы шикәр куйган. Болар бит йорт байлыгы түгел. Аларны сатып алырга кирәк. Әни кеше унҗиде ел буена бер көн калдырмыйча эшли. Көннәрен терлекләр янында уздыра, аяклары сызлауга төннәр буе ыңгырашып чыга, иелсә, билен яза алмый... Ул бит күбрәк балалары өчен тырыша, улының тамагы тук, өсте бөтен булсын, зур белем алсын, ди.

Ничек күңелен табарга әнинең, ничек тынычландырырга?

Гайнан авыр сулап юлга җыена башлады. Шкафтан ипи эзләп тапты. Аның яртысын кисеп алды да үзенең моңарчы китаплар, дәфтәрләр

тутырып дәрескә йөрткән «бригадир» сумкасына салды. Шырпы тартмасы белән тоз алды, әйбер арасына өч-дүрт бәрәңге кыстырды. Бабасыннан ук калган тар гына чалгы пәкене кулына алып караштыра торгач, ул да кирәк булыр шикелле тоелды.

Чыгып китәргә дип барганда, ишеккә җиткәч, кемдер итәгеннән тарткандай, үзеннән-үзе туктап калды. Әллә кайчан ук үлгән бабасы да, әллә кайларда йөрүче атасы да күз алдына килде. Аның үз гомерендә беренче тапкыр эшкә чыгуын, үз аягы белән чын тормыш юлына басарга җыенуын алар күреп торалар. «Нишләр икән бу бала?» дип нидер көтәләр кебек тоелды. Өй эче шул кадәр тын: Гайнанга хәтта, әгәр чынлабрак тыңласаң, йөрәк типкәне дә ишетелер сыман иде. Менә бит, әгәр ата-анасы өйдә булса, алар аны, хәерле юл теләп, озатып калган булырлар иде. Егеткә бик моңсу булып китте. Шулай да аңа күңеленең кай төшедер бәләкәй генә яктырып киткәндәй тоелды. Минһаҗ абзыйсын ул күптән ярата иде. Бара ул аңа эшкә, бара!.. Гайнан, ата-анасыннан, олылардан күрмәкче, гомерендә беренче мәртәбә зур юлга, хезмәт юлына аяк басар алдыннан сүзсез генә бер тын утырып алды.

Урамга чыгып чаттан борылуга, Гайнан рус теле укытучысы Фазилә апасына юлыкты. Ул нигәдер баштанаяк гел яңадан, бәйрәмчә киенгән, бик тырышып бизәнгән иде. Өстендәге затлы яшел фуфайкасының итәген, җиңен тарткалап, чаттагы кызыл калай түбәле, зәңгәр капкалы йортка — колхоз җитәкчесе йортына күз аткалап барганда, укучысын күргәч, туктап калды. Кашлары өскә сикерде, кулларын «чәп» иттереп бер-берсенә бәрде.

— Кого я вижу! Гайнан! Нихәл, голубчик? Студент, да?! Сине наверно, поздравить итәргә кирәктер, әйеме? Сез бит безнең гордость!

Егетнең аны бик үк күрәсе килеп тормый иде. Шулай да хәзер инде туктамыйча мөмкин булмады.

— Исәнмесез, Фазилә Корбановна... Юк, борчылмагыз, тәбрик итәсе булмас. Котларлык берни дә юк бит.

— Как то есть, юк? Ни сөйлисең? Ә университет?

Фазиләнең җыерчыклана башлаган симез битендә иреннәре артык кызыл булып күренә иде.

— Күрәсез ич, университет үз урынында калды, ә мин — монда.

— Керә алмадыңмыни? Не может быть!

— Может икән шул!

— Менә көтмәгән идем! Што-то ышанасы килми.

— Анысы сезнең эш...

— Ә бүтәннәр? Сез бит бишәү киттегез иде.

— Шул биштән нибары Конфуций гына керер шикелле диләр. Улыгыз...

— Ул керде дә инде, телеграммасы бар. Ул — молодец!

Улы Конфуцийны русчадан хәзерләргә Фазиләнең Казанда махсус укытучы яллавын әйтеп саласы килгән иде дә, Гайнан яхшысынмады.

— Зиләйлүкнең дә русчасы кыл өстендә,— диде.

Фазилә ханым нидер әйтмәкче иде дә, әлеге мәһабәт йорт янында булуы исенә төшкәч, шыпыртка күчте.

— То есть, как «кыл өстендә?» Зиләйлүк белән сез подряд бишкә укыдыгыз, что син, голубчик! Нәрсәдер не то!

Фазиләнең, һаман да әле дүртенче класс баласы белән эш иткәндәй, югарыдан түбәнгә карап, тамак төбе беләнрәк сөйләшүе егеткә ошамый иде. Андыйга китсә, Гайнан үзе дә инәләрен тырпайта ала. Тик аның вакланасы килмәде. Ул үзен бик иркен тотып елмайды гына.

— Бездәге биш тиен калада өч тиенгә генә йөри икән шул, Фазилә Корбановна...

Фазилә, иреннәрен кысып, башын чайкарга тотынды.

— Боже мой! Нинди неблагодарный бу авыл малайлары! Рәхмәт урынына ниләр генә ишетмисең!

Укытучысы белән сүзгә килүне Гайнан өнәми иде. Ул аннан тиз котылды. Чурмантаев капкасыннан күренүгә, Фазилә, якты чырай ясап, шул якка юргалады.

Бу очрашудан әллә нинди авыр тойгы калды. Өстендә ниндидер гаеп өелеп тора кебек иде.

Әмма су тегермәненә җитәрәк, Гайнан үзен җиен ыбыр-чыбырдан сафлана барган кебек хис итте. Әнә ул тегермән стенасы янында иптәшләре белән аның бабасын атканнар. Атасының атасын. Пуля эзләре әле дә күренеп тора.

Аннары ул зиратка юнәлде. Аның бабасы шушы зиратка күмелгән. Ерак юлга чыгасы булса, я берәр зур җаваплы эшкә керешер алдыннан, авыл кешеләре һәр вакыт бу тирәне зиярат кылып чыгалар иде.

Гайнан зиратның өч кенә аратлы җил капкасын сак кына ачып эчкә керде. Тавыш чыгармаска, чәчәкләргә басмаска тырышып, усал кычытканнар, корый башлаган чәнечкеле билчәннәр арасыннан сак кына атлап зират түрендәге туганнар каберлегенә үтте. Озынча зур кабер җир белән тигезләнеп килә иде. Аның өстенә корылган чардуганның да баганаларына, араталарына яшел мүк үскән. Ярты гасырдан артык искән каты җилләр, бозлы яңгырлар, рәхимсез бураннар берсе җебетеп, берсе туңдырып кабер ташын да йончытканнар. Шулай да аның язуларын укырлык иде әле.

«Бу кабердә 1918 елның апрелендә ак бандитлар кулы белән газаплап үтерелгән ярлылар комитетының членнары ята».

Уртадагы исемгә төшеп җиткәч, Гайнан аны бармаклары белән капшады: Мәрдән Мингатин. Күңелендә дулкын кузгалды. Менә бит! Аның бабасы да кайчандыр шушы юлдан йөргән, шушы басуларда ашлык чәчкән, болыннарда печән чапкан, байлар җирен бүлешкән, иң кыен чагында, бүркенә кызыл тасма тагып, акларга каршы сугышка чыккан... Тик аларны җиңгәннәр...

Гайнан дулкынланып аягүрә басты. Карале, нинди бай күңелле, нинди зирәк акыллы, нинди батыр йөрәкле булганнар ул чабаталы ярлылар! Алар кабер якасында да бирешмәгәннәр, шәфкать сорамаганнар, әнә хәзер Гайнан узган юлдан үлемгә горур атлап барганнар. «Юк, сезнеңчә түгел, Ленин әйткәнчә булыр! Бу җирләргә, бу урман белән болыннарга сез түгел, безнең улларыбыз, оныкларыбыз хуҗа булыр!» дигәннәр.

Гайнан күңелендә сүз белән әйтеп булмастай яхшы хисләр уянды. Аның бабасы шикелле үк яхшы кеше буласы, халык мактарлык ниндидер яхшы эшләр башкарасы килде.

Тау-тау болытлар, берсен-берсе кысрыклап куыша-куыша, тыелгысыз бер агым булып, Урал тауларына таба агылалар. Иген кырлары, болыннар өстеннән аларның ала-кола күләгәләре чабыша иде.

Уңга борылып, умарталыкка күтәрелер алдыннан Җидегән чишмә тавышы яңадан аның йөрәк сагышын кузгатты. Иң соңгы кичне Зиләй белән алар шул чишмә янында утырганнар иде. Җиде чишмәнең җидесен дә татып караганнан соң, Зиләй аңа берсеннән учы белән алып су эчерде.

— Монысы иң тәмлесе! — диде. Шул салкынча учы белән аның битләреннән сөеп бик озак күзләренә карап утырды. Нинди якынайганнар, ничек яратышалар иде бит. Менә хәзер Зиләй шул ук куллары белән бәлки теге күзлеклене сөядер?! Гайнанның бу һич тә башына сыймый иде. Ничек мөмкин инде ул? Кая вөждан, кая вәгъдә?!

Шуннан бирле Гайнан үзен таланган кеше кебегрәк хис итә башлады. Ул ничектер ярлыланды, бөтенләй шәрәләнеп калды хәтта. Хәзер аны берни дә куандырмый да, борчымый да кебек иде.

Шушы авыр истәлекләрне төбе-тамыры белән йөрәгеннән йолкып чыгарырга теләгәндәй, егет ачу белән кулып селтәп:

— К чорту! Бөтенесе ялган! Берсе-бер чын түгел! — дип кычкырды.

Куаклар арасында башка киелгән капчык күренде, ул да түгел, сукмак өстенә салынып үскән миләш тәлгәшләрен як-якка этәреп, каршысына Минһаҗ үзе килеп чыкты.

Гайнанның йөзе яктырып китте, ул, иңендәге рюкзагын кулына алып, башын иде.

— Исәнмесез, Минһаҗ абзый!

— Ә-ә-ә, нихәл? Ару гына йөреп кайттыңмы, егет?!

Карт, капчыгын башыннан алып, яңгыр тамчыларын селекте. Аның сакал-мыегы һәр вакыттагыча пөхтә итеп төзәтелгән, өсте-башы җыйнак, кәләпүше бераз кырынрак киелгән иде. Гайнан картның озынча ябык битенә, коңгырт күзләренә, ирен кырыйларына күз салып, кәефен чамаларга тырышты. Зиләй хакында белгән булса, болай ачык чырайлы булыр идеме икән? дип уйлады. Гайнанның сүгенүен дә ишетмәгән булырга охшый. Гомумән, карт чын мәгънәсендә бәхетле кешеләр кебек эчкерсез, якын итеп туп-туры карый иде. Гайнанга бу бик ошады.

— Ярыйсы, болай... Исән-сау.

Өстәге түгәрәк аланның биек юкәләре астындагы шифер түбәле, җыйнак кына өй каршысында алар туктадылар. Гайнан хәзер монда кунып-төнеп эшләргә тиеш булачак. Аның сап-сары баскычларына, зәңгәргә буяган тәрәзә яңакларына аеруча үз итеп карады. Бал исе аңкып торган алан һавасы, мондагы тын иркенлек, умарта кортларының гөжләүләре аның күңелен күтәреп җибәрде.

Минһаҗ карт, кулындагы рамнарын өй каршындагы өстәлгә куеп, бүкәнгә утырды.

— Әйе, соң? Нигә ярыйсы гына? Нөктәле итеп әйттең.

— Нөктәсе шул: керә алмадым...

Минһаҗ егеткә тагын бер күтәрелеп карады. Кызының кызы Зиләйлүк белән килеп йөргәнлектән, Гайнанның яхшы укуын, мәктәпне әйбәт тәмамлавын ул электән үк белә иде.

— Ишеттем! Сәер, бик... «Нишләп» дип сорарга туры килә бит инде.

Гайнан икеле-микеле җавап бирде:

— Ишеген ачарга җегәр җитмәде, авыр икән.

Карт аңа коңгырт күзләре белән ышаныр-ышанмасрак карап куйды да рамнарның берсен алып, пычак белән кыра башлады.

— Кая, үзем, — диде Гайнан.

Умартачы карт, кулларын киндер алъяпкычына сөрткәләп, ярдәмчесенең ничек эшләвен карап утырды да:

— Синеңчә, җилнең колагы бармы? — диде.

Картның һич көтелмәгән шундый сәер сораулар бирү гадәтен Гайнан электән үк белә иде. Ул сагайды. Нәрсәгә киная икән бу?

— Белмим шул. Күргәнем юк.

— Шулай булгач, җилгә кычкырудан ни файда? — Утырды-утырды да авыр сулап куйды. — Их, әлләзи, әлләзи! Куеныңа кереп беткән кызны ычкындыргансың икән, инде эчеңнән генә тын!

Егет, кызаруын яшерер өчен, йөзен читкә борды. Бу сүзләр аны чеметтереп алды. Бу инде егетлек абруена суга иде. Ачудан теленә усал сүзләр килде.

— Зиләегезгә егет түгел, машина кирәк бит! Машинага чыга бит кияүгә!

Минһаж, уңайсыз утыргандай, кузгалып куйды. Гайнанга сыный карап торды да гаҗәпләнеп ботларына сугып алды.

— Һе! «Машина!» «Зиләегез»!.. Нигә безнең генә Зиләебез соң әле ул?! Тиз онытасың икән!

Гайнан әйтер сүз таба алмыйча башын аска иде. Карт бөтен тәне берьюлы сызлый башлагандай ыңгырашкалап торды да янбашларын сыпырды. Гайнан тазарткан рамнарны алып, өй артындагы тәбәнәк келәткә таба атлады.

Картны урынсызга рәнҗетте, ахрысы, Гайнан. Егет белән онығының яратышып йөрүләренә Минһаж тел-теш тидермәгән иде бит. Бервакыт, болар унъеллыкны тәмамлар алдыннан, Минһаж бу дуслыкны үзе дә хуп күрүен сиздерде.

— Берегез булсын агроном, икенчегез булсын зоотехник,— егылып уңарсыз! Берегез иген үстерер, икенчегез умартачылык остасы булыр да бөтен районны бал белән сыйлар. Ихлас менә!

Соңгы елларда аталы малайларга кызыгып яшәгәнлектән, Гайнан гел ирләргә тартыла, Минһаж янында ул үзен дә ир булып килүче чын егет итеп сизә торган иде. Менә хәзер ул дорфалыгына үкенеп, әчен уа башлады.

Минһаж карт келәткә барып җитәр-җитмәс кире борылды да яңадан Гайнан янына килеп утырды.

— Дөнья мине ашык-пошык хөкем чыгармаска өйрәтте,— диде.— ...Сайрак уйлаганда шулайдыр да бит. Бәрәңгедә генә үскән балаң кызыгып ак күмәчкә үрелә икән, нишләргә? Кулына сугаргамы? — Минһаж, онығының авыр вакытлар кичерүен күз алдына китергәндәй, бераз башын иеп утырды. — Анасы гел авыру булды. Таң белән фермага үзе урынына җибәрергә кирәк тә бит... «Уята алмагач, янына утырып җылыйм», ди торган иде. Башка авылда торсалар да, ярдәм кулы сузып булыр иде болай. Ә мин элеккечәрәк уйладым: эшләсен, авыр эштә чыныгып үссен, эшләгәннән бер җире дә кимемәс, дидем. Безнең заманда шулай иде бит, бүтән җае да юк иде. Хәзер алай актык чигенә җиткәнче куарга ярамый икән шул. Арттырып җибәргәнбез дә тора-бара кызыйның авыр эшкә җаны суынган. — Минһаж, ярдәмчесе тазарткан рамнарны беләгенә тезеп, кузгалырга җыенды.— Ычкынды кызый кулдан, ычкынды. Уйлаганча барып чыкмады. Их, сезне! Пешмәгәннәр!

Карт бу үкенүен шундый борчылып, шундый мәгънәле итеп әйтте, гүяки ул онығын гына түгел, Гайнанны да кайгырта иде. Минһажның берни дә яшермичә эч серен әйтеп бирүенә, үзенә үпкәләмәвенә шатланды Гайнан. Аңа күңелле хәбәр әйтәсе килде.

— Минһаж абзый, сине юлда язучы абый сорашты. Сәет абый Үтәгәновтан, Ленинны күргән кеше дигәч бигрәк тә кызыксынды.

— Алай икән. Сорашып китәләр дә китүен, бер дә юньле әйбер язганнары юк шул. Онытылып әрәм була ул еллар.

— Бусы алай итмәс. Камил абый бу, депутат!..

Умартачы карт егеткә карап торды да, нидер исенә төшкәндәй, өеннән ниндидер китапчык алып чыкты.

— Без, кем... Гайнан улым, бөтенесен уртага салып сөйләшик. Гомер уздырып, чабата туздырып йөрүчеләрне яратмыйм. Ничек синең исәп?! Чынлап тотынмакчы буласыңмы, әллә?..

Гайнан кыенсынып аягүрә басты.

— Эшемне ошатсагыз, мин инде, Минһаҗ абзый, өйрәнергә дип...

— Аңлашылды. Эш тек эш булсын! Егет сүземе бу?

— Әйе, нык сүз!

— Алайса, укыштырырга кирәк булыр. Шунсыз юньле умартачы чыкмас. Мә, бусы беренче дәрес.

Бу Гайнан хыялындагы университет профессорының беренче лекциясе урынына иде.

## III

Төштән соң умарта карап ятканда, Җидегәннән Рәмзи менде. Бакыр чәчле, битенә мул булып коңгырт төрткеләр сибелгән унөч-ундүрт яшәр малай. Аны күргә Минһаҗ абзый Гайнанга ым какты. Гайнан калын гына ипи телеменә яңа гына аерган үтә күренмәле, хуш исле бал ягып бирде. Иреннәрен юри чәпелдәтеп:

— Их, бәхетле дә икәнсең, Рәмзи, умарта караган чак бит,— диде.

Рәмзинең авыз сулары килде, күзләре елтырап китте. Шулай да ул баллы ипи сузган кулны эткән булып читкә борылды. Комсызланып бал ашар өчен килгән дисәләр гарьлек бит!

— Әйем! Йомыш белән килдем лә мин! — дигән булды, береткасы эченнән алып Минһаҗга язу кисәге сузды. Партком секретаре Идрис, бүген ял көне булу сәбәпле, Алтынбикә тугае белән Җидегән чишмә тирәсенә чит авыллардан кешеләр җыелачагын истә тотып, Гайнан белән Рәмзигә ул тирәгә күз-колак булырга, яшел патруль булып чыгарга кушкан иде. Бераз эшләгәч, Гайнан белән Рәмзи шунда киттеләр. Рәмзи, бик зур эш башкаргандай, авызын чалышайта-чалышайта, икесенең дә беләкләренә киң яшел тасма бәйләде. Бу эшеннән бик канәгать булып:

— Менә хәзер законный булды! Берәр агач кисүчене, я әрәмәлектә ут ягучыны тотсак, син саклап калырсың, ә мин авыл советына чабармын! Ярыймы, Гайнан абый? — диде.

— Ярар, чабарсың. Тик андый кешеләр очрамасын диген син.

— Ие, очрамас, бар! Узган атнада, беләсеңме, чишмә тирәсендә ничә талны кисеп аттылар, ничә җирдә учак ягып ут чыгара яздылар?!

Яшь аермалары шактый булса да, Гайнан белән бу малай дус яшиләр иде. Уенга-мазарга катнашырга туры килгәндә, алар икесе бер яклы булалар. Гайнан Рәмзине һәр вакыт канат астына ала. Бу юлы да Гайнан абыйсы белән бергә туры килүгә шатланып, Рәмзи аның әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып, такылдап барды да җиңеннән тартып куйды.

— Беләсеңме нигә синең белән йөрисем килә минем?

— Белмим шул.

— Атаң кем дип сорамаганга!

Рәмзинең эти булган кешесе, кызыл чәчле, базык гәүдәле, гел елмаеп кына торучы Усман дигән егет, бу малай туганчы ук нефть эзләүчеләр белән әллә кайларга китеп, күптән үк легендага әверелгән. Малай, анасы белән, бабасы Мисбах йортында яши иде.

Гайнан Рәмзине тынычландырасы килеп кулын селтәде.

— Әй, күз алдында ич, нәрсәсен сорыйсың? Без икебез дә этисез малайлар. Син дә, мин дә.

— Юк, алай түгел, Гайнан абый! Синең башка, минем башка. Синең атаңны, әнә, кайткан, диләр, ә минем этинең күренгәне дә юк. Бәлки малае барын гел белмидер дә әле, исендә дә юктыр!

Гайнан уйга калды. Соңгы айларда атасы Харис хакында чыннан да еш сөйли башладылар. Вышка күчерү эшендә остарган да, зур дәрәҗәле кеше булып, күрше Башкортстанга кайткан, диләр. Кызыллы-зәңгәрле машинада бу тирәләрдән дә әйләнеп киткән, имеш.

Шуны ишеткәннән бирле Гайнан башында берсеннән-берсе матуррак төрле хыяллар туа торган булды. Шәһәрчә киенгән ир-егет кыяфәтле атасы, аның «Волга»сы күз алдыннан китми башлады. Атасы өйгә кайтса, ул машина бит Гайнанныкы да булачак! Әле ул гынамы! Атасының «спидола»сы, сәгатьләре, тагын әллә нинди затлы әйберләре дә бетәсе түгелдер. Тик менә анасы Җәүһәрия нигәдер аның кайтуына һаман каршы иде әле.

Рәмзи ачу белән аяк астындагы ташларны, балчык кисәкләрен тибеп очыра, тешләрен кысып куя иде.

— Синең бүген дә җенеңне чыгардыларамы әллә?! — диде Гайнан.

— Әйе, муеннары сынсын ла! Үчеклиләр: «Атасыз кеше буламыни! Анаңнан таптыр, белә ул, сиңа гына әйтми», — диләр. Дәү булып паспорт алам да чыгам да китәм. Барыбер табам мин аны!

— Кая китәсең?

— Башта Төмәнгә. Аннан эзлим дә, эти табылмаса, теләсә кая китәм, бер кеше дә белми торган җиргә... Тик бабай гына кызганыч, ялгыз кала.

Гайнан аңа сәерсенеп карап куйды.

— Ә анаң? Ул кызганыч түгелмени?

Рәмзи башын иеп бераз уйланып барды. Гайнан малайның анасын телгә алуына үкенә башлады. Авырткан җиренә кагылды, ахрысы. Рәмзи ялт кына Гайнанга күтәрелеп карады.

— Ул да җәл инде дә... Тик мин аны ул тикле җәлли генә алмыйм. Булмый!

Гайнан иптәш малаен, иңбашына кулып салып, үзенә табарак тартты. Гайнанның өченче ел үлгән энесе Нияз да хәзер менә моның кадәр булган булыр иде... Зур борчулар төшкән бит бу кечкенә кеше башына.

— Анаң турында алай әйтмә. Әни кеше бит ул! Тудырган, үстерә, тәрбияли. Ярата үзеңне. Юк, алай ярамый!

Малайның күзендә кабынган усал очкыннар аның бала йөзен гариплэндереп, чыраена явыз төс керттеләр.

— Ә нигә атасыз тапкан? Башта нәрсә уйлаган?!

— Әни хакында алай әйтү әдәпсезлек була... Соң, булган инде... Яраткан, ышанган, монда калыр дип уйлаган. Шулай китеп барасын алдан ул ничек белсен?

— Ә син, юньле кеше булсаң, үз күңелеңне генә күрмә, әүвәл башта бүтәннәр турында уйла! Белдеңме?!

Рәмзи, өлкән дустының кулын иңбашыннан төшереп, үпкәләгән кыяфәттә читтәнрәк атлый башлады.

Алыптауның Ык елгасына караган дага сымак чыгынтысында даны еракларга таралган җиде чишмә агып ята. Алар бер-берсеннән ерак түгел җиде урыннан бәреп чыгалар да, үзләрен җәйге эсседән дә, кышкы салкыннан да саклап үскән өянкеләр, карамалар, куакларга рәхмәт әйткәндәй, күңелле шаулашып, тамырдан тамырга сикерә-сикерә, болын буена ашыгалар. Чишмәләр шавыннан үзара сөйләшә-шаулаша йөгерүче балалар шатлыгы ишетелә. Бәлки алар җир астының салкын караңгысыннан шушы якты, ямьле дөньяга чыгуларына шулай куанышалардыр?!

Балалардай шаярып, шулай уйнап кына акса да, өстәге урманнан да, астагы болыннан да борынгырак бу чишмә. Ул тик мәһабәт Урал тауларына гына яшьтәш! Моннан әллә ничә миллион еллар элгәре, та-

бигатьнең титан көче, тауларны тауларга бәреп, Урал тавы ясаганда, кеше бәхетенә килеп чыккан ул.

Әгәр чишмә телгә килеп сөйли алса, нинди генә гыйбрәтле хәлләр күз алдына килеп басмас иде! Борын-борын заманнарның теге ягында, бу тирәләр тоташ урман-чытырман чагында, кыргый җанварлар чишмә суы өчен үкерешеп-талашып бирелә берсен-берсе өзгәләп ташлаган. Гаурәтенә аллы-артлы тире генә элеп йөргән йонлач кешеләр әнә шул куаклар артында күсәкләрен тотып, күзләрен елтыратып, чишмә тамагына боланнар, пошилар су эчәргә төшкәнне сагалап ятканнар.

Мөлдерәмә сулы шашкын елгаларга агып, кыргый җәнлекләрнең сусынын кайтарып тагын миллион еллар үткән. Заманның шигъри җанлы акыллы кешесе җиде тамырдан чыккан бу могҗизага сокланып карап торган да җиде туганны Җидегән йолдызга тиңләп, бер исем белән «Җидегән чишмә» дип атаган. Шуннан бирле бу чишмә — халыкның картаймас юлдашы, юанычы, тормышының матур бизәге. Шундый да газиз ул, әгәр бу чишмә булмаса, болыннарны сугарып, якын-тирәне ямьләндереп тормаса, Ык буена нидер җитмәс, халык тормышының кай җиредер китек булыр иде.

Җыр булып, шигъри аһәң булып халык тормышына үрелеп аккан бу чишмә. Биредә сугышчылар яраларын юган, качкыннар сусыннарын кайтарган. Пугачау яулары монда чатыр корып ял итеп киткәннәр. Айда көянтәле-чиләкле кыз бармы? Ул бүтән чишмәдән түгел, тәгаен, менә шушыннан күккә ашкан. Әгәр дә аның җир йөзенә яңадан кайтасы килә икән, мөгаен, Җидегән чишмәне сагынган инде ул. Борын-борын заманнардан бирле язын сандугачлар иң беренче шушы чишмә талларына кайтып кунган, иң беренче шунда сайраган. Яшь киленне су юлы күрсәтергә шушында алып килә башлаганнар. Егетләр, кызлар, кичке шәфәкъ сүнәр-сүнмәс, качып-посып Җидегән чишмә янында очрашкан. Иң татлы мәхәббәт сүзләре шушында әйтелгән, вәгъдәләр шушында бирелгән, көмеш йөзек белән чигелгән яулыкны шушы чишмә янында алышканнар. Сырхауларны дәвалаган, арыганнарга ял булган, моңлыларны юаткан бу чишмә.

Рәмзинең яшел патрульдә беренче булуы түгел икән. Ул чишмә тирәсен җентекләбрәк карарга тотынды. Чишмәнең өске ягына күтәрелсәләр, андагы түгәрәк чирәмлектә бер төркем чит кешеләр әрәмә арасына зур итеп учак якканнар да шунда чәйнекләр, котелоклар элеп нидәрдер пешерәләр, кайнаталар иде. Кайсы ашап-эчеп утыра, кайберләре шау-шу килеп кычкыра-көлә кәрт сугалар.

Боларны күрүгә алар нидәрдер яшерделәр, болай сөйләшеп кенә утырган кыяфәткә керделәр. Кайберләре исә, артларына карый-карый, куаклар артына шыңкая башлады. Гайнан моңа бик сәерсенде:

— Нигә качалар? Кемнән куркалар? — диде.

Рәмзигә үзенең Гайнаннан күбрәк белүен күрсәтү рәхәт кенә иде. Ул көлеп күкрәгенә кулын куйды.

— Кемнән булсын, менә бездән!

Болар килеп җиткәндә учак янында утыручылар утны сүндерергә-ме-юкмы дигәндәй бер боларга, бер учакка карыйлар, икеләнәләр иде.

Җиңендәге яшел тасмасын һәммәсе дә күрердәй итеп яны белән килеп басты да, икесе өчен дә Рәмзи сөйләште.

— Я, олы кешеләргә шулай килешәмени инде? Мондый урында учак ягарга ярамаганны беләсез бит! Янгын чыгарырсыз, урманны харап итәрсез! — диде.

Кайсы читкә карады, кайсы уңайсызланып китәргә җыена башлады. Әмма бер абзый култык таягы белән учакка төрткәләп усал җавап бирде:

— Кәмит кенә сез! Каян беләем ярамаганны?! Язып куелмаган бит! — диде.

Гайнан як-ягына каранды. Чыннан да, чишмә тирәсен пычратырга, ут ягарга ярамаганны зур хәрефләр белән язып куярга кирәк икән шул.

Рәмзи сүзгә тапкыр, чая малай булып чыкты.

— Юкны сөйлисең, абзый. Беләсең бит син, бу турыда хөкүмәт карары бар! Сезгә аны көн саен радио аңлатып тора, телевизор күрсәтә,— диде.

Якын-тирәдә аунап яткан буш консерва банкалары, шешә ватыклары күргәннән соң Гайнанның да каны кыза башлады.

— Бу нинди тәрбиясезлек, абзыйлар! Җилгәнсез икән, пычратмагыз инде, ичмасам,— диде.

Яшел патруль үз сүзендә нык торды. Бер читтәрәк чокыр казып бу тирәдә аунап яткан чүп-чарны шунда тутырырга, учакны сүндереп, күмерләрен күмеп китәргә мәҗбүр итте.

Икенче көнне Алтынбикә тугаена килеп чыктылар. Болын тапталмыймы? Өлгереп җитмәгән карлыгандыр, баландыр кебекләрне вакытсыз җыеп, җимеш куакларын сындырмыйлармы, учак ягып яңгын чыгармыйлармы? Ыкта балык шартлатмыйлармы? Яшел патруль һәммәсенә күз-колак булырга тиеш иде. Авыл халкы үзе нәрсә ярап, нәрсә ярамаганны яхшы белә. Күбесенчә ап-ак булкилэр агач ботагында үсә дип ышанучылар, читтән килүчеләр белән бәрелешергә туры килә иде.

Тегермән буасын язгы ташу ерып киткәннән соң, «электр тегермәне арзангарак төшә» дип, буаны яңадан бөямәделәр. Әверләп сай инеш кенә булып калганлыктан, аның аша таштан-ташка атлап кына чыгылды. Инешнең аргы ягыннан Ыкка кадәр җәелеп яткан әрәмәле, җиләкҗимешле, түгәрәк күлле зур болынны, борынгы бабаларынча, «Алтынбикә тугае» дип йөртәләр. Колхоз идарәсенә элеп куйган җир картасында ул нечкә башы бераз гына кәкрәя төшкән озынча кыяр сыман булып күренә иде.

Саргылт комга ябышып үсеп яткан бака яфраклары арасыннан яр өстендәге чирәмгә менеп бастылар. Гайнан абыйсына бер шаян күз аткач, Рәмзи кулларын бүрәнкәләндереп авыз кырыйларына куйды да күкрәгән киерә төшеп бөтен тугайга аваз салды:

— O-ho-ho-ho!!.

Ык ярына тезелеп үскән карт өянкеләрдән, карама, элмәләрдән, алар култык астындагы таллар, балан куаклары куелыгыннан бераз гына көттереп җавап та килде:

— O-ho-ho!..

Рәмзи битендәге барлык сипкелләрен балкытып, Гайнанга «күрдеңме, эш пеште!» дигәндәй ым какты да тагын кычкырды:

— Алтынбикәбн! Без бу, без! Гайнан белән Рәмзи!

Тугайдагы куелыклар, әрәмә аралары, күл өсләре беравыктан тагын аваз бирделәр:

— И-и-и-а-а-ии!..

Рәмзи, иң газиз кешесенең тавышын ишеткәндәй, куанычыннан баскан урынында сикергәләп алды.

— Әнә! Ишеттеме? Ишетте! Әйдә, кердек! Рөхсәт бирде Алтынбикәбн!

Бала чагындарак Алтынбикәнең әнә шул иксез-чиксез әрәмәләрдә яшәвенә, тугайга килгән авылдашларын яратып каршы алуына Гайнан үзе дә чын күңелдән ышана, ул да нәкъ Рәмзи кебек тугайга дәшеп керә торган иде. Әле кайчан гына бу тирә табигате тагын да байрак, серлерәк, мавыктыргычрак иде.

Гайнан яшь дустының муен тамырын кытыклап чәчен тузгытты...

— Их син! Комсомолга керер вакытың житеп килә! Ә үзең әллә ниләргә ышанасың!

— Булган ич ул, дөрес ич ул! — Рәмзи очына-очына сикергәләп йөри торгач туктады да, тирә-ягына колак салып, шыпыртлап сөйләнә башлады. — Кайдадыр шунда беренче әбиебез бар, ул бөтенесен белеп, күреп тора, ул безне ярата дип уйлау бик күңелле бит, рәхәт бит, Гайнан абый! Чын әкият бу, ышандыра торган!

— Әкият түгел, легенда!

Малай шактый ук үзсүзле булып чыкты.

— Әй, барыбер түгелмени?

— Түгел шул! Легенданың жеп очы борынгыларга барып тоташа, булып узган хәлләргә. Әкият бөтенләй башка!

Эчкәрәк кергән саен әрәмәлек куера барды, әле кызарып житмәгән баланнар, кызыл миләшләр ешрак очрады. Куак асларыннан борынга шингән үлән исе, кара карлыган исе көчлерәк бөркелә башлады. Рәмзи жимешләрнең очраган берсен авызына тутыра бирде, сораштыра бирде.

— Ә син ышанмыйсыңмы әллә Алтынбикәби булуына, Гайнан абый?

Егет аңа күз кысып:

— Што син! Ничек ышанмыйсың?! — диде.

— Бабай шулай ди бит, Алтынбикә булган, ди, безнең Жидегән утырасы урынга иң беренче өйне ире белән шул салган, ди. Бабайга аны бабасы сөйләп калдырган. Ә бабасына — аның бабасының атасы...

Моңа үзенең дә бик ышанасы килеп, Гайнан:

— Ул чагында өй үк түгел әле, куыш кына булгандыр, — диде.

— Әйдә, куыш булсын. Бермәлне менә шушы тугайга жиләк жыярга төшкәч, Алтынбикәне әллә ниткән алама кеше куа башлаган да ул куркып Ыкка сикергән. Анысы шулай инде аның, моны бөтен кеше белә. Менә аннарыгысы ничек?

— «Аннарыгысы» да ап-ачык: Алтынбикә шушы тугайның хужабикәсе булып, мәңгегә халык күңелендә калган.

Рәмзи: «Дөресен әйтәме, икән?» дигәндәй, өлкән иптәшенә күтәрелеп карады да, күзләрен ачалак-йомалак китереп бераз уйланып баргач, тагын сорап куйды:

— Ә нишләп без аңа төшкән саен дәшәбез, тавыш бирәбез?

— Дәшмичә, аның бит тугаена кемнәр кергәнне белеп торасы килә!

Бала күңелендә һичбер шик-шөбһә калмаска, һәммә четерекле сорауларга шундук жавап табылырга тиеш иде. Бара торгач, Рәмзи үзе үк ачыклап бирде:

— Алтынбикә теге алама кешедән бик куркып калгандыр да, хәзер инде тугаена начар кешеләрне кертәсе килмидер, үзе белгәннәрне генә кертәдер. Әйеме, Гайнан абый?!

Гайнан аның бу тапкырлыгын ошатып аркасыннан какты.

— Менә, менә! Үзең дә беләсең икән бит! Молодец!

Әмма яшүсмернең беркатлылык белән кызыксынуы һаман дәвам итә иде әле:

— Ә ничек бер дә картаймый да, үлми дә соң ул? Бабайлар заманында да шул бер Алтынбикә, безнең заманда да!

Гайнан яшь иптәшен үзенә тартып янтавына кысты.

— Юләр малай! Алтынбикә үлгәч, монда нәрсә кала? Шәп-шәрә болын гына кала! Әйеме? Кемгә дәшәрсең ул чагында шулай якын итеп, үз итеп?!

Алар бер-берсенә карап елмаештылар да тугайның ин аргы кырыена — «Сандугач култыгы» дигән аулак почмагына таба киттеләр. Куе әрәмәләр арасыннан боргаланып узган дымлы тар сукмакта аларның битләренә үрмәкүч пәрәвезе сарылды, яка эчләренә корыган яфрак, чүп-чар, бөжәкләр тулды. Алар миләш пешеп утырган кечкенә аланнар-

га барып чыктылар, аннары аларның сукмаклары түгәрәк булып иңеп төшкән ниндидер тирән чокырларны әйләнеп узды. Бу тирәдә кайчандыр юлбасарлар, качкыннар яшәгән, герман сугышы вакытында дезертирлар качып яткан дип сөйлиләр. Алтынбикәнең «И-и-и-а-а-и» дигән җавабы да менә шушы куелык ягыннан ишетелә бит инде. Бу тирәдә һәр вакыт ниндидер серлелек сизелә, һәр куак артында нинди дә булса көтелмәгән берәр куркыныч, берәр җанвар сагалап тора кебек иде.

Тын гына бара торгач, Ык буена килеп чыктылар. Табигать үзенең иң татлы җиләк-җимешләрен һәммәсен дә шушы тирәгә яшергән диярсең. Яр буендагы карт өянкеләргә ышыкланып биредә кара карлыган, кура җиләге, чия, кыргый алмалар үсә, бөрлегәндәй алсуланып пешкән кызыл карлыган тәлгәшләре асылынып тора.

Кемнәрнеңдер куаклар арасында чатыр-чотыр йөрүен ишетеп, Рәмзи шунда ташланды. Анда тавыш булып алды, кемнәрдер читкә йөгерде, кемдер куркып кычкырды. Озак та үтмәде, Рәмзи үзе кадәррәк бер ят кызны җитәкләп чыкты. Кызый кечкенә генә төенчеген күкрәгенә кыскан да маңгай чәче арасыннан боларның әле берсенә, әле икенчесенә куркынып күз ата иде.

— Кайсы авыл? — диде Гайнан.

Кыз, башын иеп, ишетелер-ишетелмәс кенә:

— Сөендекнеке, — дип сузды.

— Иптәшләрең кая?

— Качтылар...

Гайнан аның төенчегеннән алган чикләвекне бик җиңел генә урталай ярды. Чикләвек ямь-яшел, кабыгы да камыр шикелле йоп-йомшак иде.

— Күрдеңме? Җыярга иртә бит әле. Нигә әрәм итәсең?

Кызый, батыраеп, кыюрак сөйләшә башлады.

— Җиңгәйгә ул. Безнең җиңгәй бәбәйгә узган да күңеле шуны теләй!

— Төше бәләкәй бит әле, тары ярмасы тикле генә!

— Ә ул чикләвекнең төшен түгел, кәшәнкә[1] ачысын теләй!

Рәмзи, кызыйның сүзен расларга теләгәндәй, яшел кәшәнкәне чәйнәп карады да йөзен чытып башын селкетте.

— Фу, ач-чы! Аз гына татлы да. Иреннәрне бөрештерә... Ничек ашый ул аны?!

Кызый тагын да шәбрәк сайрарга тотынды:

— Ә ул гел ачыны теләй! Мин аңа урман алмасы да табып бирдем инде.

Гайнан белән Рәмзи бер-берсенә карашып алдылар. Гайнан, аркасына йомшак кына кагылып, аны Сөендеккә алып бара торган сукмакка чыгарды.

— Ялгыз гына курыкмыйсыңмы?

— Юк, курыкмаем. Йөгерәм генә!

— Бар, иптәшләреңә әйт: чикләвек яшел әле, без аны җыярга сентябрь башында гына чыгабыз.

Аннары алар беравык тын гына агып яткан Ык суы өстендә акчарлакларның балык аулавын карап тордылар.

Кире борылып кайтыр якка юнәлгәч, куе әрәмәлек чорнап алган түгәрәк күлдә нидер шупырдады. Камыш арасыннан күтәрелгән кыр үрдәге, канатларын сызгыртып, Ык ягына очты. Аннан төшеп калган бармак башы тикле генә ак мамык, куаклар өстендә айкала-чайкала, күбәләкләр белән бергә һавада әйләнә-уйный калды. Ике егет үрдәкле күлне аяк очларына гына басып, читтән әйләнеп уздылар.

---

[1] Кәшәнкә — чикләвекнең үскәндәге тышкы сусыл оясы.

## IV

Тугайның авылга караган читенә якынлашып килгәндә, Рәмзи нидәндер курыккандай, кинәт кычкырып җибәрде:

— Карале, кара, әллә нәрсә килә!

Карасалар, Сөендек иңкелендә ниндидер бер биек нәрсәнең селкенгәләп килгән башы күренде. Ул челтәрле баш, җир астыннан калкып менгәндәй, күзгә күренеп күтәрелә, торган саен якыная, зурая иде.

Гайнанның мондыйны элек тә күргәне бар икән.

— Вышка ич бу! — диде.

Рәмзинең ансат кына ышанасы килмәде. Ул тәмам эсәрләнгән, аның күңелендә уйларга йөрәк җитмәстәй зур өмет кабынган иде. Әгәр?..

— Кит аннан, булыр инде! — дигән булды. — Вышка бик дәү ич ул, ничек йөрсен?!

Ул яктан хәзер акрын гына гөрелдәү дә ишетелә башлады. Шунда, кинолардагы танклар атакасына охшый төшеп, үр өстенә җидемесигезме трактор килеп менде. Дүртесе алгы юньнән тарталар иде, берсе арттан килә, калганнары як-яктан озын корыч аркан белән манараны аудармыйча баралар. Шул гөрелдәшкән тракторларның нәкъ урталарында, шактый кәефләнеп туйдан кайтучы борынгы Алып бабай сыман горур кыяфәттә, киң лафетка баскан кырык өч метр биеклектәге нефть вышкасы килә.

Рәмзи, баскан урынында сикергәләп:

— Ай-яй! Кара әле! Ничек аумый, ә?! — диде. Ул да түгел, кулын чәбәкләп сикерә-сикерә көләргә тотынды:

— Гулливер ич бу, Гулливер! Лилипутлар да аны шулай як-ягыннан арканнар белән тарттырганнар бит!

Гайнан да кечкенә иптәшеннән ким дулкынланмый. Ул нидер сизенә, дулкынлана, аның хәтта тамагы кибә, лафеттагы бригадирдан күзен дә алмыйча каушап, әсәрләнеп нидер көтә иде.

Шунда Гайнанның өченче көн кич анасы белән сөйләшүе исенә төште. Ул соңрак кайтып йокларга гына яткач, печәнлеккә менә торган баскычта күренде анасы.

— Йокламыйсыңмы әле? — диде.

— Юк, ник? Нәрсә бар?

Якын-тирәдә кеше-кара булмаса да, анасының шыпыртлап сөйләшүе Гайнанны гаҗәпләндерде.

— Атаң кайткан бит!

Гайнан торып утырды.

— Ә?! Әтиме? Кая, өйдәме?

Җәүһәрия улын иңбашыннан басып кире яткырды.

— Юләр, өйгә димим ич, Башкортстаннан монда күчеп килгән. Үзем дә күрдем!

Гайнан яңадан торып утырды.

— Үзең дисеңме? Якыннанмы, исәнләштегезме?

Анасы әйтергә базмыйча бераз тынып торды.

— Исәнләште, ди! Туктамады ул, ферма яныннан узып кына китте. Ике тапкыр. Кызыллы-зәңгәрле машинада.

Гайнан менә хәзер күзләре белән шул машинаны эзләп арткарак текәлде. Бар иде андый машина, бар иде!

Бригадир идәнгә аякларын җәеп баскан килеш, кулындагы бүрек сыман нәрсәсен баш очында тегеләй-болай айкап, тракторларга юнәлеш бирел бара. Менә ул лафеттан сикереп төште дә шуларны күзәтә-күзәтә арты белән атлый. Машиналарның гүләве көенә аякларын сыгылдырып көяз генә атлап килә дә кинәт җиңел генә тагын алды белән борыла, тагын лафетына сикереп менә иде.

Рәмзи бу батыр кешедән күзен ала алмыйча сокланып телен чартлатып куйды.

— Карале син, әй! Ничә тракторны үйнатып кына йөртә бит! Нинди биек манараны ничек иттереп аудармаенча шудырып кына бардыра!

Гайнан бер сүз дә әйтмәстән башын гына ия, ул өметләнә, менә хәзер нидер булыр шикелле тоела иде. Ә вышка торган саен якыная бара, әле иңлекләрне кичеп, әле сөзәк үрләргә күтәрелеп, болын буеның әллә никадәр җирен иңләп килә. Бер караганда аны зур оркестрга, бригадирны дирижерга охшатып булыр иде. Бригадир да үз каршысында салмак кына чайкалгалап баручы йөз тонналы бу гигант манараның үзән чыкканда күпмегә авышуын, кырын-ярын урыннан узганда кайсы арканының актык чигенә кадәр тартылуын, кайсы тракторның җир тырнап үкерүен колагы белән ишетеп, күзе белән күреп кенә түгел, нәкъ дирижердай, бөтен тәне белән тойган кебек күренә.

Тракторчыларның сигез пар күзе, сихерләнгән шикелле, шул тылсымлы бүреккә төбәлгән, ә куллары шул бүрек кушканча тракторны я уңгарак, я сулгарак бора, машинаның йөрешен я тизләтә, я акрынайта иде.

Бригадирның буй-сынына сыныйрак карый торгач, Гайнан авызын ачып сүзсез калды. Аннары:

— Әти ич бу! — дип кычкырып җибәрде. — Минем әти бу!

Рәмзи аның янында тыпырдап:

— Менә, әйттем бит, име?! Әйттем бит мин сиңа! — диде.

Әйе, буе-сыны да, башын әнә шулай аз гына сулгарак кыйшайтып йөрүе дә — һәммәсе дә Гайнан атасы! Иске сырма киеп җәяү чыгып киткән кеше, әнә нинди машиналарга баш булып кайта!

Егетнең йөрәге кысылды, нишләптер көләсе, тагын әллә нишлисе, хәзер үк каршысына йөгерәсе килде. Ул җиңен тарткалап, өстен төзәткәләп атасына таба китте.

Ләкин, берничә адым атлагач ук, гүя итәгеннән тарткан кебек, туктап калды, колагына анасының: «Кайтыр атаң, җанкай-җанашлары җибәрсә!» дигәне ишетелде.

Ата белән ана арасындагы күңелсезлекнең сәбәбен егет азрак чамалый иде. Аның аңлавынча, атасының читтә йөрүенә әни кешенең үсүзлелеге дә сәбәп булды. Бакуга барып урнашканнан соң, аталары ничә тапкыр акча җибәрде, «балалар белән төял дә кил!» дип ни ялынды! Бармады аналары. «Балаларны бала итсәң, үзең кайт. Туган-үскән якларымны ташлап, әллә кайларда сөйрәләсем юк әле», дип язды. Сүзен тыңламагач, ничек кимсенмәсен ир кеше?!

Шуңлыктан, Гайнан күңелендә атасына һичбер кире караш юк иде. Әмма шул ук вакытта әнине дә аңларга, аны да рәнҗетмәскә кирәк бит әле.

Әмма хәзерге бу зур шатлыгын болар гына барыбер баса алмады. Биек вышка мәһабәт гәүдәсе белән салмак кына чайкалгалап һаман якынаеп килә, ә шул дәһшәтле гөрелтенең нәкъ уртасында сугыштагы генерал урынында, һәммәсенә команда биреп, һәммәки машиналарның гөрелтесен үзенә буйсындырып, бүтән беркем дә түгел, аның атасы Харис Мингатин кайтып килә иде бит!

Рәмзи татлы уйларга бирелеп:

— Их, минем әти дә шулай кайтасы булса, мин үн ел көтәргә дә риза! — диде.

Бәләкәй иптәшенең бу кыюсыз хыялын сүндерәсе килми иде:

— Һи! Кайгырма! Синең атаң бәлкем болардан да шәбрәк машиналарда кайтыр әле, шулай дип уйла син! — диде Гайнан.

Ул арада көтелмәгән хәлләр булып алды. Вышка Алтынбикә тугаена якынлашканда, күрше Сөендек авылыннан бирегә таба йөгергән бер

хатын-кыз күренде. Кем бу, ничек бу? дип гаҗәпләнеп торганда, очлы күз Рәмзи, дустының җиңеннән тартып:

— Сәйдә апаң бит! — диде.

Гайнан үзе дә шулай шәйләгән иде. Моның ни белән бетәсен уйлап өлгергәнче, Сәйдә йөгереп килешенә атасының муенына сарылды. Тракторлар туктады. Гайнанның аяклары аны ничектер үзеннән-үзе шул якка алып киттеләр. Менә ул инешне узды. Яр буеның комы кыштырдап артта калды, колагына тракторларның басынкы гөрелдәве килеп керде. Вышка тирәсендәгеләр һәммәсе тынып, ата белән улына текәлеп калдылар. Гайнанның маңгаена тир бәрде, ул бөтенең кызышуын сизде. Салмак кына якынаеп килгән атасының күзләре челт-челт килә, ирен кырыйлары дерелди, бая гына арлы-бирле айкаган сихри бүреген ул хәзер нишләтергә белмичә әле бер кулына, әле икенчесенә ала иде. Аннары атасының мыегы аның колак артын кытыклады, ул аның кайнар сулышы белән генә «улым!» диюен ишетте, үзен моннан дүрт-биш ел элекке кебек, яшь-яшь малай итеп хис кылды.

Авылдан, мотоциклларга атланып, колхоз председателенең урынбасары Идрис белән агроном Фәйрүзә, тагын берничә идарә члены килеп төштеләр. Исәнләшкән-күрешкәннән соң сүз карта өстенә күчте. Идрис белән агроном, Алтынбикә тугаеның төрле урыннарын күрсәтә-күрсәтә, скважинаны тугайда казуга каршы булуларын әйттеләр.

Идрис туганнан туган абыйсы Харис белән башта кочаклашып күрешкән иде, әмма тиз үк җыйнак кына кара мыегын бармак очы белән сыпыргалап, елмая-елмая гына аны үз фикерләренә күндерергә тотынды.

— Синең туган авылыңа болай шаулап-гөрләп кайтып төшүеңә без бик тә шат, Харис абый. Шулай да тугайга кертәсебез килми.

Харис икесе ике ягында басып торган улы белән кызына карап көлеп җибәрде:

— Менә сиңа, мә! Үзе кайтуыма шат, ә үзе тугайга җибәрми! Ничек була инде бу?!

— Үзең дә беләсең, скважинаны анда казысагыз, берни дә калмаячак тугайдан!

— Нигә алай бик курыктың? Безгә күпме генә кирәк? Нибары бер гектар!

Әмма Идрис үз сүзен куәтләде:

— Юк абый, булмый ул. Мондый куәтле техника кергәч, тугайдагы җимеш куаклары, җиләкле аланнар, кечкенә күлләр исән кала алмый.

Харисның бөтен күңеле янындагы улы белән кызында, ул дулкынланудан Идрис әйткәннәрнең асыл мәгънәсен аңлап та җиткерми иде әле.

— Аһ, алла! Соң килгән зарарны хөкүмәт түли бит, ярыйсы гына түли! — диде.

Агроном Фәйрүзә кулын селти-селти бригадирның каршысына ук килеп басты.

— Юк, юк, кермәгез дә, түләмәгез дә! — диде.

Зур гәүдәле бригадирга бу бәләкәй генә кызыйның каршы килеп маташуы кызык тоелды. Ул кычкырып көлде.

— Кара, кара! Монысына тикле каршы! Сез нәрсә? Акчадан баш тартасызмыни? Түлибез дим бит, түлибез!

Шундый мәһабәт машиналар белән эш иткән, үзенә баласытып карап торган дәү-дәү ир-ат уртасында Фәйрүзәгә үзен кыю тоту ярыйсы ук читен иде. Әмма үзенең хаклы булуы, бөтен колхоз исеменнән сөйләве аңа көч бирде.

— Алайса, әйтегез әле, Харис абый, тугай уртасындагы, кыр үрдәкләре бала чыгара торган камышлы күлгә күпме түлисез? «Сандугач

культыгы»ндагы меңләгән кош оясы, күке кычкыруы, сандугач сайравы, тартай белән бытбылдыкның кечке концертлары күпме тора?

Харис сискәнеп киткәндәй, агрономга күтәрелеп карады да көлемсерәп кулларын күтәрде.

— Ну, җиңдегез, мин пас! Булды, бетте! — Ул кулын селтәп тракторчыларга моторларын сүндерергә кушты. — Хуҗаларның рөхсәте юк икән, көчләп кермибез. Юк! Скважинаны бераз читкәрәк тә казырга була. Ну кайда казыйсың, анысын инде конторадагы геологлар кайгыртыр.

## V

Күп тә үтмәде, бакча уртасындагы беседкада башта нидер шытырдады, аннары микрофонга чиертүләре ишетелде. Шуның артыннан ук мөлаем хатын-кыз тавышы иртәнге әңгәмәне башлап та җибәрде.

— Тыңлагыз, тыңлагыз! «Җидегән» колхозы сөйли. Хәерле иртә, иптәшләр! Микрофон алдында колхоз председателе Ризван Чурмантаев абый.

Менә тамаша! Хуҗаларның эшне шул кадәр иртә башлауларын хуп күреп беседкага якынлашкан арада, Чурмантаев сөйли дә башлады. Аның кәефе күтәренке булырга охшый, ул «Җидегән»гә кергән өч авылның һәр йортында меңгә якын колхозчының игътибар белән тыңлаячагына, аның һәр әйткәне закон булып ишетеләчәгенә нык ышанган хәлдә, көр тавыш белән тотынды. Бүген колхоз бодай урырга керешкән икән, председатель башта шуны искәртте.

— «... Менә хәзер, шушы минутта, дружно кузгалабыз да кырга китәбез и башны да күтәрмичә эшләйбез. Эш фронтын җәеп җибәрдекме, анда инде шалтай-балтай йөрүләрне категорически бетерәбез. Все! Папирос беткән саен, механизатор Салихҗан Турай шикелле, ДТ-74 кә атланып, магазинга чабу фактларына, и шулай ук басу түреннән хатын янына кайнар пәрәмәч ашарга или анда, әйтик, мунча керергә кайту фактларына чик куябыз! Хатыннар янында соңыннан иркәләнәбез, уборка беткәч. Аңлашылдымы? Басуда ашыйбыз, басуда йоклыйбыз. И шулай ук папирос белән обеспечить итү проблемасын да бүгенгесе көннән башлап, техника кумаенча гына, эш урынында хәл итү чаралары күздән кичерү мәсьәләсе белән оешкан төстә шөгыльләнәбез. Аңлашылдымы? Аңлашылды! Все!..»

Камил: «Мал бит бу, мал!» дип кычкырып куйды, көлә-көлә кабаланып күзлеген киде. Чурмантаевның үзенә генә хас интонациясен, кызык сүзләрен онытмаска тырышып, куен дәфтәрен чыгарды.

Ризван исә, беравык микрофонга өргәләп торганнан соң, көр генә тамак кырып, янә сөйләп китте.

— «Шуннан ары килеп, завферма Җәүһәрия апасы и башка терлекче иптәшләр, сезгә дә гәп бар. Гәп шул: бу арада хурлыклы рәвештә сөт кими. Кими и все! Как завферма, как коммунист буларак, коммунизм төзү фронтында яңадан-яңа үрләр яулап аласы урында, без нишләйбез? Район сводкасында категорически аска тәгәрәйбез. Нилектән тәгәрәйбез? Чөнки дә удар темплар белән эшләмәйбез, юл яктыртып баручы район маякларыннан үрнәк алмыйбыз! Карале, сезгә әйтәм! Болай юк-барга мәлҗерәмәек, малай укырга кирә алмаганга күрә генә күңелне төшермәек әле! Андый вакытларда чын коммунист нишләй? Кан төкерсә дә сиздермәй, эшкә зарар китермәй, кырыкка ярылса ярыла, иллә мәгәр сөт-май, җон-күкәй планнарын ничек кенә булса да үтәмәенчә калмый! Азык бит сыерның муеныннан — хет яшиле, хет тегендәе. Хет шартлаганчы аша! Ну сөтне дә бир! Бүтен район каршында колхозны рисвай иттермә! Аңлашылдымы? Все. Бүтән сөй-

ләшеп тору юк. Әйдәгез әле, сынатмаек, әйдәгез әле, күрсәтәек матур эш темпларын!»

Көтмәгәндә үзе кулга килеп кергән бу «табыш»ка куанып, Камил аны көлә-көлә куен дәфтәренә теркәп алды да җиләк-җимеш бакчасына игътибар итте. Нинди генә алмалар, карлыганнар, чияләр үсми монда! Бу, ихтимал, Камил күргән бакчаларның иң тәрбиялесе, иң оста үстерелгәне булгандыр. Алмалардан хуш ис бөркелеп тора, куе бишни төскә кергән чияләр, кара, кызыл карлыганнар иртәнге кояш яктысында мең урыннан елтырап күренәләр. Һәр агачның түбе йомшартылган, җимеше артык мул булган ботакларына терәүләр куелган. Берничә урында сугару шланглары эленеп тора. Лапаслар артында шундый ук тәрбияле яшелчә бакчасы да бар иде. Камил моңа хәйран калды. Ничек өлгерәләр? Хатыны медпунктта, үзенең дә бакчада эшләргә вакыты калмый торгандыр.

Ул арада хуҗалар үзләре дә кайтып җиттеләр. Тәнзилә кунакка «хәерле иртә» теләп, җәһәт кенә аш өенә кереп китте. Ризван үзе, ап-ак күлмәгенең җиңнәрен терсәгенә кадәр сызганган килеш, кояшта көрән төскә кергән таза куллары белән билләренә таянып, бик канәгать кыяфәттә бакча буенда елмаеп тора.

— Барысына да ничек өлгерәсең? — диде Камил.

— Нот, Камил абый, Нот җиңеләйтте эшне, — ди.

— Ягъни ничегрәк дип аңлыйбыз инде моны?

— Җитәкчелекне фән кушканча оештыра белгәндә, бакчага да, бүтәнгә дә вакыт кала. Мин в основном урта звено белән эш итәм. Телефон бар, радиоузел да эшне җиңеләйтә. Төп күрсәтмәләрне бирәм дә эшемдә булам. Калган ягын урта звена үзе хәл итә. Нигә миңа алар эшенә тыкшынырга?

Камил уйланыбрак:

— Шулай икән... — дип сузып кына әйтеп куйды.

Кунакның хуҗа фикерен бик үк өнәп бетермәвен сизеп, Чурмантаев аны ышандырырга керешә:

— Әгәр, әйтик, зур заводның директоры «аһ» та «ваһ» килеп, цехтан-цехка чабып йөри башласа, зерә дә кәмит булыр иде. Шулай бит? Ут капкандай фермадан мастерскойга, аннан кырга, аннан техника паркына чабып йөрүче председательләр хәзер дә юк түгел. Алар сакал кырырга да вакыт таба алмыйлар. Тик андыйлар искерде инде. Авылга шәһәр культурасын кертергә вакыт.

Дусаев, әле һаман да нидер өнәп бетермичә, янә:

— Шулай икән... — диде, нидер әйтер кебегрәк күренсә дә тыелып калды.

Тәнзиләнең аш өеннән таба күтәреп чыгуын күреп, хуҗа кунакны бакчадагы беседкага дәште.

— Әйдәгез, Камил абый, Тәнзилә ханымның тәбәсеннән авыз итик,— диде.

Чурмантаев кичә дә кич буе хатынына «ханым» дип дәшкән иде. Тик Тәнзилә үзе моны ишеткән саен я авызын бөрештерде, я кашын җыерып куйды. Тәнзилә бөтен төсе-бите, үзен тотуы, өздереп эшләрлек таза беләкләре белән чын-чыннан авыл хатыны иде. Чәй ясап чыгаргач, Камил яныннан узганда тәлинкәсендә чәнечкесе белән чемченеп утыруын күреп, Тәнзилә башын чайкады.

— И, абый, зерә дә юк белән утырасыз инде. Безнең авылда чебен дә сездән күбрәк ашый. Ашагыз умырттырып! — диде.

Камил шаяртып кына уздырды.

— Бу хакта инглизләр акыллы фикер әйтәләр. Язучының таланты ачлы-туклы яшәгәндә генә тәмам ачыла. Симерә башласа, аннан юньле әсәр көтмәгез, диләр. Мин дә шуны истә тотам...

Хатыны өйгә кереп барганда, аңа башы белән ишарәләп, Ризван:

— Саф авыл кызы, — диде. Үзе шәһәрдә туып үссә дә, кала кызларына бик үк ышанып җитмәве, иренә тугрылыклы булуы ягыннан авыл кызларына иманы камил булуын әйтмәкче иде дә нигәдер базмады.— Ничего, үстерәм мин аны. Өченче ел Европаны әйләнеп чыктык. Пароходта узган бал-маскарадта твист биеп бүләк алдык. Менә быел Һиндстанга алып барам...

Камилнең язучы була торып та, алай ел саен чит илгә чыгып керүгә ирешкәне юк иде әле. Ә менә колхоз председателе чит илдә йөреп кайтуны Бөгелмәгә бару шикелле генә күрә. Әле җитмәсә, твист биеп бүләк алырга да өлгергән. Ул, хуҗа кеше өчен куанып, аны чын күңелдән тәбрик итте.

— Менә, ичмасам, егетлек бу, заманча! — диде.

Чурмантаев карар күзгә уңай кешегә охшаган иде. Ул инде яшьрәк, йомшаграк кешеләргә хас тән көпшәклеге чорыннан узган, чәчкә сирәкмирәк чал керә башлау чорына әле барып җитмәгән. Маңгае өстендә щеткадай тырпаеп басып торган каты, кара чәчле, кычкырып көлмичә, бик җәелеп китмичә, юка иреннәрен кысып кына сөйләшүе аның үз сүзле, нык куллы кеше булуын сиздереп торалар.

Камил аның яхшы үтеләнгән чалбар, ап-ак яхшы күлмәктән генә йөрүен искәрде. Институтны тәмамлаганнан соң ниндидер совхозда зоотехник булып эшләгән. Камилнең бөтен белгәне менә шул иде. Бу кеше тормышны ничек аңлый, аның эчке дөньясы нинди? Ничек эшләмәкче, киләчәктә ниләргә ирешмәкче була? Бу якларын Камил әле бөтенләй белми, шуңа борчылып утыра иде.

Ризванның исә иң башта язучы абзыйга ниндирәк мөнәсәбәттә булырга тиешлеген ачыклыйсы бар. Мәсәлән, райкомның беренче секретарена ишек кагып керергә кирәк. Икенче белән өченчегә Ризван кебек алдынгы колхоз председателе болай да барып керә ала. Нәчәлникнең имзасы рәсми кәгазьләрдә ничәнче урында тора, ничә урынбасары бар? Кешенең ниндирәк баскычта торуын әнә шундыйлардан да белергә мөмкин. Ә язучы кем? Ул кайсы баскычтарак тора?

— Чәйне ничегрәк яратасыз, куемы, уртачамы? — дип сорады.

Ризван ара-тирә шундый сүзләр кушкалап кунак кешегә чәй ясап бирде. Язучының чәнечке-пычакларын ничегрәк тотуына, өс-башына күз салгалап утыра торгач, узган елгы республика активы исенә төште. Анда Камил Дусаев президиумга сайланып, беренченең үз янына ук утырган иде. Чурмантаевның йөзе яктырып китте. Әһә, мәсьәлә ачык алайсам, бу язучы, чама белән, министрлар дәрәҗәсендәрәк йөрергә тиеш була икән! Ризван тамак кырып алды, чәчәкле кәгазь тастымал белән авыз тирәләрен сөрткәләде. Ул хәзер кунак белән ничек сөйләшәсен белә иде инде.

— Иҗат эшләре белән йөрисездер инде, Камил абый, әйеме? — диде.

Камил бу сорауны көткән иде. Үзен укымышлы кешеләрдән санаучы һәркем ул хакта сораштырмыйча калуны кимчелек саный, күрәсең.

— Безнең эшебез шул инде. Гомер буе эзләнәсең, уйланасың, гомер буе ни дә булса язарга тырышасың, — диде.

— Мөгаен, хәзерге тормыштандыр, әйе бит: алдынгылар хакындадыр? Чөнки дә газитләрдә гел шул турыда язалар.

— Ничек дип әйтергә...

— Ә сез уңайсызланмагыз, Камил абый, пожалуйста, бездә материал җитәрлек. Булышырбыз, уңай геройлар табып бирербез.

Язучы сагая төште. Иҗат эшләре хакында болай бик ансат сөйли бу, аз-маз булса да белепме әллә?.. Һм... Уңай герой, тискәре герой, иҗат эшләре...

Бу чибәр кеше телендә шундый җиңел уйнап торган шушы «иҗат эшләре»нең үзенә дә аңлашылмый торган әллә нинди серләре барлы-

гын, бер үк вакытта газаплы да, рәхәт тә булуын, бер утка салып, шунда ук суга ташлый торган «татлы каторга» икәнлеген язучының үзеннән башка кем аңлый? «Гәзитләрдә гел шул хакта язулары» сәбәпле генә түгел, бәлки халыкка әйтер сүзең булганлыктан, язмыйча мөмкин булмаганга күрә язуыңны ничек төшендерергә?..

— Уңай герой дигәнегез нинди булырга тиеш инде ул, сезнеңчә, кем инде ул?

— Нинди дип... безнең маяклар буладыр инде, кәңкерит алганда, планны гел арттырып үтәүчән, карусыз, тыңлаучан кешеләр дип аңлыйм.

— Киңәшегез өчен бик рәхмәт. Йөреп карыйм әле. Авыл һавасын сулыйм. Кешеләрен күрим. Каян беләсең, бәлки нәрсә дә булса йогып та куяр. Бәлки... Кем белә?!

Әмма Ризванның әдәби әсәр язуы мәсьәләсен, колхоз эшләре кебек, уртага салып сөйләшәсе, киңәшләр бирәсе килә иде. Ул кунагына ни кирәген белүенә ышанып сөйли, анынча, язучы кеше аның ярдәменнән башка берни дә эшли алмаячак иде.

— Уңай геройлар янына тискәреләре дә кирәк була инде. Андыйларга бездә иске председательләр бик күп. Әллә унбер шунда, әллә артык. Кирәк дисәгез, чакыртырмын. Нинди ен телисез?.. Бик оригиналлары бар.

Камил чак кына көлеп җибәрмәде. Менә бит замана! Синең нәрсә турында гына түгел, нинди геройларны кертеп, ничек язарга тиешлеген дә алдан ук әйтеп куялар.

Искеләр... әйтерсең иске кием турында сүз бара! Беләме икән бу шомакай ул «иске»ләрнең кемлеген?

— Сез әйткән «искеләр» хакында уйлап карарга ярый. Тик... Сез менә хәзер парадный костюмнан «Волга»да гына утырып йөрисез. Шуңа ирешү өчен, беләсезме, ул «иске» җитәкчеләр ничә пар кирза итек туздырды, күпме михнәтләр чикте?

— Шулай да аларның туйлары узды, туннары да тузды, картлар әйтмешли.

— Әнә тузсын да ди... һм. Оригинал дисез... Нindиләр инде ул «оригиналлар»?

Ризван, морадына ирешүгә күңеле булып, бармакларын бөгә-бөгә, «иске»ләрнең исемнәрен санап чыкты.

Ләкин алар арасында нигәдер беркөн теге озын егет автобуста өметләндереп әйткән Минһаҗ исеме юк иде.

— Ишетүемчә, умартачыгыз да «иске» председатель түгелме соң?

Ризван, кинәт кенә борылып, Камилгә: «Каян белә ул аны?» дигәндәй сәерсенебрәк карап куйды.

— Ә, әйе, ул да «иске»ләрнең берсе. — Ризван, сәгатенә күз төшереп, урыныннан кузгалды.— Ләкин ул кәңкрит алганда характерный түгел, председатель булуы ягыннан дим. Ул бигрәк тә мач килә бакчачы булу ягыннан...

Теге егет әйткән өмет Камилдә яңадан кабынып китте. Әгәр дә йортын-җирен ташлап киткән теге кызык тормышлы карт шул Минһаҗ булса?!

Көтмәгәндә капкадан Гайнан анасы Җәүһәрия килеп керде. Ризван сәерсенеп аның каршысына барып басты.

— Ни булды? Фермадамы? Ничек?

Ферма мөдиренең чырае җитди, иреннәре кысылган, түгәрәк күзләре тынгысызланып арлы да бирле тәгәриләр иде. Ул башын ия төшеп кунак белән исәнләште дә шуннан соң гына җавап бирде.

— Юк, иптәш председатель, хафаланма: эшләр тәгәрәп кенә бара! — диде.
— Һе! Бая әйттем бит инде кая тәгәрәвен!..
Депутатның бик төбәлеп карап торуына уңайсызланып, Җәүһәрия Камилгә яңы беләнрәк борылды. Шулай да аның, председательгә зарлангандай итенсә дә, «кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла!» дигәндәй, моң-зарын депутат иптәшкә җиткерәсе килә иде. Ул Гайнанның укырга керә алмыйча кайтуына һаман да күнә алмый, хәсрәт төене йөрәк-бәгыренә кереп утырган да шул кату һаман язылмый иде әле. Ризванның бу хәлне тискәре ягыннан телгә алып бөтен колхоз алдында оялтуы аның тагын да үпкәсен кабартты.
— И, җанкисәгем, күз алдында лабаса! Ятсак та, торсак та, утырыш белән җыелышта да гәп план тутыру чутында гына бит инде! Бәй, шулай була торып та аска тәгәрәгәч, ни эшкә ярый ул?!
Чурмантаев кунак ягына карап: «Менә ниндиләре дә бар бит әле колхозчының» дигәндәй, башын чайкап куйды.
— Соң мин дә шуны ук кайгыртып сөйләдем түгелме? — диде.
— Кайгырттың кире башыннан! Соң бит, Ризван туган, ит белән сөттән башка дөнья йөзләрендә менә мин дә бар бит әле, шуларны булдыра торган теп-тере кеше — Җәүһәрия!
— Менә тагын, синең барлыгыңны кем белми?
— Белмисез шул, белмисез! Белсәгез, азрак хәлемне сорашыр идегез, ничек алай, ник алай? дип кайгыртышыр идегез.
— Шунсыз булмый, апасы, азрак әйткәләшмичә эш бармый. Сөтнең кимүен беләсең бит!
Хуҗаның, кунакка урын күрсәтмичә, кулларын кесәсенә тыккан килеш түрә булып сөйләшүе Камилгә ошамады. Ул беседкадан урындык чыгарып куйды.
— Кем дип әйтим, сеңелем, утырыгыз! — диде.
Җәүһәрия утырып тормады, урындык аркасына нык кына ябышып сүзен дәвам иттерде:
— Җәүһәрия мин, Камил абый, Мингатина. Менә сезне дә борчырга туры килә. Ун ел буена дүрткә дә бишкә укып йөргән улымны укырга алмыйча кире борып кайтардылар. Бөтен өметкәйләрем өзелде, башларым дивана була язды. Килеп хәлеңне белсәләр, җаның эреп китәр иде дә бит кана. Кая ул! Аның урынына әле сине «шуның өчен мәлҗерәмик» дип радиодан әрлиләр. Бөтен халык алдында!
Чурмантаев иңбашларын җыергалап бакча рәшәткәсе буена барып басты, тагын борылып килде, ләкин берни дә әйтмәде.
— Әнә Сөендек председателе Һадиев яшьләрне үзе укырга җибәрә. Үз авылыңның суын эчеп, үз буразнаңда аунап үскән авыл егетебез я агроном, я инженер булып кайтса, колхозның эчен тишмәс иде лабаса!
Чурмантаев, шуның белән эшне бетерергә чамалап, капкага таба кырын-кырын атлый башлады.
— Ярар инде, апасы, әйттең — булды, аңладык. Әнә анда эшкә чыгасы бар.
Әмма Җәүһәрия аның артыннан иярмәде. Ул хәзер кыюлана төшкән, бит урталары кызарган, түгәрәк күзләре дә ешрак тәгәри башлаган иде. Председательнең күзенә карап:
— Бәй, бу эш түгелмени? Беләсең килсә, кеше күңелен табу җитәкченең иң главный эше ул. Менә шуңа башым җитми тора, Ризван туганкай: укырга кертерлек булмагач, ун ел буена ни дип азап чиктем соң мин? Укысын, кеше булсын, аттестат алсын дип тырыштым лабаса! Хәзер инде ул кәгазь кисәген кая куярга, сыер койрыгына тагаргамы? Шулайга калдымыни инде эшләр?

Чурмантаев кулларын җәеп җибәрде:

— Соң мин ни эшли алам?!

— Бәй, синең дә кулыңнан килмәгәч! Бер кәгазең, бер сүзең җитә! Син бит инде колхозның алласы да, мулласы да дигәндәй. Синсез кызлар кияүгә чыкмый, туйлар булмый, балага исем дә кушылмый. Синсез кеше тумый да, үлмәми дә!

Ризван, бу телчәннең арттырып җибәрүеннән шикләнеп депутат ягына карап алды да, «тукта инде!» дигәндәй кулын селтәде.

— Бусы минем компетенциядәге эш түгел. Егетнең урысчасы йомшак булган. Менә шул!

— Булса, аңа кем гаепле? Әллә минме, я малаймы?

— Анысын әнә имтихан әйтеп биргән — белеменә карап, гаделлек белән!

— Һе! Гаделлек, имеш! Бик беләбез ул имтиханның гаделлекне ничек юләргә калдыруын! — Җәүһәриянең ирен кырыйлары дерелдәп китте, күзләре елт-елт килеп әле Камилгә, әле Ризванга текәлделәр. Бу зарланудан берни дә чыкмаячагын ул яхшы белә, әмма аның председательдән ягымлырак сүз ишетәсе килә иде.

— Гаделлек дигәннән, минем улым ун ел буе дүрткә дә бишкә укыды, аны алмадылар. Ә Фазилнең чак кына очын-очка ялгап барган малае ничектер керде. Менә сиңа имтихан!

Ризванның үз сүзен аста калдыру гадәте юк иде:

— Димәк, тырышкан егет! — диде.

Җәүһәрия Фазилнең үз улын Казанда рус теленнән акча түләп өстәмә рәвештә хәзерләтүен әйтәсе килгән иде дә гайбәт сөйләргә теле бармады. Әмма гарьлегеп һаман җиңә алмый иде әле. Тавышы калтырануын, керфек төпләре дымлана башлавын тоеп үзен-үзе үчекләп алды: «Елап та җибәр тагын! Шул гына җитмәгән!» диде күңеленнән. Урындык аркасын чытырдатып кысты да авызын каплый төшеп тагын Камилгә борылды:

— Сез безнең олы кешебез инде, Камил абый, Казанда гына түгел, Мәскәүдә дә сүзегез сыя булыр. Җитәкче иптәшләргә шундыйларны җиткерәсе иде бит. Бер безнең малай гына түгел, бик юктан гына кире борылып кайтучылар хәтсез бит.

Депутат буларак, Камил мондыйларга үзен дә җаваплы санап башын игәләде.

— Аңлыйм мин сезне, сеңелем. Булгалый андый хәлләр. Ул һәммәбезне дә борчый. Хәзерге заманда русчаны начар укыту берничек тә гафу ителмәскә тиеш! Уңмаганлык, гамьсезлек бу, алай гына да түгел, оят бу, оят!

— Шулай булмыйча! Кайчаннан бирле Фазилә балаларыбызны урысчадан надан калдыра! Берсенең бер теше үтми шуңарга!

Үзенең тагын кызыбрак китүен сизеп, Җәүһәрия берникадәр йомшый төште.

— Борчыдым инде, Камил абый. Безнең малай ише буразнадан күтәрелүчеләрне алай төшереп калдырмаска иде диюем инде бу, Ленин бабайның бу турыларда әйткән васыятьләрен онытмаска иде дип әйтәсем килде.

— Кулымнан килгәнне кызганмам, сеңелем, — диде Камил.

Бу телдәр хатын аңа ошап куйды. Камил, үзенә сиздермичә генә, аның түгәрәк йөзен, пөхтә, җыйнак өс-башын, әдәплелеген хәтерендә калдырырга тырышты. Бигрәк тә бу хатынның үз кадерен үзе белеп, беркем алдында да үзен түбәнсетмичә, үз фикерен батыр әйтә алуы ошады. Аныңча, бу — кешене кеше иткән иң күркәм, иң кадерле яңа сыйфатларның берсе, аның да иң кирәклесе иде. Шунлыктан мондый затларга Камилнең ихтирамы аеруча зур иде. Менә хәзер дә Җәүһәрия әдәпле генә итеп Ризванны янә бер «тешләп» алды.

— Аннары, иптәш персидәтел, миңа тагын нәрсә ошамый? Киңәшмичә, уйламыйча эшләвең! Син малайны тоткансың да умарталыкка җибәргәнсең. Ә мин кайда? Шул баланы унсигезгә тикле тәрбияләп үстергән әни кеше моңа ризамы?

Ризван уртларын чәйни башлаган булса да түзде, үз «баскычыннан» түбәнгәрәк төшмәде.

— «Минһаҗ абзый» дип үлеп китәсез бит. Аңа өйрәнчек итеп биргәнгә каршы килерсез дип уйламадым да!

Җәүһәрия, авызын каплый төшеп, тыйнак кына көлеп куйды.

— Күрәм, шомарып киләсең, ансат котылдың. Ярар, Минһаҗ абзый янында ким-хур булмас. Аңа ышанып була.

Тагын шул Минһаҗ! Автобуста бергә кайткан теге егет сүзләре Камилнең яңадан исенә төште.

— Казаннан кайтканда бер егет миңа ул умартачы хакында кызык сүзләр әйткән иде.

Җәүһәрия көлемсерәп:

— Минем улым булган ул — Гайнан, керә алмыйча кайткан егет шул инде, — диде.

— Шулаймыни? Кара, миңа икесе дә бик кирәк бит. Күреп булмасмы икән?

Ризван сәгатенә күз төшергәләп ашыга башлады.

— Алайса, кунакны умарталыкка әнә Гайнан алып менсен, әйтерсең, — диде.

Китәр алдыннан Җәүһәриянең бите-күзе яктыра төште. Гүяки аның барлык борчулары берьюлы шушы ишегалдында юылып төшкән!

— Зинһар гаеп итә күрмәгез инде, Камил абый. Җил-давылның бер канаты сезгә дә килеп бәрелде, — диде. Капкага җитәрәк борылып Ризванга елмаеп күз салды. — Персидәтел иптәш син дә!..

## VI

Чупай[1] ташыннан салынган ике катлы йортны эзләп торасы да булмады. Камил аны ерактан ук күрде. Бу йорт Җидегәннең иң биек урынына менеп алган да янәшә тирәсендәге берәр катлы агач йортларга керфексез күз шикелле яңаксыз тәрәзәләре белән бик тәкәббер кыяфәттә өстән аска таба карый иде. Агач йортлар мәһабәт күршеләре янында кечерәеп, мескенләнеп калганнар. Шулай да бөтенләй үк коелып та төшмәгәннәр, үз дәрәҗәләрен үзләре белеп, сер бирмәскә тырышалар, таш йортка үч иткәндәй, иртәле-кичле төрле яктан мул итеп аны төтен белән төтәслиләр, кичкә керсәләр, таш йорттан уздырып җибәрергә тырышкандай, тәрәзәләрдән генә түгел, ишектән дә, тишектән дә, хәтта сыер абзарларыннан да электр утлары балкыталар иде.

Камил бу чагыштыруны онытмаслык итеп күңеленә беркетте дә таш баскычтан икенче катка менеп китте. Бер-ике атлады да туктады. Ул, дулкынлануын басарга тырышып, кесәсеннән валидол алып капты. Әмма, үч иткәндәй, һаман тынычлана алмый иде. Кем ул хәзер Мәдәния, егерме биш елдан соң нинди ул? Ул бит Мәдәниянең өйләнешер алдыннан кинәт кенә юкка чыгу сәбәбен дә белми. Әле алай гынамы? Казан арты кызы ни сәбәпле бу якларга килеп чыккан? Кайчан, ничек? Ире кем? Исәнме?

Бу йортка колхоз идарәсе авыл интеллигентларын урнаштырган икән. Ишек шакыганга чыгучылар:

[1] Чупай — авыл исеме. Аның басуыннан чыгарылган таш та шул исем белән йөртелә.

— Бәй, Мәдәния апа кире үз өенә кайтып утырды бит. Бирелә Идрис кенә күренгәли, — диделәр.

Урамга чыккач, Камил, өстеннән авыр йөк төшкәндәй, җиңел сулап куйды. Нигәдер ул Мәдәниянең туп-туры өенә барып керергә кыенсына иде. Бәлки Сәетне эзләп район үзәгенә юнәлергәдер? Аны да күрмичә ярамый бит. Ләкин, кузгалгач, аяклары аны үзеннән-үзе Мәдәниягә таба алып китте.

Түбән урамга туры барып чыгар өчен, Камил бозаулар көтелә торган чирәмлек аша узды. Уенда гел Мәдәния генә булса да, Әверләннән ерак түгел калкулыкта утырган ак чан янында ихтыярсыз туктады. Җир астыннан нефть бәреп чыгуны Камил табигатьнең иң серле һәм гаҗәеп романтик күренешләреннән берсе дип карый иде. Бу якларда нефть чыга башлаганнан бирле Камил күпме китап укыды, ничәмәничә танылган нефтьчеләр белән очрашты. Шулай да аңа һаман да нидер җитми, табигать аның каршында ниндидер серләрен ачып җиткерми кебек тоела иде. Тора торгач, бер читтәрәк алтын җәймәсен айкап-чайкап утырган зур факелга күзе төште. Ул да түгел, торбалар эчендәге бу басынкы гүләү Җир-ананың тын алуы булып ишетелә башлады. Камил тирә-юнен дә, кая баруын да онытты. Хәзер ул табигатьнең бөек серләре ачылганны, моңарчы басылып яткан иксез-чиксез яшерен көчләрнең дөньяга чыгуын бөтен тәне белән тоеп тора иде. Җиде кат җир астыннан ярсып, дулап менгән бу гүләүдә моннан өч йөз миллион еллар элек нәкъ шушында чайкалып яткан борынгы диңгез шавы ишетелә. Бу гүләү кыргый табигатьнең борынгы заманын хәзерге чор белән чагыштыра, бу нефть шавы миллион еллар элек җир астында кысылып калган тереклек авазларын, яшәеш куәтен бүгенге дөньяга чыгара. Бу гүләү аша Камил диңгез буеның эссе күген, котырынып үскән урманын, филләр адашырлык яшел үсемлек дөньясын күз алдына китерде, колач җитмәстәй юан көпшәле чыршы үләннәре, парашют зурлыгы абагалар кыштырдавын ишетте. Диңгез култыгының бурлат төсле яисә яшелле-зәңгәрле су үсемлекләре, алар арасында дулкын ярып айкалып йөрүче дәү авызлы, гигант гәүдәле су хайваннары, акулалар күз алдына килде...

Теге факелның, гүя шушы якты дөньяны тәбрикләгәндәй, әле Җидегәнгә, әле Ык буена баш ия-ия, җилпенә-җилпенә януына Камил, күзен ала алмастан, тәэсирләнеп карап торды. Дөньяда кеше үзе барлыкка килгәнче үк кабынып калган яшәеш очкынының менә хәзер нәкъ аның Татарстаны җирендә яңадан балкып чыгуы, чал тарихның хәзерге заманга кайнар сәламе бит бу. Гаҗәп-хәйран!

Бу күренешләрдә Камилгә тирән бер мәгънә бар кебек тоелды. Ул торбалар өстенә утырды да, кая барасын да, бөтен дөньясын да онытып, язарга тотынды...

Мәдәния бакча башына чыкканда Камил һаман яза иде әле. Мәдәния, аннан күзен ала алмыйча, бакчалары башындагы миләш агачы төбенә барып басты. Камил шул кадәр онытылган иде ки, Мәдәниянең тамак кыруын да ишетмәде. Мәдәния, кызгануга якын бер хис белән, моңсу гына елмаеп, аңа озак карап торды. Егет вакытында, Галимҗан Ибраһимовныкы кебек, елкылдап якасына ишелеп торган куе коңгырт чәченә чал кергән. Бераз гына картлык бөкресе дә сизелә башлаган түгелме икән? Үзе юк арада хатыны белән бердәнбер малае үлеп, япа-ялгыз калуын да ишеткән иде. «Юньле фатир да кайгыртмагандыр. Кая туры килә, шунда яшәп, ачлы-туклы җан асрыйдыр инде, мескенем», — дип уйлады.

Аяк астындагы вак ташларны юри кыштырдатып, басманы юри чайкалдырып Мәдәния аргы якка чыкты. Күкрәгенә кулларын кушы-

рып, Камилдән егерме-утыз адымда гына тагын карап торды: теге елларны шулай Мәдәнияне озата барганда, берәр иптәше белән әдәбият турында бәхәсләшеп, иң кадерле җәйге кичләрне җилгә очыра торган иде шул бичаракай.

Кояшка күз төшереп алды да Мәдәния тамак кырды.

— Кайларда тоткарланды соң кунак егетебез дисәм, әнә нәрсә сихерләгән икән аны!..

Камил сикереп торды, сиртмәле адымнары белән салмак кына килеп кулларын сузды.

— Гафу ит, Мәдәния, мавыгыбрак киткәнмен... Ни хәлләр? Иминлекме?

— Ярыйсы әле, Камил абый, бер көйгә...

Мәдәниянең кулларын җибәрмичәрәк торып, Камил аның йөзенә текәлде.

— Ничә ел инде... аерылышканга? Егерме бишме, артыкмы?

— Күп инде, күп, Камил абый, хәтсез.

Кыз вакытта оялып читкә борылучан кара күзләр хәзер Камилгә кыенсынмыйча, кызыксынып туп-туры карыйлар, гәүдәсен тотуында да ниндидер горурлык, мөстәкыйльлек сизелә иде. Бу үзгәрешкә хәйран калып, Камил үзе дә сизмәстән «сез»гә күчте.

— Мин сезне теге яңа йортта эзләгән идем дә...

— Ә, шулайдыр. Фатир бирделәр ич.

Бәрәңге бакчасындагы тар сукмактан өскә күтәрелеп ишегалдына керер алдыннан Мәдәния, туктап, «Рәхим итегез!» дигәндәй, башын сизелер-сизелмәс кенә иеп Камилне алдан җибәрде.

— Өенә кайтканның ояты юк дигән олылар.

Ишегалдына кергәч, җиңел генә, уйланып кына кунак белән янәшә атлады. Камилнең йөрәге сулкылдап куйды. Сыгылмалылыгын әле һаман да җуймаган чандыр гәүдәсенең әнә шундый яшьләрчә җиңеллеге, башын әнә шулай горур гына игәләп куюы, кулларын җәеп җибәргәндәге нәзакәтлелек Камилнең хисләрен яңадан уятып җибәрде. Сәхнәдә очып кына йөрүче нечкә билле, нәфис хәрәкәтле элекке Мәдәния яңадан күз алдына килеп басты. Камил дулкынланып туктый төште, тагын бер күтәрелеп карады. Мәдәниянең битендә бер генә җыерчык та юк, тик берникадәр олысымаклык кына өстәлгән иде. «Син һаман да шулай матур да, яшь тә икәнсең бит әле!» дип әйтәсе килде.

Хатыны дөнья куйганнан соң Камил бүтән өйләнмәскә, калган гомерен соңгы сулышына кадәр иҗат эшенә багышларга адарынып куйган иде. Менә хәзер күңеленең иң эчкәреге бер почмагында «бәлки?..» дигән бер гөман уянды. Әгәр дә Мәдәния тол калган булса, әгәр дә яшьлек хисләренең уннан бере генә булса да сүнмичә сакланган булса... Кем белә, бәлки...

Кунакның аңа күзен ала алмыйча текәлеп каравыннан Мәдәния нидер сизенде. Тик ул ир кунак белән аны каршы алучы хуҗабикә мөнәсәбәтеннән атлап чыгуны һич тә муафыйк күрми иде. Әдәпле генә тамак кырды:

— Улым да бик көткән иде дә... Менә туры килмәде... — диде. Камилнең бер генә секундлык шушы күңел зилзиләсен шуның белән бастырып та куйды. Камил, шуңа йомгак ясагандай:

— Шулай икән... — дип сузып әйтте. Альберт яисә Ричард кебегрәк исем ишетүне көтеп сорау бирде:

— Улыгыз кем була? Ни исемле?

— Идрис.

Әһә! Менә каян белә икән парторг Камилнең яшь чагын!

— Яшәр өчен яңа йорт җайлырактыр да инде. Газы, суы, электры дигәндәй...

— Шулай да бит кана. Тик яшеллек эчендә гомер иткән кешегә алар гына җитенкерәми икән шул. Үз өемдә мин бит бер атлауда җылы чирәмгә чыгып басам. Ә тегендә — таш, цемент.

— Заманасы шулай куша бит, Мәдәния. Бәлки ияләнер идегез әле? Яңалыктан качу килешмидер.

— Һай, булмый икән шул! — Баскыч төбенә килеп җитәрәк, Мәдәния башы белән ымлады. — Менә шушы инде минем сагынып кайткан иске куышым!

— Шулай икән...

Кайчандыр нарат бүрәнәләрдән салынса да, еллар үтү белән көл төсенә кергән, бераз җиргә дә иңә төшкән дүрт-биш тәрәзәле, өйалдылы, чоланлы иске генә өй икән.

— Шулай...

Кунакның еш кына әйтә торган бу «сөземтәсе» Мәдәниягә «йортының әллә ни кызыгырлык урыны юк икән югын» дигәндәй ишетелде. Ул үпкәләмәде, ирен кырыйлары көлемсерәп кенә куйды. Шәһәр кешесеннән шуннан да артык нәрсә көтәсең?.. Алар авыл өенең буыннан-буынга, әбисеннән оныгына, әнкәсеннән килененә күчеп килә торган эчке серләрен, күңелгә якын нечкә йолаларын аңлый алалармыни?

Мәдәния суыксынгандай бөрешә төшеп, ике кулын күкрәгенә кысты.

— Булмый икән шул. Ничек шулай ансат кына ташлап чыкмак кирәк? Иске булса да төп оя, бу нәселнең җиде буынын тирбәтеп үстергән җылы бишек бит ул! Узган кичне йөрәгемнең астын өскә китереп, бөтенесе күңелемнән үтте: үлем-җитеме дә, шатлык белән рәхәте дә. Күз алдына китереп кенә карагыз: күпме баланың дөньяга килгәндә беренче авазын ишеткән бу нигез, ничә кешенең монда актык сулышы өзелеп, соңгы тапкыр күзләре йомылган!

Камил хуҗабикә фикеренә кушылмагандай башын чайкады:

— Андый шомлы хатирәләр күңелне баетмый, аларны оныту хәерлерәк!

Бусагадан кергәндә Камил стеналарга шигәеп күз салды. Аның кайбер өйләрдәге кебек, түр башында хуҗа белән хуҗабикәнең башларын башка тидереп, елмаерга тырышып янәшә төшкән төче, симез рәсемнәрен дә, тупас рамга тезелгән туган-тумача, кода-кодагыйлар кыяфәтен күрергә дә теләге юк иде. Андыйлардан элекке шәһәр мещанлыгы, купецлар туклыгы аңкып тора кебек иде. Бәхетенә каршы, Мәдәния андыйлардан югарырак тора булып чыкты.

— Онытырга вөҗдан кушмый торган яклар да бар икән шул, Камил абый!..

— Шулаймыни? Мәсәлән?

Мәдәния түр якның ике тәрәзә арасына элгән асылмалы көзгене алды да аның астыннан килеп чыккан язуны күрсәтте. Сер сөйләгәндәй шыпыртлый төшеп:

— Менә мондыйларны ничек калдырмак кирәк тә, ничек онытмак кирәк?! — диде.

Камил күзлеген киеп язуга үрелде. Бүрәнәнең иң тигез урынына бик борынгыча урап-чолгап уңнан сулга таба зәгъфыран төсле саргылт кара белән түбәндәгеләр язылган иде:

— «Дәвек бабай әйтеп калдырмыш ки, Салават батыр каты орыштан соң Җидегән чишмәдә җәрәхәтен юган, янә бу нигездә нигъмәт җигәч, Урал ягына китеп гаиб булган» [1].

Шуннан түбәнрәк башка кара белән тагын бер истәлек язылган иде:

— «Елкы елында хут [2] кергәч, Җидегәнне абҗур команда басты.

[1] Гаиб булган — югалган
[2] Хут — март ае.

Сыгырдан сыгыр, куйдан куй калмады — һәммәсен суйды, ашады. Ирне, хатынны — барчасын янган ут аша үткәзеп, баш бирмәүчеләрне күпердән атты. Аллаһе тәгалә сабырлык биргәй».

Мәдәния укыганны тын гына көтеп торды да кулы белән ишарәләп кунакны өйалдындагы чоланга әйдәде. Ишек артына элгән чигүле тастымалны алган иде, аның астыннан күренер-күренмәс хәлгә килгән тагын бер язу килеп чыкты.

— «Мәүлет башында буйга уздым. Төшемдә атлы-кылычлы ир-ат күрәм. Ярабби, нәзерләрем кабул булып, ир бала тапсам икән».

Үзең дә теләмәстән кемнеңдер иң газиз, иң яшерен серен ачу кебегрәк иде бу. Камил уңайсызланып күзлегән сөрткәләргә кереште.

— Бу минем иремнең анасы була инде — кайнанам.

Иң соңгысы өйалды тактасына яңалиф белән язылган иде.

— «4 ндә август 41 ел сугышка чыгып кителде. Фашистларның башына җитеп исән-имин илгә кайтылса, ике аягымның берсен дә читкә атламас идем, гомер буе Җидегән чишмәне багар идем».

— Монысы ирем язуы була инде, Мәрвинеке...

Нигәдер Мәдәниянең ирле булуын күз алдына китерү мөмкин түгел иде. Ул ирле хатынга охшамый, теге вакыттан бирле шулай, бер кемнеке дә булмыйча, кыз килеш яшәгәндер кебек иде... Камил гаҗәпләнеп аңа астыртын гына күтәрелеп карады.

— Шулаймыни? Кара... Мәрви дисезме?

— Әйе, шулай. Ул сүзендә торды. Кайткач гел чишмәләр янында кайнашты. Читәннәр үрде, чишмәләрне, чыгар юлларын тазартып, кадерләп торды. Менә бу язуларны да ул саклады, күчереп алып музейларга да җибәреп йөрде. Казаннан килгән хатларда аңа рәхмәт әйтәләр иде.

Мәдәния, кунактан күзен алмыйча, җавап көтте.

— Бәлки безнең заман өчен сәер тоеладыр бу, әйе бит? Әллә кайчангы язулар...

Кунак кеше, дулкынланып күзлеген сөртә-сөртә, бер язуларга, бер Мәдәниягә карап ала иде.

— Нигә сәер? Һич тә сәер түгел. Без наданнарга гыйбрәтле сабак бу! Әйе!

Мәдәниянең йөзе яктырып, күзләре нурланып китте.

— Шулай дисезме? Алайса, мин дә әйтим инде: болар әби-бабай истәлеге генә түгел, халык язмышы теркәлгән монда. Мин бу язуларны болай гына ташлап китә алмыйм, Камил абый. Бу йортны музей итеп сакларга дибез. Яшь буынга гыйбрәт булсын!

Язулар Камилгә Мәдәния уйлаганнан да көчлерәк тәэсир иткән иде. Ул аларны хәзер үк теркәп куймакчы булып куен дәфтәренә сузылды, тик яхшысынмады. Мондый язмаларны аның элек тә укыганы бар иде. Гаҗәп! Нигә игътибар итмәде икән? Халыкның рухи дөньясын, тарихи вакыйгаларны дөрес аңларга ярдәм итә торган гаҗәеп чыганаклар бит болар! Шуның өстенә, язу-сызу халыкның борынгыдан ук канына сеңгән диган сүз бит бу. Язмага, китап сүзенә ихтирамы зур булган. Кәгазь юк заманнарда тузга язган, һич югында, үз фикерен стеналарга, соңрак китап кырыйларына булса да язып калдырырга тырышкан. Камил, рәхмәтен белдереп, хуҗабикәгә баш иде.

— Нинди ташлап китү? Боларны алтын хәрефләр белән язып музейга куярга кирәк!

Мәдәния кече өендә самавар белән кайнашкан арада, Камил аның ак өендә арлы-бирле йөренде. Хәзерге алдынгы колхозчы өендә ни булса, биредә дә һәммәсе бар иде. Әмма Камилне болар гына кызыксындырмады. Чөнки кыйммәтле җиһаз эчендә яшәп тә, һаман да надан килеш калучылар бетәсе түгел ләбаса!

Китап кибетендә эшләүченең китаплары күп булуы да гаҗәплән-

дермәде. Әмма шкафның өске шүрлегендә күн белән тышланган узган гасыр китаплары, Каюм Насыйри, Мәрҗани әсәрләре, борынгы каллиграфия белән пөхтәләп язылган кулъязмалар күреп, Камил хәйран калды. Каян болар? Кем укый? Кыз чагында ТБУМ [1] гына тәмамлаган гади авыл кызы ничек боларны уку дәрәҗәсенә күтәрелде икән?

Табынга узышлый хуҗабикә моны бик ансат аңлатты:

— Казан артында кечкенә чана белән авыл саен, базар саен йөреп китап сатучылар күп булган. Сез аны беләсез. Минем бабам — нәкъ шул кәсеп кешесе. Болар шуның мирасы.

Түр стенага эленгән, кара җирлеккә көмеш хәрефләр белән язылган шәмаил янында янә дә туктамыйча булмады.

Яхшылык кылса гәр кемсә,
Онытмазсың ничә еллар;
Гафил булма, белеп торгыл,
Синдәй адәм вә һәм анлар.

— Монысы атам истәлеге. Арча ягындагы бер мәдрәсәдә карт шәкерттән яздырып алдым дип сөйли иде.

Камил хәзер Мәдәниянең бу иске йортны ни сәбәпле музей итәргә теләвен яхшы аңлый, аның хуҗабикәгә ихтирамы торган саен арта бара иде.

Кунак кеше Мәдәниядән үзе башлап берни дә сорашмады. Аның уенча, гомер буе сер булып сакланган ул газиз истәлекләр, Җидегән чишмәдәй, үзләре бәреп чыгарга тиеш иде. Башта ул хуҗабикә табынындагы пөхтәлек белән муллыкка, ризыкларның тәмлелегенә сокланып бетә алмады. Мондагы кебек сизелер-сизелмәс кенә алсу төс йөгергән хуш исле коймак, кәрәзле ак күмәч, болындагы чәчәкләр исен аңкытып торган ләззәтле ак май, ихтимал, Ык буе колхозларында гына була торгандыр. Җиз подноста кояш нурлары уйный, чәй ясаганда Мәдәниянең кулы-кулга йокмый, савыт-саба, чәй кашыклар тавышсыз-тынсыз уйнап кына йөри иде.

Камил алдына кайнар чәй ясап куйгач, Мәдәния кулындагы тастымалы белән самаварның тәпиләрен сөрткәндәй итеп, үзе сүз башлады:

— Кем уйлаган?.. Утыз елга якын бит.

Нәкъ Камил көткәнчә булды. Ул күз кырые белән генә Мәдәниягә карап алды. Хуҗабикә каршы алганда кыюрак күренсә дә, хәзер самаварга ышыкланыбрак утыра иде. Аның тавышы да акрыная төште, ул кинәт «син» дип, ярым шыпыртлап сөйләшә башлады:

— Син мине сәхнәгә чыккач ук таныдыңмыни?
— Әйе... Ничә еллар качып йөрсәң дә...
— Битемне каплап бетергән идем бит.
— Гәүдәңнән, биюеңнән.
— Ай-ай, үткен дә икән күзең, Камил абый!
— Син сәхнәдә нәкъ кыз чагыңдагы кебек җитез бөтерелдең, терекөмештәй агып кына киттең. Ул биюне бүтән берәү дә алай булдыра алмый.
— И, анысы матурлап әйтүеңдер инде, Камил абый.
— Юк, чыны шулай! Хәрәкәтләрең хәзер дә бик нәфис, ифрат килешле, күңелгә үтеп керә торган.

Мәдәния самавар артына елыша төшеп башын иде.

— И, шулайдыр инде...

Кыенсынып читкә таба карады. Әле хәзер дә матурлыгын җуймаган күперенке ирен кырыйларында моңсу гына, оялчан гына көлемсерәү бизәкләре күренде. Иреннән соң берәүнең дә аңа мондый сүзләр әйткәне, болай яратып караганы юк иде әле. Яхшы да түгел бу, килеш-

[1] ТБУМ — тулы булмаган урта мәктәп.

ми дә. Балаларың үсеп беткәч... Кул аркасындагы юан зәңгәр тамырларга күзе төшкәч, Мәдәния, авыр сулап, аларны икенче кулы белән каплады. Аннары җиңел генә торып басты да:

— И, күрми дә торам! Сүнеп бара икән ләбаса! — дигән булып, самаварын җилтерәтеп өйалдына алып чыгып китте.

Камил арлы-бирле йөргәләргә тотынды. Өйалдыннан Мәдәниянең чарт та чорт чыра сындырганы, самаварга өргәне ишетелде. Ул да түгел, тавышсыз-тынсыз, оекчан гына кереп-чыгып ул табынга тагын әллә ниләр өстәде. Бүлмәнең һәр почмагыннан, һәр әйбердән җанга газиз тынычлык, ягымлылык, җылылык сизелә, бөтенесе үзенә тартып тора иде. Нигә Камил үзен-үзе шушындый сөйкемле гаилә тормышыннан мәхрүм итте икән?

Хуҗабикә самаварын яңартып урынына кертеп утырткannan соң да Камил һаман шул соравына җавап эзләде. Кыз чагында бу иреннәр югарак та, алсурак та, бу күзләр үткенрәк тә, тылсымлырак та иде. Камил аны өзелеп ярата иде. Нигә аерылыштылар? Нигә өйләнешмәделәр соң алар?

Кунак алдына кайнар чәен ясап, сый-хөрмәтен якынайтып куйды да Мәдәния нәкъ әнә шул хакта сүз кузгатты:

— Ничек уйлыйсың, Камил абый, теге вакытны нигә шулай җир упкандай юкка чыкты икән бу кызый?

Кунак кеше уңайсызланып селкенгәләп алды. Ул үзе башларга тиеш икән дә бит!

— Әйе, әйе! Минем өчен һаман да табышмак әле ул.

Мәдәния алдына гына карап алъяпкыч почмагын бөтерә, аның калын кара кашлары ара-тирә тетрәнгәләп куя иде.

— Хәтереңдәдер: ул чакны безнең Мәңгәрдә Казан студентларының зур кичәсе булды.

— Әйе, бәрәңге алырга барган идек шикелле.

— Нәкъ! Иптәшләрең шигырь сөйләделәр, син, үзең әйтмешли, «чыпчык борыны тикле» генә хикәя укыдың.

Камил, өстәлгә таянып, Мәдәниянең авызына текәлде.

— Дөрес, хәтерлим. «Безнең әниләр» дип исемләндеме икән?

— Шулай. Сугыштан кайтмый калган улларын төшләрендә күрүләре белән дә юанып, ачлы-туклы килеш колхоз эшендә йөрүче сабыр холыклы, нечкә күңелле аналар хакында иде ул. Хикәят итеп язмасаң да, алар гел күз алдына килә инде, югыйсә. Шулай да елый-елый тыңладылар, рәхмәтләр әйттеләр, сине яшь талант диделәр.

Мәдәния Камилгә күзләрен мөлдерәтеп карап торды да авыр сулап куйды, алъяпкыч почмагы белән ирен кырыйларына тиеп алды.

— Мин дә куандым. Тик миңа кызарырга да туры килде. Ник дисәң, ул хикәя миңа атап язылган иде бит. Андагы озын керфекле, алтын куллы җитез кыз Мәдинә мин идем. Син үзең шулай дигән идең. Син хикәя укыганда иптәш кызларым, миңа күз кыскалап, үчекләп тә утырдылар...

Камил, «әйе», «дөрес» дигәндәй, ара-тирә башын игәләде, үзе дә белештермәстән, әле бер кесәсеннән, әле икенчесеннән өендә калдырып килгән папирос тартмасын эзләмәкче булды.

— Мин, юләр, шушы куанычыңны минем белән дә уртаклашырсың дип көттем. Күземне алмыйча, йотардай булып йөзләреңә текәлдем. Бер дә чыктың, һич дә чыктың сәхнәгә. Залга баш иеп рәхмәтләр әйттең, шук сүзләр әйтеп көлдердең. Ә мине оныттың...

Камил урыныннан сикереп торды.

— Ничек? Нишләп онытыйм мин сине?!

Мәдәния самавар артынарак елышты.

— Шулай! Каршыңда күзләрен тутырып карап утыручы сөйгән кызыңа, ичмасам, күңел өчен генә, ичмасам, бер генә тапкыр да күз тө-

шереп алмадың! Ә бит ул чагында безнең танышканга бер елдан артып киткән иде инде. Атна саен «бер күрергә зар-интизар...» дип хатлар алыша торган идек.

Кунагының кызарып йөзен каплавын күргәч, Мәдәния җайсызланып сөйләүдән туктады.

— Бетте, сөйләмим! Әй, ялгыш ычкындырдым, ахрысы. Юкка гына кузгаттым! — диде. Коңгырт-яшел күзләрен мөлдерәтеп кызганып торды да җәһәт кенә барып Камил янындагы тәрәзәне ачып җибәрде.— Карасана! Шайтан телемнән тарттымы соң?

Шундыйрак игътибарсызлыгы өчен Камилгә моңа кадәр дә кызарырга туры килгәне бар иде. Шулай да үзен мондый фидакарьлек белән сөючегә шундый авыр яра салганмын дип кем уйлаган? Шул кадәр үк ваемсыз, шундый ук онытылучан булдымы икәнни соң ул? Оят бит, оят!

Камил читкәрәк борылып кулын селтәде.

— Әйтеп бетер, Мәдәния. Соңгарак калса да, сабак булыр. Миңа булмаса, бүтәннәргә! — диде.

Хуҗабикә кунагына шигәебрәк карап алды да янадан самавары янына килеп урнашты.

— Хәзер әйтеп тә ни файда инде? Күңелдә төен булып калмасын дисәң генә. Шул төнне миндә беренче тапкыр көнчелек уянды. Мин синең берьюлы ике яр сөюеңне белдем.

Камил хәйран калып башын чайкарга тотынды:

— Ай, Мәдәния, ни сөйлисең? Юк, юк!! Моңарчы ышандым, монысы... Бигайбә!

Мәдәния самавар тәпиен ышкый-ышкый елмаеп җавап бирде:

— Шулай да хак сүз бу, Камил абый, һич ялгансыз!

— Юк ла, ышанмыйм да! Син мине икейөзле дип уйламыйсыңдыр бит?

— Юк, алай дип уйламыйм!

Мәдәния калын кашлары арасыннан күзен кыса төшеп тагын бер көлде дә кинәт җитдиләнеп авыр сулап куйды.

— Ышанмыйча хәлең юк, Камил абый, шулай ул! Синең иң өзелеп сөйгән ярың мин түгел, язган әйберләрең булып чыкты. Ул төнне мин менә шуны төшендем.

Камил авызын ачып Мәдәниянең күзләренә текәлде.

— Ә? Әсәрләрем?! Гаҗәп... Язган әйберләрем миңа чыннан да бик газиз. Ләкин алар мәхәббәттә нишләп комачау итсеннәр икән?! Менә ул ягын әйтә алмыйм, белмим, ай-һай!..

— Башыңа төшкәч аңлыйсың икән шул. Андый көндәш тә була икән дөньяда!

— Арттырмыйсыңмы, Мәдәния?! Мин бит сине бик нык яраттым! Бөтен дөньямны бирердәй булып, чын күңелдән!

— Белмим... Сүздә, хыялда гына булмадымы икән?! Язучы халкы хыялга бай бит ул. Телдән син аны теге вакытта да әйтә килдең. Хатларың бер утка, бер суга сала торган иде. Мин аларны күкрәгемә кыса-кыса, акылымнан шашардай булып укый идем. Ә тормышта нәрсә килеп чыкты, чынында?.. Син аларны әллә кайчан онытпансың инде, Камил абый, ә минем әле бүгенгедәй күз алдымда.

— Ул чакларны мин дә хәтерлим, Мәдәния, бик нык исемдә!

— Шул ук кичәдә минем биегәнем исеңдәме, алайсам?

Камил чигәсен уды, ияген сыпырды. Ләкин ул һич алдаша белми иде...

Мәдәния кыенсынып карап торды да көлеп алды.

— Менә шул шул! Хәтерләмисең? Син беренче рәттә утырдың. Ун-

сигез яшәр тап-таза, чибәр кыз, мыскалламаган ефәктәй [1] саф күңелле гөнаһсыз кыз каршында бөтерелде — җанын ярып бирердәй, очып кунардай булып! Синең алдыңда ул бөтен яшьлек дәртен, йөрәк ялкынын дөрләтте! Шуннан нәрсә булды? Кичә беткәч, син аны ялгыз калдырдың. Я, әйтеп кара, Камил абый, кыз бала бит мин! Ничек гарьләнмисең?!

Камил, идәнгә төбәлгән килеш маңгаен уып:

— Ай, Мәдәния, әйтеп торасың тагын!.. Ничек алай булды икән соң, һич аңламыйм! — диде.

— Мин дә аптырадым шул. Ул чагында без вәгъдәләр дә бирешкән идек инде. Кичен син шул хакта нидер әйтер дә шикелле идең.

— Шунда үзең минем янга килгән булсаңчы!

— Бармадым шул, авыл кызы гына булсам да, мин бит кеше, Камил абый! Ә көндәшем, ни тикле шәп булса да, нибары кәгазьгә төшкән сүз генә! Соңыннан ишеттем: сезне мактап сөйләгән укытучылар белән төн буе шигырьләр әйтешеп, җырлашып утыргансыз...

Камил чигәләрен уарга тотынды. Депутат булып сайланганнан соң аны тәнкыйть белән борчымый башлаганнар, аның колагы ягымлы дулкыннарга, мактау сүзләренә генә көйләнеп бара иде. Боларны тыңлап утыру аңа җиңел булмады. Оятына каршы, ул Мәдәниянең бер генә дәлилен дә юкка чыгара алмады. Бар иде шул андый чаклар, бар иде шигърияттнең исерткеч томаны эчендә башлар әйләнеп, биек, биек сәмаларда [2] очкан чаклар. Шөһрәтне дә бит теләсә кем күтәрә алмый. Кайберәүләр дан канатында күкләргә менеп китәләр дә бераздан «лып» итеп җиргә килеп төшәләр...

Камил хуҗабикәнең каршысына килеп башын иде.

— Бик зур гөнаһлы мин синең каршыңда, Мәдәния, гаепле. Җәберләгәнмен, үземне дә бәхетемнән мәхрүм иткәнмен. Соң булса да кичер син мине, кичер!

— Нинди гөнаһ булсын ул, Камил абый? Юри эшләнмәгән бит. Син шулай аңлагансың, ә мин — бүтәнчә...

— Шул төнне юк булдың бит син?! Эзләсәм дә таба алмадым.

— Әйе, шул төнне. Төн буе өзгәләнеп елап чыктым. Кимсенеп булса да шундый уйга килдем: бу кешегә кияүгә чыксам да, ул китапларын барыбер миннән ныграк яратыр. Мин аңа кочаклап ятудан башкага ярамам. Нишләргә иде соң миңа, газиз башларымны кайларга олактырырга?..

Капка шыгырдаганга Мәдәния ярты сүздә бүленеп калды. Аның бераз сипкеллерәк озынча ак йөзеннән сизелер-сизелмәс кенә канәгатьсезлек шәүләсе узды. Әмма ишектән улы Идрис белән Гайнан күренүгә, ул якты чырай белән аларның каршысына барып басты.

— Әйдүк, әйдүк, Гайнан энем, күптән күренгәнең юк. Берәр күнелсез хәл бармы әллә, югыйсә?! — диде.

— Әллә ни юк. Сез утырыгыз, — дип, ике егет Камилгә карый-карый ишегалдының икенче ягындагы бакчага чыгып утырдылар.

Камил, «нихәл итмәк кирәк?» дигәндәй, кулларын җәеп егетләр артыннан чыкты. Мәдәния ишек янагына сөялгән хәлдә күңелсезләнеп калды. Аларның очрашулары һәр вакыт менә шулай я иң куанычлы, я иң кыен чакта өзелеп кала түгелме соң?!

Ишегалдындагы җимеш бакчасына чыккач, язучының моңсу йөзенә күзе төшеп, Идрис уңайсызланды.

— Менә бит, кунак абыйны тагын борчырга туры килә инде, — диде.

[1] Мыскалламаган ефәктәй — үлчәүгә кермәгән, кеше кулы тимәгән.
[2] Сәмаларда — күкләрдә.

Камил:

— Зарар юк, берни түгел! — дигән булды.

Чынын гына әйткәндә исә аңа һич тә җиңел түгел иде. Хәзер аңа бәлки берүзе генә калырга кирәк булгандыр? Ничектер моның очына чыгарга кирәк иде ләбаса!

Идрис икеләнебрәк торды да кулындагы газетаны Камилгә сузды.

— Мөмкин булса, укып карагызчы, Камил абый. Бик тә борчуга салды әле бу мәкалә кисәге. Хәер, сез ничек диярсез тагын.

— Район газетасымы? Кая әле?

— Бик сәер. Көтмәгәндә...

Камил кояшлы якка килеп басты да, күзлеген елтыратып, кайбер урыннарын кычкырып, кай төшләрен эченә йотып укырга кереште:

— «Яңа пальтога иске ямаулык». Һәм... Болай исемнең отышлысын тапкан икән үзе. Я, нинди ямаулык икән ул? «Колхозыбызның председателе Ризван иптәш Чурмантаев бик инициативалы җитәкче. Ул фермаларга су кертергә, ташландык сазлыкларны эшкәртергә хыяллана...» Алай, алай... Ары киттек. «Ләкин бу прогрессив башлангычка уңайсызлаучылар да юк түгел». Кызык! Ифрат! Яле, ни сәбәпле комачаулыйлар икән? Әһә, менә анысына да җавап бар: «Андыйларны колхоз интереслары кызыксындырмый. «Табигатьне яклыйбыз» дигән сылтау артына яшеренеп, асылда искелекне саклап калырга исәп тота ул бәндәләр!»

Камил гаҗәпләнеп башын селкеп торды.

— Менә сиңа мә! Күрәсезме? Иң яхшы ният белән әйтелгән фикерләрне менә ничек пычратканнар! Гаҗәп! Бу ташлар шап иттереп нәкъ безнең бакчага килеп төште бит инде. Шулаймы?

— Әйе, Ризван абый тәкъдименә сезнең белән Җәүһәрия җиңгидән башка каршы чыгучы булмады шикелле.

Камил, уңайсызланып булса да, үзен күптән борчыган сорауны бирмичә булдыра алмады:

— Сез битараф булдыгыз, ахрысы?

Идрис иңбашларын уйнатып алды.

— Иң кыены да шунда шул. Зам буларак мин аңа буйсынмый хәлем юк. Ә партком секретаре буларак принципта мин — каршы.

— Соң?

— Җәмәгатьчелек фикере туплана төшсен дигәнрәк уй бар. Сездәге сайлаучылар хаты да шул турыда бит...

— Аңлашылды... Я, ниндирәк җәзалар көтә инде ул «бәндәләрне»? Менә тыңлагыз: «Мондый черек настроениеләр җимергеч удар алмыйча калмас дип ышанырга кирәк. Патриот».

Камил, газетаны өстәлгә куеп, башын чайкады. Мәкалә Идриснең дә кәефен кырган иде.

— Ялган бит бу, спекуляция. Иң әшәке ягы шунда: алай түгел икәнлеген моны язган кеше үзе дә белә!

Камил аңа сәерсенеп карап алды. Нигә шушы фикерне теге көнне чишмә өстендә үк әйтмәскә иде икән? Гаҗәп!

Гайнан гүя абыйсына үпкәләгән сыман:

— Шул кеше парткомда учетта тора, сиңа килеп взнос түли, — диде.

Идрис энесе ягына кулын селтәде.

— Без — без инде ул. Менә Камил абый өстенә пычрак ата бит әле.

Камил Дусай, чалара башлаган чәчен уч төбе белән сыйпап, агачлар күләгәсендә йөренде.

— Әй, исегез китмәсен! Безнең язучы халкына моннан хәтәррәкләрен дә ишетергә туры килә. Тик мине бер нәрсә генә гаҗәпләндерә

газетаның редакторы — көләч йөзле Дәрҗия ханым — алай түгелен белмиме? Белсә, ул моны ничек бастырды икән?!

— Минемчә, монда аннан көчлерәкләрнең кулы уйнаган.

— Шулай дисезме?

— Әйе, һич тә икеләнмичә әйтәм!

Гайнан үзенең бик яшь булуы, бу абыйларның икесеннән дә биегрәк булып сузаеп торуы өчен уңайсызлана иде. Ул, буен аз гына булса да кыскартырга теләгәндәй, бөкрәя төште.

— Бу нәстәкәйне кем язуын мин аз гына чамалыйм, ахрысы. Ялгышмасам.

Идрис «әйе» дигән сыман баш иде. Камил әсәрләнеп:

— Шулаймыни? — диде.

— Шулай. Бик тискәре кеше язган моны. Үзен генә чын коммунист дип йөртүче бер карт. Тик әйтсәң яхшы түгел...

Гүя фикерен раслатасы килгәндәй, Идрискә карап алды.

— Дөрес, исемен үк әйтмәгәндә дә ярый, — диде Идрис.

Аның фикеренә кушылуын белдереп, Камил дә башын игәләде.

— Вакыты җиткәч болай да ачылыр. Я, шуннан? — диде.

Гайнанның коңгырт күзләре шундый түземсезлек, шундый тәвәккәллек очкыны белән ялтырады ки, Идрис абыйсы көлеп җибәрде.

— Булмаса, яшь буынга сүз бирик!

— Бик рәхәтләнеп! Ни әйтмәкче була соң яшь буын!

— Хәзер.

Гайнан, куеныннан кәгазьләрен ала-ала, кояш яктысынарак килде.

— Мин ул кешегә җавап язып карадым. Дәрҗия апа басса, «Нигә мин Җидегәнне ташлап китә алмадым?» Исеме шулай.

— Бераз озынрак икән дә, шулай да ярый торган, — диде Камил.

Мәкаләсен укый башлагач, Гайнан үзгәреп китте. Әйтерсең кыюсыз егетне алмаштырып куйдылар. Аның йөзенә алсу кызыллык йөгерде, тавышы бер усалланды, бер йомшарды, тагын кырысланды. Урыны белән йодрыгын да айкап куйгалады.

Казаннан укырга керә алмыйча кайтканнан соң, ул байтак вакыт арлы-бирле сугылып йөргән дә читкә китәргә булган. Менә бөтенесе әзер: өс-баш та, чемодан да. Ул инде туган йорты белән дә, иптәшләре белән дә саубуллашкан. Чишмәләр белән дә хушлашыйм дип, суын эчеп, битен юып йөри икән, шунда әллә ни булган: читкә китә алмый башлаган! Ни сәбәп? Аны нинди тылсымнар, нинди көчләр туктаткан?

Бу укучысының мәктәптә бер фәнгә дә артык исе китмәве, берни белән дә аеруча мавыкмыйча ничектер үзен һаман да бер төрлерәк, ваемсызрак кына тотуы укытучы вакытында Идрисне борчыган иде. Мәкаләне укыганда аның чырае яктыра барды. Егетнең дулкынланган йөзендә ирләрчә ныклык, тәвәккәллек чалымнары балкып китте, ул инде битараф кеше түгел иде.

— «Чөнки бит Җидегән чишмә безнең авылның җаны икән, күз өстендәге кашы икән, аннан башка юк икән бит ямь, юк икән! Әйтегез миңа, кайда бар бүтән андый чишмәләр, әйтегез! Ул бит мондый бөтен Ык буена бер генә, Урал таулары итәгендә андый чишмә бер үзе генә! Гасырлар буена халыкка дару-дәрман булып килгәнме? Килгән! Үзенең яме, суының тәме белән гомер буе тән һәм җан азыгы булып рәхәтләндергәнме? Әйе, рәхәтләндергән! Шул җитмәгәнмени сезгә, әй, эшкуарлар?!»

Тәэсирләнеп тыңлый торгач, Камил, ялкынланып китеп, кулын күтәрде. Аның: «Шәп, энекәш!» дип Гайнанның иңбашыннан кагасы килгән иде дә, тыелып калды. Язучы иптәшләренең «вакытыннан элек мактап, яшьләрне бозасыз!» дип, ничә мәртәбә ризасызлыкларын белдергәннәре бар.

Шулай да, бу егетнең туган ягына мәхәббәтен әнә шулай үзенчәлекле итеп яза алуы, табигать күркәмлеген шулай чын күңелдән кайгыртуы аңа бик ошады. Күрәсең, буш түгелдер бу егет. Чишмә өстендә барган бәхәсне мыегына чорнаган да әнә нәрсә китереп чыгарган!

«Сөрмәгез Алтынбикә тугаен, тимәгез чишмәләргә, бикләмәгез таш капчыкка, әй, апалар, абыйлар! Сез бикләрсез дә китәрсез, ә безгә нәрсә кала? Челтерәп аккан тере чишмәләр урынына емкость дигән таш капчыкмы? Без — киләчәк буын кешеләре! Бу җирләрдә сездән соң без яшисе. Безнең шәрә җирдә утырып каласыбыз килми. Безгә яшеллек, матурлык, муллык кирәк! Безгә чишмәләр дә, урманнар да, камышлы күлләр дә, тугайлар да — һәммәсе дә кирәк! Бирегез безгә тугай белән чишмәләрне! Кулда көч, йөрәктә дәрт җитәрлек! Өмәләр ясарбыз, юкны бар итәрбез, ал да гөл итәрбез. Ышаныгыз безгә, өлкәннәр!»

Камил егетнең кулын кысмыйча булдыра алмады. Идристә мәкалә матур өметләр уятты. Бәлки энекәш үзен шушы эштә табар? Бәлки бу яңа гына борынлап килүче яшь журналистның беренче адымыдыр! Ә табигатькә мәхәббәте мәктәптә уянмаганмыни? Димәк, Идриснең өлкән класс дәресләрен тугайда уздырулары, таңны Ык буенда каршылаулар — берсе дә бушка китмәгән!

Шулай да Идрис үзенең куануын артык сиздермәде.

— Без, дисең, яшьләр, дисең. Кемнәр соң алар? — диде.

— Комсомол иптәшләрем. — Гайнан уйланып торды да: — Күпчелеге, — диде.

— Һәммәсе дә түгелмени?

— Юк, шул. Укып карадым да, Ризван абыйга ошамас, диләр. Кайсыберсе «Патриот»ка тел тидерүдән шүрли.

— Дөрес җавап бу аңа, энем, һәйбәт җавап биргәнсең. Бастырып кына булса.

Камил арлы-бирле йөренде дә егетләрнең иңбашларына кулын салды.

— Беләсезме? Бу мәкалә белән газетада аңгәмә башлап җибәрергә була. Бөтен халыкны кузгатырга! Әйтсеннәр фикерләрен! Табигатьне ничек булган — шулай саклау гына түгел, тагын да баету хакында сүз йөртергә! Моңа сайлаучылар хатын да өстәп басарга!

— Нәкъ шулай! Нәкъ!

— Тик Дәрҗиянең мондый мәсьәлә күтәреп чыгарга батырлыгы җитәр микән?

Гайнан түземсезләнеп баскан урында таптана, өлкән абыйларының һәр сүзен йотып алырдай булып, елтыраган күзләре белән әле берсенә, әле икенчесенә текәлә иде. Тик аны дөрес аңлыйлармы?

— Ык буеның башка җирдә булмаган иң матур урыннарын саклап калу турында сүз бара...

— Бик вакыт! Кайда урман ул, кайда болын, чишмә, әрәмәлек булырга мөмкин. Менә күрерсез, басылсын гына! Хатлар белән бөтен редакцияне күмәчәкләр. Минемчә, шулай!

Идрис энесенең иңбашыннан какты:

— Ишеттеңме?

Гайнан ерылып киткән авызын җыя алмый иде.

— Әйе, абый, — диде.

— Шундый йөкне күтәрергә әзерме соң син?

— Күтәрәм, абый! Тик үзем генә түгел, иптәшләрем белән! — Тагын ни әйтәсен белмичә бер урында таптанып торды да: — Рәхмәт сезгә, рәхмәт! — диде.

Бер башлаган эшне очлап чыкмыйча Мәдәниянең җаны тынмый иде. Яшь чакларын исенә төшерү аның тынычлыгын алды.

Гайнан мәкаләсен укып бетерүгә чамалабрак, Мәдәния самаварын да яңартты, төче коймак та пешереп алды.

Тик ул дәшәргә дип чыкканда Идрис кунакны тарантаска утыртырга җыена иде. Анасыннан гафу үтенгәндәй:

— Безгә Ык буена төшәргә туры килә бит әле, әни, — диде.

Мәдәния тагын берүзе генә калды.

## VII

Редактор бүлмәсенең ишеге бераз ачык калган иде. Аннан кемнәрнендер сөйләшүен ишетеп, Гайнан кәтәргә булды. Тик торасы килмичә, район газетасының стенага эленгән соңгы санын караштырырга тотынды. Бит саен берәр савымчы, я механизатор басып тора. Аларның һәммәсен дә елмайттырып төшергәннәр. Биттән-биткә күзен йөртә торгач, Чурмантаев фамилиясенә юлыкты. Аннан интервью алганнар икән.

— «...Сөтне һаман күбрәк тә күбрәк кудыру агымдагы моментта көннең кадагына сугучы иң җаваплы һәм дә конкрет бурычларның берсе булып тора. Шул максатлардан чыгып, колхоз правлениесе колхозчы массаларны һәртөрле агитация-пропаганда, масса-политик, масса-оештыру чаралары белән чолгап алуны алга куйды диясе килә»...

Тешләре арасында ниндидер тимер кисәкләре әвәләгән кебек тоеп, Гайнан тизрәк читкә карады. Әгәр редактор үзе дә газетасының теле шикелле шундый җансыз, шыксыз булып чыкса, Гайнан мәкаләсен кычкыртып суячаклар иде. Карангалый торгач, витрина өстендәге язуга күзе төште. Ярый әле. Бусы — брак үрнәге итеп эленгән икән.

Ул яңадан редактор бүлмәсеннән килгән хатын-кыз тавышына колак салды. Ни бар анда? Сөйләшеп утыралармы? Киңәшмәме?

— «Халыкның күңел түренә үтеп керү өчен иң көчле, иң хак сүзләр табарга кирәк. Бармы шундый тылсымлы, ялкынлы сүзләр, кайсын әйтү белән ялкау эшкә күтәрелсен, җәмәгать байлыгын әрәм-шәрәм итүче җир тишегенә керердәй булсын, кешеләрдә эш дәрте кабынсын!?»

Ул да түгел, бүлмә эчендә машинка тукылдарга тотынды. Озак та үтмәде, идән шыгырдатып йөри-йөри әлеге хатын-кыз сөйли башлады:

— «...Халыкка җиткерәсе иң дөрес, иң гадел сүзләрне безнең партиябез әйтте, аның иң көчле көрәшчеләре, иң танылган пропагандистлары, язучылары әйтте. Тик шунысы бар, ул сүзләрне попугай шикелле хиссез кабатлау берни дә бирә алмый. Күңелләргә үтеп керсен, яхшы теләкләр кабындырып җибәрсен дисәң, син аларны үз тойгыларың белән җылытып, үз йөрәк ялкының белән дөрләтеп чыгар! Менә ничек эшләргә тиеш чын агитатор, чын пропагандист!»

Тагын язу машинкасы тукылдый. Гайнан гаҗәпкә калды. Редактор мәкаләсен башта сөйләп карый иде, ахрысы.

Гайнанның кулы үзеннән-үзе куен кесәсендәге мәкаләсенә сузылды. Ул да иң дөрес сүзне, иң хак сүзне әйтергә тырышкан иде шикелле. Барып чыктымы икән?

Редактор машинкада баскан җиреннән ишеккә борылды. Гаҗәпләнеп бераз текәлеп торды да:

— Нихәл егет, ни йомыш? — диде.

Гайнан үзенең вакытсыз килеп керүен, редакторның эшен бүлдерү яхшы түгеллеген хәзер генә аңлады.

— Бик ни инде, Дәрҗия апа, әллә ничек килеп чыкты. Капылт кына... Мин теге ни... чишмәләр турысында!

— Чишмәгезгә ут капмагандыр бит? Әллә берәрсе күтәреп алып киттеме?

— Күтәреп дип... Юк та! Гәзитәгездә кирле-башлы китәреп, гел ялгыш язганнар.

Дәрҗия ирен кырые белән генә көлемсерәп диванга барып утырды.
— Ә син дөп-дөресен генә язып килдең инде, әйе бит?

Егет үзенең «әйе» дип ычкындыруын сизми дә калды. Тик шунда ук тагын үкенде. Шушы чибәр ханым белән егетләрчә сөйләшә белмәве, аңа аңгырарак кына бер малай булып күренүе ачуын китерде.

— Син ул мәкаләгә каршы чыкмакчы буласыңмыни?

— Әйе! Үзегез гәзиткә гел хак сүз генә язылырга тиеш дисез бит!..

— Ничектер бит әле, кемнеке дөресрәктер!

— Фәсхетдин абзый бөтенесен әвеш-тәвеш китереп, бозып күрсәткән!

Дәрҗия матур күзләре белән усал итеп карады.

— Бик тә озын телле булып чыктың әле син, энекәш! Безнең газетада Фәсхетдин имзасы белән андый мәкалә чыкканы юк!

— Бәй, аныкы булуы әллә каян кычкырып тора! Тамак киереп кычкыргандай, бөереннән чыгарып язган! Кулы да аныкы, сүзләре дә!

Мәкаләсен укыганда Гайнан, андый-мондый була калса сикереп торырга әзер булып, урындыкның кырыена гына утырды. Редакторның берничә тапкыр кашлары җыерылды, озынча коңгырт йөзендә канәгатьсезлек билгесе пәйда булып, кулына карандаш алды. Ләкин, ничә тапкыр кыҗрап куйса да, төзәтергә кулы бармады. Гайнан үзалдына елмаеп: «Әһә! Булмыймы?! Боза алмыйсыңмы!» дип куанып утырды. Бу мәкаләне ул бер утыруда язды, һич тә баш ватмыйча. Әйтәсе сүзләре каләм очыннан үзләреннән-үзләре тәгәрәп кенә тордылар. Шул чак Гайнан үзендә ниндидер бер яңа хис, рәхәтләнү хисе тойган иде.

Нечкә кашлары өстенә төшеп торган куе-сары күперенке чәче Дәрҗияне сөйкемле итеп күрсәтә иде. Карап утыра торгач, егетнең башына шаян уй килде: әгәр шулай туры килсә, Дәрҗиягә өйләнер идеме икән?..

Менә редакторның алсу тырнаклы матур бармаклары карандашны тегеләй-болай әйләндергәләде дә тукталды.

— Музей! Нинди музей?!

— Табигать музее, апа. Табигатьнең иң матур, иң кадерле урынарын бозмыйча киләчәк буынга саклау өчен оештырыла.

— Монысын да үзең уйлап чыгардыңмы?

— Юк, апа, теге көнне чишмә өстендә сөйләшкәндә әйттеләр. Ул хакта радиода сөйлиләр, гәзитәләрдә дә күп язалар. Тик сезнең гәзиттә генә берничек тә күренми... хәзергә.

Дәрҗия ачуланмыйча гына:

— Әле синең шулай тешләп ала торган гадәтең дә бармыни? — диде.

— Юк, апа. Сүз уңаенда гына әйтү бу, теләк формасында гына...

Ниһаять, Дәрҗия башын күтәрде, аңа ягымлы итеп карады.

— Мәкаләң ошады, энекәш. Яза беләсең. Син шулай сызгалап тор: нинди яңалыклар бар, планнар ничек үтәлә? Алдынгылар тәҗрибәсе, фермалар...

Гайнан берни аңламастан урыныннан торып яңадан утырды.

— Ә монысы?

— Кертә алмыйбыз.

— Нишләп, апа? Үзегез ошады дидегез бит!

Дәрҗия мәкаләне өстәл аша Гайнанга сузды.

— Кичә басканны бүген сызып утырырга газета ул, энем, балалар уены түгел. Аңлашыламы?

Гайнан озын гәүдәсе белән өстәл каршына килеп басты.

— Юк, апа, аңлашылмый! Тегесе кычкырып торган ялган булса да төзәтмисезмени?

— Нинди ялган? Ул хәбәрне авторитетлы олы кеше язган. Председателегез дә раслады.

— Дөресен яза икән, нигә үз исемен куярга курыккан?
Редактор егеткә сыныйрак карап алды да кечкенә машинкасын алдынарак тартты.
— Ул аның үз эше. Телисең икән, син дә «Шүрәле» дип куя аласың, я «Байгыш» дип.
— Юк инде, апа! Алай койма артыннан таш атып ятмыйм инде мин! Комсомол алай өйрәтми!
Чыгып барганда Гайнан редакторга тагын бер күз салды. Дәрҗиянең күз төпләре көйгән сыман күренә, авыз читләрендә дә ике сызык бар икән. Дәрҗия аның нык сүзле булуынамы, яшьлегенәме кызыгып, бераз моңаеп караган кебек күренде. Гайнан баягы шаян уе исенә төшеп башын селекте. Юк, ул моңа өйләнмәс иде, юк!
Мәкаләнең басылмавы хакында ишеткәч, Камил кәефсезләнде. Чалара башлаган чәчен биш бармагы белән артка тарап, байтак вакыт бүлмәсендә пошынып йөрде.
— Кайларга гына борынын төртми шул кәһар төшкән әләк! — диде.
Егет бу сүзгә бераз сәерсенде, шулай да сорарга кыенсынды. Камил аны урамга кадәр озата чыгып тынычландырып калды.
— Кайгырма, энекәш! Шундый тискәреләргә каршы көрәшү бик файдалы. Ул кешенең ихтыяр көчен ныгыта, гадел кеше итеп, көрәшче итеп чыныктырып үстерә!



## VIII

— Умарталарны кышка әзерләр чак җитеп килә, — дип, Минһаж агай кичә Гайнанга корт өен тазартып куярга кушып киткән иде.
Сентябрь бетеп килә. Кич-иртә сизелерлек үк суыткалый башлады. Шулай да Гайнан җәйдән килгән гадәтен ташламады. Бик иртә торды да майкадан гына җиде мәртәбә умарта бакчасын йөгереп әйләнде, унбиш тапкыр киртә аша сикерде, турникта уйнады. Аннан соң Гөбердәвек чишмәгә төшеп, аның зәңгәрләнеп аккан салкын суын күкрәгенә сипте. Тәненең кызыл борыч белән угандай кызуына рәхәтләнеп бииби сөртенгәндә чишмә өстендәге өянкеләргә күзе төште. Бер көтү сыерчык кап-кара булып агач башларын сырып алган. Үзләре туып-үскән Ык буйларын, мондагы тугайларны исләрендә калдырырга теләгәндәй, моңаеп кына як-якларына караналар. Гайнанга бик моңсу булып китте. Аерылышу күңелсезлеген сыерчыклар да сизәләр, язгы кебек ярсып, дәртләнеп чутылдамыйлар, хушлашу авазларын уйчан басынкы тавыш белән өзек-өзек кенә сызгырып куялар иде.
Шул вакыт арттагы сукмакта аяк тавышы кыштырдады. Борылып караса... теге Бөгелмәдә очраган кыз! Өстендә ап-ак халат, кулында буш шешәләр тутырган кара сумка. Кызый киермә кашлы чем-кара күзләре белән егетнең кызарган тәненә текәлеп, учын-учка бәрде:
— Кара һин, әй! Ниндәй мәрәкә тип торһам, Татарстан за ла Тарзан бар икән, әй! — диде.
Егет шатлыгын яшереп тормыйча авызын ерып:
— Аһ, күрми дә торам! Кунак кыз! Әйдәгез, рәхим итегез! — диде.
Ләкин егетнең күгәрә башлаган иреннәре кызыйны чын-чыннан борчый иде, күрәсең, ул уены-чыны белән:
— Тарзан булһагыз ла, бу һезгә жунгли түгел, өшиһез бит! — диде.
Кунак кызның аны кайгыртуы да, калын кашларының менеп-төшеп уйнап торуы да Гайнанга бик ошый иде. Ул көлә-көлә өстен киенеп, кызга кулын суздь.
— Башта танышыйк — Гайнан Мингатин.
Кунак кыз да башын нәкъ Гайнандай иеп, кулын да, авыл малайларыдай, ерактан ук айкап күреште.

— Шәүрә Байбулатова!

— Шәүрә? Бәрәкәт! Димәк, күрше ил кызы? — Гайнан иртәнге соры томан белән өртелгән Ыкның аргы ягын күрсәтте.— Әнә генә синең Башкортстаның!

— Минең? Нигә һинеке дә түгел!

— Дөрес, тапкыр җавап! Тик минеке Татарстан...— Бу кызыйның теле йомшак, сүзләрне ул ничектер, иреннәре очында уйнатып кына йөрткәндәй, үзенчә матур итеп бик җиңел әйтә иде. — Исемең дә бик сөйкемле икән, «мине әйтегез!» — дип, үзеннән-үзе җырлап кына тора.

Кызый, кара сумкасын атындыра төшеп, яңадан татарчага күчте:

— Хәзинәдә бары...— диде.

Гайнан аның яшь, чибәр йөзенә текәлеп:

— Кара әле! Син теге «Шәүрәкәй» дигән башкорт җырыннан төшеп калган Шәүрә килен түгелме? — диде.

Шәүрә башын чайкады.

— Юк шул. Мин «төшеп калганнардан» түгел.

— Һәйбәт әйттең! Авызыңа бал да май!

— Аннары төшәр өчен башта менәргә кирәк. Ә минем җырга менәрлек берни дә майтарганым юк әле.

— Мм... кара, синең телең бар икән бит! — Гайнан кызыйның янына ук килеп басты.— Беренче очрашканда, тегендә Бөгелмә вокзалында, мин сине телсездер дип уйлаган идем.

— Нинди исәр уй килмәс иләс-миләс башка!

Шәүрә, сумкасын җиргә куеп, егеткә сыныйрак карады. Бу озынкай аңа кемнедер хәтерләтә иде. Ләкин кемне икән? Ул кешене искә төшерә алмыйча, сумкасын яңадан кулына алды.

— Мин эш белән килдем.

— Аңлыйм, Шәүрә туташ. Бик рәхмәт, сизенәм, сине Камил абый җибәрттергән.

— Кем тагын анысы?

— Зур кеше. Язучы, депутат.

— Шулай укмыни әле? Бик кадерле кеше икәнмен алай булгач. Яуаплы эш менән йөрим икән!

— Бик, зерә дә!

Шәүрә халат кесәсеннән юан кара карандаш алып чишмәләрнең исемнәрен язарга хәзерләнде.

— Аерым-аерым кирәк!

— Рәхим итсәңче, Шәүрә туташ! — Гайнан кырыйдан башлады.— Беренчесе Мәрви чишмәсе. Иң шаулысы Гөбердәвек. Аның күршесе — Зәңгелә чишмәсе. Аннары Баллы чишмә, Балан тияк. Ник дисәң, әнә өстендә генә балан куагы үсеп утыра. Аның янында Умырзая, иң кырыйдагысы — Олан чишмә...

— Нигә «Олан»?

— Кечкенә булганга, иң соңыннан килеп чыкканга.

Шәүрә шешәләрне ике бармагы белән генә тотып су тутырып алды да ап-ак марля белән корытып, кыйммәтле даруларддай кадерләп кенә сумкадагы ояларына тезде. Кызыйның пөхтәлеге Гайнанга ошады. Әледән-әле күз салгалап алуы да күңелне кытыклый, сөйләшәсене китерә иде.

Гайнан кызыйның сумкасын чишмә өстендәге ташка алып куйды.

— Бәлки син «бу чибәр егетне ничәнче күрүем соң әле?» дип баш ватасыңдыр? Бик караштырасың!

— Андый ваем төшкәне юк әле башыма.

Кызый китәргә җыенгач, Гайнан аны умарталыкка дәште.

— Бәлки кереп чыгарсың? Чәй эчәрбез бал белән.

— Телеңдә гел бал да май. Күрәм, байларча синең эш!

Гайнан кулы белән өстәге зур умарталыкны, андагы ике юкә арасына кертеп салган, тәрәзәләре белән Ык болыннарына карап утырган җыйнак кына өйне күрсәтте.

— Дөрес, әй! Ярлы түгел мин. Бер үземә йөз кырык умарта асрыйм, аларда әллә ничә миллион хезмәтче тотам. Индира Ганди җибәргән затлы чәй генә эчәм, бал белән майда гына йөзәм. Әйдә күтәрелдекме?

Кызый Гайнанга кайсы ягы беләндер ошый башлаган иде. Хәзер аның кунак кызны болай бернисез, һич югында, күңеленә берәр җылы сүз салмыйча җибәрәсе килми иде. Сумкасын үзе алып, машинасына озата төште.

— Беләсеңме, Бөгелмәдә очрашканнан соң минем сине яңадан күрәсем килә башлады...

Дөресен генә әйткәндә, үзе килеп чыкмаса, ул Шәүрәне бөтенләй онытып иде. Хәзер исә үз ялганына үзе ышанды, айлар буена аны гына уйлап йөргән кебек тоела башлады.

— ...Ә менә икенче тапкыр очрашкач, беләсеңме, нәрсә уйладым?

Кунак кыз күз кырые белән генә карап, көлемсерәп куйды.

— Өченче тапкыр күрешмәсәм иде дипме?

— Юк ла, киресенчә...

Сукмакның бер тар урынында Гайнан куак астыннан бөгелебрәк чыккан иде. Шәүрәнең күз алдына икенче бер кеше килеп басты. Ул да машинасыннан нәкъ шулай бөгелеп чыккан иде, аның да аркасы шулай чыгынкырак, буе озын, маңгае калку, борыны шуныкы кебек озынча «дөрес» борын иде. Ул кеше Шәүрәне, яңгыр сибәләп торган көнне кызганып, скважинадан кызыллы-зәңгәрле «Волга»сына утыртып алып кайтты. Шушы тирәләргә җиткәч, машинасын туктатты да чишмә ягына карый-карый тәмәке тартты. Шәүрәнең аңлавынча, бу тирәләр ул агайның нечкә тойгыларын уяттымы, яисә монда аның бик газиз якыннары бармы, шулайгарак охшый иде. Үзе дә туган-үскән якларыннан аерылып киткән китек күңелле кеше булганлыктан, бу абзыйның дулкынлануы кызга да йокты.

Шәүрә Гайнанга гаҗәпләнебрәк карап алды. Бу егетнең кеме булыр икән соң ул озын агай! Кардәшеме? Чәч тарауларына кадәр бер.

Кызыйның әледән-әле шулай текәлеп каравы Гайнанны да кытыклый башлады.

— Мин кемгәдер охшыйм, ахрысы. Әллә кем дә булса миңа охшыймы?

— Юк, син аңа охшыйсың. Ул өлкәнрәк.

— Юньле кешеме, ичмасам?

— Юньле генәме әле! Мировой! Чәче Джон Кеннединекенә охшаган.

Гайнан кунак кыз алдында биш бармаклап чәчен артка сыпырырга тотынды.

— Чынлап әйтәсеңме?

— Ялган сүз белән авызымны пычратмыйм әле!

— Һа-һа-һа! Менә әйттең, ичмасам! Тик моны безнең Дилбәр ишетсә, беләсеңме, харап эш!

— Ишетсә ни була! Синең чәчеңә ул хуҗа түгелдер бит?

— Һе! Белмисең әле син! Ул шундый «дөрес» кыз! «Нигә син комсомол башың белән чәчеңне капиталистлар җитәкчесенә охшатып тарыйсың?» дип җанымны алыр, я эш кузгата башлар.

Олы юлдагы «Кәҗә тәкәсе» дип йөртелә торган машинага якыная төшкәч, Гайнан акрынрак атлый башлады.

— Чынлап әгәр, Шәүрә, очрашу өчкә тулганда һәркайчан берәр мәгънә килеп чыга.

Шәүрә читкә карап кулын селтәде.

— Ә безнең башкорт «өстән һоң көс» тияр. Анда инде әллә нәмәкәй көтәһе калмай.

— Бездә алай түгел, Шәүрә. Өч — ул түгәрәкләнү, йомгаклау булып чыга. Сабан туенда өч тапкыр җиңсәң, батыр каласың. Әкияттә дә шулай: өч тапкыр сызгырсаң, өч гыйфрит килеп чыга. Егет өч юл чатыннан узып өч диңгез кичә, өч сарайда өч дию не үтереп, өч патша кызын коткара... Өч тапкыр очрашканнан соң, безгә дә нидер булыр. Каян беләсең, бәлки мин сиңа өйләнеп куярмын!

Шәүрә рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Ап-ак вак тешләре күренеп китте, күзләре кысылып бетте дә ул урында кара сызык кына калды.

— Алайһа, мин һинең менән осрашмаска тырышырмын!

— Нишләп алай? Юк, алай булмый, ярамый. Шәүрә, очрашыйк!

— Юк, кирәкмәй! Ансат кына өйләнгән кеше ансат кына аерыла да!

«Кәҗә тәкәсе» сигнал бирде. Шәүрә ашыга башлады.

— Анализларны кая куярга?

Гайнан нидер өмет итеп:

— Үзем барып алырмын, — диде.

Шәүрәнең сүзе кыска булды:

— Көндез өйдә булмаем, кисен бик һоң кайтам.

— Ә мин төнгә каршы да бара алам, соңрак та!

— Төнлә минем йоклый торган гадәтем бар!

Егет көлемсерәп башын чайкады.

— Карале, торган саен ныграк ошый барасың син миңа!

Машинасына җитәрәк Шәүрә борылып:

— Гөбердәвек чишмә янында булыр! — дип кычкырды.

— Кайчан!

— Төннәр узып таңнар атканда!..

Гайнан тагын нидер сорамакчы булып авыз ачканда, машина фырылдап китеп тә барды.

Төш идеме бу, өнме, әллә йокы белән өннең ике арасымы — ни хәл бу?! Бөтен дөньяны ниндидер бер тылсымлы моңсу аһән биләгән. Шул гаҗәп моң Гайнан күңеленең эчкәресеннән дә эчкәресенә үтеп кергән дә моңарчы барлыгын үзе дә сизми йөргән иң нечкә, иң газиз тойгыларын уяткан. Менә ул шундый нәфис авазларның тел белән әйтеп булмастай, берни белән дә чагыштырмастай рәхәт диңгезендә тирбәлә. Гайнан иртәнге алсу томан белән өртелгән Алтынбикә тугаена карап утыра икән, җәй башының моңсу иртәсе, әрәмәләрдә өздереп-өздереп сандугачлар сайраган чак икән. Әмма нигәдер бик ямансу, нәрсәдер юксындыра, бу моңны яңадан ишетә алмассың, бу рәхәтне яңадан татый алмассың, нидер узып бара, бөтенләйгә югала кебек тоела иде.

Менә Гайнан, су астыннан күтәрелгәндәй, акрын-акрын бу тылсымнан арына барды, уяна барды. Ачык тәрәзәдән сыек кына таң нуры белән бергә агылып кергән кызлар тавышы ишетте:

Һандугас, һандугас,
Китмә, китмә, һандугас,
Канаттарың талдырып,
Туган илне калдырып...

Егет сикереп торды да аннан-моннан өстенә элде. Шәүрә җырлавын белә иде инде ул. Сүзләрен әнә ничек йомшак, ягымлы итеп әйтә, «Һандугас»ны әнә нинди үзәкләргә үткәреп суза. Бу — җыр гына түгел, аның алдында чын сандугач үзе тора. Шәүрә аңа күз яше белән ялвара кебек. Аһ, егетләр! Бу кызыйны үзе каршы алу өчен ничә көннән бирле шушы умарталык өендә куна бит! Ничә көн рәттән кояш чыкканчы чишмә өстендә көтеп алды. Ә Шәүрә әнә нинди иртә килгән!

Атылып-бәрелеп ишектән чыгуга, астан дулкын-дулкын булып җырның ахыры килеп менде:

Һандугас, һандугас!
Һин китәһең, мин калам...

Гайнан әсәрләнеп бер генә сулышка туктап калды. Аның моңарчы күкрәктән чыга торган мондый калынча моңсу тавышны бер бик мәшһүр башкорт артисткасыннан гына ишеткәне бар иде.

Егет тар сукмактан, куакларга тотына-ябыша, чишмә янына ашыкты. Чыгарга җыенган кояш нурлары эчендә бер генә секундка чишмә өстендә Шәүрәнең ак халаты күренеп калды. Әмма Гайнан абына-сөртенә төшеп җиткәнче, ул тирәләр бушап калган, бөркәүле яшел машина әрәмәләр арасыннан бер күренеп, тагын югалып, олы юлга чыгып бара иде.

Шулай. Анализлар булды. Хәзер инде күңел үз урынында булырга тиеш иде кебек. Ләкин егет тынычлык таба алмады. Әлеге җырның моңы, һич калмастан, аңа ияреп йөрде, юк, алай гына да түгел. Җыр үзенең иң нечкә борылышлары белән өздереп аның күңел түрендә кабатлана, йөрәкне кысып-кысып ала, дулкынландыра, әллә нишләтә иде. Гайнан уйлана-уйлана умарталыкка менде, анда тынычлана алмыйча, яңадан чишмә тамагына төште. Ләкин җыр торган саен көчләрәк дулкынландыра башлады. Әйтерсең үзләренең тылсымлы моңнары белән Одиссейны сихерләргә тырышкан кош аяклы кызлар-сиреналар кебек, Шәүрә дә егетнең күңелен биләр өчен үз урынына менә шушы җырын калдырган, сихерләсен, эзләп барсын дигән. Күбрәк уйлаган саен егетнең борчуы арта барды. Нигә таң белән килеп җырлый, нигә кача, нигә күренмәскә тырыша?

Гайнанның күңеле нидер сизенде, менә хәзер ук, түзә алмастай булып, шушы минутта ук Шәүрәне күрәсе килә башлады.

Егет сәгатенә күз генә салды да Шәүрә яшәгән күрше авылга йөгерде. Сәгать әле алты гына тулып килә, Минһаҗ менгәнче Гайнан яңадан үз урынында булачак иде.

Ике авыл арасындагы үзәннән барганда сискәндереп, кинәт баш очыннан гына «выжт» иттереп сыерчык өере үтте. Алар шул кадәр тиз, шул кадәр ашыгып очалар иде ки, Гайнан күтәрелеп караганда, офыкта кара шәүлә булып сызылып кына киттеләр дә юкка да чыктылар. Бераз баргач, таныш авазлар ишетеп, Гайнан башын күтәрде. Мәһабәт өчпочмак булып киек казлар көньякка ашыга, кояшның беренче нурлары төшкән алсу канатларын хушлашып яулык урынына болгыйлар, моңсу итеп каңгылдашалар. Казларның Сөендек урамындагы туганнары тынгысызланып арлы-бирле очыналар, үз телләрендә саубуллашып калалар иде.

Гайнан дулкынланып тау кырыенда туктап калды. Табигатьнең беркем дә, берни дә тыя алмый торган бөек көче бөтен җан иясен хәрәкәткә китереп, һәммәсен көньякка, җылы дәрья буйларына, эссе сахраларга ашыктыра иде.

Әй Шәүрә! Аңа да нидер булмадымы икән! Аның соңгы җырында йөрәкне чеметеп-чеметеп ала торган ниндидер аерылышу сагышы ишетелде түгелме соң?

...Шәүрәнең фатир карчыгы алтмышлардан узган ак чырайлы, озынча битле, пөхтә киенгән әби баскыч төбендә тавык-чебешләрен туйдырып утыра иде. Бу яшь кешенең мышкылдап килеп керүенә әллә ни гаҗәпләнмәде. Егеткә күзлек өстеннән дә, күзлек аша да тыныч кына карап утыргannан соң:

— Китте, — диде.

Шәүрәнең Уфада техникумда укып, Татарстанга нефть эшеннән

практикага гына килүен дә белә, шулай да кинәт кенә китүе Гайнанның башына сыймый иде.

— Ничек китте, нишләп китте? Што син, әби!

Хуҗабикә, «минем белән сөйләшеп торырлыгың бармы соң әле синең?» дигәндәй, егетне башыннан аягына кадәр күзе белән сөзеп чыкты.

— Синең бер дә китеп караганың юкмыни соң, олан? Ничек киткәнне белмисеңмени? Машинага утыралар да тү-тү, түт!

«Олан» дип кимсетүен кара әле син!

— Кая китте?

Карчык икмәк ваклавыннан туктады. Тезләренә таянып торып басмакчы булды да нигәдер кире уйлады.

— Әйбәтләп сөйләшергә өйрән башта, шуннан ары килерсең, яме!— диде. Алдында торган савытка икмәк ваклап тавык-чебешләрен дәшәргә тотынды. — Ти-ти, ти-ти...

## IX

Дәрҗия белән исәнләшеп хәл белешкән арада Камил аның өстәле артына стенага эленгән рәсемгә игътибар итте. Җиде чатның гарасатлы җилләренә күкрәкләрен куеп, биек кыя башында мәгърур басып торучы пар эрбет агачы иде бу. Көчле өермәләр, котырган давыллар аларны төбе-тамырлары белән йолкып алырдай булып кырыкка бөккән, тегеләй дә, болай да сыгып кабыкларын каезлаган. Ләкин ике эрбет, башларын горур тотып, һаман да яшиләр, үсәләр! Һаман да якты күккә омтылалар! Тойво Яннельнең «Мәгърур эрбетләр» дигән рәсеме иде бу.

Камил Дусайның бер рәсемгә, бер аңа карап алуына уңайсызланып, Дәрҗия:

— Сезгә дә ошады, ахрысы? — диде.

— Ифрат! Күрәсең, бу батырларны сез дә ихтирам итәсездер? Шулаймы?

— Әйе. Мусалар язмышын искә төшерә ул.

— Берникадәр бөтен халык язмышын да хәтерләтә. Хәтта боларны үз эшеңә үрнәк итеп тә алырга мөмкин. Журналистка да, язучыга да. Ничек, сезнеңчә?

Дәрҗиянең ирен кырые сизелер-сизелмәс кенә тибрәнеп куйды. Камил, чибәр ханымның үзенә генә хас чалымын тотып алуына куанып, күңеленнән генә: «Әһә! Ирониясе болай икән ханымның!» — диде.

— Безнең эштә шәхси батырлык белән генә әллә ни тожырып[1] булмый, Камил абый. Редакция мең җеп белән меңнәрчә шәхескә, йөзләрчә коллективка тоташкан. Газетаны җәмгыять фикеренең сейсмографы дип атарга була.

Әдипнең йөзе яктырып китте, ул шатланып:

— Кара, бик һәйбәт фикер бит бу, образлы чагыштыру, эһем-һем... Ләкин ул машина янында кем утыра бит! Менә нәрсәдә бөтен хикмәт! — Дәрҗиянең йөзеннән нидер укыгандай, Камил аннан күзен алмыйча текәлеп карады.

Дәрҗия, өстәл янынннан кузгалып, көлә-көлә диванның икенче башына килеп урнашты да йөзен каплады.

— Турысын әйткәндә, мин сездән сагая башладым, Камил абый. Сез минем әйтәсе фикеремне йөземә карап белергә чамалыйсыз шикелле.

— Шулаймыни? Шулай ук әрсезләндем микәнни?! Гафу, гафу! Бетте, алайсам, моннан соң песи генә булып, идәнгә карап кына утырам...

[1] Тожыру — кылу, нидер эшләгән булып маташу. (Казан арты шивәсе.)

— Аны шуннан әйтәм: Америкада хисләрне укый торган яна аппарат уйлап чыгарганнар. Хәтта кешенең уйларын идарә итә башлаганнар, имеш. Котым чыга шундыйлардан! Үз тойгыларыңа да үзең хуҗа булмагач, ни кызыгы кала яшәүнең?!

Камил аның сүзләрен җөплəп башын игәләп утырды.

— Әйе, дөрес, кем, Дәрҗия! Ул чагында кемдер синең уйларыңны үзе теләгән якка борачак, сине үзенә кирәкле юнәлештә уйлатачак. Ә син, ит турагыч шикелле, аңа кирәкле фикерләрне эшкәртеп бирүче бер аппаратка әвереләчәксең, бер бөек кеше әйтмешенчә, хәтта кечкенә бер винтикка. — Камил, ханымның янадан кәефенә тиюдән сагаеп, аңа күз генә төшерде дә үзалдына гына елмаеп куйды. — Әгәр тирәнтенрәк уйласаң, сез әйткән фикердән редакциянең сейсмографына бер генә адым бит.

Дәрҗия уйлап карады да башын чайкады.

— Аңлап җиткермәдем.

— Бик ансат! Баягы фикер: редакция — сейсмограф. Үзегез шулай дидегез.

— Шулай дидем. Сейсмографка охшый да ул. Районның бөтен тормышын сизеп тора.

Камил тураеп тезенә сугып алды.

— Хуп, сизеп, теркәп тора! Ләкин сейсмограф лентасында туры сызыклар да, бер өскә, бер аска сикергән борчулы дулкын-дулкын сызыклар да булырга мөмкин. Әгәр сез дулкынлы сызыкларны кәрзингә ата барып, туры сызыкларны гына калдырсагыз, шул ук шомарту, тигезләп күрсәтү килеп чыгачак.

Дәрҗия алсу төскә буялган озынча тырнакларын якын ук китереп, әле берсен, әле икенчесен карап алды да кычкырып көлеп җибәрде.

— Камил абый, әйдә качышлы уйнамыйк, ярыймы?

— Ярый, хуп! Яратам бер сүздән аңлаган кешене!

— «Патриот» мәкаләсе борчый сезне. Үзегез дә беләсез, Камил абый, халык каршысына чыкканчы иң элек үзебезгә уйлап бетерергә кирәк: кайсы беренче планда тора, кайсы файдалырак? Чәчү мәйданын арттыруммы, әллә матурлыкны саклыйбыз дип бернигә ярамаган әрәмә белән чишмәләргә ябышып ятумы?

Редакторның бәхәскә керүе Камилгә ошый иде. Димәк, яхшымы, яманмы, аның үз фикере бар. Әдип һәм депутат булу сәбәпле генә аңа каршы әйтәселәре килмичә, үзләренә ошаса да, ошамаса да, «Әйе шул, Камил абый», «Шулай шул, иптәш депутат» дип торучылар беренче сүздән үк Камилнең гайрәтен чигерәләр иде.

Камил, идәндә йөренгәли торгач, Дәрҗиянең каршысына килеп туктады.

— Гафу итегез, редактор җәнаплары. Бу хан заманыннан калган иске караш, игенчелек эшендә консерватизмлык бу!

Гаҗәпләнүдән Дәрҗиянең кашлары өскә сикерде, ул уңайсызланып урыныннан кузгалып китте.

— Аңлашылып җитмәде, Камил абый, сәеррәк!

— Нәрсәсе аңлашылмасын икән? Сез эзләнергә, уйланырга, яңача эшләргә яратмаучы ялкауларның стандарт фикерен кабатлыйсыз. Алар нәрсә ди? Башта булдыра алган кадәр табигатьне күбрәк имәргә, бөтен җирне сөрергә, төпләргә, йолкырга, кыскасы, аның җилегенә суырып калырга кирәк. Соңыннан күз күрер!.. Шулай килеп чыга бит!

— Без — практиклар. Бүгенге көннең таләбен кайгыртмыйча булдыра алмыйбыз.

— Менә, менә, мин дә шуны әйтәм! Табигатькә төзәлмәслек яра салынса салынсын, әмма бүген бир син аңа, бүген!

— Табигатькә күрә торып зарар салынмый анысы, Камил абый, монысы хатадыр бәлки?!

— Үзегез әйттегез: бернигә дә ярамаган әрәмәлек дип. Сезгә мәгълүм булсын, Дәрҗия ханым, табигатьтә кирәкмәгән, бернигә дә ярамаган бер нәрсә дә юк! Бер нәрсә дә! Әрәмәлек ул — дым хәзинәсе, ул табигатьнең инкубаторы, лабораториясе! Нинди генә яшеллекне дә кап-кара итеп сөреп ташлау ул экология законын бозу, ул әйләнә-тирәнең дымын киметү, ул кислород чыганагын харап итү дигән сүз. Бер булдымы?

Дәрҗия ихтыярсыздан «әйе» дигән сыман башын иде, ләкин депутат фикеренә кушылмавы чыраеннан ук күренеп тора иде. Камил кулларын болгый-болгый дулкынланып дәвам итте:

— Авыл хуҗалыгында шул кадәр агроном, шул кадәр күп институтлар эшләп тора, аңа хөкүмәттән шундый шәп техника, шундый бай ашлама килеп тора! Шундый заманда да уңышны әрәмәлек сөрүдән генә көтеп яту, гафу ит, Дәрҗия, бу бик примитив, хәтта, мин әйтер идем — иң иске ысул. Моннан мең ел элек чеп-чи надан мужиклар да урманны нәкъ шул сылтау белән яндырганнар, шулай сөргәннәр!

Дәрҗия аптырабрак карап торды да язучы абыйга икенче яктан сүз кушып карады:

— Бу юлы усалланып килгәнсез дип әйтимме шунда!..

Депутат кешегә болай кызып китү килешмәвен шунда гына абайлап, Камил гафу үтенде.

— Аңлыйм, Дәрҗиякәй, аңлыйм! Ләкин... кайберәүләрнең кигәне кара костюм, бәйләгәне шәп галстук, утырганы «Волга», сөйләгәне «культурный» да, «комплекс» та «агрегат» булса да кылган гамәле табигатьне бозу була. Наданлык бу, сеңелкәем! Мин бу хакта тыныч кына сөйли алмыйм!

— Наданлык ук дисезмени?

— Әйе, шулай дим! Күз алдында бит! Алтынбикә тугаен сөрү ул йөз еллар дәвам иткән наданлыкны яңадан кабатлау дигән сүз. Безнең гасыр башында, беләсезме, бу тирәдә урман күпме булган? Барлык җирнең өчтән бере кадәр. Хәзер шуның яртысы гына калган. Кая киткән соң ул? Әнә шулай, чәчү мәйданын арттырабыз дип, кискәннәр дә яндырганнар, сөргәннәр!

Дәрҗия башын иеп уйга калды.

— Азрак калган икән шул.

— Бик аз! Ифрат та! Шулай итеп шул яшеллекне киметү хәзер утырган ботагыңны кисү булып чыга! Хөкүмәт карарлары тыя моны хәзер!

Депутат иптәшнең бүген район башкарма комитетында буласы, Мәдәния китап кибетен ябуга, аның белән очрашасы, аннары кичке сигездә Казанга очып китәсе бар иде. Камил, сәгатенә күз салып, Дәрҗиянең каршысына килеп утырды.

— Мин сезне ышандырдыммы икән, Дәрҗиякәй, әллә юкмы әле?

Редактор бу картаеп килүче чуар йөрәкле кайгыртучан кеше белән һәммәсен уртага салып, ачыктан-ачык сөйләшә ала иде. Ул, үпкәләгән булып, иркәләнгән кыяфәт белән зарланырга кереште:

— Сезне сайлаганда мактап сөйләвемә үкенеп бетә алмыйм, Камил абый. Сез минем күземне дә ачтырмыйсыз, аз гына кызганмыйсыз да, ичмасам!

Дәрҗиянең иреннәре ифрат матур уелган, үпкәләгәндә ирен урталары нәни генә бүлтәеп чыга, йөзенә аерым бер матурлык өстәп, аны балкытып торалар. Аның озынча матур йөзе, әнә шундый сары-коңгырт чәче бик борынгы бабаларыннан ук мирас булып калгандыр, ул Идел буендагы борынгы болгар кызларына охшыйдыр кебек иде.

Дәрҗия шушындый җитди дөнья хәлләре хакында бәхәсләшкәндә дә сөйкемле чибәр ханым булып кала, «беразга гына түз инде» дигән

сыман, үзен-үзе юатып һәм иркәләп акрын гына алмаш-тилмәш кул аркаларын сыпыра иде.

Камил ничектер үзеннән-үзе ягымлырак сөйләшә башлады.

— Сезгә үпкәләү бик килешә, Дәрҗиякәй, тагын да чибәрләнебрәк китәсез. Әнә шулай бераз гына үпкәләтеп булса да, мин сезнең көндәлек тормыштан өскәрәк күтәрелүегезне теләр идем. Журналист булырак, киләчәкне күз алдына китереп фикер йөртүегезне.

— Киңәшегезгә бик рәхмәт, Камил абый.

— Сезне шомлы сүзләр белән шикләндерәләр. Өрәк, искелек, фәлән дип. Алтынбикә легендасыннан нигә өркергә? Шул легенданы алып ташлагыз әле, нәрсә генә кала? Матурлык кына түгел, яшәү мөхиты бу, аларсыз бу тирә яши алмый. Беләсез бит: туган-үскән җиренә бөтен җаны-тәне, газиз хисләре белән берекккәндә генә кеше чын кеше була! Космополитларның кешелек җәмгыятенә игътибарга лаеклы берни дә бирә алганнары юк әле.

Дәрҗия тәрәзә каршысына барып уйланып торды да, өстәленә килеп, кәгазьләр арасыннан нидер эзләргә тотынды.

— Теге егетнең җавабын басып чыгарсам, әлеге карт җанымны алачак, зуррак кешеләр алдында да җавап бирергә туры киләчәк.

— Басмыйча калдырсагыз, Фәсхи ялганын укучыларга көчләп таккан булачаксыз!

— Нигә? Аңа мин кушып яздырмадым ла! Үз хәбәренә ул үзе җавап бирә.

— Алай гына түгел! Аңа каршы фикерне бастырмау — ул гаделлекне яшерү. Фәсхи белән бергәләп ялганга ышандырырга тырышу булып кала.

Камил Шәүрә эшләгән анализ кәгазьләрен өстәлгә куйды.

— Хәлбуки, менә медицина да безнең яклы. Чишмәне суы файдалы булганга шифалы дигәннәр.

Дәрҗия кыен хәлдә калды. Ул авыр сулап куйды.

— Уен эш түгел бу, Камил абый. Фәсхи белән Ризван икесе дә зур стажлы сыналган кадрлар. Абруй, дәрәҗә! Ә теге малай кем?

— Егетне гаделлек яклар, хакыйкать! Ә халык һәр вакыт гаделлек ягында! Кайсы як хаклы, кайсы ялгыша икәнлекне укучы үзе әйтсен! Нигә укучыга шундый мөмкинлек тудырмаска? Нәкъ газета эше бит бу! Нигә укучыны чәйнәлгән әзер фикерләр белән генә тукландырырга? Үзе уйласын, үзе баш ватсын! Озак эшләми торгач, баш ялкаулана, мүкләнә!

Камил редакторга кулын суды:

— Мин бик ышанам, Дәрҗиякәй, иманым камил: төрле лозунглар артына яшеренеп ул кешеләргә табигатьне гарипләндерергә ирек бирмәссез! Шулай итеп шул, теге рәсемне бик белеп куйгансыз. Һәйбәт үрнәк бу!

Дәрҗия көлеп иңбашларын сикертте.

— Алардай нык торырга көч җитсә!

— Гаделлек намена — җитәр! Хакыйкать өстен чыксын өчен көрәшү — изге эш! Сейсмографыгыз да шулай куша бит!

Райбашкармадан чыккач, сәгатенә күз салуга, Камил «аһ» итте, жиденче ярты булган! Ә ул алтыда кибет янында булырга тиеш иде инде. Монысы икенче мәртәбә вәгъдәсез булуы! Өченче көн дә: «Бәтенесен ахырына кадәр ишетмичә китәсем килми. Зинһар тагын бер күрешик инде!» дип Камил үзе язу җибәргән иде. Анысында эшкә мавыгып соңга калган иде. Менә бүген яңадан! Сибәләп яуган яңгыр астында плащ якасын күтәреп Камил йөгерә-атлый китап кибетенә

ашыкты. Район үзәге яңа төбәккә күчеп шактый ук зурайган, икешәрөчәр катлы яңа йортлар салынган, китап кибете искечә, читтәрәк калып тора иде. Камил үзенең һәр вакыт менә шулай «астына су кергә башлагач» кузгалуы, иң мөһим эшне иң ахыргы минутына кадәр сузу кебек шушы ахмак гадәте өчен үзен юл буенча орышып барды. Аннан кыз вакытында нинди җәберләнүенә карамастан, Мәдәния бит Камилгә нинди изге тойгылар саклаган. Ә ул менә шундый саф күңелле, инсафлы кешене ничәнче мәртәбә рәнҗетә. Кая монда намус, кая оят!

Камил Дусай: «Бәлки китмәгәндер, бәлки көтәдер әле», — диди юл буе үзен юатып барды. Очрашсыннар гына! Ул Мәдәниядән һәммәсе өчен гафу үтенәчәк, барлык гөнаһларын, вөҗдан газапларын юып төшерәчәк!..

Кибет ишегендә йозак күргә, Камил коелып төште.

Үзен кая куярга, нишләргә белмичә торганда, аның янында, гүя күктән иңгәндәй, әллә каян гына Гайнан пәйда булды. Күтәрелеп карамыйча сүлпән генә:

— Исәнмесез... — диде.

Бераз сүзсез торганнан соң:

— Авырдыгызмы әллә? — дип сорап куйды.

— Юк, болай...

— Әллә берәр көтелмәгән хәл килеп чыктымы?

Шушы мыексыз егет каршында Камилнең үзен гаепле хис итмичә чарасы юк, ялганнарга теле бармый иде.

— Юк, чыкмады... — дияргә мәҗбүр булды.

Менә хәзер егет җанланып китәр, редакциядәге мәкаләсенең язмышы хакында сорашмыйча түзә алмас дип көткән иде. Ләкин егет ул хакта ләм-мим сүз әйтмәде. Нәкъ балалар үпкәләве белән үпкәләп иреннәрен турсайтып барды да авыр сулап куйды.

— Җиңги-апа сезне шундый көтте, шундый борчылды, елап җибәрәме дип торам. «Мин күп тапкырлар көтеп карадым, миннән калмады», дип әйтергә кушты. Хушыгыз!

Гайнан, озын, юка гәүдәсен туп-туры һәм мәгъруρ тотып, бер генә дә борылып карамыйча, үзенең Җидегәненә кайтып китте. Камил яңгыр явып торган шыксыз, пычрак урамда берүзе калды.

Камил кая барасын үзе дә белмичә урам буйлап китте. Караңгы да төшеп килә инде. Гомерендә беренче тапкыр алданган бичара яшь кызның ачы күз яшедәй, елап, сыкранып өстән тавышсыз-тынсыз һаман көзге яңгыр сибәли.

Картаеп килгән көнендә Мәдәнияне тагын бер тапкыр җәберләве аның йөрәген тырный, ул үзен һич гафу итә алмый, һаман әлеге гадәтен каргый иде. Моңарчы күңел түрендә зәгыйфь кенә булса да «бәлки, бәлки...» дигән өмет яшәп килә иде. Дөрес, яшь вакытта яраткан бу сөйкемле ханым белән Камил яңа тормыш корып җибәрүгә ышанмый. Ул кадәресе беренче очрашуда ук ачыкланган иде шикелле. Шулай да Мәдәния аңа бик газиз, ул — аның беренче мәхәббәте, ике арадагы бу якынлык тойгысыннан, Мәдәниянең бөтен тормышыннан картая башлаган һәм бик тә өшәнгән бу ялгызак җанга ягымлы җылылык сирпелеп тора иде. Хәзер Камил үзен ифрат та ялгыз һәм бәхетсез кеше итеп хис кылды. Аның бөтен гомере нинди дер шулай шыксыз ягымсызлыкта узды, ахрысы. Я аның Мәдәниянеке кебек сагынып искә алырлык гаилә тормышы, я варис булып калырлык балалары юк. Аның Мәдәниянеке шикелле һәр почмагыннан акылыңны баетып торучы ата-баба нәсихәте белән бизәлгән үз куышы да булмады. Узды гомер. Аның әллә кайчаннан бирле бер ягымлы хатын-кыз сүзе ишеткәне, иркәләнгәне, бер сөйкемле караш күргәне юк. Кемгә кирәк ул? Кемгә кирәк аның ягымсыз, мәгънәсез бу фидакарь тормышы?..

Авылның бөтен юньле кешеләре матур пәрдәләр эленгән әнә шундый җылы, якты өйләрендә бала-чагалары белән мәш килеп, гөрләшеп яшиләр. Буп-буш урамда, салкын яңгыр астында ул гына күшегеп йөри, ул гына берәүнең дә газизе дә, кадерлесе дә түгел...

Башы түнеп, бөтен өметләре кырылып, яңгырлы урамнан барганда машина кычкыртканга сискәнеп китте. Каршысына килеп туктаган «Волга»ның ике күзе акаеп аңа төбәлгән. Машинадан атылып чыккан шофер егет, кабаланып:

— Абый, кайчаннан бирле эзлим! Соңга калдык бит! Ун минуттан самолетыгыз оча! — дип кычкырды.

— Шулаймыни?! — Камил әле шоферга, әле машина алдындагы яңгыр җепләренә аңлар-аңламас карап торды да куанычыннан баскан урынында таптанып көлеп җибәрде. — Ай, рәхмәт, энекәш! Яхшы хәбәрең өчен мең рәхмәт! Шәп булган! Ярый, хуш, энекәш! — диде.

Камил кунак өенең ишегеннән кереп киткәнче шофер егет берни аңлый алмыйча гаҗәпләнеп торды. Камил исә иртәгә Мәдәнияне күрү мөмкинлеге тууга куанып бетә алмый иде.

## X

Ләкин Камилнең иртәне көтәргә йөрәге түзмәде, шул кичне үк Сәетне эзләп китте. Шактый ук соң булуга карамастан, укытучы бу төнге кунакка гаҗәпләнмәде. Ачык чырай белән каршы алып, шундук чәйнек тотып коридорга чыгып китте.

Бүлмәсе кечерәк кенә икән, кухня-мазары да күренмәде. Кайчандыр акшарлаган стена буенда ярыйсы ук таушалган диван-карават, тәрәзә янында бер өстәл, каршы як стенада гади тактадан гына әмәлләгән китап стеллажы. Нибарысы шул гына иде. Әгәр газ камерасыннан исән котылучы бу үзе булса, аның ялгыз калуының да аңлатмасы әзер. Ул озак еллар госпитальләрдә ятканнан соң өенә кайтырга исәп тотканда, аның элекке хатыны күптән бүтән ирдә булган. Сәеттән калган балаларны да яшь ир тәрбияләп үстергән. Сәет кайткан кичне хатыны нишләргә белмичә өзгәләнеп: «Я, инде мин нишлим?! Урыннарны ничек җәйим?» дип елый башлагач, Сәет солдат капчыгын аркасына асып, үзе чыгып киткән.

Сәет табынга килеп утыргач, Камил аны ялан баш, күзлексез хәлендә күреп имәнеп китте. Аның кашлары, керфекләре урынына кызыл җөйләр генә сузылган, целлофан ябыштыргандай ялтырап торган маңгае өстендә биш тиенлек акча кадәрле батып төшкән урыннан миенең мелт-мелт итеп тибүе күренә, бер күзе кыйшайган иде. Төсе-бите кунакка ничек тәэсир итүен хуҗа үзе дә сизә иде.

— Мәктәпкә беренче керүемдә балалар да курыкты. Иләндерү бик кыен булды. Мин аларга ишектән үк шигырь укып керә торган булдым. Шулай иткәч, йөземнең гариплеген күрми башладылар.

Ул, кунагының йөзенә ничектер аеруча бер җылы итеп елмаеп карагын килеш, уң кулы белән үзенә-үзе дирижерлык итеп шигырь укып алды:

Төн утырып шагыйрь шигырь язды,
Ак кәгазьгә тамды яшьләре.
Тышта давыл иде — бертуктаусыз
Күк күкрәде, яшен яшьнәде.

Давылланып көчле җилләр исәр,
Йокыгызны бүлеп кичләрен,
Давыл белән туган таң нурлары
Сөйләр сезгә аның хисләрен.

Чыннан да, хәзер бүлмәдә һәйбәт укылган шигырь генә ишетелә. Укыганда Сәетнең ап-ак тешләре генә күренеп кала. Шул кадәр гарипләнгән тәндә шундый ап-ак тешләрнең исән калуы хәтта ничектер берникадәр гаҗәп тоела иде.

Сөйләшә торгач, Камил автобуста телгә алынганнардан умартачы Минһаҗны табып сөйләшүен әйтте, аны исенә төшерүе өчен Сәеткә рәхмәтен белдерде.

— Менә газ камерасыннан исән чыгучының да кем булуын бик беләсе килә иде, мөмкин булса... — диде.

Камилнең аңа: «Бәлки ул сез үзегездер?» — дип тә әйтәсе килгән иде. Ләкин ничектер уңайсызланып калды.

Хуҗа кеше кунагына күзен тутырып карап торды да сигаретын кабызды. Әмма беренче суырыуында ук төнчыгып, бик озак сулыш ала алмыйча торды.

— Мин сезне юкка борчымадыммы икән?! Ул хакта күп язылды бит инде, — диде.

— Мондыен укыганым юк. Әдәбият коткара кешене, дүрт юллык шигырь!

— Шулай да...

Сәет бүлмәсендә йөренгәләде дә яңадан Камилнең каршысына килеп басты.

— Бәлки Иштирәк урманына барып кыр казларын озатып кайтыргадыр? — диде.

Алар Иштирәктән чыкканда таң алдыннан гына була торган караңгылыкның тәмам куерып җиткән чагы иде. Сәет «Жигули»ен басу юлына боргач, Камилдән гафу үтенгәндәй, юлдан зарланып алды:

— Бу тирәләр күптән түгел генә туңга сөрелде. Бераз селкетәләр инде, — диде.

— Зарар юк, йокы ачылырга яхшы булыр.

Сәет машинасын трактор төрәннәре сырлап узган сикәлтәле юлның әле бер ягына, әле икенче кырыена боргалап ипләп кенә алып барырга тырыша иде. Камил аның белән янәшәдәге йомшак урынга аркасын терәп җайлабрак утырды. Самолетта Казанга очасы урында кара төндә әллә кайдагы урманга кыр казлары күрергә чыгып китү үзе үк мавыктыргыч бер маҗара иде. Шуның өстенә, Сәет үзе табышмакка әверелеп бара. Кем ул? Газ камерасыннан исән чыккан кеше үземе?.. Булса, нигә яшеренә? Сәетнең машинага кергәндә аякларын, билен бөгә алмыйча азаплануын күргәч, Камил моңа тәмам ышанган иде. Дәүләтнең аңа «Жигули»не бушка бирүе дә тикмәгә генә түгелдер, күрәсең.

...Әле уңда, әле сулда авылларның сирәк кенә төнге утлары күренеп кала, машина тәрәзәсеннән сентябрь төненең салкыная башлаган дымлы һавасы, чи туфрак исе керә иде.

Байтак юл алганнан соң Сәет машинасын акрынайта төште.

— Беразга туктап алсак ничек булыр? — диде.

— Нигә, бик тә шәп булыр!

Алар басу уртасыннан сузылып менгән урман полосасы янында туктаганнар иде. Каршы яктагы үрдә кечерәк кенә бер авыл шәүләсе күренде. Шул яктан сабыр гына таң беленеп килә. Иксез-чиксез галәмнең кояш дигән җисеме хәзергә әле үзе кайдадыр чамасыз еракта, Урал тауларының аргы ягында ук иде булса кирәк. Әмма аның зәңгәрсу-шәмәхә нурлары күкнең түбәнге өлешен гаҗәеп төсләргә бизәде, җидегән йолдызның көянтә башын алтын төскә манды, әлеге авылның биегрәк йортлары, силос манаралары әкият дөньясындагы тылсымлы силуэтлар булып калкып чыктылар. Барлык борылышларын түгәрәкләп, бөтен нечкәлекләрен урынына җиткереп сузып кына таң әтәче

аваз салды. Әйтерсең ул авыл өстенә авазлардан үзенең затлы каурыйлары төсле кызыл, зәңгәр, алтынсу тасмалар сузып җибәрде.

Сәетнең еш-еш тын алуыннан, нидер әйтергә омтылып кузгалгалап куюыннан Камил аның дулкынлануын сизеп тора иде. Шигырь укып үлем авызыннан бәреп чыккан нечкә күңелле кеше яңа көннең мондый мәһабәт туу тантанасын ваемсыз каршы алмаска тиеш иде. Шулай булды да. Сәет кунак кешегә иелә төшеп, бер кулы белән үзенә үзе дирижерлык итеп, ярым шыпырт тавыш белән җыр әйтте:

Таң таң ата, Чулпан калка,
Чулпан таңны уята.
Сызылып таңнар аткан чакта
Елата да җырлата.

Сәетнең тавышының ягымлылыгына, җырны һәм шигырьне соклангыч дәрәҗәдә оста һәм күңелләргә үткәреп укуына баш иеп, Камил аңа рәхмәт әйтте.

— Сездә артистлык сәләте дә бар икән!

— Минем кәсебем шул. Әдәбият кануннарын өйрәтү генә җитми бит. Балаларда әдәбиятка, гомумән бөтен шигърияткә мәхәббәт тудырасым килә. Ул аның эчке матурлыгын, эстетик куәтен аңласын!

— Аһ, һәр әдәбият укытучысы үз вазифасын шулай аңласа икән!

— Җыр әйтеп күрсәттем бит әле. Мин аны дәресләрдә мисалга китерәм. «Таң таң ата...» дип кабатлавы, таңны Чулпаннан уяттыруы, «сызылып таңнар атканда» дип өзелеп-өзелеп әйтүе бу бит шигърият, моны шигъри җанлы кеше генә иҗат итә ала!

Камил аның беләкләреннән тотып күзләренә текәлде.

— Мин хәзер ышандым: газ камерасыннан исән чыккан кеше бүтән берәү дә түгел, сез үзегез! Шулаймы?!

Сәет нидер уйланып торды да Камил каршысына килеп башын иде.

— Дөрес. Тик мин аны сезгә белдереп куюыма хәзер бик үкенәм. Шөһрәткә омтылу кебек булып чыга.

— Үзегез үк әйттегез бит: мондый гыйбрәтле хәлләрне белеп үссен яшьләр, дошманга яшьтән үк нәфрәт уянсын!

Сәет кояш чыгышы ягының яктыра баруын искәреп, машинасына таба атлады.

—Казлар кузгалганчырак барып җитсәк...

Урман эченә култык булып уелып кергән тугайдан казлар кайгылдаганы, ниндидер шаулаган тавыш ишетелә иде. Камил баш очында эшләпәсен селкеп куанырга тотынды.

— Килгәннәр! Бар казлар, бар! Аз да түгел.

— Бәхет басты, алайсам!

— Һай, болай булгач!

— Кайтканнар, җанкисәкләрем. Аларга ашарга да аз кала, урын да тараеп бара, шулай да һәммәкие туган ягына ашыга.

Тугайга якынлаша төшкәч, машиналарын калдырдылар да җәяү генә киттеләр. Алда шау-шу көчәя барды. Байтак кына узгач, Сәет инеш буендагы әрәмәлектә туктарга ишарә итте. Алар куак аргына постылар.

Ун-унбиш адым гына алда, шактый киң урман инеше күренеп ята. Аның аргы ягындагы иртәнге аксыл томан эчендә бик күп соры шәүләләр кайнаша иде. Киек казлар караңгы белән үк уянган булсалар кирәк. Алар хәзер яр буенда, ярым сазлыкның түмгәкләре арасында чупланеп йөриләр, сайлыкта җим эзлиләр, инешкә кереп коенып чыгалар да, төзәтенәләр, каурыйларын аралыйлар. Кайберләре, канатларын җәеп, бөтен көчләренә кагыналар да, тыела алмыйча, йөгереп китә-

ләр. Шул ук вакытта бу берничә дистәме, әллә берничә йөзме каз, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, берөзлексез каңгылдыйлар, ара-тирә гайрәтләнеп кычкыргалап та куялар иде.

Сәет, әрәмә арасыннан башын алып, Камилгә ым какты.

— Җыелыш бара монда, я бәрәр кинәшмә! Шунсыз боларның да эшләре пешми, күрәсең.

Бу вакытта ярыйсы ук яктырып килә, томан сыекланa төшкән, киек казлар ачыграк күренәләр иде инде.

Шау-шу тәмам кызып киткән вакытта арадан берсе кинәт кенә «Кыйгак, кыйгак!» дип аваз салды да уртага килеп чыкты. Сәет янәшә яткан Камилгә тагын башы белән ымлады:

— Күрдегезме? Бу инде аларның утаманнары кычкыра! — диде.

Болын өсте, сагайган сыман, берничә сулышка тынып торды, аннары казлар бөтен көтүе белән бер якка йөгерешергә тотындылар.

Сирәк очрый торган бу кадерле күренешнең бер генә детален дә күрмичә калмаска иде. Камил, куакларны аралап, торып басты. «Нигә магнитофон алып килмәдем икән?» дип уфаланды.

Ул да түгел, теге каз муенын суза төшеп йөгереп китте дә «кыйк!» дип һавага күтәрелде.

Сәет куанып:

—Менә сиңа фәрман! — диде.

Алдагы каз артыннан, шап та шоп канатларын кагып, бүтәннәре кузгалды. Тугай өстендә мамыклар, каурыйлар очып йөри башлады.

Камил, гүя казларга үзе дә ияреп китәргә теләгәндәй, дулкынланып һәм әсәрләнеп алар артыннан кызулап урманга таба атлады.

— Гаҗәп, нигә болайга таба очалар, көньякка түгел? — диде.

Сәет, казлардан күзен алмастан, ниндидер шатлык вәгъдә иткән ым белән:

— Сабыр итегез, сабыр! — диде.

Менә казлар ярым түгәрәк ясап култык өстеннән әйләнделәр дә, гүя үзләрен кундырып, тамакларын туйдырып чыгарган шушы игелекле урыннарга рәхмәт әйткәндәй, шат каңгылдашып көньякка юл тоттылар.

— Күрдегезме? Каз булып каз яхшылыкның кадерен белә! Нигә бу аларның рәхмәт әйтеп әйләнүләре булмасын икән?!

Болар өстеннән узганда киек казлар инде өчпочмак булып тезеләләр иде.

Сәет аягүрә басып, иң газиз кешеләрен озаткандай, ягымлылык белән каз көтүенең һәр хәрәкәтен шәрехләп торды:

— Кайсы чыгар икән алга, юлбашчы булып барырга?.. Әһә, әнә, иң зурысы чыкты. Иң тәҗрибәлесе, күрәсең. Тик беравык баргач, аны икенчесе алмаштырыр. Җиңел түгел ул — алдан һава ярып барулар.

Өстән бик күп канатлар сызгырып үтте. Канат җиле озатып калучыларга да килеп бәрелә кебек тоелды.

Сәет, ерагая барган казларга дымлы күзләре белән сокланып карагaн килеш, кул изәргә тотынды:

— Күрегезсәнә, нинди матур булып тезелделәр! Нинди моңлы иттереп тавыш бирәләр! «Хушыгыз, хуш!» диләр инде алар. Ишетәсезме? Киләсе язга чаклы, яңадан әйләнеп кайтканчы! И, табигатьнең иркә балалары!

Авыру укытучының каз көтүеннән күзен ала алмыйча, гыж-гыж сулап, әрәмәлектәге әле бер, әле икенче ачыклыкка килеп чыгуы, аның шушы кыргый гүзәллеккә чын күңелдән, сабыйларча соклана, шатлана белүе Камилне тетрәтеп җибәрде. Бу минутта Сәет үзенең гариплеген дә, ялгызлыгын да — һәммәсен дә оныткан, ул хәзер чын мәгънәсендә бәхетле кеше иде.

Каз көтүе һаман кечерәя барып, ниһаять, күренмәс булды. Сәет,

эшләпәсен кулына тоткан килеш, шул якка караган хәлдә күрсәнеп куйды.

— Нинди еракладан кайталар бит алар, рәхмәт төшкерләре! Ләкин һич адашмыйлар, нәкъ менә шушы тугайның өстенә килеп төшәләр.

— Йолдызлардан чамалыйлар, — диде Камил.

— Ә көн болытлы булса?

— Менә ул ягын әле профессорлар да тәгаен генә ачыклап бетерә алмыйлар. Төрле гипотезалар бар.

Сәет нәрсәгәдер куангандай, селкенгәләп алды:

— Ә мин беләм! Туган ил мәхәббәте алып кайта аларны! Иң ышанычлы компаслары шул! Бөтен җелегенә сеңгән ул аларның!

Укытучы авыру аягын сузып, түмгәк өстенә утырды. Юксынгандай, беравык тынып калган тугай ягына карап торды.

— Тик елдан-ел кими баралар. Күрдегез бит, менә быел ике-өч дистә генә кайттылар. Без малай чагында бу тирәдә инә ташларлык та урын калмас иде... Мин аларны сугыштан кайтканнан бирле ел саен язын каршы алам, көзен менә шулай озатам. Югыйсә, атарга да рөхсәт итмиләр. Нишләп шул кадәр кими болар, ә?

Камил анысын да белә иде, хәтта кирәгеннән артыгын. Әгәр киек кошларга язын-көзен узып барышлый туктап ял итә, туклана торган урыннар калдырмый торган булсалар, тагын берничә елдан Сәеткә авыру аягын мазасызлап, монда килеп йөрисе дә булмаячак.

Ләкин нигә яхшы кешенең күңеленә шом салырга? Сәетнең үз борчуы үзенә җиткән. Камил аның күңеленә җәрәхәт өстәмәскә булды.

— Юллары бик ерак, күбесе кайтканда кырылып бетә. Безгә иң көчлеләре генә кайтып җитә, — диде.

## XI

Кичә Гайнанның атасы узгынчы артыннан кечкенә генә язу җибәргән иде: «Район газетасында бастырган әйберең бик ошады. Менә бит. безнең нәселдән дә язучы килеп чыкты. Бик күрәсем килә. Сөйләшәсе сүзләр дә бар. Иртәгә тәгаен генә барып чыгарга исәп».

Гайнан елмаеп укыды да, умарталыгында эшләрен бетергәннән соң, тау кырыена килә-килә атасын көтә башлады.

Алыптау итәгеннән уза торган олы юлда торбалар, кирпечләр, нинди дер станоклар төягән йөк машиналарының исәбе-хисабы юк. Әмма Гайнан көткән машина күренми иде әле.

Гайнанның күз алдына каударланып сөйләшүчән кызу канлы, гайрәтле атасы килеп басты. Куллары дәү, үзе дә киң сөякле, көчле кеше иде. Бер сабан туенда, кызмачарак баштан куллары белән этеп, әйнең матчасын кузгатканы бар. Ул да түгел, бөтен дөньясын җимерердәй дулаган чагы күз алдына килде. Колхозның иң кыен, иң ярлы чаклары иде. Айлар буе димләп тә әнисен читкә китәргә күндерә алмагач, яман тузынды, тәмам ярсыды, чәй эчкән җиреннән сикереп торып, урындыгын тибеп очырды. Бәлки әнине ышандырырга көче җитмәгәнгәдер? Шуңа гарьләнгәндер? Шул хәтле кызды, хәтта тавышы буылып, теле тотлыга башлады. Бер сүзен әйтте, икенчесен йотты, теленә килмәгәннәрен бармак очларын уа-уа һавадан эзләп, «син теге, син ни!..» дип буталып торды-торды да сүз буасы кинәт ерылып, ташып та китте:

— Бармы акылың, юкмы акылың, син ни, чүпрәк баш! Алла колы, сине ни, әллә теге, сине бит яктыга сөйриләр! Калага, иликтр яктысына, ак калач белән хәлвә ашарга! Ә син? Син нәмәрсә? Ә син һаман шул абзарларың ягына тартасың! Алайса, әнә бар, нит, чәнчелеп кит! Тиресте тугансың, ахрысы, шунда ни үк, аягыңны үк сузарсың! —

Җилтерәтеп элгечтән кожанын йолкып алды, ишек янына җиткәч, тагын кычкырып җибәрде: — Җитте! Туйдым! Синең сүзең белән йөреп моңарчы да күп чиләндем! Моннан соң авылында әнә ни, әнәтерәк, эземне дә күрмәссең!

Шулай да бер тилпенүдә генә бөтенесен дә өзә алмады. Бер атнадан, башын иеп, яңадан кайтып керде. Тик әни кеше аны коры гына тотып, кире борып җибәрде.

Җибәрүен җибәрде дә, шундук, кече якка чыгып, пышык-пышык елый да башлады.

Шул китүдән китте, әйләнеп кайтмады. Алай да эзен югалтмады. Бераздан ул Бакудан үз янына дәшеп хат язды: «Бергә оешыйк, бары — бергә, югы — уртак»,— дигән иде.

Бер сүтелә башласа, гел сүтелә генә икән.

Анасының үз туксаны туксан булып чыкты. Бармады. «Ичмасам, ике аягымның берсен дә кыймылдатмыйм,— диде.— Ата-баба нигезен ташлап балаларым белән кеше ишеге төбенә барыр хәлем юк. Безнең колхоз эшен күрше килеп эшләмәс. Бөлсәң дә үзең, көлсәң дә үзең», — дип кисте дә салды.

Кисеп салуын салды да, күрәсең, ул җенлене өйдән чыгарып җибәргәндәй җиңел генә күңеленнән чыгара алмады. Төнлә уянып киткәч, кече якта шыпырт кына елап ята торган иде.

Гайнан да ул вакытта инде уңны-сулны аңларлык үсеп килүче малай. Әнә энесе Нияз бик үзәккә үтте. Ул төннәрен елап уяна да як-ягын капмаларга, атасын таптырырга тотына:

— Кайда әти? Әле генә менә шушында иде бит, кая китте? — дип өзгәләнә торган иде.

Баштарак аны, әтиең я Бөгелмәгә, я Казанга китте, дип юаттылар. Әмма озак көтеп тә кайтмагач, ул беркемгә дә ышанмый башлады. Капка төбенә чыгып:

— Әтием, җаным-бәгърем, кайт инде!..— дип, атасын үзе чакыра торган булды. Шулай бик моңлы итеп, бу өндәвенә бөтен сабыйлык сагышын, иң тирән моң-зарын салып дәшә дә, узучы кешеләр арасыннан атасы килеп чыкканын көтә башлый. Ул күренмәгәч, еларга җитешеп, әлеге зарын яңадан кабатлый торган иде. Узып баручылар читкә борылып күзләрен сөртәләр, я аркасыннан сөеп, я берәр ягымлы сүз әйтеп узалар...

Ул бичара шулай моңаеп йөрде-йөрде дә Ык суы туңар-туңмас тимераяк шуганда боз астына китеп үлде.

Тормышның бик кыен чаклары булгалады. Әмма аналары бервакытта да «атагыз фәлән дә атагыз төгән» дип тел озайтмады.

Апасы Сәйдә белән Гайнан исәярәк төшкәч, шундый киңәш бирде:

— Безнең арада ниләр генә булып узса да, аның шаукымы сезгә тимәсен. Яратыгыз, якын итегез, ул сезнең атагыз! — диде.

Урыссу ягыннан олы юлда кызыллы-зәңгәрле «Волга» күренде. Ул тәрәзәләрен ялт-йолт уйнатып килде дә кинәт бу якка борылды. Шул инде, шул!

Егет тынычсызлана башлады. Тик шундук үзенең йомшаклыгына ачуы килеп төкереп куйды. Аннары тураеп төшеп, яшел шакмаклы ковбойкасының җиңнәрен тарткаларга, якасын төзәтергә тотынды, чалбарына сырышкан тигәнәкләрне йолкып ыргытты.

Машина тирбәлгәләп килде дә астарак туктады. Әти булган кеше кулын бер селтәү белән «дөп» иттереп машинасының ишеген япты да бер-ике атлагач ук туктап калды. Гайнан атасының машинадан оста шоферларча җиңел чыгып, кулының килешле селтәнүенә кызыгып куйды. Бер генә сулышка үзенең шул машинада выжылдап кына авыл урамыннан узып китүе күз алдына килде. Гайнан үзе дә йөртә белә бит! Менә бер әйләнсәң...

Ләкин хыялланырга вакыт юк, атасы өскә менеп килә иде.

Нигәдер иң элек аның балтырларын кысып кына торган җинел, матур итегенә күзе төште. Аннары изүеннән алтын сары «яшен» сузылып төшкән зәңгәр теннискасы күренде, коңгырт төскә кергән беләгендә, күзне камаштырып, алтын битле матур сәгате ялтырап китте. Аның бөтен торышыннан егетләрчә уңганлык, сөйкемле генә бер пөхтәлек, үз тормышыннан тәм табып, хезмәтенең рәхәтен татып яшәве күренеп тора. Атасының вышка күчерүе күз алдына килүгә Гайнанда горурлык хисе кабынды. «Кайтмыйм авылга! Кайтсам, кесә тулы акча белән «Волга»га утырып кына кайтам!» дип язган иде. Тәки үзенекен иткән, булдырган, молодец!

Атасы аңа беренче булып кул сузды:

— Исәнме, Гайнан! Сау гынамы?

— Саумы... сез!

Харисның күзләре зуррак ачылдылар. «Сез?» Нигә «сез»?.. Тик улының кул җылысы аның бу төксе җавабын шунда ук онытты. Эти кеше үзенеке шикелле үк дәү кулларны каты гына кысып, беравык җибәрмичә торды.

Элекке этиме, бик үзгәргәнме? Унөч-ундүрт яшьлек малае белән көч сынашкан булып көлә-көлә чирәмгә егылган чагыннан нәрсә калган? Үзе егетләрчә булырга тырыша да бит, картлык та әнә үкчәсенә баса башлаган шул: маңгаена җыерчыклар чыккан, чәченә көрән төс кергән. Алары моннан киткәндә юк иде. Шулар янына тагын борын астына кечкенә генә, бармак иңе генә купшы мыек ябыштырып кайткан. Әмма күзләре шул ук, бер дә үзгәрмәгән, нәкъ истә калганча. Шул күзләрдәге үз итүне, якынлыкны, алардагы мөлдерәп торган сагынуны, чиксез куанычны күрүгә Гайнан йомшап китте. Элекке этисе! Шул! Бала чактан ук, әнә шул куллары белән баштан сыйпап, аркадан сөйгән чактан ук күңел түрендә сакланган газиз якынлык, үз итү җылысы хәзер дә сүнмәгән, сүрелмәгән! Юкса, бит ул аның күңелендә ниндидер бер игелексез, каты бәгырьле, җансыз бәндә булып гәүдәләнә башлаган иде. Түгел икән, юк икән! Гайнан куанычыннан үзе дә бала чагына кайтты. Элекке шикелле атасының ике җиңенә барып ябышасы: «Бөтенләйгә бит инде, эти, шулай бит?!» дип дәшәсе килә башлады.

Тик шунда, әллә кайдан гына, капка төбендә аягын бөкләп атасын көтеп утыручы әнисе күз алдына килде дә, Гайнан кинәт кенә тураеп куйды. Икенче сулышта ул инде яңадан салкын канлы булырга тырышучы буй үскән егет иде. Йөзендә дә үзенең һаман да әле балалыктан чыгып бетмәвенә бераз уңайсызланудан башка әллә ни үзгәреш күренми иде.

Нәрсәдән башлап җибәрергә, ни әйтергә белмичә, беравык таптанып тордылар. Эти кеше бер елмаеп куя, икенче сулышта еламсырагандай йөзенә кызганыч бизәкләр чыга иде. Ул куанычыннан һәм дулкынлануыннан әйтер сүзен әйтә алмый, шулай да әйтми дә тормый, башын да чайкый иде:

— Менә син, мм, теге ни... һе! Дәү үскәнсең бит!

Ул бик кыюсыз гына, гүя сабыйлыктан әле генә чыгып килүче бу егетне шушы орынуым белән керләндермәмме икән дигәндәй, сагаеп кына улының иңбашына кагылды. Бик якын итеп, авыз тутырып «улым!» дип дәшәсе иде дә бит... әллә ниләр телен богаулый. Бүтән сүз таба алмагач:

— Ниме соң, Гайнан, утырып торыйкмы? — диде.

— Әйдә соң, утырыйк.

Гайнан атасын карт юкәләр төбендәге йомшак чирәмгә алып китте. Харис, көйрәтеп җибәрәсе килеп, кесәсенә сузылды. Тик шундук

кулын кире алды. Яхшы түгел. Быел гына мәктәп тәмамлаган егет, әле тартмый да торгандыр, юктыр...

Әти кеше, улыннан күзен алмастан, тезләрен кочаклаган килеш, селкенгәләп утыра иде.

— Әллә үзең генәме?

— Әйе. Минһаҗ абзый бүген мунча керә.

Харис авыз эченнән генә «мм» диде. Эшләгәндә тирен сөрткәндәй, мазут карасы сеңгән кулының аркасы белән маңгаен сыпырды. Берәз көттерде дә тагын сорады:

— Шулай ниме инде, школны бетердең дә монда калырга булдыңмы?

Улы аңа җәһәт кенә күз сирпеп алды. Иртәме-соңмы, мондыйрак сорауга барыбер җавап бирмичә булмас иде. Тик атасы, дөнья күргәнрәк кеше булганлыктан, бәлки тизрәк аңлар?

— Әйе, колхозда эшләргә исәп.

— Ничек, гел шушында гына калыргамы?

— Шулай...

Харис телен чартлатты, тагын «мм» дип сузды. Моңа кадәрге тәҗрибәдән чыгып, моннан соң нинди сораулар явачагын Гайнан алдан ук белә иде. Атасы авыз ачканчы, үзе сорап өлгерде:

— Син шул вышкада инде? Әйеме?

— Шунда. Вышкалар күчерәбез. Син бу җирләрдән бал суыртасың, ә без алтын суыртабыз. Карасын!..

Әти кеше көчәнеп кенә көлеп куйган булды.

Гайнан:

— Бик әйбәт, сезгә асты, безгә өсте. Сыярбыз, — диде.

«Өйгә кайтырга итмәгәнсең икән...» — димәкче иде дә вакытында телен тыйды. Анасы «тазарынып кайт!» дип кире борып чыгарган бит. «Тазарыну»ның ни икәнен белмәсә дә, әнигә каршы килеп булмый иде.

Сүз ялганып китмәгәнгә кыенсынып, Гайнан даган аскан урыннарына учак кабызып җибәрде дә атасының каршысына килеп утырды.

— Яшәү кайдарак була инде?

Харис башы белән Ыкның өске ягына таба ымлады.

— Шәһәрдә. Өйрәнелгән: газы, тегесе-монысы, дигәндәй, эштән кайтуына ваннасы. Пожалыста, кер дә чум!

Улы «алай икән»... дигән сыман башын иеп куйды. Ул озак кына итеп әледән-әле атасына карап торгалый иде. Аның күз карашы гына, ирен кырыйларындагы бизәкләр генә түгел, хәтта әнә шулай тезләрен кочаклап атынгалап утыруы да таныш. Бәлки, атасы, анасы белән өчәүләп шушы Ык болыннарында җиләк җыйганда, я бәлкем печән чапканда шулай утырганы булгандыр? Ләкин тагын да якынайта торган нәрсәдер күз алдына килер шикелле тоелганда, борын астына ябышып торган әлеге шыксыз ямаулыкка күзе төшә дә, бөтенесе дә җимерелә иде... Гайнан атасын начар итәсе килми иде. Бәлки аны гаиләсен ташлап китәргә балалар белмәгән берәр зур сәбәп мәҗбүр иткәндер?.. Гаҗәп түгел бит!.. Уен да түгел. Ул ташлап китү аркасында нинди генә кыенлыклар күрмәделәр, ничек кенә кимсенмәделәр! Ул китмәсә, бәлки Нияз да исән булыр иде әле. Шулай булуга карамастан, ул атасына үпкәләми иде. Өйгә генә кайтсын! Өйдә әти булсын! Әмма әнисе? Менә анысы читенрәк. Ай-һай!..

Харис баягы соравын барыбер онытмаган икән.

— Тегендә, дим, укырга нилектән кермәдең? Әләгеп булмадымы?

Егетнең коңгырт төкләр куера башлаган ирен тирәләре сизелер-сизелмәс кенә яктырып алды. Гаҗәп бит, әй! Ничек бу олы кешеләр һәммәсе дә диярлек шул бер чамарак уйлыйлар? Әйтерсең вузга керми кайттыңмы, син инде ниндидер бер кимчелекле, ярым-йорты кеше! Әйтерсең унны тәмамлаган яшьләр барысы да я профессор, я инженер гына булырга тиеш! Ул Казаннан кайтканнан бирле мондый сораулар-

га җавап бирә-бирә туеп беткән иде инде. Әле, җитмәсә, һәркайсы си-не кызгана, кайгыңны уртаклашкан була, җитмәсә, сиңа киңәш бирергә тотына. Фу! Нинди ерунда!

Аның атасына чын күңелдән дөресен генә әйтәсе килде:

— Урысчам сыек булды, — диде.

— Менә сиңа, мә! Электән үк әйбәт укыдың бит!

— Шулай да... Икенче вузга биреп карасам, бик тырышкан булсам, бәлки...

Әти кеше кәмит кенә итеп аскы иренен бүлтәйтте.

— Ничек инде ул? Үзең нитәргә, кирәргә дип бара торып тырыш-ма, имеш!

— Мине кайбер абитуриентларның кылануы...

— Ә? Кемнең, нәрсәнең?

— Аби-тури-ент. Минем шикелле укырга кермәкче булып барган малайлар-кызлар. Бигрәк тә аларның ата-аналарының кыланышы җа-нымны кыйнады. Вузга эләгү өчен нинди генә ялагайлык эшләмиләр, нинди генә кимсенүләргә бармыйлар! Җаннарын саталар, икейөзлелә-нәләр, алдашалар, укытучыларның табаннарын гына үпмиләр. Синең шикелле үк малай инде ул, югыйсә. Сәләте дә, акылы да ташкүлчим генә. Шулай да көчәнә бит! Я инженер, я профессор булмакчы. Ә төп сәбәбе нәрсә? Ничек кенә булса да авылга борылып кайтмасын!

Харис улы әйткәнне ошатмыйча телен чартлатып куйды. Гайнан аны күрмәгәнгә салынды.

— Шунда бөтенесен чамалап карадым. Геолог эшен ялатаммы, юкмы? Белмим. Инженер буласым киләме? Әллә тагы! Ә колхоз эшен яратам. Кайттым да киттем! Менә шул.

— Һм. Ансат кына!

— Әйе! Ул кешеләр миңа авыл җирен мыскыл итәләр кебек тоел-ды. Ә мин авылны яратам. Бабай шикелле. Беләсең бит, безнең бабай туган-үскән җире өчен жанын да кызганмаган! Батыр кеше булган безнең бабай. Намуслы кеше! Аны әле хәзер дә зурлап искә алалар.

Әти кеше утырган урынында кузгалгалап, тамагын кыргалап алды. Каш астыннан улына күз салды. Үскән малай, укыган кеше шикелле сөйләшә. Харис онытып җибәргән икән дә, малай онытмаган! Әллә кайлардан кубарып чыгарды!

— Бабаң шулай! Маладис булган бабаң! Безнең нәсел вообще бир-ми ул, алдан атларга ярата! Ул чагында революцияне җирнең өстендә ясарга кирәк булган, бабаң — анда! Безнең заманнарда менә җирнең астында революция ясалды. Анысында инде менә миңа насыйп булды. Ә сиңа инде тагын да өскәрәк үрмәләргә тиешле!

Атасының мактанырга яратуын Гайнан электән үк белә иде. Ника-дәр читтә йөрсә дә, шактый дәрәҗәгә ирешсә дә, һаман да шул бер-катлы мактанчык булып калуын шәйләп көлемсерәп куйды.

— Кайларга үрмәлисен, ничек үрмәлисен мин каян белим? Өйрәтү-че булмагач!

Аркасында утлы кырмыскалар чабышып йөри кебек тоеп, Харис җилкәләрен селкеткәләп утырды. Шайтан белсен! Малайга җавап та-бу кыенлаша башлаган. Ниһаять, ул сигаретын кабызмыйча булдыра алмады.

— Ну анысына үз башың да кирәк инде, гел җитәкләп йөрергә ди-мәгән! Әнә ни, синең белән укыган теге кем, кыз бала булса да, элак-кән бит әле. Минһаҗ онысы дим.

Гайнан даган астына чыбык-чабык ташлаган булып атасына яны белән борылды.

— Ул куштанизм фәнен яхшы белә.

— Ә, ничек? Нәрсәкәй фәнен? Нигә, син дә укымадыңмыни аны? Ниндидер яңа...

Харис нәрсәнедер исенә төшергәндәй күзен челт-челт йомып торды да кычкырып көлеп җибәрде:

— Әй, малай актыгы! Үртисең бит?!

— Бер дә үртисем килми, дөресе шулай.

Егетнең бу хакта сөйләшәсе килми иде. Ул Зиләйлүкнең туган авылын ташлап китү сәбәбен ничек аңлатсын? Монда чагында «Алтынбикәм, ак чишмәкәем, айлы кичләрең, алсу таңнарың!..» дип тәчеләнеп шигырьләр язып йөрсә дә, аны бик тиз онытуын әйтсенме? Казанга барып эләгүенә беренче очраган машиналы инженерның муенына асылынуы хакында сөйләсенме? Юк! Егет атасына читенсенебрәк карап торды.

— Юк, мин ул сукмактан бара алмыйм шул. Дөрес юлларың булса, пожалыста, күрсәт, әле эш узмаган.

Дагандагы чәйнеге кайнап чыгуга, Гайнан карт юкәләр күләгәсендәге өстәлдә чәй әзерләде. Умарта келәтеннән аш тәлинкәсе тотырып кәрәзле бал алып чыкты, ак икмәк кисеп куйды.

— Әйдә, әти, чәйләп җибәрик, — диде.

Улының үзенә сиздермәскә тырышып, Харис аның бөтен буй-сынына, йөреш-торышына сокланып утырды. Озын бармаклы киң кул. Нәкъ үзе инде. Буйга да озын, аз гына бөкре сыман. Анысы бабасыннан. Көч-куәт билгесе. Хатын-кыз эшенә дә кулы ябышып тора икән. Менә ул ягы инде анасыннан. Тик Харис улын һич тә умартачы итеп күрәсе килми иде. Ул үтә күренмәле яшькелт-сары сыек балны икмәк телеменә ягып капты да башта улының сый-хөрмәтен мактап алды. Аңа улының атасы булып, аның белән күзгә-күз карап утыру бик ошый, бу инде үз өенә кайткан шикелләрәк иде.

— Киңәш дигәннән... Ну инженерга укысаң, я геологка?!

— Аларның нәрсә икәнен белмичә, күңелең тартмыйча торыпмы?

— Һи, напрасно нечкәлисең! Кеше шулай укый бит әле. Диплом гына булсын! Кулыңа шул кәгазь кердеме, барыбер күтәрәләр. Башта инженер, аннары өлкән, аннары главный! Ихлас, мин нәчәлниклар белән сөйләшим, сине атказанган кешенең малае итеп канительсез-нисез алалар!

— Юк, җаным теләмәгән эшкә укый алмыйм, булмый.

— Акчасы күбрәк килә башлагач, җаның тели ул. Менә — мин! Простой тракторчы бит! Ә хәзер — пожалысты! Минем исем кайларга гына таралмаган! Акча да шәп төшә!

Әти кеше белән бәхәсләшү яхшы түгел, ничектер араны бозмыйча гына аңлашырга кирәк иде. Гайнан атасына чәй ясады да баллы тәлинкәне аның алдынарак этәрде.

— Тәмлеме Җидегән балы?

— Бик инде, бик, ни, телеңне йотмалы!

— Минһаҗ абзый белән мин дә җыйдырттым бит аны!

— Күреп торам. Тик бу синең эш түгел, Гайнан, картлар эше бу!

— Нигә алай булсын икән? Картлар белән бергә үлсен дисеңмени умартачылыкны? Киресенчә, тагын да күбрәк булсын бал, теләсә кайчан, теләсә кемнең табынында булсын! Мул булсын!

Харис буш чокырының төбен өскә каратып каплады да кулларын яулыгына сөртте.

— Шулай да моңарчы умартачылыктан инженер да, геолог та, бүтән олы кеше дә чыкканы юк әле!

— Миннән инженер, я юньле геолог чыгамы, юкмы, анысын әле аның шайтан да белми! Ә менә бу эш — минеке! Мин моны яратам, җан рәхәте табам! Әнә ул нечкә билле миллион хезмәт иясе һәммәсе дә минем дусларым. Колхозга агрономнар, механизаторлар кирәкме? Кирәк! Ә умартачы кирәк түгелмени?!

Харис кулын гына селтәде. Ике арадагы аңлашылмаучылыкның һаман тирәнәя баруы Гайнанны да борчый иде. Ул ике арага тагын бер басма салып карады.

— Теге гәзиттә басканны ошаттым диден бит.

— Әйбәт, әйбәт! Мин алай булдыра алмас идем...

— Шул эшкә читтән торып укырга керсәм дип торам. Журналист та булырга, авылдан да аерылмаска исәп.

Харис гаҗәпләнеп кулларын җәеп җибәрде.

— Нигә аңа укып баш ватарга? Мәктәптә өйрәтteләр бит инде язарга! Синең болай да шәп чыга бит?.. Әнә хатын-кыз язсын! Язу-сызу, машинкада тукылдату алар эше.

Соңгы елларда Харис нык куллы, авторитетлы бригадир буларак һәркайчан үз сүзен тыңлатып өлгергән иде. Үз малаен күндерә алмавына мыегы кабара башлады.

— Авыл да авыл дисең, бабай дисең. Бабаңнар заманы күптән узды бит инде. Ул вакыттагы авыл юк хәзер. Хәзерге авыл ярты юлда торып тора. Элекке урыннан купкан, ә калага барып җитмәгән. Нигә сиңа ике арада буталып йөрергә? Олы тормыш, олы юл калада инде ул, шунда башлана!

— Син ул юлны үзең күреп кайткан кеше инде...

— Аны да күрмәгәч, нинди эти соң мин? Калада бит әнә ничек! Сигез сәгатеңне тутырдыңмы, үзеңә-үзең пан! Авылдагы шикелле тәүлек буе чиләнмисең!

— Авылда да шулайга таба бара бит инде.

— Кая ул кала артыннан җиту?! Әнә минем! Кайтып керүемә — ванна, телевизор, тегесе-монысы. Чыгам дисәң — ишек төбендә машина. Утыр да чап!.. Минем исәп калага алу сине, үз яныма. Шундый перспектива барында нигә авылда ятарга?! Дөньяда бит бер генә торып каласың.

Гайнан атасына якынаюдан һаман да өметен өзми иде әле. Ул аның каршысына үк күчеп утырды да, элекке тойгыларын, бергә яшәгән чактагы кадерле истәлекләрен уятасы килеп, аерата үтемле итеп, ягымлы тел белән башлады:

— Авыр тоелса да, үпкәләмә син, эти. Без сине өчәүләп көттек, өч ел көттек. Менә килдең, рәхмәт, сөйләшәбез. Тик син бит менә машиналарың белән телевизорларыңны икешәр-өчәр тапкыр телгә алдың, ә менә әнине бер генә мәртәбә дә искә төшермәдең, хәлен дә сорашмадың!

Эти кеше бурлаттай кызарып яңадан сигаретына ябышты.

— Ә ул мине машинам-нием белән кире борып чыгарды. «Тазарынып кайт минем яныма!» диде. Шайтан белсен, нишләргә тиештер мин!

— Син уйлап карадыңмы, бәлки аның үпкәләргә хакы булгандыр?! Син бит безне иң кыен чакта ташлап киттең.

— Мин сезне Бакуга, диңгез буена, электрлы, газлы фатирга чакырдыммы? Чакырдым! Ә ул үзенең һаман да шул әлеге ни, сыер абзарында, тирес арасында калды!

Усал сүзләр әйтсә дә, Гайнан атасының тел төбендә үкенү сизде. Аның күңелен йомшатып була иде әле.

— Сиңа әни булып та уйлап карыйсы иде. Ул әллә кайларда йөреп өйрәнмәгән, аңа туган яклары бик газиз.

— Шулай булгач, үпкәләргә ничу!

Гайнан, тешләрен кысып булса да, каты әйтмәскә тырышты:

— Үзең беләсең, әби үлеп китте, әни берүзе калды. Бөтен авырлык шул бер аңа өстендә иде бит!

Харис чынаягын улына сузды.

— Мин сезне ач та, ялангач та итмәдем, җибәреп тордым! Кадерен белгән кешегә — җитәрлек!

Егет атасының чынаягын алып тагын чәй агызды. Бал тәлинкәсен аңарак этеп куйды.

— Шулайлыкка шулай, анысы. Тик менә эти булып син безне ничек тәрбияләдең? Мин укыган елларда, әллә кемнәр булырга хыялланың үскәндә миңа берәр киңәш бирдеңме соң син? Хатлар язып, минем хәлемне белешеп, инженер булырга, геолог булырга кызыктырдыңмы?

Харис әллә кайларга караган килеш сигаретын суыра, ара-тирә һәйбәт чалбарыннан, кыска кунычлы матур итегеннән тәмәке көлен өреп төшергәли, әмма җавап таба алмый иде.

Гайнанның «әтиле» дә буласы килә, шул ук вакытта өйгә кайтыр алдыннан эти кичәдә күрәсе килгән кайбер кайгыртучанлык якларын да уятырга тели иде.

— Син югында кече улың боз астына кереп үлде. Ә син менә аны юксынып бер генә сүз дә әйтмәдең. Уйлап кара, әнинең сиңа үпкәләргә хакы юкмыни?

Эти кеше, авырткан җиренә кагылган кебек, йөзен чытып башын иде.

— Чардуган эшләтәм... менә дигән иттерәм, күрерсең. Анысы минем өстә, — диде.

Атасының хөкем алдында утыргандай башын аска июе кызгандырды. Атасын үз иткәнлеген, хәлен аңлавын сиздерәсе килеп, Гайнан тагын да йомшаграк сөйләшә башлады.

— Синең үз эшең бик әйбәт, үз эшең мактаулы, әни үз эшен ярата, аны фермасыннан аерып булмый. Тартма син безне шәһәргә, кузгатма! Апа кияүдә, әни ялгыз, картаеп та килә. Мин аңа булышырга тиешме? Колхозны ташлап, күп акча белән җиңел тормыш эзләп китүчеләр гел чыгып кына тора. Алар өчен дә эшләргә кирәкме? Кирәк! Менә ни өчен мин авылда калам.

Сигарет суыра торгач, Харисның авызы ачытып беткән иде инде. Ул астагы кызыллы-зәңгәрле машинасыннан күзен алмастан нишләргә белмичә аптырап утырды. Аның өенә кайтасы килә иде. Дөрес, аны акчасы өчен яратучылар аз булмады. «Тазарынып кайт!» дип әйтә икән, хатыны дөрес сизенә. Картая төшкәч, Харис җан җылысын, туганлык җылысын юксына башлады, туып-үскән яклар да үзенә тартты. Ләкин ул мал тулы машинасы белән дә, җиңел кала тормышы белән дә берсен дә шаккатыра алмады. Менә хәзер аңа улы Гайнанга элекке шикелле үз итеп «улым» дип дәшәргә, аңлашыйк дияргә, аларга да юл куярга кирәк иде. Ләкин элек хатынының үзеннән акыллырак булуына кимсенгән булса, хәзер Гайнанның ул биргән киңәшләрне берсен-бер калдырмыйча пустәккә чыгаруы аны тагын гарьләндерде. Харис ничек кенә булса да үзен акларга тотынды:

— Авылда калсаң, анысы көчлек эш түгел. Тик сиңа олы юлга чыгарга ярдәм кулы сузасы килгән иде. Только мин биргәннәрне дә күрмәгәнгә салышырга ярамый. Өй сипләргә дә җибәрдем, өс-башыгызга да. Белмим тагы. Мин ни дип, үземнең әтилек бурычымны нитеп, үтәп бардым дип йөрим. Аннары менә, син укырга керсәң-нитсәң дип, үз исеменә особый книжке заводить иттем. Менә ул!

Харис күкрәк кесәсеннән күксел тышлы дәфтәрчек чыгарып Гайнанга сузды. Тик шунда бик зур дорфалык эшләвен төшенде. Гайнанның үпкәсе, ачуы, тагын әллә ниләр аны баскан урынында тораташ итеп калдырды.

Гайнан борылып та карамастан, умарталыгына таба кузгалды. Харис горурлыгын да, кирелеген дә онытып улының артыннан китте.

— Гайнан, улым! Таштан ясалмаган бит мин!..

— Тәки куып җиттем бит! Вәт качкын! Ник әйтмичә киттең?!

Монарчы Шәүрәнең үзен дә, аның иптәшләрен дә болай поезд кузгалып киткәч, вагонга сикереп менеп озата барганнары юк иде әле. Аның йөзендә тыйнак кына кызлар куанычы балкый. Каршысында елмаеп алмаш-тилмәш әле бер аягына, әле икенчесенә авышып торучы колгадай озын егетнең сулышы капкан.

Ләкин Гайнан ачуланмый. Шәүрәнең иптәшләреннән аның кайчан китәсен белгәч тә, иң беренче очраган машинага утырып Ютазыга чабуы турында сөйлисе килә. Тик тамбурда икәүдән-икәү генә калгач, нинди дер башка сүз, кирәгрәк сүз әйтәсе иде бит. Ләкин андый сүз телгә килми. Егет кинәт кенә исенә төшеп кесәсеннән газета чыгарып бирде.

— Сине атна буе эзләдем... Менә монда синең анализларың да басылган, врачлар белешмәсе белән. Бик рәхмәт инде, Шәүрә!

Кызый газетаны әйләндергәләп:

— Әү, әсәем! Ысынняанмы?— ди, үзе егеттән күзен ала алмый.

Егетнең дә шатлыгы эченә сыймый, аның авызы колагына кадәр ерылган иде.

— Беләсеңме нинди мач килде бу! Шап тегеләрнең авызына! Без аларны хәзер!..

Гайнан йодрыгын селкеп күрсәтте. Алар бер-берсенә карашып көлештеләр дә янә сүзсез калдылар.

Поезд исә чаба да чаба, Башкортстан чигенә һаман якынлаша, Гайнан районыннан ераклаша бара, димәк, Гайнанга кайдадыр төшеп калырга, димәк, аларга тиздән аерылышырга туры киләчәк иде.

Ике яшь йөрәк икесе дә бер-берсенә ошауларын, алай гына да түгел, шушы арада ярыйсы ук якынаеп өлгерүләрен сизәләр. Болай гына, берничә генә аерылып китәселәре килми, күңелдәге бу шатлыклы яңа тойгыны ничектер бер-берсенә сиздерергә кирәк иде. Ләкин — ничек?

Шушы җыйнак кына йомры гәүдәне Гайнанның иркәләп кенә кочагына аласы килә башлады. Ләкин берни әйтмәс борын, аз гына сөйләшмичә, тота-каба кочакка алу әдәпсезлек булыр кебек тоелды. Андыйны китапларда да мактамыйлар. Менә кинәт поезд тартылып китүгә, Шәүрә ничектер үзеннән-үзе егетнең кочагына килеп керде. Кызый уңайсызланып: «Ай!» диде. Ләкин егет аны иңнәреннән тотып алган иде инде, Шәүрә тартышып тормады. Караидел урманнарында эшләгәндә җил-яңгырдан алар биек, юан агачларга ышыклана торганнар иде. Бу озын буйлы таза егетнең култык астында да Шәүрәгә бик тыныч һәм рәхәт бит. Иңбашларында ул аның озын бармаклы дәү кулларын сизә, башны аз гына күкрәгенә таба исән, йөрәгенең ашкынып дерелдәве ишетелә. Шәүрә үз-үзенә генә елмаеп куйды.

Гайнан кызның чәченә борынын сузып:

— Синнән гөл исе килә, — диде.

— И, каян икән?..

— Бәлкем, чәчеңнәндер...

Ул да түгел, кызыйның муенында бер урынга егет бармак очын тидерде. Борчылган тавыш белән:

— Шәүрә, Шәүрәкәй! Сине кыйнадылармы әллә? Менә бит көеп чыккан? Әнә нихәтле! — диде.

Шәүрә нигәдер куркынды, муенын җыерып кинәт кенә читкә тайпылды.

— Ай, кытыгымны китерәһең! — дигән булды. Тәрәзәгә борылып, каушаган, кабаланган хәлдә көйгән урынны яшерергә, якасын өскә таба тартырга тотынды.— Ботакка бәрелдем... скважинага барганда.

Кунак кыз көйгән урынны куруне ошатмаган кебек күренде. Гайнан ышаныр-ышанмас кына: «Ә-ә-ә...» дип сузып куйды. Ул әле бик яшь, үсмерләр шикелле бик тә беркатлы, гөнаһсыз егет иде. Кайчакта комсыз иреннәрнең дә тәндә шундый эшәке бизәкләр калдыруы мөмкинлеген башына да китерми иде.

Шәүрә, борчылып, икеләнебрәк берничә мәртәбә ялт та йолт Гайнанга күз атты. Аның нидер сөйлисе, аңлатып бирәсе килә. Ләкин кыюлыгы җитми, шикләнә, әйтә белмичә сүз башлап бу егет белән ике арадагы шундый ялкынлы дуслыкны әрәм итүдән курка иде.

Шулай әйле-шәйле борчылып барган арада, поезд Урыссуга килеп туктады. Шәүрә, егеттән аерыласы килмичә, поезд кузгалганчы кулын җибәрмәде. Гайнан җиргә сикергәч, кара күзләрен мөлдерәтеп:

— Хат яз, яме? — дип пышылдады. — Ярыймы? Язасыңмы?

— Кая?

— Өфегә.

— Хуш, син дә яз!

...Машинадан төшеп калуга, Гайнан йөгерә-атлый фермага юл тотты. Иртән ул уянганда анасы әллә кайчан үзенең терлекләре янына киткән иде инде, өйгә кичсез кайтмаячак, ә Гайнанның кичкә кадәр көтәргә түземлеге җитми, анасын хәзер үк күрәсе килә иде. Дөрес, ул аңа үзенең шундый чибәр, шундый яшь сөйгән яры булуын, аны, артыннан җитеп, республиканың чигенә кадәр озата баруын да сөйләмәс. Монысы егет кеше үзе генә белә торган иң татлы, иң газиз сер булып калыр. Әмма аның бу шатлыгы үзеннән-үзе бәреп чыгарга тора, яшьлегенең шундый бәхетле көннәрендә анасы белән бергә буласы, Шәүрә хакында үзе генә белеп, әмма һич тә тешен агартмыйча, янында гына булса да утырасы килә иде.

Цемент идәнле якты ферма бинасында ике якка тезелеп киткән сөтбикәләр һәркайсы үз эше белән мәшгуль: ашыйлар, күшиләр, чуен тәлинкәләргә йомшак иреннәрен тидереп су эчәләр, мышныйлар, мөгрәп куялар иде. Гайнан аннан чыгып кызыл почмак ишеге төбенә килде. Анда нindидер җыелышмы-утырышмы бара, Дилбәр кычкырып нидер укый иде. Ара-тирә Хельсинки, Биссабон, Бангладеш, Мөҗиб әр Рахман кебек исемнәр ишетелгәли иде. Гайнан агитатор укып бетергәнне тышта гына көтәргә булды. Дилбәр тынганнан соң анасы йомгаклап берничә сүз әйтте:

— Ярар, әйбәт укыдың, монысы өчен рәхмәт. Тик икенче вакыт үз телең белән сөйләсәң тагын да үтемлерәк булыр. Без бит газетаны үзебез дә укый беләбез!

— Онытыла бит, Җәүһәрия апа, истә калдыруы кыен.

— Ә син онытылмаслыгын гына хәтердә калдыр, каймагын гына!..

Тавышыннан чамалаганда Минһаҗның кече кызы Язидә иде шикелле, — агитаторга сорау бирде:

— Мөҗиб әр Рахман демократ кеше иде, халыкның азатлыгы өчен көрәште. Безгә дә килгәне бар. Нишләп үтерделәр икән?

— Хәзергә мин әйткәннән башка берни дә билгеле түгел. Икенче әңгәмәгә тикле, бәлки яңа хәбәрләр алыныр...

Шул ук тавыш икенче соравын да бирде:

— Кипр дигән дәүләттә кызыл кара белән президентлары Макариос кына кул куя икән. Шул дөресме?

— Дөрес!

— Каян беләсең?

— Ә син алай түгеллеген каян беләсең? — диде Дилбәр.

Бөтен бүлмәләре белән шаулашып көлешеп алдылар.

Улын күрүгә, Җәүһәриянең түгәрәк йөзе җанланып, күз читләре нурланып китте.

— Һа! Синең эшләр шәп, ахрысы. Авызлар ничек ерылган!

— Зарланырлык түгел болай.

Улын күптән һәм хәтта зарыгып көткән булса кирәк, янына килеп аның килеш-килбәтенә рәхәтләнеп карап тора башлады.

— Иртәдән бирле күренмисең... Каядыр чыгып чаптың да!

— Бушап булмый... Умарталыкта эш — менә! — Гайнан кулы белән муенын сызып күрсәтте. Анасы, аннан күзен алмастан, мәгънәле генә итеп көлемсерәп торды.

— Шулайдыр... Бу арада мәшәкатьләрең күбәеп китте ич.

Гайнанның кашлары үзеннән-үзе өскә сикерде. Анасы үзенең үтәли күрә торган әнә шул коңгыртлары белән аның бөтен эч серләрен белеп тора кебек тоелды. Һаман да шул ягымлы тыныч тонда:

— Моңынчы умарталыкка бабаң сукмагыннан менелә иде. Хәзер әнә Сөендектән әйләнеп мену модасы кергән икән!

Кара әле син аны! Анасы аның Шәүрәне эзләп күрше авылга баруын гына түгел, Ютазыда булып кайтуын да беләдер, ахрысы. Бу Гайнанда хәтта үзе белән горурлану хисе тудырды. Улың малай гына түгел инде, әни кеше! Ул, тирәнгә җибәрмәсә дә, көлә төшеп бераз серлерәк итеп әйтеп куйды:

— Төрле чаклар була инде ул.

Җәүһәрия, улының аркасына йомшак кына кагып, башын селекте.

— Ярар, шулайдыр инде, була торгандыр... Тик арттырып җибәрмә. Чамалап!.. Әнә үзеңне дөнья бетереп эзләп йөриләр, шуны гына әйтәм.

— Кем эзли?

— Кем эзләсен егет кешене, кызлардыр инде! — Ак халатын салып, шәмәхә фуфайкасын кия-кия, кызыл почмактан Язидә чыгып килә икән. Алар Ямьле Тугай урта мәктәбендә Гайнан белән бер елларда-рак укыганнар иде. Язидә мәктәпне ике ел алдан тәмамлап, әле генә алган аттестаты белән туп-туры кияү кочагына барып керде. Шуннан бирле фермада Җәүһәрия кулы астында эшләгәнлектән, алар якынаеп беткәннәр, туганнар кебек дус яшиләр иде. Гайнанга:

— Әйдә, алып кайтыйммы үзеңне? — диде.

Җәүһәриянең эшләре бетмәгән икән. Язидә белән Гайнан кайта торырга булдылар.

Яшьлегеңне, матурлыгыңны бөтен ферма халкына күрсәтеп егет кеше белән менә шулай янәшә атлау Язидәнең күңеленә хуш килде. Аларның буйлары да бер чама, икесе дә чандыр, зифа буйлы, яшь аермасы да әллә ни түгел иде. Очраган бер кеше: «Карасана, болар бик тә пар килгәннәр икән ләбаса!» дип әйтәчәк. Һәрхәлдә, шулай дип уйлау Язидәгә бик ошый иде. Быел яз көне өйләнешүләренә бер ел тулар-тулмас ире үлеп, Язидә яшь-яшь килеш тол калды. Вакытында рәхәтен күреп бетермәгән кыз чагына яңадан кайтып, Язидә яшьләр эшенә яңадан катнаша башлады. Аны комсомол комитетына сайладылар, аңа төрле мәдәният эшләренә ярдәм итүне тапшырдылар.

Авыл белән ике арада аларны истә-оста югында башкорт ягыннан килгән ястык кадәр генә соры болыт куып җитте. Сүзгә мавыгып күрми дә калдылар, эре, салкын яңгыр коя да башлады. Язидә, чыркылдап көлеп сикергәли торгач, болонья плащын баш өстенә күтәрде.

— Чыланасың бит, кил әйдә! — диде, Гайнанны плащы астына алды. Ямьле Тугай мәктәбенә бара-кайта укып йөргәндә дә вакытына карап шулай бер плащ, я бер зонтик астына ышыкланган чаклар булгалый иде. Язидә Гайнанга дәрес хәзерләргә дә булышкалады. Элек ул аңа энесе шикеллерәк иде, ә хәзер менә нигәдер азрак тартына...

Күптән очрашмаган кешедәй, Гайнан күршесенең йөзенә, килеш-килбәтенә күз салгалап барды. Гаҗәпләнүенә каршы, ул хәзер хатын-кызга сыныйрак, кызыксыныбрак карый башлаган иде. Кайсы чибәррәк, кайсы сөйкемлерәк... Чия төсле плащ астында Язидәнең йөзе алсу-ак булып күренә. Ә үзе нәкъ унынчыда чактагыдай нечкә билле иде. Гайнанга бу бик ошады. «Язидә үзен саклый белә, бүтән савымчы кызлар шикелле җылы сөтне күп эчсә, ул да симереп киткән булыр иде», — дип уйлап алды.

— Бу плащың сиңа бик төс килә икән, битеңне алсу иттерә, — диде.

— һа-һа! Торып-торып торҗагун. Әле генә күрдеңмени?! Мин инде аны өч елдан бирле таскайтлыйм!

— Китсәнә аннан! Әй, кызлар матурлана белә инде ул. Иртәнге сөт белән юынгач та бит шулай ап-ак та, алсу да була диләр түгелме соң?

Плащның Язидә кулындагы итәге кинәт ычкынып китте. Язидә «ай!» дип аны эләктереп алды да күз ачып йомганчы бөгәрләп култык астына кыстырды. Яңгыр туктап та өлгергән икән бит. Язидәнең озынча ябык йөзендә гаҗәпләнү, үпкәләү бизәкләре уйнап алды.

— Әй син, алай бик кызыксынгач, сөт белән үзең юынып кара, үзең! Егетләрнең дә матур буласы киләдер бит?

Алар авыл башына кайтып җиткәннәр иде.

— Ярый, хуш! — диде Язидә, күтәрелеп карамыйча, сүлпән генә атлап түбәнге урамга төшеп китте.

Язидәнең үпкәләве Гайнанның тынычлыгын бозды. Ул аның артыннан бармакчы булып омтылды. Тик аны үчекләргә теләмәвен, болай, шаяртып кына әйтүен ничек аңлатыр?.. Нигә бу акыл дигән нәрсә арттан гына ияреп йөри икән? Нигә бу сүзләр Язидә белән сөйләшкәндә теленә килгән, нигә Дилбәр белән әрепләшкәндә түгел?!.

Урам башында күңелсезләнеп торганда, тырылдаган, шытырдаган шыксыз тавыш белән бөтен якын-тирәнең, кош-кортның котын алып, түбәнге урамнан «мотай» атылып чыкты. Тракторчы Салихҗан Турай икән. Әллә фамилиясе, әллә кушаматы, аны авылда шулай атыйлар иде. Ул Гайнан янына килеп шып туктады да, тамагына нидер тыгылгандай, куллары белән болын ягына күрсәтеп нидер гыжылдады, кызды, ярсыды. Исенә төшеп тамак астындагы тишекле көмеш төймәсен бармагы белән баскач кына кеше аңларлык сүзләр чыга башлады.

— Әй, сез, комсомол! Сез монда гүләйт итеп йөрисез, ә тегендә анә Алтынбикәне харап итәләр!

Гайнан җилтерәп Турайның каршысына барып басты.

— Кем харап итә, кем? Ничек харап итә?

— Ничек булсын? Җимеш куакларын бульдозер белән актарып ташлыйлар да сөреп яталар!

— Үзең күрдеңме?

Сүзенә ышанмаганга ачуы килеп, Салихҗан күзләрен акайтып карады.

— Рас әйтәләр, значит, күргән! Интересно, күрмәгән булсам, нигә баядан бирле куян куган дай синең артыңнан чабып йөрим икән мин?!

— Нигә мине эзлисең, Сабирҗан абый, нигә Идрис абыйны түгел?

— Нигә, нигә? Әле җитмәсә, сорап тора! Чурмантай белән Идрис өйдә юк. Ә син комсомол исеменнән бу турыларда гәзиткә язып чыккан кеше! Онытттыңмыни? Менә карап карыйк, кәгазьдә генәме синең егетлек, әллә в самом деле батыр егетме син?!

Авылда председатель кушкан эшне туктатырга берәүнең дә көче җитми иде. Уйлана торгач, комсомол секретаре һәм агроном Фәйрүзә белән киңәшеп карарга булдылар.

Турай курткасының биленә ябышып, урамдагы сикәлтә саен очына-сикерә, Гайнан кайчак явызлыкның яхшылыкка әверелүе мөмкин

булуы хакында уйланып барды. Менә хәзер аны үзенең «мотаенда» әллә үлемгә, әллә идарәгә очыртып баручы шушы гыжылдык бугазлы кеше яшь егет чагында бик башсыз бәндә булган. Әлеге колхоз бакчасының даны бөтен тирә-якка таралып уңышны шәп биргән елы икән. Минһаҗ абзыйның күз карасыдай күреп алты-җиде ел буе тәрбияләп үстергән, берсеннән-берсе затлы өч төрле алма бирә торган тәҗрибә алмагачы булган. Алмалары пешеп, тәҗрибәнең нәтиҗәсен билгеләргә җыенган көннәрдә генә шул алмагачның өч зур ботагын каерып төшергәннәр дә алмаларын берсен-бер калдырмыйча талап киткәннәр. Ләкин бу явызның кем булуын ул чакта һичкем белмәгән. Минһаҗ абзый моны бик авыр кичергән, хәтта авырган. Түзә алмаган, бер зур җыелышта бөтен халык алдында шул кешене күз яше белән каргаган. «Шул алмагачныкы шикелле булып ул явызның кулы-аягы каерылып чыксачы!» дигән.

Сугыш башланган ел көзендә үк бугазы авыр яраланып, гыж-гыш килеп шушы Турай кайтып төшмәсенме? Бөтен авыл халкы «аһ» иткән. Турай урамга чыгарга кыенсынып өч атна өендә яткан, әмма нишләсен, чыкмыйча әмәле юк. Яшәргә кирәк ләбаса. Минһаҗ аны сөйләшмичә өч тапкыр кире борып җибәргән. Дүртенче килүендә нәрсәдер әйттереп ант иттергән. Менә шуннан бирле Турай табигатьнең иң-иң якын дусты, яклаучысы, ә Минһаҗ аның каршындагы изге, иң дәрәҗәле кеше иде.

Фәйрүзә шакмаклап сызылган ашъяулык кадәр зур кәгазьгә, кроссворд чишкәндәгедәй, бер язып, тагын бозып исәпсез-сансыз цифрлар утыртмакта иде. Болар нигә килүләрен әйткәч, карандашын җайлап кына сузып салды да башын күтәрде. Ул бик тыныч иде.

— Председательнең профессор кул куйган пичәтле кәгазе бар, — диде.

— Нинди кәгазь?

— «Тугай болынын әрәмә-чытырман шикелле чүп-чар баскан. Аның хуҗалыкка файдасы юк», дигән.

Турай мазутка буялган кара бармагы белән ак төймәсенә басып өстәлгә иелде.

— Әйт әле, пажалыста, кем хуҗа безнең җиргә? Безнең авылга аяк басмаган әллә кайдагы профессормы, әллә без үзебезме?

Агроном карандашын аркылыга борып куйды. Ул узган ел гына институт тәмамлап килгән тыныч кына холыклы басынкы бер кыз иде. Холкын-фигылен ошатып, быел яз яшьләр аны комсомол секретаре итеп сайладылар. Фәйрүзә боларның үзләренә сорау бирде:

— Профессорга каршы мин нишли алам?

Турай дөп иттереп өстәлгә китереп сукты.

— Син нәрсә, понимаешь! Совет вузында сине табигатьнең колонизаторы булырга өйрәттеләрмени?

Монысы хәтта Фәйрүзәне дә урыныннан кузгатты. Ул рәнҗеп стенага таба чигенде.

— Сез бигрәк инде, Салихҗан абый, әлләниләр әйтәсез! Нишләгән мин ул кадәр?

— Нишләмәгән шул менә!

— Әйтеп сөйләшегез!

— Сезнең эшеләрне шулай димичә кем дисен?! Чын агроном булсаң, якла син табигатьне, якла син болын-кырларны! Хет чуртның үзеннән сакла!

Агроном янадан кәгазенә иелде, ләкин борчылып тагын турайды.

— Ничек тыңлатыйм? Булмый бит! Беләсез ич үзегез... Мин кем аңарга?

Тугайның бозылып өлгермәгән өлешен генә булса да сөрми торырга күндермәкче булып, агроном белән Турай болынга төшеп киттеләр.

Гайнан редакциягә ашыкты. Дәрҗия белән бергәләп депутатка мөрәҗәгать итүдән башка чара калмаган иде.

Алар шалтыратканда Камил Дусай, бәхеткә каршы, Казанда туры килде. Күрәсең, ул хәерле сәгатьтә керешкәндер. Телеграмма икенче көнне иртүк килеп төште. Авыл хуҗалыгы министры, Алтынбикә тугаеның киләчәк язмышы фән оешмалары белән киңәшеп хәл ителгәнче, аны бозуны туктатырга әмер иткән иде.

## XIII

Шәүрәне озатып кайтканнан соң, Гайнан аерата дәртле бер тормыш белән яши башлады. Кая гына бармасын, ниләр генә эшләмәсен, Урал таулары арасыннан килеп чыккан әлеге кара күзле, йомры гәүдәле башкорт чибәре һәр даим илһам фәрештәсе булып аның бөтен тормышын нурландырып, дәрт биреп куйды. Дәрҗия киңәше белән Казан университетының журналистика факультетына документлар әзерләп җибәрде, кичләрен үз бакчаларында күз бәйләнгәнче бәрәңге казыды.

Җәүһәрия улының бу араларда шулай җилкенеп эшләвен, сызгыргалап, авыз эченнән җырлап кына йөрүен көлемсерәп күзәтә иде.

— Нәмәкәй булды сиңа? Әллә берәр тиле корт чактымы үзеңне? — диде.

Кичләрен клубта Гайнанның авызын җыя алмыйча гел көлемсерәп йөрүен, һавалы гына кыяфәттә кызларның әле берсен, әле икенчесен биергә дәшүен дә яшьләр кара күзле кызның сихеренә юрадылар. Авыл кызларының берсен дә санга сукмыйча, әллә кайдагы башкорт кызына һушы китеп йөрүеннән көнләшәләр, ара-тирә үпкәләүләрен сиздереп каты гына тешләп тә алгалыйлар иде. Гайнан исә андыйларны колак очына да элмәде. Чөнки, аныңча, Дилбәр дә, бүтәннәре дә мондый чын, кайнар мәхәббәтне татып карарга сәләтле түгел, андый чиксез-чамасыз зур бәхет Гайнан белән Шәүрәгә генә насыйп иде.

Байтак вакыт шулай исәрләнеп йөргәннән соң, ул кич утырып Шәүрәгә хат язды. Ул хатның бер генә юлы да кешегә аңларлык булып чыкмаган, бары тик гашыйклар гына укый алырлык мәхәббәт сүзләре, ялкынлы җырлар, йөгәнсез хыяллар белән мөлдерәмә тулган иде.

Сабырсызланып көтә торгач, Шәүрәдән дә җавап килде. Тора-бара Шәүрә белән хат алышу Гайнанның иң куанычлы бер тормыш бизәгенә әверелде. Хат алган көннәрдә ул шатлыгын кая куярга белмичә өендә дә, иптәшләре арасында да өзлексез көлә-шаяра, фермага барып анасы янында әллә никадәр эш майтарып ташлый иде.

Әмма хатлар Гайнан көткәнчә үнбиш көн-өч атна саен килеп тормый шул, андый чакларда аның тормыш күген караңгы болытлар каплый иде.

Шундый көннәрнең берендә ул тагын бер озын хат язды.

«... Син киткәндә урманнар, куаклар гел яшел иде. Хәзер инде алар яшелен салып, гел алтын парчадан гына киенделәр. Син колач салып йөзгән Ык суы салкынайды, син йөргән болын сукмакларына кызгылтсары яфраклар түшәлде. Ә синнән хат һаман юк та юк. Ник җавап бирмисең? Минем яшьлек тойгыларымны гамьсезлек, ваемсызлык күмеп калдырыр дип уйламый торгансыңдыр бит? Әй, каракаш, белеп тор: әгәр дә бу хат сиңа барып җиткәнче берәр җирдә озаграк ятса, аңа үзеннән-үзе ут кабыныр да ул янып көл булыр. Әгәр син шулай озак хат язмый торсаң, минем йөрәгем көтәр-көтәр дә бер заман түзә алмыйча шартлап ярылыр...»

Менә ул хат киткәнгә дә байтак вакыт узды. Гайнан хат килер вакытны башта атналап, аннан соң көнләп, тора-бара сәгатьләп саный

башлады. Ә хат дигәнең һаман да юк иде. Нигә килми? Язган булса, нигә ул кадәр озак йөри? Әллә үпкәләдеме? Әллә, югыйсә, күңеле сүрелдеме?

Менә бүген Гайнан умарталыкта Минһаҗ абзыйсы янында эшләп кайтты да кичкә таба Иштирәккә почта бүлегенә китте.

Эш вакыты бетеп килә, җыештыручы апа бер кырыйдан идән юарга тотынган иде. Гайнан бер өстәлгә барып үзенә «хат юкмы?» дип сорады. Алдындагы пакетларга шак та шок пичәт сугып утыручы кызый моңа күтәрелеп кенә карады да башын селекте. Гайнан, һаман да өметен өзәсе килмичә:

— Кичке почта килгәндер бит инде? — диде.

Теге кызый, эшен дәвам иттереп, «әйе» дигән сыман башын иде.

— Анда да юк, әйе?

Кызый тагын башын селекте. Аның шул кадәр ваемсыз, шул кадәр таш йөрәк булуын Гайнан аңламады. Аның каршысында япь-яшь егет йөрәк ялкынын баса алмаенча, нишләргә белмәенчә сөйгән ярыннан хат көтеп тора бит, хат көтә! Аның йөрәк бәгырьләрендә нинди түземсезлек, нинди сагыну, ялкын кайнавын аз гына да сизмиләрме икәнни?! Андый хатларны кая ул тегендә-монда аунату, кая ул икенче көндә калдыру — андый хат килеп төшүе белән, хат ташучылар, авыруга кислород мендәре илткәндәй, ашыгыч ярдәм машинасы белән шундук илтеп тапшырырга тиешләр иде!..

Почта кызы, егетнең һаман да аның тирәсендә селкенгәләвен күреп, сәерсенебрәк карап торды да:

— Юк бит, апаем! [1] Юк! Бәлки, язмагандыр да әле! — диде.

Егет, аңа җавап бирмәстән, болдырга чыгып китте. Биредән Башкорт иленең тау буйлары, ерактагы зәңгәр урманнары яхшы күренә иде. Тәлләрдән төшми җырлана торган Дим буе да, Ашказар да, Таштугай да — һәммәсе дә әнә шул тылсымлы якта иде. Шәүрә дә... Егет кинәт кенә борылып яңадан керде. Теге кызый өстен-башын төзәткәләп чыгып бара иде. Гайнан иң кырыйдагы кечкенә тәрәзәгә килеп, яшел яулыгы өстеннән башына парлы телефон колакчыны элгән бер хатынга дәште:

— Апа, миңа Башкортстанны алып бирә алмассызмы, ә?

Әлеге хатын авызы каршысына эленгән кара көпшәгә «әйе», «була», «хәзер», «сөйләшегез!» дигән сыман, кыска-кыска сүзләр әйтте, кемнәрнедер бер-берсе белән тоташтырды, кемнәргәдер «юк», «җавап бирми» диде. Бер тынып торган арада Гайнанга да күзен сирпеп алды. Нәрсәдер ачыкларга теләгән сыман, бераздан тагын карап куйды да:

— Ай-һай, булырмы икән, энем? — диде.

— Бәлки, тырышып карарсыз әле, апа, ә?..

— Белмим шул, белмим генә шул...

Тагын сөзеп кенә карап алды. Шулай да сөйләшүчеләрне тоташтыра торгач, Башкортстанны да дәшәргә, бик тыныч, әмма талчыккан тавышы белән иксез-чиксез мәртәбә бер үк сүзне кабатларга тотынды:

— Ә-әллү! Ә-әллү!.. Нарыштау, Нарыштау!.. [2]

Үзенең үтенечен тыңлап, шундый мәшәкатьле эшкә тотынган бу мәрхәмәтле апага Гайнанның ихтирамы торган саен арта барды. Ул аның кулларының бик килешле бөгелеп-сыгылып килүен, ара-тирә кайбер кешеләргә нидер әйтеп, әдәпле генә елмаеп, башын иеп, я булмаса, күз төбендәге зәңгәрсу күләгәләрен сыпырып куюларын рәхәтләнеп карап торды. Әмма ул Гайнанга бик арыгандыр кебек күренде. Чыннан да, ничә сәгатьләр буе бер дә кузгалмастан, һаман да шулай

---

[1] Ык буенда кечкенәләргә иркәләп «апаем» диләр. Почта кызы авызыннан исә бу сүз егет кешене малайсыту булып ишетелде.

[2] Нарыштау — Октябрьский тирәсе.

чарт та чорт тоташтырып кара әле син! Кайбер дорфа бәндәләрнең, һичбер сәбәпсез җикеренеп:

— «Нәрсә йоклап утырасыз анда?! Даваегыз тизрәк! — дип урынсызга җикеренүләренә түз әле син! Аның бармаклары сызлыйдыр, өендә тузгак башлы бер-ике кечкенәсе көтә торгандыр. Шулай да боларның берсен дә сиздермичә, ташка тамучы тамчы тырышлыгы белән, бераз гына көйли төшеп, ул һаман үзенеке итә, һаман бер сүзне кабатлый иде:

— Ә-әллү! Ә-әллү!

Шулай хәтсез вакыт дәшә торгач, кинәт аның йөзе яктырып китте, тавышы яңгырабрак, күңеллерәк ишетелә башлады.

— Нарыштау! Киньябикәме бу? Киньябикә җаныем! Өфенне генә бирче әле! Хәзер үк! Бер чибәр егетнең Өфегә зерә дә важный сүзе бар! Буламы? Ай, рәхмәт!

Телефонистка башы белән генә егеткә стена буендагы будкага керергә ымлады. Трубканы кулына алуга, бик еракта, әллә кайлардагы караңгылыкта телефонның аргы башы «челт» итеп бүтән чыбыкка тоташкан кебек булды, аннары икенчесенә, өченчесенә. Гайнан үзен торган саен Шәүрәгә якыная баргандай хис итә. Менә аның ялкынлы хисе, кайнар теләге электр куәтенә кушылып тын аккан Ык суын кичте, республика чиген дә ашты, Кавказның мәшһүр Бииштавына охшап тау култыгында җәелеп яткан Нарыштауны да үтте. Коеп яуган яңгыр астында калын урманнарны, сары төс баскан Дим буйларын, эрелеваклы авылларны узды. Аның үзеннән-үзе кабынып китәрдәй ялкынлы мәхәббәте бөтенесен аякка бастыра, телефон юлындагы барлык аппаратларны хәрәкәткә китерә кебек иде.

Бу минутта әнә шушы апа кебек телефонисткалар Гайнан каршында иң зур мактауга лаеклы, иң хөрмәтле кешеләр иде. Нинди генә бөек эшләрнең гамәлгә ашуына ярдәм итәләр, ераклардагы кешеләрне берберсе белән тоташтырып, ничәмә-ничә сөйгән ярларны кавыштырып, үзләре дә уйламастан никадәр изгелек эшлиләр, никадәр кешене бәхетле итәләр бит алар!

Телефон басынкы гына гүли, нәрсәдер шытырдап куя. Инде шәт ерак та калмагандыр. Менә, менә Өфенең үзенә, андагы Гайнан күргән биш катлы мәһабәт олы йортка барып керер. Зур залдагы сизгер аппаратлар үзеннән-үзе хәрәкәткә килеп, нечкә чыбыклар бер-берсенә тоташыр да техникумда звонок челтерәр. Аннары инде — Шәүрә!..

Тик шунда телефонистка Гайнанга кулын әметсез селтәп будкадан чыгарга әйтте. Ул арыган кыяфәттә урындык аркасына сөялгән иде.

— Бетте, энем-җаным, харап иттеләр! Барып җиттек дигәндә генә кайсысыдыр өзде дә ташлады,— диде.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Тик телефонистка каршындагы панельдә генә ишетелер-ишетелмәс челдәп берсе артыннан берсе ак төймәләр ачыла иде. Телефонистка графиннан агызып су эчте, әллә кайдан гына кечкенә яулык чыгарып маңгаен, авыз кырыйларын сөртте. Шулай бер генә сулыш тын алды да искиткеч сабырлык һәм үҗәтлек белән яңадан Өфене дәшәргә тотынды.

— Ә-ллү! Ә-әллү! Нарыштау, Нарыштау!..

Шунда телефонистка йөзе кинәт балкып көлеп куйды. Гайнанга тагын кул изәде.

— Тизрәк, энем-җаным, сөйләш!

Егет, дулкынлануын басарга тырышып, әдәпле генә тел белән Шәүрәне дәшүләрен үтенде. Телефонның теге башында беразга гына тынып калдылар. Әллә Шәүрәнең дөп-дөп басып коридордан килгәне ишетелә, әллә Гайнанның йөрәге шулай тибә... Әмма телефонда Шәүрә түгел, ир кеше тавышы ишетелде.

— Нужәли шуны да белмисең? Эстудиннәр бит хәзер Урал аръягында кәртуф чүпли! — диде ул.

Түземсезлек белән көткән хат кыш булып кар яткач кына килеп житте. Ул нигәдер шактый ук калын, житмәсә, аны заказной итеп өй адресына җибәргәннәр иде. Конверт эченнән Шәүрәнең нindидер очучы офицер белән янәшә утырып елмаеп төшкән рәсеме килеп чыгуга, Гайнан эсселе-суыклы булып китте. Нәрсә бу? Нинди табышмак? Берәрсенең мыскыл итүеме? Юк, мыскыллап язмаганнар иде. Хатның ахырына «Шәүрәнең дус кызы» дип кул куйган, үзенчә юкка ышанып вакытын әрәм итмәсен дип, Гайнанны кызганып язган. Шәүрә менә шушы очучы егеткә кияүгә чыга икән, алар озакламыйча, туй итеп, нинди чит илгә бөтенләй торырга китәчәкләр. Ә Шәүрәнең үзенең Гайнанга хат язарга кулы бармаган, чөнки ул аны кызгана икән, дус кызына әйбәт егет дип мактаган. Тик Шәүрә теләгәнчә тормыш итү өчен әйбәт булу гына житми икән.

Аның иң газиз тойгыларын оятсыз рәвештә мыскыл итәләр. Гомерендә икенче мәртәбә! Башта мәче тычкан белән уйнагандай уйныйлар, шаяралар да соңыннан иһаһайлап көләләр. Шәүрәнең аны тиз генә арада икенче бер кешегә алыштыруы шул кадәр рәнҗетте, Гайнан рәсемне вак кисәкләргә турап мичкә ыргытты.

Мондый кайгыны кичерү ансат түгел иде. Гайнанның беркетә дә кулы бармый башлады. Көннәрен эшкә мавыгып уздырса да, кичләрен үзен кая куярга белми иде. Университеттан җибәргән дәресләрне укый башлый да берни дә аңлый алмыйча кире куя, телевизор карарга тотына да кашларын җимереп икенче бүлмәгә чыгып китә. Элек ни яратып тыңлаган башкорт радиосы сөйли башласа, кәефе кырыла да «шарт» итеп радиоалгычны сүндереп куя иде.

Шундый көннәрнең берсендә колхоз уңыш бәйрәме уздырды. Колхозда яшьләр елдан-ел азая барганлыктан, алар күз өстендә каш шикелле, гел игътибар үзәгендә булдылар. Җыелыштан соң колхоз председателе яшьләрне клубта бер бүлмәгә җыеп сыйларга уйлады.

Өстәл тулы ризык та шешәләр. Ни генә җаның тели! Ите, бәлеше, пәрәмәч, бавырсаклары! Иң түрдә Зиләйлүк утыра — бик важный булып, самавар төсле көмеш күлмәге белән ялтырап. Кунак булып кайткан бит. Каникулга. Аннары Язидә, Дилбәр, агроном Фәйрүзә Җиденче Рафаэль, Конфуций, Гайшә-малайша, Фәрид абый, председатель хатыны Тәнзилә, тагын бүтәннәр.

Иң башта Чурмантаев сүз әйтте:

— Беренче тостны сезнең исәнлеккә күтәрик, туганнар, «Кызыл маяк» колхозының яшь кызлары, яшь егетләре исәнлегенә! Сез төп терәк диясе килә. Сез сөйрәп чыктыгыз колхозны алдынгылар сафына! Дан сезгә, и рәхмәт, данке [1], спасибо, и все!..

Аннары Фәсхетдин абзый әйтте:

— «Кызыл маяк» туфрагыннан күтәрелеп чыккан иң уңган, иң мактаулы студентлар исәнлегенә! — диде.

Гайнан, уены-чыны белән:

— Иң элек шәп кияүгә, машиналы кияүгә чыккан студенткага дип тә өстик! — диде.

Көлештеләр дә эчеп тә җибәрделәр. Зиләйлүк күзенең агы белән Гайнанны чәнчеп алды. Чәнечсә тагын! Нәрсә ул хәзер аңа! Тфү! Ан-

[1] Данке — рәхмәт (немецчә)

дыйларның поты бер тиен! Һе, машина, имеш! Бүген тели икән, бүген машиналы була Гайнан!..

Ул моңарчы бөтенләй эчмичә, стаканына иренен тидерер-тидермәс хәйләләп кенә утырган иде. Бу юлы хәйләсен тоттылар.

— Юк, энекәш, хәрәмләмә! Давай, төбен күрсәт! — диделәр. Гайнанның мондыйны әле беренче генә эчүе булганга, ул кылкынды, күзләреннән яшьләр атылып чыкты. Зиләйлүк рәхәтләнеп көләргә тотынды:

— И олан, әле син һаман да шулай гөнаһсыз сабыймыни соң?

Аннары рюмкасының нечкә биленнән бармак очлары белән генә чеметеп алып, Ризван белән чәңгелдәтеп чәкеште дә эчеп тә җибәрде. Шундук битенә алсулык йөгерде, күзләре елтырый башлады. Озак та үтмәде, Зиләйлүк бөтенесен үз авызына каратты:

— Их, сезне, авыл дисәң авыл! — диде, көрсенеп куйды. — Чын культурага бик ерак шул әле. Сез менә, Тәнзилә ханым, үзегез врач, ә рюмка тотканда чәнти бармагыгызны тырпайтып куясыз. Хәзер алай ярамый ни в коем случае! Искерде инде ул. Хәзер менә ничек, биленнән генә тотасы! — Зиләйлүк рюмканы ничек тотасын күрсәтте.— Менә сез машина, фәлән дисез. Нәрсә ул машина? Фи! Подумаешь!

Зиләйлүк бер иптәш кызының, Индонезиягә чит ил халкы теленнән практикага баргач, министр малаена кияүгә чыгуын сөйләп китте:

— Менә кайда ул экзотика! Менә кайда ул байлык, затлы, зиннәтле киемнәр! Океан, ап-ак яхталар! Океан утрауларындагы мәңге яшел бакчаларга министр персональный самолеты белән илтеп куйган. Беләгезме? Андагы җәннәт ризыклары, тутый кошлар, матур егетләр, ялангач диярлек биюче кызлар!..

Беренчесендә кылкынган иде дә, икенчесендә батырайды егет. Зиләй алдында дәрәҗәсен саклап калу өчен генә түгел, юк! Төкерә ул аңа! Эче поша башлаганга. Аның Зиләй сөйләгәннәргә ышанасы килми, әмма ышанмыйча да булдыра алмый иде. Моннан сигез-тугыз ай гына элек «Ямьле Ык буйлары» дип шигырьләр чыгарган, аны бер көн күрмичә торса, акылыннан шашардай булып йөргән бер кызыйның хәзер туган ягын да, Гайнанның үзен дә кимсетеп утыруы аны җәберли иде. Ул Минһаҗның кече кызы Язидә белән биергә кузгалды да җай килү белән чыгып таю ягын кайгыртты.

Клубтан чыккач иң беренче аңына килгән тойгы — гәүдәсенең ифрат дәрәҗәдә җиңеләеп китүе булды. Әйтерсең ул төнге урамда кар ерып атламый, әйтерсең шушы салкынча һаваның рәхәтен сулап йөзеп кенә бара. Трактор чанасы актарып узган тирән буразнага килеп төшүе була, «эһ» иткәнче, инде ул аның теге ягында! Менә рәхәт, менә кәеф!

Бөтен дөнья төрле авазлар чыгарып уйный, бөтерелә, әйләнә. Колакларда әллә күктән иңгән, әллә җәһәннәмнән чыккан мең төрле көйләр чыңлый, баганада тимер чыбыклар чыжылдый, күктә йолдызлар айкала, электр лампочкалары бер аска авалар, ул да түгел, бөтен урамы белән күккә күтәреләләр.

Күңел шундый җилкенә, шундый канатлана, Гайнанның беркайчан да үзен шундый шат та, кыю да, көчле дә итеп хис кылганы юк иде әле. Нигә моңарчы шулай гел басынкы, гел «әдәпле» генә булып йөрде икән соң ул? Нигә аңа да урамнан бер киерелеп узмаска, нигә бер ябагаларны коеп алмаска?

Егет, шушы йөгәнсез рәхәткә түзә алмыйча, изүен чишеп җибәрде. Аның сикергәләп бисе, кычкырып җырлыйсы килә башлады. Нигә җырламаска! Ул кемнән ким? Эшлиме ул? Эшли! Егет кешеме ул? Егет кеше! Урамның уртасыннан күкрәк киереп җырлап барырга полный хакы бармы аның? Бар!

Ән-нә килә автомобиль,
Төй-йәгәннәр пый-йала шул...

Тик башлап җибәрүе булды, кемнәрдер капка төбендә чырык та чырык көләргә тотындылар. Гайнан туктады. Кызлар инде бу, шул чырылдыклар!

— Нәрсәкәй сез анда... кеш... кешнисез? Бәлки... Бәлкем, кеше... я, бәлкем...

Аның тәне җилдән житез, колмактан җиңел. Ә теле авыр. Авыр, чән... чәнчелеп киткере! Телне хәтта әйләндереп тә булмый. Әйтерсең тел очына килолы гер асып куйганнар. Ул, кулын селтәп, ары китте.

Әле генә булып узган күңеллелекләр өзек-өзек булып күз алдында әйләнә башлады. Язидә белән бөтерелеп йөрүләре. Әллә ун, әллә йөз... Аның бөтен гәүдәсе йоп-йомры, биле нечкә, үзе йомшак. Иңбашлары да, беләкләре дә. Үзеннән ниндидер ялкынлы дәрт бөркеп тора. Башны әйләндерә торган.

Без үз-зебез культур-найлар,
Кал-лада тор-масак та шул...

Нигә шул кадәр кыбырсык бу тәрәзә утлары, нигә шулай айкала? Гүя качыш уйнагандай, гел арлы-бирле килеп атыналар. Гайнан шулар арасыннан алсу абажурлысын табып алды да, пышылдап:

— Ятмаган...— диде.

Ниндидер чиктән тыш яшерен, серле, хәтәр эшкә тәвәккәлләгәндәй, як-ягына каранды, бу егетлегенә канәгать булып, үзенә-үзе күзен кысты.

Әмма капка төбенә җитәрәк, әллә кайдан гына Шәүрә күз алдына килде дә, Гайнан, ниндидер начарлык эшләгәндәй, кинәт туктап калды. Бер генә сулышка хәтта ул айнып киткәндәй булды. Уңайсызланып, бер килгән ягына, бер кызыктырып үзенә өндәп торган әлеге аулак өйгә каранды. Күңеленең әллә кай төше бу өйгә керүне өнәми, бу аның иң изге, керсез, пакь тойгыларын рәнҗетер кебек тоела иде.

Тик шунда Зиләйнең яшьтән сөйгән егетен машиналы кияүгә алмашуы, Шәүрәнең дә аннан качып, астыртын гына әллә кайдагы очучы егеткә кияүгә чыгарга җыенуы исенә төште. Гайнан, нәрсәдәндер жирәнгәндәй, йөзен чытып, кулын селтәде:

— Бөтенесе ялган! Бөтенесе икейөзле! Юк ул мәхәббәт, юк! Юк аның чыны! Юк! Вәссәлам! Кемгә кем туры килә, әйдә вәләй!

Бераз кыенсынса да, күңеле бу эшне бик үк ошатып бетермәсә дә, тора торгач егет бу йортка кермичә булдыра алмаячагын сизде. Ниндидер бер сәер кыргый дәрт, аяклары белән бер сүздә булгандай, тыелгысыз рәвештә аны шул серле алсу тәрәзәләргә тарта иде. Туры гына басып тора алмаса да, капкага якынайган саен аның акылы сафлана бара, төрле хәтер тартмалары ачыла бара иде. Ничә тапкыр карчыкларның аны мактап сөйләүләрен ишеткәне бар:

— И, Җәүһәрия җаным, бик бәхетле син! Улың шундый да инсафлы, шундый да әдәпле, кызлар шикелле!

Гайнан, каршыдан килгән ниндидер тәбәнәк машинаның якты утларыннан күзләрен яшереп, тар гына сукмакка борылды. Йодрыгын йомарлап: «Булмыйм мин кызлар шикелле, булмыйм, булмыйм!» — диде. Ава-түнә капка келәсенә барып ябышты.

Башка көннәрдә Язидә фермадан теле чыгардай булып арып кайтса да, аннан-моннан гына капкалап, тизрәк урынына аварга ашыга, караватына барып җиткәндә, аның инде күзләре йомылып беткән була иде. Баягы кичәдән бераз сәрхушләнеп, шуның өстенә, ничектер гадәттәге тынычлыгын җуеп кайтканлыктан, ул бүген ятарга ашыкмый, дөресрәге, ята алмый иде әле. Председательнең аны яшьләр янына дәшүе Язидәнең үзе каршында дәрәҗәсен күтәреп, куандырып җибәрде. Ул

ире белән барлы-юклы бер ел чамасы гына яшәп калган булса да, үзен тол хатыннар рәтендә саный башлаган иде. Ә менә бүтәннәр алай уйламый икән бит, рәхмәт төшкерләре! Юкса, Ризван аны Зиләйләр, Гайнаннар янына мәҗлескә дәшкән булыр идемени? Язидә башта моңа сәерсенеп, кермәскә дә уйлаган иде. Каян беләсең Ризванның уенда ниләр барын! Җәен Алтынбикә тугаеннан машинасына утыртып кайткандагы кебек, бәлки елмаеп-көлеп кенә тагын кул салып карарга җай эзли торгандыр? Алдан бераз йомшартып куярга уйлыйдыр? Әмма озакламыйча председательгә үтенече төшәчәге исенә килде дә барасы итте.

Язидә, тәненең һаман да сүрелеп җитмәвен тоеп, кофтасын салды. Кечкенә ягы кирәгеннән артык җылы кебек тоелганлыктан, ак өенә чыкты да, пәрдәләрне төшереп, йөренергә тотынды. Авыз эченнән генә көйли-көйли, шифоньер көзгесе каршысыннан узды. Түр яктан әйләнеп килешли, ялгыш кына яңадан күз салды. Ошады ул үзенә-үзе. Көндез фермада калын фуфайкалар аның һәммә җирен дә бер төрле, бүрәнәдән таслагандай юанайтып күрсәтсә дә, хәзер әнә яшәреп китте. Биленең һаман да нечкә булуы, күкрәкләренең нәкъ үз урынында горур басып торулары аның күңелен күтәреп җибәрде. Язидә яны белән, аннары аркасы белән әйләнде. Толымнарын сүтеп, чәчен иңенә таратты. Чәче йомшак һәм кулны рәхәтләндерерлек шома иде. Өстән төшкән яктылыкта чәче, бер борылганда ничектер җай килеп, куе коңгырт эфәктәй затлы төскә кереп елкылдап китте.

Язидә, көйләвеннән туктап, авыр сулап куйды. Аның бу чибәрлеге беркемгә дә кирәк түгел, ул ялгыз, аны күрсәтергә урын да юк иде.

Ул, шифоньерның иң өстәге тартмасына үрелеп, алсу ефәк тасма белән бәйләп куйган кечкенә генә төргәк алды. Аны бармак очы белән генә сүтеп, йомшак нәниләр күлмәген күкрәгенә кысты. Шунда бөтен тәне буйлап ниндидер бер татлы рәхәт җәелде. Ләкин күзләре моңсу иде. Коры хыял гына бит бу, хыял гына! Бу төргәкне ул Габделхәйгә чыгып бераз яшәгәннән соң, тозлы кыяр тели башлаган кебек сизгәч, яшереп кенә район кибетеннән алып кайткан иде. Габделхәй, мәрхүм, бераз ваемсызрак, басынкырак кеше иде шул. Япь-яшь хатын белән яшәүнең рәтен-җаен да, рәхәтен дә белеп җиткермәде, ахрысы. Кая ул анда нечкә билләр, ефәк чәчләрнең кадерен белү. Хатынының матурлыгы белән кызыксыну, аңа игътибар итү! Арып кайткач, килеп ава да вакыты җиткәч торып китә, исенә төшермәсәң, күп вакыт янында хатыны барын да онытып җибәрә иде бугай.

Бала күлмәкләрен нәүмизләнеп кенә яңадан урынына куйды. Өй тулы бала үстерәсе иде дә бит, югыйсә...

Йокларга вакыт, иртәгә дүрттән үк торып фермага төшәсе бар иде. Ләкин нигәдер Язидә һаман тынычлана алмый иде әле. Моның сәбәбен үзе яхшы сизенсә дә, белмәмешкә салышты. Алай тирәнгә җибәрмичә, ансат кына, өстән генә уздырып җибәрәсе килә иде. Ләкин никадәр теләмәсә дә, яңа гына мыек чыга башлаган озын буйлы яшь егет, уч иткәндәй, һаман күз алдыннан китми, билендә ул аның озын бармаклы зур кулын, йөзендә ягымлы карашын сизә, аңа бик рәхәт булып китә иде. Ничә тапкыр шул егетнең читтән генә соклanып карап торганын күргәне бар. Шундый көннәрне Язидә таулар әйләндереп ташлардай дәрт белән, армый-талмый, уйнап кына эшли торган иде.

Язидә, кече якка чыгып, маңгаен караватның салкын тимеренә куйды. Әгәр шул чын мәхәббәткә әйләнсә!? Әгәр Гайнан аны тол хатын итеп кенә түгел, болай яратса, чын-чынлап, Язидә итеп, матурлыгы, сөйкемлелеге өчен?.. Ах, әгәр шулай була калса, Язидә аны өрмәгән җиргә утыртмас, гомере буена бәхетле итәр, иркәләп кенә яшәтер, бер-

сеннән-берсе матур, берсеннән-берсе таза малайлар, кызлар үстереп бирер иде. Яшь аралары да күп түгел, югыйсә — нибары ике генә ел. Күпмени ул? Ай, булмас ул, тәтемәс Язидәгә андый бәхет! Күпсенер язмыш, ай, күпсенер.

Ниһаять, ул, күпер өстендә аяк тавышы һәм машина гүләвен ишетеп, үзенә-үзе:

— Җитте сиңа! — дип кычкырды да, үзен-үзе орышып, мич артына кереп китте. Анда битен, муеннарын юды, тәнен юеш сөлге белән сөртте. Инде утны сүндерәм дигәндә генә, капка төбендә аяк тавышы кыштырдады. Язидә, нишләргә белмичә, идән уртасына килеп басты.

Озак та үтмәде, Гайнанга өйалдыннан шикләнеп кенә дәшкән хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Кем анда?

— Мин!

— Кем соң син?

— Һе! О-о-оныттың дамыни? Ш-шул арада? Гайнан ич!

— Ә?! Мена тагын!.. Ничек? Нишләп... бу вакытта?

Әчке якта бераз тынлык урнашты. Байтак вакыт ишек ачылмый торды. Егетнең баскычтан урталай бөгелергә җитеп, аягын чалыш-чолыш атлап менүенә бик уңайсызланып карап торды да Язидә, төсе бозылып, теләр-теләмәс кенә артка чигенде. Икеләнеп торды да өй ишеген ачты.

— Ай, апаем, бу ни хәл? Җәүһәрия апа җибәрдеме әллә?

— Нинди «апаем»? — Гайнан, аркасы белән ишек яңагына сөялеп, Язидәнең күзләренә текәлде. Дөнья күргән егетләрнең сөйләвенә караганда, мондый вакытта оялмаска, нахал булырга, кулыңа төшкән малга чытырдап ябышырга кирәк иде.— Нинди «апаем» булыйм мин сиңа? Егет кеше килгән сиңа! Егетнең дә ниндие әле! Во!

Язидәнең күзләре шар булды, чигенә-чигенә барып караватына ябышты, кысылган иреннәре арасыннан ачулы пышылдап:

— Ник килдең?! — диде.

Гайнан, бөтен кыяфәте, чырае, килеш-килбәте белән күпне күргән егетләргә охшарга тырышып, Язидә исә айкала-чайкала көлемсерәргә тотынды.

— Ник дисеңме? Һе! Сәер! Зерә дә! Кунак егеттән шу... шулай сорыйлармыни? Күрәсем килде... И все!..

Язидә, куркынып:

— Әнекәем! — дип битен каплады, хәле беткәндәй кинәт кенә караватына утырды. Ул әллә еламсырый, әллә Гайнанны үчекләп шыпырт кына көлә идеме, белмәссең хатын-кызны, ул кадәресен аңларга Гайнанның акылы да, түземе дә җитмәс иде. Я иркәләнүе, я кылануыдыр дип уйлап, егет ава-түнә чишенә башлады.

Анасына булышырга баргач, фермада көн саен диярлек очрашканлыктан, егет Язидәгә ияләнеп беткән, ул аннан әллә ни ятсынмый да иде. Бу яшь хатынның җыйнак гәүдәсе, ягымлы теле, килешле буйсыны Гайнанга бик ошый иде. Язидә моны үзе дә сизә иде түгел микән? Ник дисәң, ул аны якын күрә, «Гайнан энем» дип кенә дәшә, шаяртып күз кыскалый иде. Бервакытны хәтта анасы югында Гайнан аны, уз ише кебек шаяртып, юри генә саламга да төртеп еккан иде... Ә бүген соң, бүген?! Юк, бала түгел Гайнан! Андыйны гына сизә инде ул, сизә!..

Син ашыкканда ул кабалана дигәндәй, пальтоның төймәләре чишелми, җиңнән һаман да кул чыкмый. Гайнан һәмишә ишек янында мышкылдый иде әле.

Шулай азаплана торгач, борылып караган иде, егет шаккатып туктап калды. Ташка үлчим, бу нинди тамаша? Нинди әкәмәт?! Язидә яулыгын, гүя утка ташларга җыенгандай, ачу белән башыннан йолкып алды да урындыкка ыргытты, усалланып башын селкеп җибәрде. Коңгырт куе чәче матур булып, түгәрәкләнеп килгән шәрә муенын, иңбашларын, бөтен йөзен каплады. Аннары ул көлмәк итәген тездән югары кайтарып, оекларын салырга тотынды. Менә ул ялан аяк калды. Гайнанның беркемдә дә коеп куйгандай мондый матур балтыр, шундый нәфис нәни аяк күргәне юк иде әле. Егетнең күзләре әлҗе-мөлҗе килә, ул юньләп карый да алмый, шул ук вакытта читкә борылырга да көче юк иде. Менә син Язидә, менә сиңа көн дә күреп ияләнеп беткән фуфайка кигән савымчы! Аның дәү резин итекләре эчендә шундый матур аяклар йөргәнен кем белгән?

Ул арада Язидә, битенә сибелгән чәчләре арасыннан күзләрен елтыратып, нииндидер бер үҗәт кирелек белән, авызын кыйшайта-кыйшайта, куллары белән артка сузылып, аркасындагы сәдәпләрен ычкындыра башлады. Тик аның кулларының дерелдәп китүе, йөзендәге усаллык галәмәтләре генә чиктән тыш дулкынлануын, бу каударлануның яхшыга түгеллеген сиздереп торалар иде.

Гайнан, карап торырга тәкате калмыйча, ишеккә таба борылды. Чамадан артык исергәндә кеше саташа башлый да, аңа гел шундый ышанып булмастай әкәмәт нәрсәләр күренә, дип ишеткәне бар иде. Ул, ишек яңагына сөялеп, күзен йомды. Тик күңеле болгана башлады да күзләрен яңадан ачты. Аз гына борылуына, үз күзенә үзе ышанмыйча, тагын күзен йомды, тагын ачты. Ап-ак нәфис шәрә беләкләргә, күлмәк якасыннан башлары төртеп чыккан ике коңгырт төймәгә күзе төшкәч, Гайнан, өнсез-авызсыз калып, тораташ булып катты. Язидәнең исә моңа һич исе китми шикелле иде. Ул, битенә сибелгән чәчләрен бер якка селтәп, усал тавыш белән.

— Кая борыласың! Күрергә кергәнсең бит, кара! — диде.

Егет каушавыннан бер ишеккә борылды, бер әлеге сихерле күренешкә. Ни хәл бу? Әллә, югыйсә, әбиләр сөйли торган теге юха елан микән бу? Аныңча, бу бит... мондый хәл бөтенләй башкача булырга тиеш иде. Аның хыялында бу бик кадерле, бик яшерен, гомер буена онытылмастай нииндидер баш әйләндергеч серле хәл булып, ике арада гына калырга тиеш иде. Ул кергәч, Язидә чәй кайнатып җибәрер дә алар кара-каршы утырып күңелле генә чәй эчәрләр. Язидә аны ни беләндер кыстый-кыстый сыйлар, нииндидер ягымлы сүзләр әйтер, дип уйлаган иде. Аннары Гайнан теләр-теләмәс кенә, эленке-салынкы гына киенә башлагандай итенер. Юри генә... Язидә, ояла-ояла гына, шыпыртлап кына: «Китәсең дәмени? Утырасың бар иде...» дигән булыр. Ә монда...

Язидә егеткә үткен күз аткалап, әллә шаяртып, әллә үчекләп усал пышылдый башлады:

— Нигә телеңне йоттың? Бик егетләнеп кергән идең бит! Ә?!— диде.

Бу искиткеч тере сыннан күзен ала алмастан, сихерләнеп, Гайнан карышкан иреннәрен ачарга, нидер әйтергә тырышты.

— Алай ук инде... Ни... дигәч тә...

Язидәнең чын мәхәббәт хакындагы баягы матур хыялыннан алай ук ансат кына мәхрүм каласы килми, ул әле һаман да өметен өзми, Гайнан ялгыш кына, исереклек белән генә шулай килеп кергәндер дип уйлый. Тыштан никадәр усал кебек күренсә дә, күңеле түрендә өмет чаткысы һаман да сүнми иде. Бәлки, алай түгелдер әле!.. Юктыр...

Язидә күлмәген күкрәк тирәсенә тартты да кинәт Гайнанның каршысына торып басты. Күзләрен усал елтыратып:

— Бәлки синең миңа өйләнәсең киләдер? Ә? Өйләнәсеңме миңа?! — дип пышылдады. Егет кинәт айный башлады. Кара, бу ягын башына да китермәгән икән бит. Язидәнең йөзендәге җитдилеккә, үзен менә шулай ярым-ялангач диярлек хәлдә дә бик иркен, ифрат тәвәккәл тотуына караганда, ул һич тә шаярырга уйламый, әгәр җылы сүз чыкса, бер генә сулыш та икеләнеп тормаячак кебек иде. Егетнең тыны кысылды. Маңгаена тир бәреп чыкты. Бәлки... Чыннан да?

— Шулай кинәтме? Хәз... хәзер үкме?.. Мин бит, әле бит ул хакта...

Язидә аның әйтеп бетерүен көтмәде. Күзләренә кистереп караган килеш:

— Алайса, ник кердең? — диде.

— Соң кайчаннан бирле дус булгач...

Язидәнең тавышы тагын да усалланды, күзләре очкынланып китте.

— Әһә! Дус булгач, сине бусагадан атлап керүеңә кочаклап алалар инде, шулаймы? Ник дәшмисең? Ә син инде, кибеттә йөз илле грамм салып чыккан шикелле, моннан да шулай узышлый гына кәефләнеп чыгасың? Әйеме? Шулаймы? Шуңа кердеңме?

Язидәнең йөзеннән нур качкан, иреннәре куырылып килгән, күзләре рәхимсез иде. Егет башта кызарды, аннары әллә ничәнче тапкыр тиргә батты. Әйтерсең моңарчы һәммәсе дә ниндидер сәер, хыялый төш кенә булган да менә монысы тормышның нәкъ үзе, чыны, рәхимсез-аяусызы иде. Егет, салынып төшкән пальто җиңен сөйрәп, нишләргә белмичә, ишеккә таба атлады. Ләкин шунда ук кире килде, тотлыга-тотлыга:

— Язидә, зинһар! Алай түгел бит инде! Ну... кердем инде... Синең хакта шулай уйларга әллә?! Түгел инде, юк! Мин әллә... Син бит... — дип мыгырданды.

Тик Язидә аның сүзләрен тыңламый иде инде. Ул йөрәк бәгырьләренә үтеп керердәй каты рәнҗү белән битен каплап үксеп елый иде.

— Ходаем, үләрсең хурланып! Шундый басымчак итеп! Җәүһәрия апага ни йөзем белән күреним?

Гайнанның аны юатып аркасыннан сөясе, ничек тә булса тынычландырасы килә иде. Ләкин ул, теленә бер сүз дә килмәүгә гаҗиз калып, кашларын җыерды, йодрыкларын йомарлады. Башы түнгән кешедәй, миңгерәп, акылын җыя алмыйча бәрелә-сугыла йөри торгач, ничектер, кухня яктан салкын су алып чыкты. Әмма Язидә аның суын этеп кенә җибәрде.

— Шаклар катам, башларыма сыймый. Габделхәйнең тракторга өйрәтүе дә онытылдымыни? Мәете артыннан күз яшьләрен тыя алмыйча елап барган син түгелме соң?

— Язидә дим, зинһар!

— Әнә Габделхәйнең әле кабере дә басылып җитмәгән, ә син аның хатынына... Шундый көннәргә калдыммыни соң?! Я, нинди хурлык!.. Нинди оят!..

Егет, башына сугуларын көткәндәй муенын җыерып, куырылып, стенага барып терәлде. Ул хәзер җир тишегенә түгел, янган утка барып керер, камчы белән аркасын ярганга риза булыр, тик бу хатын аның җанын телгәләмәсен, тизрәк туктасын гына иде. Нигә телгә ала ул Габделхәй абыйсын? Төнлә белән аның иң соңгы мәртәбә урам уртасыннан берүзе җырлап кайтуын Гайнан үзе ишетеп, үзе күреп калды бит. Шундый үзәкне өзеп, шундый җаннарны тетрәткеч моңлы итеп җырлаган иде ул төнне. Егет хәтта, моңа шомланып, әллә никадәр артыннан ияреп кайткан иде. Ә икенче көнне, яктыргач, Габделхәйне үзе сызган буразнасында үле хәлендә таптылар. Ни булган? Нидән үлгән? Никадәр тикшерсәләр дә, беркем очына чыга алмады.

Гайнан яңадан борылып караганда, Язидә, өстенә чуар халатын киеп, сулыга-сулыга бит-күзләрен сөртә иде.

Егетнең ярылырга җитеп башы авырта, авызыннан моңарчы дөньяда барлыгын да белмәгән әллә ниткән җан биздергеч сасы исләр килә иде. Ул үзен муеныннан пычракка баткан кебек хис итте. Язидәгә якын килү түгел, күтәрелеп карарга да кыенсынып, ишек янында торды. «Шундый саф, шундый пакь күңелле, гөнаһсыз кешене нахакка рәнҗеткән өчен син уләргә тиеш!» — дисәләр, егет, үзен һич кызганмастан, хәзер үк үләр иде. Ләкин бу ахмаклыкның җәзасыннан алай ансат кына котылып буласы түгел иде әле.

Шулай башын иеп торды-торды да, гафу итүенә өмет багламаса да, һич югында, тавышын гына ишетү өчен, тагын бер сүз салып карарга булды.

— Язидә...

Тик Язидә җавап бирмәде, тавышын да ишетәсе килмәгәндәй тагын да читкәрәк борылды. Елый-елый каргый һәм рәнҗи торгач, ул, ничектер арып, бушанып калгандай хис итте.

Гайнан, ишеккә таба караган килеш, авыз эченнән генә тагын әйтеп куйды:

— Эчерттеләр бит. Беренче тапкыр. Чамасыз киткән...

Егетнең шулай мескенләнеп, еларга җитешеп дәшүе Язидәнең яңадан ачуын кабарта башлады. Язидә аны тагын орышып ташламакчы булды. «Кергән чакта бик батыр идең бит! Ничек алай бик тиз шәлперәеп төштең?!» — димәкче иде. Ләкин Гайнанның мөлдерәгән күзләренә, балалар сымак гөнаһсыз кыяфәтенә астыртын гына күз салып алды да нигәдер йомшап китте. Башы белән генә ымлап, ишетелер-ишетелмәс:

— Ярар... Бар! — дип пышылдады.

*Ахыры бар.*

Ренат Харис

# РӘССАМ

*Казанның атаклы рәссамы Николай Иванович Фешин истәлегенә*

I

## Гүзәл тән

Сарафанын салды да
Көтмәгәндә бөтенләй ялангач калды...
Кулларына урын тапмады —
Кушырды-аерды, кушырды-аерды да
Тимгел-тимгел янган йөзен каплады...
Бармаклары арасыннан мөлдер-мөлдер
Үкенү акты, үкенү акты, оялчан тамчыларга әверелеп...
Кисәк кенә борылды да курсистка
Чуар кәнәфигә барып ятты...

Рәссамның
һәр төсне кырыкка яра белүче
һәр сызыкта җан хәрәкәте сизүче,
һәр хәрәкәттә кырык мәгънә күрүче күзләре
Соклanудан каушап калдылар,
Беравыкка йомылудан туктадылар.

Йа, хода!
Аның остаханәсеме бу?!
Өнеме бу, төшеме бу?!
Тере кешеме бу?!

Күзләре күргән
Йөрәгенә үтте... Дулкын булды...
Дулкын, ниятка әверелеп, кулларына тулды.
Пумаласын алды рәссам, мастихинын [1],
Киндеренә беренче буяуларын салды.

[1] Мастихин — артык буяуны киндердән кырып ала торган махсус калак.

Пәйда булды иркен маңгай, чиста битләр,
Ишелеп торган коңгырт чәчләр...
Һәм пумала адаштырды үз хуҗасын шул чәчләрдә...
Шул чәчләрдә... Чәчәкләрдә... аланнарда,
Яланнарда, болыннарда, камышларда...
Рәхәтләнеп, шатлана-шатлана адашып йөрде рәссам
Һәм кинәт
Ике игезәк күл күрде.
Чумып китәсе, эреп бетәсе килде аның шул күлләрдә...
Шул күзләрдә...
Яшерен теләк тулы серле күзләр!
Төбәлебрәк караган саен тирәнгәрәк,
Убагарак сөйрәп төшереп,
Һушны алырлык назлы сүзләр сөйли торган,
Эретеп иркәли торган
Сусаган күзләр!
Сулыш җиленнән бөгелергә әзер сизгер керфек,
Канат-кашлар!
Ике каштан килеп чыккан
Алсу канатлы горур борын,
Ирләр күз карашы җыелсын дип очы уелган
Җыйнак ияк
Рәссам сихере белән пәйда булды.

Алды рәссам кызыл төсләр.
Сызды рәссам алсу җәя.
Уксыз җәя.
Утлы җәя — өске иреннәр.
Тыгыз, сутлы, йомшак кереш — аскы иреннәр.
Утлы... татлы...
Ягымлы сүз генә ата торган,
Күзләр йомылу белән
Башка ирен эзләп ачыла торган,
Утлы, татлы һәм беркатлы,
Җан төнлеге,
Йөрәк ишеге иреннәр!

Кысылып калсы килде рәссамның шулар арасында,
Кысылмый яшәү мөмкин түгел бу тормышта —
Кысса кыссын утлы ирен,
Салсын мәңгелек ярасын.

Ал буяуга манды пумаласын —
Оялчан шәфәкъ кызартты кызның бит алмасын...
Төсмерләнде колак,
Колак йомшагы — тамчы гөл тамчысы булып.
Өзелеп таммасын —
Тот кайнар, дуамал дулкын тулы иреннәрең белән!
Керфек белән генә кытыклап
Уйнар өчен яратылган ап-ак муен!
Кыен рәссамның керфекләренә, кыен...

Беләкләрен каерып-бөкләп,
Терсәкләрен чәнчеп, ипләп,
Учларын ачып баш астына салган...
Җир тетрәүләрдән дә көчлерәк тетрәнүләр күргән,
Чын кысылуларның ни икәнен сизеп кенә белгән
Тулы күкрәкләре иркенлектә калган.

Алар — яшәешкә һәйкәл белән тәгәлләнгән
Ике калкулык,
Кулың кагылса җаныңны тотып ала торган
Ике тере ахак,
Алар — хатын-кыз табигатенең
Сабый иреннәре генә аңлый торган,
Гашыйк ирләр иреннәре генә аңлый торган
Өнсез сүзләре —
Мәхәббәтнең кешедәге бер начарлыкны да
Күрмәскә дип мәңгелеккә йомылган күзләре!

Юк, пумаласы белән сылап түгел,
Бармаклары белән сыйпап,
Юк, бармаклары белән генә түгел,
Учларына тутыра-тутыра,
Кагылган саен тетрәнә-тетрәнә,
Нирванәгә китә-китә ясады ул аның күкрәкләрен.
Кыргыйланып аласы килде аның —
Яшел болын, көлсу әрем, чәчрәгән чәчәк
Дөньясы булып күренде аңа чуар кәнәфи...

Йөрәге туктады аның, типте, туктады, типте...
— Киен! — диде ул, — бүгенгә җитте.
Кызны чуар кәнәфидә ялгызын ташлап,
Әллә нишләп,
Өенә үк кайтып китте.

Сузылып ятты. Күзен йомды.
Күз алдында — яктыдан-якты гүзәл тән.
Күзен ачты.
Күз алдында — ачыктан-ачык гүзәл тән.
Төн... Караңгы... Балкый ике тулган Ай...
Һай! Ни шомарак каз тәне чыккан
Йомры ап-ак беләктән?!
Ни нечкәрәк тотсаң учың күмелә торган
Тыгыз, итләч шул билдән?!
Ни йомшаграк
Уч күзе генә күрә алган очлы оча сөягеннән?!
Ни җыйнаграк
Ишелеп торган, күпчек кебек күпереп киткән,
Һәрчак ирләр күзенә бәрелгән
Купшыдан-купшы янбашлардан?!
Ни тирәнрәк,
Ни җылырак,
Ни татлырак
Үзеңне шуларның барчасының
Колы һәм иясе итеп тою хисеннән?!.
Төн караңгысында эреп юк булды рәссам,
Чапты остаханәсенә...

Йа, ходай!
Остаханәме бу?
Хыялдагы дөньямы бу?
Өнме? Төшме?
Киндерендә тере кеше!
Тере... кеше...

Иртән,
Остаханәгә кыз килгәндә,
Рәссам чуар кәнәфидә ярым елмаеп,
Августның беренче кояшын да күрмичә,
Германиянең Россиягә
Сугыш игълан иткәнен дә белмичә
Йоклап ята иде...

Кыз курка-курка гына сурәтнең япмасын ачты.
Юк, юк! Анда ул түгел,
Анда — тәнгә әверелгән илаһи пакьлек,
Анда — батырлар, акыллылар, матурлар анасы булырлык
Тиңдәшсез гүзәл!

Кыз япманы япты...
Рәссамның иреннәре,
Борын очы,
Ияк очы
Алсу буяуга буялган...

Кайда, кайда хәзер
Рәссамның гыйшыктан исәрләнгән,
Сокланудан әсәрләнгән иреннәре эзе
Ябышып калган сихри сурәт?..

Төнлә шашып-шашып үпкән сурәтен рәссам
Шул гөнаһлы иртәдә үк
Елый-елый тураклап атты.

II

## Сугым сарае

Караңгыга алып керделәр...
Хыянәтчел караңгылык...
Маңгаена бирделәр берне тукмак белән.
(Һәрбер җанның, кешеләрнең бер булса да,
Ярый әле, кешелекнең маңгае бердәнбер түгел...)
Чайкалып китте пәһлеван —
Иленә дошман бәреп керү хәбәрен алган
Патша кебек.
Акаеп китте күзләре,
Сугыш башлауга сәбәпче булган ядрәне йоткан
Эрцгерцог күзләредәй.
Үкерде дә тынлыкны, йөрәктәге тынычлыкны үтерде
Мөгезләре арасына томырдылар тагын берне —
Алпан-тилпән китте үгез,
Уңын сулга, сулын уңга атлады да,
Капланды ул җир идәнгә.
Бездәй мөгез яшь бер сугымчының
Тишеп чыкты аяк битен.
Штык очына эләктемени — һушы китте.
Соры керде, кызыл чыкты авыр мөгез —
Һәм кан китте сугымчының аягыннан.

Һәм кан китте яшь үгезнең бугазыннан
Күм-күк кереп кызыл чыккач чалгы пычак.

Һушсызларны, аңсызларны чалып ату авырмыни!..

Алмашынгач кеше аңы ерткыч аңы белән,
Кушылды сугымчы каны үгез каны белән,
Кеше каны хайван каны белән...

Йа, хода!
Аның остаханәсеме бу?
Әллә сугыш сараемы?
Әллә сугыш сөременә баскан,
Канын агызып яткан Европамы?

Кан исе чуалтты рәссамның хисен,
(Хисне генә чуалтамы соң кан исе?!.)
Исертте пумалаларын.
(Аларны гына исертәме соң кан исе?!.)
Пумалаларын атып бәрде дә рәссам
Саф һавага чыкты.
Ә Казанда — соңлаган көз.
Карлы яңгыр канлы күз яше күк авыр.
Авыр култык таякларына —
Бер аяк бәрабәренә җиңеләеп кайткан солдатларны
Йөртү авыр.
Аталары бәрабәренә бер тамакка кимегән
Гаиләләргә авыр,
Әтисез калган балаларга,
Ирсез калган җиләк хатыннарга,
Георгий тәресе тагып уйнаган сабыйларга,
Георгий тәресе тагып хәер сораган агайларга,
Шуларны күргән күзләргә авыр,
Кешедән кешегә шатлык илтә алмаган
Сүзләргә авыр.

Күкрәк өчен бар булса да,
Күңел өчен юк саф һава —
Җир сулышы җил — укшыта...
Ләгънәт, ләгънәт суешка,
Кан коешка,
Сугышка ләгънәт!

Кан исеннән исергән пумалаларын кулына алды рәссам —
Сугышчылар кулы канга буялды,
Күзләренә төште пычак бәзе яктылыгы,
Берсенең кулы ап-ак булып сузылды аска,
Сузылган саен ерагайды баштан,
Ерагайды акылдан, хистән.
Ерагайды да максатына житте —
Менә ул, күзе кызган козгын башы кебек,
Мәрҗәндәй кан агып яткан
Үгез бугазына кереп китте.

Нәрсә калган кеше кулына үгез бугазында?
Нәрсә кирәк кеше кулына кан эчендә?

Сабый чәбәклисе кул,
Ипи сындырасы кул,
Йорт корасы кул нинди юлда?

Мастихынына сытты рәссам
Ал, кызыл, ак, сары буяу
Һәм сылады киндеренә.
(Алар белән рәссам чәчәк-гөлләр,
Гүзәл тәннәр ясый иде...
Пәйда булды ыргакка эленгән, тиресе туналган,
Бу бөркегән дымлы түшкә.
Буп-буш, буп-буш...
Эчәксез, үпкәсез, бавырсыз...
Баһадир йөрәк — тутыгып беткән тимер чөйдә.
Үгезне үгез иткән мәһабәт куыкка
Су тутырып уйный малайлар.

Йа, хода!
Бу үгез түшкәсеме?
Контрибуция түләп ыштансыз калган
Берәр дәүләтме бу?
Әллә һәрбер яуның соңы шушымы?
Әллә шушымы сугышлы Җирнең киләчәге?

Ипи валчыгын идәннән күтәрүчеләр
Ипидән дә изгерәк канны таптап йөри.
Кеше йөгергән каны белән тере,
Кеше кан таптап йөри.
Имин булырмы җире,
Бөтен булырмы иле,
Сау булырмы теле,
Пакь булырмы көне,
Тыныч булырмы төне? —
Кеше
Чапыр-чопыр
Кан
Таптап йөри...

Аяк астында җәйрәп,
Хыянәткә дучар булган пәһлеван кебек,
Хокукыннан мәхрүм ителгән дәүләт кебек
Телен тешләп,
Үле күзе белән безнең тере күзебезгә карап,
Үле күзе белән безнең тере күзебезгә кадап,
Үгез (үгез генә микән?) ята,
Үгез (үгез генә микән?) канга баткан.

Йа, хода!
Остаханәме бу?
Сугым сарае гынамы бу?
Әлә сугышлы Европамы?
Кайсы ил үгез хәлендә —
Сербияме? Германияме? Россияме?

Сугым сараенда тынчу, суык.
Үгез бугазына кулын тыккан сугымчы әйтә:
«Монда рәхәт. Әйдә курыкма — кулыңны тык...»

Ә икенчесе кычкыра:
«Ач ишекне — һава керсен... буылып үләм»...
Өченчесе кет-кет көлә:
«Кан исен яратмыйсыңмы?
Бар болынга, үлән аша...»
Дүртенчесе шешә тоткан —
Аягы яралы сугымчыга түгелгән каны урынына
Аракы бирә — артсын каны.
Утырган җире — кан күле...
Сугымчының тәне тере, күңеле үле.

Карады рәссам үз кулына.
Караса — куллары пычрак.
Көзгегә килде...
Төсе качкан күзләренә карап
Күрде үзенең күңелен —
Әлсерәгән туган илен,
Ямалып беткән Казанын,
Керләнгән остаханәсен,
Һәммәсен, һәммәсен...

Пумалаларын керосинлы савытларга атты,
Япты сурәтенә киндер япма,
Китте Болак мунчасына...

«...Пумалалар чистарыр.
Тән сыярлык мунча бар.
Күңел кайда кул юар да,
Ил ничек йөзен юар да,
Җир кайчан тәнен юар?..»

III

## Яңгыр боткасы

Дөнья яңгыр көтә.
Яфракларны корылык өткән.
Черергә тиешле нәрсәләр чери алмый.
Шытканнары үрли алмый.
Дәүләтләрнең, континентларның хәле киткән —
Ялалары тирәсендә чебен өере.
Сәясәтләр бугазында канлы төер —
Йотып җибәрергә йотым су кирәк.

Халыкның йөзендә күз яше булып аккан,
Җыерчык булып калыккан
Сугышны каргау эзе юылмаган.
Яраланып, яраксыз булып кайтканнарның
Бармакларыннан курок эзе юылмаган.
Колакларыннан — җан бирүчеләрнең
Иң йогышлы тавышлары юылмаган.
Инде өч ел сугым сарае булган Җир дә
Юынмаган...

Буламыни болай яшәп?!.

Мә, Җир! Ал, Җир! Яудырам яңгыр ал нурдан,
Зәңгәр нурдан, яшел нурдан, күк нурдан —
Юынсын кеше,
Юынсын кош-корт,
Юынсын үлән!

Пумаласы белән манды, сызды,
Манды, сузды рәссам киндеренә —
Коелардан су сосылды, тулды чиләк-бадьяларга.
Әбиләр дә, балалар да
Көлешә-көлешә су сибеште бер-беренә.
Яшьләр тәмам азды —
Берсе старостаның күкрәк калаена
Су сибәргә базды.
«Күгәртәсез, черетәсез государьның калаен»,— дип;
Су бөркегән малайны куып китте староста
Аксаклап-аксаклап...
Су сибеште халык такмаклап-такмаклап:

Яңгыр яу, яу, яу, яу.
Майлы ботка казанда,
Алтын кашык базарда,
Көмеш акча болытта,
Шунысын да онытма...

Һәм тотынды кинәт яңгыр...
Җирдә түгел, яуды рәссам күңелендә...
Күк күкрәми, яшен яшьнәми коелдылар мул тамчылар
Коендырып бар дөньяны —
Яшелләнде соры үлән,
Елмайдылар кашкарыйлар,
Елтырап китте тәрәзәләр,
Ачылды бикле капкалар,
Гөрләделәр вернисажлар,
Һәм кибетләр, һәм базарлар...

Җил-җиләсләр җилеп керде тынчу сугым сараена,
Түбәсен тишеп яңгыр акты аның канлы идәненә...
Юындылар сугымчылар...
Тузгыдылар сугымлыклар, таралдылар болыннарга...
Юындылар сугышчылар — әлбәттә, исән калганнары,
Әгъза калдырып булса да
Туган илләренә кайта алганнары.
Юынды сугыша-сугыша,
Мылтык ясый-ясый керләнеп беткән халык...
Юынды җир болыт мунчала алып...
Юынды рәссамның остаханәсе,
Татлы гөнаһ шаһите чуар кәнәфи,
Юынды кыз —
Маңгаенда ак ялтырап,
Иренендә кызыл ялтырап,
Күкрәк очларында көрән ялтырап
Актылар энҗе тамчылар.
Актылар — биленең нечкәлеген,
Бөеренең текәлеген,
Ботларының тыгызлыгын тоя-тоя,
Аңнарын җуя-җуя,

Тøймә кендегенең кайнарлыгын сизә-сизә,
Парга әверелмичә чак-чак түзә-түзә...

Актылар мылтык көпшәләрен тутыктырып,
Тупка юшкын утырттырып,
Җәбетә-җебетә дары мичкәләрен,
Юа-юа сүздән яман сүзне,
Юа-юа күздән яман күзне,
Җаннан кара җанны,
Каннан кара канны,
Сүндерә-сүндерә уйда, ниятта бикфорд шнурларын,
Батырлыкта дуамаллыкны,
Дуамаллыкта юләрлекне
Бетерә-бетерә акты хыялый сулар.

Йа, ходаl
Аның күңелеме бу?
Аның илеме бу?
Аның Җиреме бу?
Барысы да шундый чиста!
Барысы да ул дигәнчә!
Ул дигәнчә — бөтен кеше теләгәнчә!

Йа, хода!
Ничек тиз булды бу?
Ничек алай тиз үзгәрде бөтен хәят,
Бу Җир шары?

Үзе дә сизмәстән кычкырып җибәрде рәссам
Киерелеп, кулларын җәеп:
«Минә ул бәхетле, пакь, чиста дөнья!
Минә, минә!..»
Кулы нәрсәгәдер килеп бәрелде...

Остаханә генә икән ләбаса бу, киндер генә...

Рәссамның күңеле утлы күз яшьләренә коенды...
Якын офыкларда,
Илләр, тәхетләр өстендә
Яшенле яңгыр җыелды.

1976

Әсгать Мохтар

# ЧИНАР

РОМАННАН ӨЗЕК



Анабиби иншасына нигездә үз атасы хакында ишеткән-белгәне һәм аңа карата үз мөнәсәбәтен язган иде. Анасы Кумри шул кеше аркасында ничек хур булган, оятка калган. Анасы авырып киткәч тә, ул бәндәдән хат-хәбәр килмәвен, шул хәл анасының үлеменә сәбәп булуын тасвирлаган...

«Аның гаебе белән хәзер минем үз ата-анам юк. Башкаларныкы кебек апам яисә агам юк. Һич югы, бер кече сеңелем булса икән... Хәзер бер миһербанлы кешене ата күреп торам», дип, ахырдан гына кушып куелган иде.

Гариф әкә бу бер бит кәгазьне бик озак укыды. Күз керфекләре дымланып чыкты, күкрәк тирәләре чәнчеп-чәнчеп алгандай итте. Әчке тойгыга бирелеп кайда утыруын да онытыбрак җибәргән икән, Шәфигуллинаның:

— Күрдегезме инде? — дигән карлыккан тавышын ишеткәч кенә исенә килде.

— Нәрсәне? — диде ул, әлегә ни әйтергә белмичә.

— Кызыгызның язганнарын.

— Әйе, — диде Гариф әкә, ни өчендер шул бер бит кәгазьне һәмишә кулында тотып. Тавышының кинәт үзгәреп, «авыраеп» калуын сизеп, тагын кыска гына итеп «әйе» дип кабатлады.

Карт педагог исә гадәти нәсихәтенә күчте.

— Балаларны мондый гаилә кичерешеннән, түбән фикерләрдән саклау сезнең белән безнең вазифа. Аларны без олы, пакь хисләр, заман хакында якты уйлар уятып тәрбияләргә тиешбез.

— Миңа калса, Анабибинең бер гаебе дә юк. — Гариф әкә класс житәкчесенә текәлеп карады. — Биредә язылганнарның барысы да хак бит!

— Ә ул яшь баланың безнең совет гаиләсе хакында шулай хөкем йөртүе педагогик кануннарга туры киләдер дип уйлыйсызмы?

— Педагогикага... — Гариф әкә җилкәсен җыерып куйды. — Ләкин ни барын язган бит ул. Күреп-белгәне шул икән, ни язсын? Һәркем үз гаиләсен тасвирларга тиеш булгандыр бит, шулаймы?

— Шулай. Әмма... хәер, менә карагыз башка балаларның иншаларын. Бусын! Башкаларын да. — Шәфигуллина берничә дәфтәрне өстәлгә алып куйды. — Һәммәсе яхшы, якты тормыш хакында! Көндәлек вак-төякне катыштырмый, бәхетле гаилә, бәхет турында горурланып язалар.

Ахыры. Башы 10 санда.

— Бәхет... мин беләм, ышанам, Анабиби бәхетнең нәрсә икәнен анык кына әйтеп тә бирә алмас әле. Хәер, хәзер шуны тасвирлап бир дисәләр, моны мин дә җәһәт кенә язып бирә алмас идем. Миңа ошаганы шул — Анабиби үз күңелендәгең, үзе уйлаганны язган. Ә бу бит яман түгел. Мин: «Моны эшләмә», — дип, аңа әйтә алмыйм.

— Һай, болайга калса, яман булып бетәр бит, төшенәсезме? — дип, Шәфигуллина Анабибинең язмасын селкеп куйды.

— Ул дөресен язган!

— Сез, иптәш Ачилов, өйдә бик аз буласыз — кичен-көндезен сәфәрдә, кыр-далада. Ә кыз бала ялгызы яши бирә. Холкы кире, теләнә ни килсә, шуны әйтә дә, яза да. Без моңа юл куя алмыйбыз.

— «Теләнә ни килсә»не түгел, уенда барын әйтәдер, хөрмәтле мөгаллимә иптәш. Кызымны мин беләм.

— Хактыр да, сез — ата кеше. Ләкин ата дигән мөһер безнең укытучылык эшебезгә комачауламаска тиеш. Ә әдәбият укытучысының зарын әле мин бөтенләй әйтмәдем...

— Шулай да мин аңа моның өчен ачулана алмыйм. Ул нәрсә уйласа шуны язган. Юкса, тормышта бер төсле яшәп, язмада икенчегә әверелсенме? Өйдә бер төрле сөйләшеп, мәктәптә шуның киресен язсынмы бала? Шуны өйрәтү безнең вазифамы? Икейөзлелеккә өйрәтү килеп чыкмасмы соң?

Класс җитәкчесе Гариф әкәнең соңгы сүзләренә ни дип җавап кайтарасын белми тынып калды. Ә Гариф әкә исә күңеленнән: «Анабибинең ул хәерсез атасы, янсә шул ук Зыяханов ишеләр шушындый ялгыш тәрбия җимеше түгелме соң?» дип уйлап куйды. Хәтта ул моны шушы «педагогика кануннары» эчендә өлкәнәйгән укытучыга мисал итеп әйтмәкче дә булган иде, шулай да: «Чакыруыгыз өчен рәхмәт. Сөйләшкәннәрне мин кабат уйлап карармын. Хушыгыз»,— дип саубуллашуны хуп күрде. Һәм, эшләпәсен култык астына кыстырып, кабинеттан чыгып китте.

Өйдә ул Анабибигә ни дип әйтергә дә белмәде. Кызы борчылып атасының сүз башлавын көтә, үзе, юк-бар эш табып, шуның белән булашкан була, ләкин астан-астан гына аңа караштырып алгалый иде. Әле генә ул әйванда көндәлек фәлсәфәсенә бирелеп утырган Тимерне, бер дә юкка ачуланып, куып чыгарган иде. Инде атасына чәй пешереп китерде дә юашланып кына читтән аңа карап утыра башлады. Гариф әкә аның хәлен сизеп, чәй капкалаган итте дә, ахры, үзе дә чыдамады, кызын чакырып китереп, кочып алды. Күңеле тулып торган Анабиби аның киң күкрәгенә йөзен каплау белән, еш-еш борын тартырга керешә. Байтак кына шулай онытылып тордылар.

Шуннан соң янә берничә көннәр Гариф әкәгә тагын ямансу, авыр булып калды. Җыелышта утырамы ул, иркен кыр-дала буйлап берәр яры барамы — ялгызлыктан, әллә артык җаваплылыктан туган шул авыр кичерештән һич арына алмый иде. Әлеге «инша» мәсьәләсеннән соң Анабиби белән ике арада әлегәчә яшәп килгән эчкерсезлеккә, икесе дә моны һич теләмәсәләр дә, гүяки ниндидер күләгә төшкәндәй булды.

Беркөнне өлкә партия конференциясендә Мария Васильевнаның докладын тыңлап сүз алышканнан соң, инде барысы да таралышып беткәч, ул, кайтыр юлын бүлеп, туп-туры аның өенә китте.

Мария Васильевна бер нигә яраксыз иреннән аерылганнан бирле, чәче агарып картайган тутасы һәм сугышта үлеп калган агасының ике баласы белән яши. Өч бүлмәле квартиралары якындагы йортларның берсендә иде.

Мәрьям яңа гына ваннадан чыккан икән. Йөзеннән бик тә уңышлы үткән эш көненнән соң гына була торган канәгатьлек нуры бөркелеп тора иде. Ул юеш башына тастымал чорнаган, өстендә өйдә генә кия

торган иркен көлмәк. Бу көлмәктән ул Гариф әкәгә тагын да килешлерәк күренде. Гәүдә авырлыгы сизелми, буйга да калка төшкән кебек иде.

— Кереп яхшы иткәнсең, — диде Мәрьям хуш күңел белән.— Үземнең дә искә килгән иде... Көнозын бергә җыелышта утырып, чәй дә эчми кайтып китү килешмәс.

— Чәй дип кенә түгел, сөйләшәсем килеп кердем.

Мария Васильевна үткән юлгы «фикер алышуны» хәтерләп, иренен тешләде.

— Өйдә эш хакында сөйләшмик, әнә утыр, — диде ул, өстәл янәшәсендәге көрсигә күрсәтте. — Апам!

— Хәзер, Маша,— дип, русча җавап бирде апасы ашханәдән.— Кунак бераз эчәрме?

— Эчәсеңме? Эчә, эчә! — диде Мәрьям Гарифның ни әйтерен дә көтмәстән.

— Өйдә кирәкми дисең инде, алайса? Өйдә бер, эштә башкача буламы? Өйдә үз уйлаганыбызны, үз күңелебездәгене сөйләшәбез дә, эштә, җыелышларда, үзебезне яхшы күрсәтер өчен, тиеш дип кабул иткәнне генә әйтәбезме?

Алар бер-беренә карашып алдылар. Мария Васильевнаның баядан бирле балкып торган йөзе кырысланып калган кебек булды.

— Әллә ниләр сөйлисең, Ариф! Бүген дә кәефең юк синең.

Гариф әкә, терсәген өстәлгә терәп, башын учлап тотты.

— Хак... бигрәк бәйләнчеккә әверелдем, ахры, кичер, Мәрьям.

Мария Васильевнаның апасы тирән тәлинкәләргә гөмбә шулпасы салып чыгарды. Аннан соң шуңа өстәл уртасындагы пыяла савыттан каймак тамызып, бизәкле агач кашыклар өләшеп чыкты. Ашханә ягыннан тагын нәрсәләрнеңдер чыж-пыж килеп пешкәнлеге ишетелеп тора иде. Ярый әле, ул чыж-пыж бар. Юкса, бу өнсез тынлыкта һәркемнең шупырып шулпа эчүе генә ишетелеп, алар тагын да уңайсызрак хәлгә калырлар иде. Мария Васильевнаның инде ашыйсы килүе дә онытылган, тамагына аш үтми, кунакка үрнәк өчен генә кашык йөрткәли иде.

— Ярый, әйтер сүзең йомып калма инде, әйтә бир. Минем докладка кагыласыңдыр, шәт.

Гариф әкә аш өстеннән башын күтәрми генә берара елмаеп алды.

— Нигә ыржаясың?

— Үзең дә беләсең икән. Ә мин белергә теләмисең дип уйлый идем. Димәк, чамалыйсың. Яхшы, алайса... Хәер, бәлкем бик үк яхшы да түгелдер.

— Ачыграк итеп аңлатып булмыймы? Нидер боргалыйсың...

— Әйе, кайбер кеше өендә бер төсле, ә эш урынында — бөтенләй икенче... Плакатка әверелә дә кала. Тик кайберәү моны үзе белеп шулай эшли, бәгъзеләре исә белештермичә, шулай тиеш санап, шулайга әверелгәнлектән эшли. Тик икесе дә бүгенге өчен яраксыз, минемчә.

— Хуш, алайса, шул икейөзлегә мине дә кертәсең инде син... Әйтеп бетер, башлагач.

— Юк, мин ул кадәр кискен сүзләрне куллана алмыйм. Әмма докладың артык шома, уңыш һәм ирешкәннәргә иллюстрация кебегрәк төзелгән иде. Ә анализ кайда? Инде яхшыны да чагыштыру таләп итәлә. Шулаймы? Ә синдә исә ул юк. Ягъни, гомумән синдә диюем түгел, бүгенге докладыңда юк иде.

— Тагын ниләр юк, дәвам ит.

— Бер генә мисал. Тау кышлакларыннан сигез мең патриот яңа совхозларга күчеп килде, дидең. Ә аларның ничә йөзенең кире китүен әйтмәдең. Беләсең бит, җиде йөзләп кеше киткән. Шушы көнгә кадәр буш яткан далага хәят, яшәеш алып килдек, дидек. Ә тау буендагы

ничаклы гөлбакчаның корып, кышлаклар таркалуын әйтмәдең. Шуны белә торып та, үз эчендә яшереп калдың. Үз-үзен аямас диһканнарыбыз ихтыяры белән алты совхоз ныклап аякка басты — бүген дәүләткә өч йөз мең тонна пахта бирде, дидең. Ә беләсең, алар әле дә булса, инде җиде ел, үз-үзләрен акламыйлар. Өстәвенә, аларны даими исеп торган эссе җил аптырата. Шуңа тагын уңышка зыян килә. Керем аз, ул «азамат диһканнарның» тормышы җайга салынмаган, авыр. Ни өчен, ни сәбәпле, кемгә кирәк?! Коммунизм өчен, киләчәк өчен көрәш шулай җинел яулана дип әйтергә теләмәсәң дә, тыңлаганда шундый хис калдырды ул докладың. Һәрбер яңа эшнең кыенлыгы була. Каршылыксыз уңыш та, алга барыш та булмый. Сиңа моны сөйләп, төшендереп торасы юк. Тик нигә син һәммә эшнең уңышын, булдырылганын гына тасвирлап, аның ялтыравык ягын гына күрсәтергә тырышасың? Моны без, урындагы хәлләрне тәгаен белеп утыручылар, сизенәбез, аңлыйбыз бит. Ләкин тыңлыйбыз, кул чабабыз, җитмәсә. Син дә моны яхшы аңлыйсың, Мәрьям.

— Хуш, җыелышта без син әйткәнчә эшләгәннән нәрсә үзгәрер иде?

— Нәрсә үзгәрәме? Чын хакыйкать, чын хәл күз алдыбызга киләчәк иде. Төпле анализ ясалачак иде. Нәрсәдән канәгать, нәрсәгә күз җитмәгән булуыбыз күренәчәк иде. Ул чакта без үз-үзебезгә ышанып рак эш итәр идек. Тормышчанрак булачак иде. Иң мөһиме — бер-беребезне яхшырак белеп, эчкерсезрәк сөйләшкән булыр идек,— дип, Гариф өстәлне күздән кичерде. — Кая әле, эчемлек тә бар дигән идегез шикелле.

— Апам, — дип кычкырды Мария Васильевна. — Шәрабыңны оныттың, ахры... Хуш, без бер мәсьәләне чишеп алга киттек ди. Моңа игътибар юнәлтү, ирешелгәнне исбат итү яманмы? Һич кирәксезме?

— Кемгә? Кемгә исбат итәргә? Үзебезгәме? Мин сиңа, син миңамы?

— Хуш, әйтик, халыкка агитация, пропаганда өчен булсын ди. Син, секретарь, моңа да каршымы?

— Гамәл, эш, ирешелгәннәр — үзе агитация. Аны коры сүзгә әверелдереп, тәкрарлап торуны мин бикәргә саныйм, — дип көлде Гариф әкә, алдындагы шәрабтан авыз итеп алды.

— Әлегә үзеңнең дә коры сүз генә ич. Ихтимал гына.

— Юк, минем конкрет фикерем бар. Син уйлаганны сизенеп торам. Эшкә керешүеңә ни гомер, ихтималларың күп — ә эшең, нәтиҗәсе кая соң димәкче син. Минемчә, уйлана, хыяллана белү — үзе эш. Безнең яшьлектәгечә әйтсәк, һөҗүмгә хәзерләнгәндә җитәкчегә хыял да, хистойгы да ят нәрсә дип уйлый кайберәүләр. Аны әмер бирүче итеп кенә күз алдына китерәләр. Җитәкче хискә, хыялга бирелмәсә, башкалар күңелен аңлармы? Беләсеңме, бер диһкан миңа нәрсә диде? — Гариф әкә кесәсеннән блокнотын чыгарды. — Менә. «Хәзинә генә байлык түгел, ярата белү дә байлык. Кеше күзендә куаныч, шатлык күрү дә байлык ул», — диде.

— Шулай, матур хыял белән хискә артык бирелеп йөрсәгез, янә бер елдан соң да совхозларны аякка бастыра алмассыз. Ул чакта без сезне эштән азат итәрбез. Эшкә тәкъдим иткән кеше буларак, ул очракта да беренче сүзне миңа әйтергә туры килер.

Әңгәмәне кинәт шулай борып, Мария Васильевна сөйләшүнең күңеленә ошамавын белдерде.

— Моңардан шашмам,— диде Гариф әкә сабыр гына.— Беләм, холкым авыр, ул да шул хисчәнлек белән хыялыйлыкның бергә кушылуыннан киләдер... Тик бу ике тойгыдан мәхрүм затны мин эш башына куймас идем. Андыйларны барлык эштән азат итәр идем.

— Районыңда ни гомер тулганып шушы фикергә килдеңме?

— Юк, әле минем тагын бер фикерем бар: Куйки районын тузгы-

тып, халкын мәҗбүри төстә яңа җирләргә күчереп ялгыш иткәнбез. Аның үз йөзе, тоткан урыны бар иде.

— Тагын шул Куйки районы, — дип, Мария Васильевна, әлегә кул тидермәгән рюмкасына үрелеп, берничә мәртәбә уртлап куйды. — Экономик яктан иң көчсез, зәгыйфь район булганын беләсең. Үсәр, яңарыр өчен перспективасы юк иде ич. Җире аз, тау-таш арасы, хуҗалыгы берьяклы — бакчачылык кына. Аны да киңәйтү, арттыру мөмкинлеге юк. Ул район тулаем дәүләткә файда китерерлек түгел, хосусый милекчелек оясы иде. Кая барма, базарда шул шивилгәннәрне очратыр идең: үз бакчам — үз акчам. Без төзегән совхозлар — дәүләт таянычы алар. Моны бала да белә. Ә синә мин төшендерәм.

— Мин бала түгел шул. Мин аңлыйм — далада ул пахтаны атабаба кәсебен мөкатдәс иткән бакча осталарын рәнҗетмәстән, аларны кузгатмастан да игеп булыр иде. Илнең яңа җирләрне ачу тәҗрибәсе моңа мисал... Хак әйтәсең, тирә-юнь базарында Куйкинең даны зур иде. «Куйки — ил күрке» дигән әйтем дә бар иде элгәре. Хәзер моны синең белән миннән көлү өчен генә әйтсәләр инде. Гүзәллек, матурлыкны акчага тиңләү кебек үк көлке бу, аңлыймсың?

— Күпертмә ул кадәр. Экономик яктан зәгыйфь, киләчәксез районнан дәүләткә ни хәер, син аны беләсең. Тик үз хисләрең генә моңа карыша.

— Алайса, читкәрәк китеп, Кырым, Кавказның тау-ташлы диңгез буйларын алыйк. Алар да бит пахта да, башка төр хәзинә-байлык та бирми дәүләткә. Гүзәллек, шифалы саф һавалары белән кыйммәт алар халыкка. Ә без... И!

Гариф әкә тагын шәрабка үрелде.

— Уңышсыз киная... Аша, котлетың суына.

Мария Васильевна, үз-үзен тыеп, өзек-өзек кенә җавап бирсә дә, эчтән кайнап, янып утыра иде. «Нишләмәкче соң бу? Обкомның җиде ел дәвамында эшләгән эшен, өлкәнең данына әверелгән яңалыкны инкарь итмәкчеме? Юкка чыгармакчымы? Кем аңа андый хокук биргән? Ни өчен ул үз-үзенә баз казый әле? Буталчык, мәгънәсез фикерләр, тәкъдимнәр... Юк, мин аннан моны көтмәгән идем», — дип уйланды, газапланды ул. Күтәрелеп Гарифка карады. Тулы йөзе агарынып калган, төсе качкан иде. Гарифны белә: күпме эчсә дә исермәс, тик шулай төсе генә үзгәрер аның.

— Коммунизмның материаль-техник базасын төзүчеләр без дибез, Ариф. Бөтен ил-мәмләкәт шуның белән мәшгуль. Ә син һаман хис, тойгы тирәсендә чуалып йөрисең түгелме? Кемдер кемнедер рәнҗеткән, җәберләгән төсле синә... — Мария Васильевна табын яныннан ук торып китте, иңенә дебет шәлен бөркәнеп, якындагы шкафка барып сөялде. Гариф әкә исә, башын иеп, сүз катмый гына уйланып утыра бирде.

Ә тышта әллә кайчан инде караңгы төшкән, урам фонарьларына күптән ут алынган иде.

— Нигә тын калдың? — диде Мария Васильевна ни дә булса әйтергә кирәген уйлап.

— Исемә төшеп китте әле... Сугыш бетүгә иң элек атамны кайтып күрдем. Аннан соң Сарагөл янына Шивилгәнгә киттем. Шул беренче таңда ук түзмәдем, Сөмбелтамчы чишмәсенә төштем. Бик тә сагынылган иде. Туган җир, якыннар төшкә керде исә, Сөмбелтамчы да искә төшми калмый иде бит. Ул бит минем яшьлегем хатирәсе булып күңелгә сеңгән. Беләмсең, ут эчендә йөргәндә, төнге разведкаларга барганда-кайтканда берәр төрле чәчкә-гөлгә юлыксам да, ялгыз утырган ап-ак каенны күрсәм дә, үзебезнең шушы яклар искә төшми калмый иде. Бервакыт шулай бер күлгә, күк гөмбәзедәй күм-күк, тып-тын күлгә юлыктым. Нигәдер шундук күземә яшь тулды. Адашып өен тап-

кан нәни көчектәй, сабый баладай, тетрәнә-тетрәнә ахмакларча еладым. Сөмбелтамчы күз алдыма килде... Ә син «һаман хис, тойгы тирәсендә чуалу» дисең. Юк, мин алар «тирәсендә» түгел, алар минем үземдә бугай.

Мария Васильевна аның җилкәсенә кулын тидереп җай гына селеккәндәй итте. Гариф башын күтәреп, аның көлемсерәгән йөзеннән: «Уян, кай якка китеп калдың, башыңа киттемәллә?» — дигән мәгънәне аңлады.

— Ярый... менә син докладыңда ничаклы сан санап чыктың: тонналар, гектарлар, эш көннәре, километрлар... Ә кешенең куанычы, минем шушы күз яшьләрем, карлы тау түбәләренең, инеш-чишмәләрнең йөрәктәге эзе калыккан бер күңелнең рәнҗеше, башка берәүнең ихласы, кешенең уй-хыяллары — әйтче, боларны ничек, нәрсә белән үлчисе? Кайсы җирдә, кемгә сөйлисе?

Мария Васильвна: «Ярар инде, куеп тор, соң бит хәзер», — димәкче иде дә, тагын сабырлыгын җыеп, Гариф каршына барып утырды.

— Мин Ватан сугышы батырыбыз Түйчи Ирегетовны якыннан белә идем, — дип дәвам иттерде сүзен Гариф әкә. — Аңлы, белемле егет, яшь коммунист иде. Күпләр аны белми, коеп куйган батыр итеп кенә беләләр. Бик нечкә күңелле, гөл ярата иде ул. Һич иренмәс, иртәдән кичкә кадәр гөл-чәчкә тирәсендә кайнашыр иде. Синеңчә, шул егет дошман дзотына күкрәген куяр алдыннан нәрсә уйлагандыр дисең?

— Белмим, нәрсә соң?

— Андый вакытта уйланырга вакыт калмый... Нинди көч аны дзотка ташланырга мәҗбүр иткән, син шуны әйт?

— Үч газабы, үч ярсуы.

— Юк. Юлбарысны ярсурак та диләр...

— Аң.

— Ярсу-гайрәттән гайре ни кирәк? Коммунист йөрәкле булу кирәк, минемчә.

Ике бармагы белән маңгаен кысып, Мария Васильевна арыган кыяфәт белән:

— Бу сүзләрнең барысы да хак. Ләкин син районның хуҗалык эшләренә бары тик шул яктан гына карасаң, без ул чакта, минем чамалавымча, синнән һич нинди планның үтәлешен көтеп ала алмаячакбыз, — диде.

«Акыл дисеңме, ихтыяр көче дисеңме — һәммәсе бар, һәммәсе житү. Их, шунда бераз хис-хыялга да урын булсачы! Ә бит бар иде. Алары да бар иде. Нинди борылыш, сикәлтәләрдә сибелеп-югалып калган соң алары!» — дип уйлады Гариф әкә, Мәрьямнең кыз чакларын күз алдына китереп.

Ул чакта Мәрьям кызарып пешкән алма кебек, һич тик тормас бер чая кыз иде. Әледән-әле аның чыңлатып, яңгыратып көлеп җибәрүен ишетүләре ни тора! Гариф рабфакның чыгарылыш курсында укый, ә ул Гарифтан бер ел соң кергән иде. Күпләр Гарифка: «Бу кызыйның сиңа күңеле төшкән», — диделәр. Гариф үзе дә моны чамалый, Мәрьямнең башка кызлардан көнләшүен сизенә иде. Һай, ул яшьлек! Берәүнең сине читләрдән көнләшеп, үз күреп йөрүе нинди бәхет икән бит ул! Бер сылуның үзеңә текәлеп карап алуын күрү күңелләргә нинди шифа!

Тик ул көннәрдә яшьлек дәрте белән очынып йөргән мәһабәт кыяфәтле тау бөркетенә сокланып караучылар бер ул гына түгел иде шул. Шундыйларның берсе — беренче курсның бик тә садә, мөлаем кызы, кышлактан яңа гына килгән Нәзми исемлесе иде. Ул Гарифны ни сәбәпле үз иткәндер, тик Гариф кына аңа шундый ук хис-тойгы белән җавап бирә алмады. Ә бер көнне ул кыз аңа мәхәббәт хаты язып җибәргән булган. Тик ул хат ни сәбәптер директор кулына эләккән иде.

Бу 1929 елны булды. Ул вакытта мондый хәл бик хәтәр тоела, җыелышларда, учкомнарда, комсомол комитетларында тикшерелә иде. Нәзминең мәхәббәт хатын да директор гомуми җыелышка куйды. Икесенең дә хәле бик мөшкелләнде: Гариф якламаса, Нәзмине укудан куачаклар, яклады исә, үзен дә гаепле санаячаклар иде. Инде ни эшләргә? Ә җыелыш бик кискен, берәү дә Нәзмине яклардай сүз әйтми. Башта бериш карт укытучылар әхлакый тотнаксызлыгын, «бозыклыгын» тиргәп, фаш итеп чыкты. Кайбер егетләр, кызлар шул ук тегермәнгә су койды. Һәм, ниһаять, сәхнәгә ярсып, кабынып Мәрьям килеп чыкты. Гариф әкәнең әле дә күз алдында: ап-ак беләкләре ачык, җиңел-житез хәрәкәтле. Рабфак егетләре бердән аңа текәлде — бу кыз гүя үзенә тартып тора иде. Ул сөйли башлау белән залдагы һәркем, гүя аннан очкын алып, бердәй кузгалып, кабынып китте.

— Үзбәк кызының бүген «сүәмен!» дип ачыктан-ачык әйтүе үзе бер яңалык ич! Үзе бер җиңү! — дип сүз башлады Мәрьям. Ул кызыпкызып бик озак сөйләде. Бу хәл өчен Нәзмине гаепләмәскә, мактарга кирәк дип, җыелышны җанландырып, мәсьәләгә икенче юнәлеш бирде.

Бу күренеш Гариф әкәнең күңеленә мәңгегә сеңеп калган иде.

Һай, бар иде ул Мәрьям атлы кызда йөрәк тә, яшьлек дәрте дә! Бар иде, бар!..

— Сүзебез килешмәде, Гариф. Мәйлең, алайса, иртәгә үк Беренченең үзе янына кер.

Гариф әкәнең әле генә күз алдында торган чая, үзсүзле кыз Мәрьям юкка чыгып, янә бүгенге Мария килеп басты. Бу — аның сүзләре иде.

— Юк, — диде Гариф әкә, кулына папирос алды, ләкин аны кабызмады. — Мин синең белән сөйләшәм. Дөрес, бүген күп нәрсә әйттем, ялыктырдым. Үз итеп ахыргы сөалемә җавап бирче: яшьлегеңне син кайчан, кай җирдә югалтып калдырдың, Мәрьям?!

Мария Васильевна сискәнеп башын күтәрде. Үтә авыр булып китте аңа бу сүз. Җавап бирә алырлык та түгел. Нигәдер аптырап калды. Газаплы уйлар йөрәк тибешен тизләттеләр.

Ашханә ишегендә апасы күренде. Ул да көрсенеп Марияга карап тора кебек иде.

— Миңа ни дип әйтсәң дә, районнардагы хәлләр хакындагы тасвирың хата, — диде Мария Васильевна.

— Минем фикер генә түгел, күпләр белән очраштым.

— Элеккеге Шивилгән базарчылары белән, алыш-биреш юлында сөяге каткан качаклар белән гәпләшсәң, алар ни димәс!

Бу сүзләрне әйткәндә Мария Васильевнаның тавышы тимердәй чыңлап китте. Ул янә аяк өсте баскан иде. Гариф утырган җирдән генә аның ачулы йөзенә карап, йомшак кына дәште:

— Мәрьям, син, обкомның секретаре буларак, үз урыныңда түгелсең, — диде.

Шул сүз белән ул, урыныннан кузгалып, чөйдән пинҗәген алды. Ишек катында торган карчыкка: «Аш өчен рәхмәт», — диде дә, кулын үбеп, саубуллашып чыгып китте.

Мария Васильевна аны озата чыкты. Ә ишек ябылгач, ак буяулы салкын ишек яңагына терәлеп, хәлсез генә байтак басып торды. Ашыгып янына килгән тутасы аның сыгылып төшкән иңбашына җылы кофта япты, кочып алды.

— Кайчаннан бирле кыйналасың шуның белән... Ир башы белән... Нигә юл куясың шуңа? Нишләп йөрәккә тия ул? — дип әрнеп, җәлләп, Марияның хәленә кереште апасы.

Мария Васильевна хәлсез генә елмаеп:

— Куй... калдыр, апа гынам, — диде.

...Урамда машина шавы тынган, төн карангы, төнге җил тирәк яфракларын серле генә шыбырдата иде. Гариф башта ашыгып барды, инде берара киткәч, Мария Васильевна йорты каршына кире борылып килде. Өченче катта фәкать Мәрьям тәрәзәсендә генә ут яна иде. Ул кәләпүшен кулына алды, озак кына шул тәрәзәгә карап, бер урында таптанып торды, шуннан соң гына бөтенләйгә китеп барды. Өлкә комитеты тирәсендәге бер мәйданда калдырган иде машинасын. Шунда юнәлде. Хәзер үк районга кайтып китү нияте белән, кабинага кереп утырды. Әмма моторын кабызмады, сөялгән килеш тынып калды. Якын-тирәдә кемнәрнеңдер көлешә-көлешә йөргәнлеге, тагын ниндидер ят авазлар ишетелеп тора иде. Ул, төнге авазларга колак салып утыра-утыра, йокымсырап китте шикелле. Төш күрде. Төшендә аның Анабибие иреннәрен бөрештереп елый икән: «Бөтенесенең кечкенә сеңелесе бар», ди, имеш.

Гариф әкә, уянгач та, Анабибинең әлеге иншасын хәтерләп елмаеп куйды. Төштә күргәне өндәге белән буташкан икән. Япадан-япа ялгыз шул балакай. Хәзер каникул вакыты. Тимер пионер лагерена вожатый булып китте. Бу бала берүзе өйдә, зар-интизар булып утырадыр... Атасы да бүген менә бу җирдә әле.

Шәһәр урамнарына җан керә башлады. Инде таң аткан, тук-тук аяк тавышлары, кибет, гараж ишекләренең шыгырдап ачылганы, сөтчеләрнең чөкердәшкәне ишетелеп куйгалый. Гариф әкә инде күзен ачып, кузгалырга хәзерләнгән иде. Шул чак ул кемнеңдер:

— Хуҗайка, бинаграт чканка![1] — дип, карлыккан тавышы белән кычкыруын ишеткән шикелле булды. Бигрәк таныш тоелды аңа бу тавыш. Як-якка каранды. Беркем дә күренми иде. Урам аша, йокылы баласын җитәкләп, ашыгып бер хатын гына үтеп бара.

Бу бала янә Анабибине, аның төштә: «Бер нәни генә сеңелем булсачы», — дигәннәрен исенә төшерде. Булса, кызы көне-төне шуның белән мәш килер иде. Әллә берәрсен асрауга алыргамы?

Гариф әкә машина тирәли әйләнеп чыкты, тәгәрмәчләрен типкәләп карады. Янә Мәрьям исенә төште: «Мәрьям ни хафа кылды икән? Артыграк әйтелде түгелме? Әллә баш иеп барып кичерүен үтенсенме икән?..»

Арырак шарлап аккан фонтан тавышы Гариф әкәне ул газаплы уйдан бүлдерде. Бу ни хәл әле? Кешеләр аңа эш көнен башларга дип ашыгалар, ә ул һаман төнге төшләре белән әвәрә килә. Фонтан янына килеп битен чылатты, иске чиркәү янәшәсендәге җиләк-җимеш базарына кереп, бер кәсә катык эчте. Инде һич тоткарланасы түгел иде. Ашкынып машинасына килгәндә, янә баягы карлыккан тавышны ишетеп, туктап калды.

— Хуҗайка, бинаграт чканка!

Әле үзен күрмәсә дә, тавышыннан таныды бу юлы.

— Симёгач!? — дип, ул тегенең каршына төште. Чыннан да бу Шивилгәннең Иргашы икән. Ул җиңел брезент итектән, өстендә җәйге ак чапан, биленә кат-кат кыек яулык бәйләгән, шуңа төрле зурлыктагы кайчы-пычаклар, янә әллә нәрсәләр кыстырган иде. Озын саплы зур кайчысын иңбашына элеп куйган. Боларның барысы йөзем агачын кисү, карау өчен кирәк корал иде.

— Әй, Ариф әкә икән бит. Әссәламегаләйкем! — диде аңа, ике кулын сузып, каушап калган Иргаш. Ул кечерәк кенә буйлы, ә «Симёгач» кушаматы аңа атасыннан калган иде. Ул хакта авылда болай сөйлиләр: Иргашның атасы, авылның оста бакчачысы, көнкүрештә исә садәнең дә садәсе булган. Кем ни әйтсә, шуңа ышана икән. Юл буендагы

[1] Йөзем агачының кирәкмәс ботак-сатагын кисеп, көзгә эшкәртеп калдыручының тәкъдим-мөрәҗәгате.

телеграф баганаларына чыбык тартучы бер монтерга юлыга бу. Иргашның атасы моңардан: «Нәрсә эшлисең?» — дип сорый. «Менә, багана утырткан идек тә, ялгыш утыртылган. Шуны үлчим. Кире алу хәтәр кыйммәткә төшә икән. Инде ни эшләргә белмибез. Әллә сатарга гына инде үзләрен». Иргаш атасы уйга кала. Юл буенда ул симёгачлар хисапсыз күп, бакча кирәк-ярагына, терәүгә бик тә кулай, үзләре кыйммәт тә түгел икән. Монтер белән сәүдә озакка сузылмый, Иргашның атасы булган акчасын санап монтерга тоттыра. Шуннан бирле аларның яңа кушматы — Симёгач. Гариф әкә шунысын да белә — Иргаш, атасы кебек үк, бакчачы һөнәрен нык үзләштергән оста иде. Кушаматы гына түгел, әле кәсепкә чыккан һөнәре дә ата мирасы иде. Яшьли эшләп үскән кеше. Шивилгән халкы аның хакында: «Симёгачның бакчасы мәрҗән-йөзем барчасы», дип юкка гына такмакламый иде.

Дөрес тә, сентябрь башында инде ул бакчада яфрак күренмәс, тәлгәш-тәлгәш җимеш каплаган булыр аны. Бер сабагы бер коштабак булыр. Мәрҗән кеби йөзем-йөземгә булыр. Ул үтә күренмәле җимешләрнең шәфәкъ нурында әйтерсең эчтән шәм балкып тора.

— Нишләп йөрисез биредә, Иргаш иптәш? — диде Гариф әкә, чак кына «Симёгач» кушаматын кабатламый калды.

Болай гына, — дигән булды Симёгач, иңбашына аскан озын кайчысын кая куярга да белми торды. — Райком икәнсез, әкә, ишетеп шатландык.

— Сүзне бутамый тор. Далага, яңа совхозга күчеп төшмәдегезмени?

— Күчеп төшкән идек, әкә.

— Соң нәрсә? Күңелгә ятмадымы?

— Хак әйттегез, әкә, булмый.

— Совхоздан качып, биредә капкадан капкага йөреп, кеше бакчасын карыйсың, ә?

Иргашның сакал-мыек баскан йөзе бүзәреп китте, тайпылып читкә карады.

— Бакчалар харап була, әкә. Кайсы йортка кермә — чир. Аны хәзер кисмәсәң ни булыр? Таудагы бакчалардан тарала чир, — дип, үзенең сырхау баласы хакында сөйләнгән сымак сукрана башлады Иргаш.

— «Хуҗайка, бинаграт чканка», имеш. Ә пахтаны кем игәр, кем карар? Үзлегеннән үсми бит ул... Чыдамсыз...

— Юкка ачуланасыз, әкә. Мине дә чыдамсыз дисәгез. Эшкә чыдыйм мин. — Иргаш берара каралып каткан уч төпләренә карап торды, «менә мин кем» дигән сыман, кулындагы каты пружиналы ботак кискеч кайчыны уйнатып алды. — Кайберәүләр кебек акча дип йөрүем түгел. Бакча бир син миңа, райком әкә. Чүл уртасында булса да бакча булсын, барырмын, эшләрмен!

Райком секретаре аның соңгы сүзләрендә ихласлык тойды, үз эшенә бирелгән кеше икәнлеген чамалады. Бу хис аңа да таныш, якын иде. Шулай да ул кырыс кына:

— Качак белән эшем юк, йөри бир! — дип, ачуланып китеп барды.

Китүен китте, ә Иргаш ачынып калды. Исем-аты районга мәгълүм бакчачы, күптән тормышта үз урынын тапкан ир-егет бит, югыйсә. Ә хәзер менә урам таптаучы. Гариф әкә дә аңа бер дә юктан җикеренеп ташлады. Ул гына гаепләме соң күңел биргән, үзенә шатлык-бәхет китергән кәсебеннән аерылуга?

Шуларны уйлаганнан соң Гариф әкә янә Иргашны эзләп китте. Иргаш шул ук почмакта, җилкәсе белән таш диварга сөялеп, моңсу гына утыра иде. Гариф әкә аны чакырып алмады, каршысына үзе барып басты. Тамак кырып куйды. Иргаш, сискәнеп, башын күтәрде.

— Насың бар шикелле, Иргашбай. Миңа да өлеш чыкмасмы? — диде.

— Бар, бар, әкә. — Иргаш кабаланып биленә уралган яулыкларын актара башлады. Җиз белән нәкышләнгән нас савытының да йөзем агачына төшкән кебелә дымыннан күгәреп яшелләнә башлавын күрде Гариф.

— Һай, бу кебелә харап итә икән бакчаларны, — дип көрсенде ул, сузылган савыттан бер чеметем вак нас тәмәкесе алды. — Аны бетерүе кыенмы?

— Тирә-юньгә таралуын тоткарлый алсак, җинел булыр иде.

— Шулаймы.... — Гариф әкә ни әйтергә аптырагандай кесәсеннән түбәтәен чыгарып каккалады да башына киеп куйды. Кояш инде кыздыра башлаган иде. — Иргаш, син Шивилгәнгә кайт булмаса.

Иргаш, аптырап, аңа күтәрелеп карады.

— Бөтенләйгә... Райком әкә кушты диярсең.

— Котыртма инде, Ариф әкә...

— Хак әйтүем. Анда да карт-коры гына калган. Бакчалар харап була дисең ич. Мансур атаны да кайтарырбыз. Көчең кызганмый тырыш син анда. Әкренләп Сөмбелтамчы кешеләрен дә кайтарырбыз.

— Ариф әкә! Райком әкә, чынмы бу?

— Сөйләштек — бетте. Бала-чагаң нихәл, сау-сәламәтме һәммәсе?

— Яхшы, бик яхшы.

— Аларны да алып кит. Өйләрне, бакчаларны рәтләгез. Соңрак үзем барып карармын. Акчаң бармы?

— Юк, акча кирәкмәс миңа... Рәхмәт, барын да сез әйткәнчә эшләрбез. Безнең бәхетне үзегез килеп күрегез, әкә. Шивилгәнне яңадан гөлбакча итмәсәмме... атам каргар...

Аның йөзе яктырып китте. Хәтта Гариф әкәне ул кочаклап ук алмакчы иде. Тик үз-үзен тыеп, кулын гына сузып калды. Бу хәлгә Гариф әкә дә сөенде. Күңеле үсеп киткәндәй булды.

— Хәерлегә, Симёгач! — диде ул, саубуллашканда җилкәсеннән какты.

Гариф әкә өенә кайтып кергәндә, ишегалдына бала-чага тулган иде. Алар шундук чыр-чу килеп машинаны урап алдылар. Анабиби, атасы кочагыннан котылгач:

— Ах, бу шаяннар, — дип зарланган сыман, төрлесе төрле җирдә аунап яткан савыт-сабаны, урындык, примус ишеләрне җыештырырга кереште.

Гариф әкә, майкадан гына чыгып, ишегалдына, бакча сәкесе тирәсенә су бөркергә кереште. Йортта һава шундук җиңеләеп китте. Кечкә чәйдән соң ул, караштырасы китап, газеталарын күтәреп чыгып, шул сәке янәшәсендәге тәбәнәк өстәл янына утырды: берничә атна элек тау районнарының экономикасын өйрәнергә керешкән иде.

Аш-су өстәлен җыештыргач, Анабиби дә шунда килде. Аяк очына басып, үрелеп, өстәл өстендәге лампочканы кабызды.

— Мәрьям апаны күрдегезме, дәдә?

— Күрдем, сиңа сәлам әйтте.

— Кунак йортында кундыгызмы?

— Әйе.

Анабиби шулай әле ары, әле бире килеп, үзенә юк-бар эш табып, сөйләнә бирде.

— Яхшы миһманханә идеме? Иң биек дүртенче катта идеңме, дәдә?

— Ә-ә? Әйе, әйе, дүртенче катта идем.

— Палас-әйберләре әйбәт идеме? Матурмы?

— Каефеңә карап инде, кызым. Күңел якты чакта каефең дә әйбәт була. Эшеңнән канәгать икәнсең — һәммә нәрсә матур күренә ул.

Гариф әкә шул арада дәфтәренә нәрсәдер язып куя, китап битләре арасына кәгазь кисәкләре кыстыргаларга да өлгерә иде.

— Дөрес әйттең, дәдә. Миңа да вакыты белән күңелле, ә вакыты белән... Ни сәбәптән бер яхшы да, бер ямандыр һич әйтеп бирә алмыйм. — Анабиби, сәкегә йомшак җәймә өстенә утырып, аягына күлмәк итәген урады. — Тимер бу хакта бер көнне бик кызык итеп әйтте: һәммә нәрсәнең мәгънәсе бар, һәммә нәрсәне төшендереп бирә алам, ди. Бәхет тә, мәхәббәт тә гап-гади төшенчә, ди... Сөйләп тә бирде.

— Я, я, ничек диде?

— Вай, хәтеремдә калса икән?! Соңыннан Камилә апа аны акылга өйрәтте. Камилә апа — аларның укытучылары. Мәктәпкә быел килде. Үзе яшь-яшь, үзе укытучы, кызык бит. «Әйдәле, булмаса, роза гөленең исен сүз белән тасвирлап бир безгә»,— диде.— Анабиби «пырх» итеп көлеп алды.— Гаҗәп инде, Тимер ни дип сөйләргә дә белми, бик уңайсыз хәлгә калды. Мактанмасын, шулай бит, дәдә?

— Һай, кызым! Сүз белән һич әйтеп, төшендереп булмастай никадәр нәрсә бар дөньяда, — дип, Гариф әкә алдындагы китабын ябып куйды да бер тарафка текәлеп карап тора башлады. Баядан бирле радиодан ишетелеп торган моңлы арияләр тынган иде. Төне дә тыптын. Бары тик баш очындагы лампочканың гына «черр» килеп янганы ишетелә иде. «Ник тын утыра бу кызыкай» дип караса, Анабибинең дә күз кабаклары авыраеп йокы белән тартышуын күрде ул.

— Миңа хәзер яхшы, — диде кызы, иреннәрен көчкә кыймылдатып. — Ни өчен шулай икәнлеген дә беләмен... Чөнки сез өйдә бүген...

Шул сүз белән ул утырган килеш кенә йоклап та китте.

Гариф әкә аның сөйкемле йөзенә бер текәлеп карап куйды да, күңеленә тагын ямансу булып калды. Инде эшнең бүгенгә җитәрен чамалап, ул да урыныннан кузгалды. Анабиби өстенә яхшылап япканнан соң утны сүндереп, китап-журналларын култыгына кыстырды да, өйгә кереп китте.

...Ул элекке район газетасының саргайган битләрен актарып утыра. Нindидер тантанага багышланган бер сәхифәдән, «мин хакмы» дигәнрәк бер кыяфәт белән, аңа Симёгач Иргашы карап тора иде. Иске газетадагы шул иске рәсем Гариф әкәгә бик тә кызык тоелды. Ә сурәт янәшәсендәге мәкаләдә Иргаш тау кышлагында яшәүче якташларын яңа җир, яңа совхозларга күченергә өнди иде. «Күчешкә теләк белдермәгән искелек калдыкларының безнең арабызда булуы мөмкин түгел», дип, бик тә китапчалап язган иде ул мәкаләсен. «Арыслан йөрәкле азамат батырлар ул чүл-даланы гөл итәр... Шул ватандашлар сафында булуым белән мин бәхетлемен»... дигән. Менә сиңа Иргаш! Кем аңа ышанмасын — ул бит районның алдынгысы?!

Хәер, бер Иргаш кына моны әйтсә икән. Газетаның һәр саны диярлек шундый «арыслан йөрәкле ватанпәрвәр... җиңүчеләр» өндәмәсе белән тулып чыккан. Гүя шул сусыз чүл-далада гына икән барлык бәхет-сәгадәт дип уйларсың. Әйтерсең бөтен хәзинә шунда тупланган да, тик әлегәчә аны күрүче, белүче генә булмаган. Инде хәзер элеккеге җайлы тормышны, йорт-җирләрне калдырып, шул хәзинә артыннан ил белән шул сусыз далага күчеп утыру кирәк икән. Гүя башкача булуы мөмкин түгел.

Иргашның рәсемнән шулай карап торышын, гел китапчалап язган сүзен хәзер шәһәр урамында «Хуҗайка, бинаграт чкан» дип йөргән Иргаш белән чагыштыр инде... Бөтенләй башка кеше диярсең. Әйе, никадәр катлаулы бу тормыш...

Юк, тормышны, кешеләрне гадиләштереп, бер яклы гына күрергә теләү үзен акламый. Тормыш үзенә мәгълүм үзәннәр буйлап ага бирә. Ул агымга булышу гына кирәк. Менә ул, зур бер район җитәкчесе, көн-төн шул тормыш үзәгендә кайный, кыр-далада да, идарәдә дә кешеләр белән даими очрашып тора. Аларның күбесе бик гади, әйбәт. Бик сирәге генә үзен газетта язылганча «батыр» дип уйлыйдыр, шәт.

Берәү дә берәүгә охшамаган, һәркем үзенчә — үз холкы, үз акылы. Ләкин аларның һәрберсе үзенә бер хәзинә. Шулай ук совхозның да, колхозның да үз уңышы һәм әлегә хәл кылынмаган кыенлыгы, җитешсезлеге бар. Гариф әкә фикеренчә, яна, чирәм җиренең чын батырлары ул хәрби хезмәттән кайткан гаскәри егетләр, яисә тәҗрибәле җир белгече, һөнәр осталары, үз теләкләре белән килгән йөзләрчә комсомол яшьләр булырга тиеш. Ә мәҗбүри күчереп китертелгәннән яки үзе адашып килеп тә, күңеленнән элекке тормышын, элекке йорт-бакчасын оныта алмаган, шуны сагынып яшәгән кешедән ни өмет? Аларның күбесе кире китәчәк. Әйе, биредә, бу юнәлештә күп төрле гадәт, мөнәсәбәтләрнең, гаилә тормышы, кәсеп-һөнәр, тәкъдир-бәйләнешләренең «кирәк» белән «мөмкин» дигән төшенчәләрне үзара килештереп, чамалап эш иткәндә генә уңышка ирешеп булачак иде.

Гариф әкә инде моны тоя да, күрә дә башлады шикелле. Соңгы вакытларда ул эшкә шул чаклы бирелеп тотынды ки, инде үзендә бетмәс көч-гайрәт сизә, хәтта берникадәр канәгатьлек хисе дә кичерә башлаган иде. Райком утырышларында да элеккедәй тын гына, тыңлап кына утырмый, ерак кышлакларга да даими йөреп тора. Райкомга кеше чакыртып, хәл-әхвәлне алар аша гына белеп эш итүне кире какты. Аның һәр нәрсәне үз күзе белән күреп, үз күңеле аша үткәрәсе, шуннан соң гына нәтиҗә чыгарасы, кирәк чараны күрәсе килә иде. Ул сәфәр вакытында кешеләр белән сөйләшеп тә, бәхәсләшеп тә ала. Хәтта урыны белән тавыш күтәрергә дә туры килгәли. Иң куанычлысы шул — әкренләп эшенең нәтиҗәсе күренә башлады. Максат ачыклана барды. Районның һәр төбәгендә хәзер Гариф әкәнең якын фикердәше бар. Дөрес, аны, ул алып килгән тынгысызлыкны куралмаучылар да юк түгел. Әмма ул һаман йөреп тора, инде ул барып күрмәгән хуҗалык, аны танымаган кеше хәзер районда юк диярлек иде.

Беркөнне ул, ерак совхоздан таң алдыннан гына кайтып керүе сәбәпле, райкомга соңлабрак килде. Караса — кабул итү бүлмәсе тулы халык, аны көтәләр. Совхоз, колхоз җитәкчеләре, партком секретарьлары килгән, редактор Назаров та шунда ук. Гариф әкәнең күзе иң элек Түләгәнгә төште: аны ул күптән көтә иде.

— Кичерегез, — диде Гариф. Һәммәсе белән күреште дә, барысын берьюлы эчкә, кабинетына алып кереп китте. Кабинет зур түгел. Утыргычлар тәртипсез куелган диярлек, шкаф ишекләре ачык, китап-журнал кайсы кая чәчелгән. Хуҗаның күптән үзендә булмавы күренеп тора.

Гариф әкә өстәл янына үтмәстән үк Түләгән янына тукталды да:

— Кечкенә Фирүзә нихәл? — дип, сүз башлады.

— Рәтләнде, Ариф әкә, рәхмәт. Үзем менә диссертацияне яклау вакытын кичектерергә рөхсәт алдым, — дип, Түләгән аңа кулындагы телеграмманы күрсәтте.

— Ни сәбәпле кичектерәсең аны?

Түләгән кояшта чуендай каралган кулы белән киң маңгаен сыпырып куйды. «Чынын әйтергәме?» дигән сыман, як-ягына каранып алды. Бүлмәдәгеләрнең кайберсе үзара гәпләшә, бер ишләре райком секретаре белән Түләгәннең ни сөйләшүенә колак салып утыра иде.

— Я, хуш, ни өчен? — дип кабатлады Гариф әкә.

— Әлеге экономик совет инде... үзе бер институт бит.

— Аның ни бәйләнеше бар?

— Ә ул минем күземне ачты, Ариф әкә. Әлегә бик юашланып йөрелгән, күп нәрсәне күреп бетермәгәнбез икән. Эчке хуҗалык хисабы үзе бер тема дип уйладым әле. Сезнең ул тәкъдим безгә чүпрә кебек булды: хәзер аның белән кызыксынмаган, безгә ярдәм итмәгән кеше совхозыбызда калмады кебек. Һәркем ни дә булса берәр эш башкара. Мәсәлән, «Водхоз» безнең алтынчы бүлекчәгә биргән суны бер ярым

мәртәбә арттырып язып килгән икән. Кичә шул бүлекчәгә бардым — су юлына да, электр линиясенә дә счетчик куйганнар, төгәл исәпләп баралар. Хисапчылар курсы ачтык, — дип, Түләгән боларның барысын да сөенеп сөйләде. Аннан соң папкасыннан кәгазьләр алып: — Менә болары киләчәк эш планнарыбыз. Моңарчы миллионнарны җилгә очырганбыз икән... Киләсе елдан, әгәр дәүләт планы арттырылмаса, совхоз рентабельле эшли башлар дибез, — диде.

— Ә план арттырылса?

— Нишлисең бит...

— Бу хакта уйлашырга кирәк, — дип, Гариф әкә Түләгән күрсәткән эш планнарын, исәп-хисап таблицаларын карап чыкты. Башкалар да бу сөйләшү белән кызыксына, алар да ара-тирә сүз катып куялар иде.

— Минем карашымча, Түләгән, сезгә тагын берничә мәсьәләгә игътибар итәсе бар. Иң беренчесе: бар нәрсәне көйдергән «әфгани» җиленә каршы көрәш. Моның өчен нәрсә эшләп була? Галимнәр белән багланышка керергә кирәк. Басу читләренә агач утырту өчен махсус бригада тоту кирәктер бәлки. Икенчедән, элекке бакчачылар тәҗрибәсенә таянып, совхоз бистәсен яшелләндерү чарасына керешергә, йорт тирәләренә җимеш бакчалары утыртуга хәзерләнергә кирәктер, минемчә.

Түләгән боларны язып куйды. Бүлмәдәгеләр җанланып төрлесе төрле тәкъдим әйтә, сорау бирә башлады. Аннан да моннан:

— Иптәш Ачилов! Ариф әкә! — дигән авазлар ишетелеп тора иде. Гариф әкәнең әле Түләгәнгә әйтер сүзе дә бетмәгән икән:

— Сезнең экономик совет ныклап эшкә керешкән икән, менә райкомнан беренче үтенеч: үзара ярышның нигезле, тикшерелгән билгеләмәләрен чамалап, шартын хәзерләү — сезнең өстә. Әйтче, Зыяханов ничек, комачауламыймы?

Түләгән ни дип җавап бирергә белми торган арада, телефон шалтырады. Гариф әкә өстәлне әйләнеп үтеп трубканы алды.

— Тыңлыйм! Кем? Ә-ә, Симёгач! — диде ул, ирексездән куанып. — Тыңлыйм, тыңлыйм, Иргашбай... Бакчалар ни хәлдә? Нәрсә, нәрсә? Кем килде? — Гариф әкә бер мәлгә сүзсез калды, йөзе агарып киткән төсле күренде. — Кайчан? Хуш. Кышлак советында да, шифаханәдә дә булды инде, алайса? Кызык... Тагын күренмәдеме соң?

Трубканы куеп, кабинеттагыларга күз йөртеп алды. Ни хакында сөйләште әле алар? Гариф әкәнең хәтере чуалып киткән иде, тик үзен тыеп кына, башланган әңгәмәгә кушылмакчы итте. Янәшәсендә генә Назаров икән, аңа шаярткан төсле итеп:

— Сезнең элекке каһарманыгыз шалтырата... Иргаш, — диде.

Редактор аның ни әйтергә теләвен төшенмәде. Башкалар да көлмәделәр. Гариф әкә күңелендәге үзгәрешне чамалап өлгермәгән бер совхоз директоры гына баягы сөйләшүне дәвам иттерергә ниятләп:

— Ачилов иптәш, нишләп андый экономик советны бездә оештырмадык? — диде.

Аңа кушылып тагын кемнәрдер:

— Без дә һаман читтә калабызмы?

— Моңа райкомның махсус карары кирәкме? — диештеләр.

— Белмим, — диде Гариф әкә, елмаеп. Ул сөйләшүнең нигә килеп төртелүен аңлады. Әйе, үз эше, үз йомышы белән килгән бу төрле-төрле кешенең, үз йомышларын онытып, Түләгән сөйләгәнгә мавыгып утыруларын ул күреп торды. Аларның күбесе өчен әле бу яңалык, ачыш иде. Шул сәбәпле аларның үз мәсьәләләре икенче планга күчкәндәй булды.

— Әйе, райком бу яхшы тәҗрибәне районның башка совхоз һәм колхозларына да тәкъдим итәчәк, — дип төшендерә башлады ул. Тик

кабат Иргаш шалтыратуын хәтерләп: — Җәмәгать, әле күп нәрсәне ачыклыйсы, киңәшәсе булыр. Менә Түләгән сезгә аңлатыр. Фикерләшегез. Минем зарур эшем килеп чыкты, — дип сүзне туктатты.

Шулай диде дә кабинетын боларга калдырып чыгып китте. Тик ашкынып урамга чыккач кына, кая барырга кирәклеген белмәгән сыман аптырап калды. Нишләргә соң аңа? Әйе, иң әүвәл Анабибине кайтып күрергә! Алып китсәләр?!

Иргаш бик күңелсез хәбәр әйтте аңа. Анабибигә ата тиешле Исраилов дигән берәү Шивилгәнгә кайткан икән. Кешеләрдән сораштырып, кышлак советы, шифаханәләрдә булып Анабиби хакында белешеп йөргән, ди. «Нияте бозыкка охшый, әйтеп куюем дидем, Ариф әкә»,— ди бит Иргаш.

Нәрсә икән нияте ул явызның? Анабибине алырга бит аның хакы юк! Белә бит ул аны.

Күңеленнән үзен шулай юатырга теләсә дә, Гариф әкә тыныч түгел. Йөрәге уттай дөрли кебек. Юлда очрап сәлам бирүчеләрне дә күрмичә ашыгып, ярсып атлый бирде.

Капка ишеген кемдер эчке яктан терәтеп куйган иде. Кул тыгып ачыйм дисә — һич ача алмый, кулы дер-дер калтырана башлады. Газап белән генә ачып, эчкә керде. Каушап, каударланып, үз-үзен тыя алмастан:

— Анабиби! — дип кычкырды.

Җавап кайтаручы булмады. Бары тик күрше йортның эте генә өреп куйды. Гариф әкә кинәт хәлсезләнгән аягын көчкә сөйрәп өенә юнәлде. Әгәр шул вакыт каршына, йокылы күзен уа-уа, Анабиби үзе килеп чыкмаса, ул, мөгаен, ишек төбендә үк егылган булыр иде. Онытылып кызын күкрәгенә кысты.

Анабиби дә аңа нидер булганын аңлады. Юкса бит, атасының монарчы аны болай шашып кочканы да, маңгаеннан үпкәне дә юк иде. Калтыраган кул, ниндидер серле караш...

— Нимә булды, дәдә? Ник болай вакытсыз кайттыгыз?

Гариф әкә, аны янә күкрәгенә алып бер ара тик торды да, аннан соң авыраеп якындагы бусагага утырды.

— Тирләп чыккансыз... Ә мин йоклаганмын. Чәй куяргамы, дәдә?

— Юк, кызым, — диде башта Гариф әкә, кызының кулын җибәрми генә. Ләкин шундук, тагын ни дип әйтергә дә белмичә: — Я, мәйлең, бар чәй куй, — диде.

Утырган җиреннән үзе һаман Анабибине карый, күзәтә иде. Байтак вакыт шулай утыргач кына аңа хәл керде. Инде ул үз-үзеннән көлә: «Тинтәк! Нигә бу кадәр ыгы-зыгы килеп чабып кайттым соң әле? Кызыма берәрсе яныймы? Әллә, югыйсә, кызын туганнан бирле дә күрмәгән бер яман аңа кул сузарга дип уйлыймы? Сабый чагыннан үз кулымда үсмәгәнме, үз кызым түгелме? Нигә дип хафаланам соң әле!»

Ул шуларны уйлап, җәһәт кенә урыныннан кузгалды...

Тик барыбер шул көннән күңеле тынычсызланып калды. Кая гына бармасын, өенә ашкынып, берәр хәл булмагае дип кайта иде. Анабибиен күргәч кенә тынычлангандай була иде. Хәзер ул ял көннәрен дә күбрәк кызы янында уздырырга тырыша. Ә бер көнне аны шәһәргә алып барып, икәүләп «Доктор Айболит» операсын карап кайттылар. Кайда гына булмасын, ул аңа бүләк алып кайта иде. Анабиби дә үзгәргән кебек, нидер сизенә кебек иде. Атасы берәр җирдән кайтса, куанычы эченә сыймый, сөенә.

Ләкин ул үзгәрә, ачыла барган саен Гариф әкәнең күңелен болыт баса барды кебек. Күз алдыннан һич кенә дә Исраилов китмәс булды... Ул яман кызын даулап килсә, ни дияр, моңа ничек түзәр! «Хәер, килеп тә ни эшли алыр соң? Ни йөзе белән килер икән?» дип үз-

үзен юаткан итә... Иң кыены — бу хәлне Анабибигә дә белдертәсе килми бит.

Тагы ике атна узды... Ә Исраиловның исә һаман күренгәне юк. Гарифның аңа булган нәфрәте инде әченә сыймый башлады. Бер көнне «табармын әле мин ул әбләһне, эшләрем генә бераз бетә төшсен. Аңлатырмын миң аңа аңламаганын» дип, йөрәксенде дә исенә килеп, Шивилгәнгә барасы итте. Иргашка биргән вәгъдәсе дә бар, бакчалар хәлен дә белешер...

Тирә-юньгә, тау һәм үзәнлекләргә күз билгесе — сары төс кергән, ә тау битләрендәге чикләвеклекләр, киресенчә, каралып күренә иде. Ерактагы тау башларында кар һаман бетмәгән, ул очлы түбәләр кояшка чагылып ялтырап тора иде. Алар астында күм-күк булып бакчага күмелеп утырган тау кышлаклары шәйләнә. Ара-тирә өзлексез шаулап агып торучы елгачыкны узып китәсең. Тик тирә-якта һичкем юк шикелле. Елан эзедәй борма-борма тау сукмакларын үлән басып киткән. Алда, ташландык бакчалар өстендә, җиңелчә генә һава дулкыны тибрәнә. Ә тауларга якынайган саен алар чүгә бара төсле иде.

Якындагы кыя өстенә менеп баскач, Гариф әкәгә аста, тирәклектә, нидер ялтырап киткән кебек булды. Бу, шөбһәсез, машина иде. Машинаның алгы пыяласы кояшта шулай чагылып китүчән. Ләкин кем бу? Юлсыз ничек килеп кергән, ни дип кергән ул анда? Гариф әкә таштан ташка атлап кире аска төшә башлады. Әмма ят машинага җитмәстән, туктап калды. Каршында Мария Васильевна иде. Ул ашыкмый, күрәсең, кулын маңгай турысына күтәреп, озаклап карлы түбәләргә карап тора, иелеп чәчәк өзеп ала, я булмаса, кулындагы таягы белән нидер эзләгәндәй, үлән араларында актарына иде.

Ул — ялгызы. Чәчәкле җиңсез күлмәктән. Аягында үкчәсез гади туфли. Башына, бит-маңгай тирәләрен кояштан сакларлык итеп кенә, ак косынка япкан.

Гариф, каршына барып җитмәстән юри тукталып, аңа сокланып тора башлады. Мария Васильевнаның бирегә килеп чыгуына ул үзе сәбәпче икәнен чамалады. Һәм бу хәл үзе генә дә көтелмәгән сөенеч иде. Димәк, теге вакытта әйткәннәре Мәрьямгә тәэсир иткән.

Мария Васильевна да Гариф әкәне күреп алды һәм ялгыш юлда тотылган бала сыман кызарынды, уңайсызланды, гүя аңардан: «Ә менә Куйки якларын да килеп күрер иткәнсез»не әйттермәс өчен, үзе сүз башлады.

— Их, көне лә көне!.. Аз гына саф һава сулыйм дип килдем әле. Арылды соңгы атнада... Ә монда сулыш юлларым ачылып китте.

— Юк, Мәрьям, — дип бүлдерде аны Гариф әкә, шаярткан сыман.— Ачык әйт, минем сүзләрдән соң тау районына кызыгып калгансың син. Ә күңелең тарткан эшне эшләргә кирәк. Килеп яхшы иткәнсең, Мәрьям.

Мария Васильевна, «мактанма!» дигәндәй, аңа кискен генә карап куйды. Алар кыя-ташлар, җәенке карагачлар арасыннан боргаланган тар сукмак буйлап атлап киттеләр...

— Әллә миңа бу тау күренешләре, табигать манзарасы яттыр дип уйлаган идеңме? Сезгә ул экономик советны башлап җибәрү яраган кебек, бәлкем безгә дә ара-тирә лирикага бирелү килешәдер?

Икесе бергә тирә-якны яңгыратып көлешеп алдылар. Мария Васильевнаның, көлгәч, йөзе нурланып китте.

— Анысын да җиткерделәрме?

— Әйе, ишеттек. Ишетмәслек тә түгел. Кайбер колхоз җитәкчеләре, башка эшләрен ташлап, шуның белән генә шөгыльләнәләр. Һәммәсен белеп торабыз. Вокзалда депутат булмәсен яптырганыңны да, парктан плакат-өндәмәләрне алып ташлатканыңны да, пахта совхозларындагы элекке бакчачыларга ни дип киңәш иткәнеңне дә... Хәтта мәгариф өлкәсендәге мәсьәләләргә карата шәхси мөнәсәбәтеңне дә

беләбез. Тик тагы ни-нәрсә эшләп узынырсың — шунысын белүдән генә мәхрүм без.

Гариф әкә көлеп тора бирде. Мария Васильевнаның соңгы кинаясе, аның дәрәҗәсендәге кеше өчен бик үк мәгъкуль саналмаса да, артык яманлау да түгел иде бит.

Үргә менеп җиткәч, алар ауган каратирәк өстенә утырып хәл алмакчы булдылар. Янәшәдә генә бары да бертигез, бер чама агачлар, маскхалат кигән гаскәриләр кебек, тезелешкән. Өстәге текә таулар да гүя алар сагында торган кебек иде. Их, иртәнге чык белән шул дымсу сукмаклардан ялан аяк йөгереп үтсәң икән!

— Алдыбыздагы күренешләр безнең матур хыялга охшый түгелме, Мәрьям. Тик без... китәрбез, ә болар мәңге шулай калыр.

Мария Васильевна баядан бирле кулындагы яфракка сокланып карап утыра иде. Гаҗәеп шул бу табигать. Менә гап-гади симметрия, гап-гади тамыр җепселләре генә кебек. Ә никадәр нәфислек, төгәллек үзендә! Гариф әкә дә аның ни белән мәшгуль икәнен күреп:

— Кайбер галимнәрнең фараз итүенчә, һәрбер нәрсә, шул җөмләдән бу яфрак та, без, кешеләр дә, имеш, электроннарның мәгълүм бер тәртип белән урнашуыннан тора. Әгәр бервакыт, әйтик, миллион елдан соң, шул тәртипкә үзгәреш кертелсә, имеш, кешелек дөньясы икенче кат хаят кичерәчәк, ди. Әгәр канунлят, безнең Тимер әйтмешли, шундый очраклылыклардан гына торса... Кызыкмы?

— Яхшы юаныч.

— Ләкин ул миңа ошамый. Электрон, исәп-хисап, коры канунлят...

— Фән аларсыз яшәми.

— Минемчә, фәндә дә иң әүвәл гүзәллек булырга тиеш.

— Кешенең мәгънәви дөньясы катлаулы...

Кояш инде шактый күтәрелгән, көн эсселәнә башлаган иде. Алар торып киттеләр. Гариф әкә ташлар арасыннан сөзелеп чыккан чишмәдән ятып су эчте. Су тешкә тиярлек салкын иде. Аннан соң Мария Васильевнага дуләнә җимешен өзеп авыз иттерде. Һәм шунда ул, ни сәбәптер, күптәннән күңелен газаплап торган Исраилов мәсьәләсен кузгатты. Аның Шивилгәнгә килеп йөргәнен, шуңа үзенең пошаманга калуын сөйләп бирде. Анабиби дә нәрсәдер сизенә булса кирәк, борчыла башлады, диде.

— Юк, мин аны барыбер табармын, җирдә булса — колагыннан, күктә икән — аягыннан сөйрәп чыгарачакмын, — дип әйтә башлаган иде, Мария Васильевна аны тыныч кына бүлдерде:

— Ә тапканның соңында аны нишләтерсең соң, төшенмәдем, — диде.— Хәкемгә бирә аламсың? Юк. Ул сине үзе судка биреп, баланы тартып алмасын. Шул кадәр михнәттән соң, шуныңча тәрбия биргәч... Ялгызлык сине бетерәчәк.

— Ул бәндәгә йөрәгемдәгесен әйтмәсәм, түзә алмыйм, каным кайный, — дип, Гариф әкә адымын тизләтте. Бер ара киткәч кенә, Мария Васильевнаның артта калуын чамалап, янә тукталды. — Үлем түшәгендә яткан хатынын, баласын ташлап киткән, инсанның инсанлык тойгысына төкергән бер түбән җан бит. Башка җирдә дә шундый ук этлек кылып йөргән булса? Шулай булгач, мин аның шушы тирәдә йөрүенә ничек түзеп торыйм да ничек тыныч йоклый алыйм ди?!

— Тәүбә диең, — диде Мария Васильевна, кулындагы таякны җиргә ташлады. — Бигрәк яхшы уйда икән райком секретаребыз. Ничек итеп сине сайлаганыбызга хәйран калам... Үзең үк кешелекле булыйк дип тәкърарламыйсыңмы соң?

— Мин дә бит кеше.

— Хак. Хәлбуки, ул да — ата.

— Кемнең кемлеген беләсең. Ярдәм ит син миңа.

— Ә нәрсә эшләвем кирәк?

— Тәрбиягә бала алмакчымын, Анабибигә сеңел кирәк. Мәслихәтең бир, киңәш ит, нишләргә миңа?

Ул Мария Васильевнадан: «Әбау, райком секретарена бала багып утыру килешерме?» — дигәнрәк җавап көтә иде. Ләкин Мария Васильевна алай димәде, текәлеп күзенә генә карап алды. Карашында шелтә юк иде. Олыгаеп барган кешенең бу үтенече хәтта икесенең арасын ныгыткан да кебек булды. Ник дисәң, ул үзе дә кайвакыт, ялгызлык хисе аеруча нык сизелгәндә, шул хакта уйлана бит. Үзенең күп еллар фәкать эш белән генә юанганын аңлый иде ул. Гариф исә аның шул тирән ярасына кагылып киткәндәй итте.

Кояш югары күтәрелеп кыздыра башлаганда, алар саубуллаштылар. Гариф әкә Иргаш белән Мансур атаның хәл-әхвәлен белешергә дип Шивилгәнгә барыр булса, Мария Васильевнаның исә кичен шәһәрдә җыелышка кайтасы бар икән.

— Бигрәк яхшы ял иттек, күңелләр язылып, рәхәт булып китте, — дип, ул машинага таба китте. Гариф әкә урыныннан кузгалмады. Ул Мария Васильевнаның уйчан гына атлап, коелган яфракларны кыштырдатып китүен карап калды. Ә машина кузгалам дигәндә генә исенә төшеп:

— Анабибигә сеңел алуны мәслихәт диясез инде? — диде.

— Мәслихәт дим!

— Ә тау районын элекке хәленә кайтару мәсьәләсе ничек?

— Ә-ә?!

Гариф әкә кычкырып та карады. Аңа таулар гына җавап кайтарды...

Гариф әкә белән Мария Васильевна дустанә мөнәсәбәттә булсалар да, араларындагы киеренкелек кимемәде. Киресенчә, эшкә кагылышлы бер генә мәсьәлә дә бәхәс, бәрелешсез узмый иде. Бу хакта район кешеләре дә, өлкәнең партия һәм совет җитәкчеләре дә хәбәрдар иделәр. Аларның төрле киңәшмә һәм утырышларда әйткәләшеп алулары гадәткә кереп бара кебек. Икесе бергә туры килгән җыелышта берсе сөйләсә, икенчесенең каршы чыкмый калганы сирәк иде.

Ләкин аларның район җитәкчеләренең соңгы җыелышындагы кебек чиктән ашканы булмады. Бу көнге шау-шу үз җирлегендә генә калмыйча, башка районнарга да ишетелде. Кешеләр: «Ачилов янә үзен күрсәткән», «Инде нәрсә булыр икән?», «Кайчангача дәвам итәчәк бу?» — дип, төрлесе төрлечә бәя бирә башлады. Мария Васильевнаны яклаучылар булган кебек, Гариф әкәне хак санаучылар да җитәрлек иде.

Асылда алай зурдан кубарлык һични булмады кебек. Гариф әкә үзенең докладында бары тик күптән уйлап йөргән, инде күпләргә әйтелгән фикерен генә кабатлады. Аның әйткәне шул: чирәм җиргә көчләп күчерелгәннәр арасында үз кышлакларына кайтаруны таләп итүче булса — рөхсәт бирелсен. Ә совхозда торып калучыларга, киләсе бер-ике елда бакча булдыру шарты белән, җир бүленсен, диде. Дәүләткә мамык тапшыру планын кимендә ике ел үзгәртмәскә һәм аны арттырып утәүче хуҗалыкларга өстәмә түләргә, диде. Аннары: элекке Куйки районын аерырга, аңа үзенә хас экономика белән шөгыльләнергә рөхсәт итәргә кирәк! дигән тәкъдимне кертте.

Боларны трибунадан әйткәнче үк әле ул кайбер идарәләрдә булып, аларның җитәкчеләре белән киңәш тотуын, кирәкле экономик мәгълүматлар туплавын да искә алып үтте. Кайберәүләрнең, бүгенге тормыш таләбен яхшы белеп бетермичә генә, эшлекле булып күренергә йөрүләрен фаш итте. Бу җәһәттән аеруча Зыяханов белән Мария Васильевнага каты эләкте.

— Хезмәт кешесенең фидакарьлеге, үз-үзен аямый эшләве хисабына гына җиңү рапортлары бирү дәвере үтеп бара. Ләкин әле без ул чирдән арынмаганбыз. Мәсәлән, аерым җитәкчеләр иҗади уйланмый, исәп-хисап белән исәпләшми, әмер биреп кенә эшләтүне кулай күрә. Ә бит җитәкчелек итү — ул күрсәтмә биреп тору гына түгел... Хәтта кайберәүләр җитәкчене «нечкә күңеллелек»тән азат булырга тиеш дип саный. Бу — бик яман, иптәшләр!

Гариф әкә сөйләгәндә Мария Васильевна түзмичә берничә мәртәбә урыныннан торды. Әйтелгәннәрнең гадәттәгедән кискенрәк булуы залда утыручыларга да тәэсир иткән, зал җанлана төшкән иде. Әйе, ике җитәкченең болай тартышуы беркемне дә битараф калдырмады.

— Тәкъдимнәрегезнең нигезендә дәүләт мәнфәгатен алдын кую юк, — диде Мария Васильевна. Бәхәсләшә башлау белән, алар «син»нән «сез»гә күчәләр. Бу исә аларны тагы да бер-берсеннән аера сыман иде.

— Әнә шул шул, — дип элеп алды Гариф әкә. — Кайберебез югарырак, дәрәҗәлерәк эш урыны биләде исә, үзен дәүләт мәнфәгатен кайгыртучы берләнбер кеше итеп хис итә башлый. Әйтерсең башкалар аны кайгырта алмый, гүя дәүләтне алардан яклау кирәк. Биредә утырган һәркемгә мәгълүм: дәүләтебезнең киләчәктә дә көчәя, куәтләнә төшүе зарури. Ләкин менә бу залда утыручылар, кыр-басуда эшләүчеләр шул ук дәүләт үзе түгелме соң? Алар мәнфәгате, аларның тормыш муллыгы, күңел көрлеге, ниһаять, бәхет-сәгадәте дә дәүләт мәнфәгате түгелме соң?.. Тормышыбызның өстенлеге дә шунда ки: аерым шәхес мәнфәгатен уйлау — бездә дәүләт мәнфәгатен кайгырту да бит ул.

— Бәлкем киресенчәдер!

— Мәгънәсе бер. Моны бер-береннән аерырга теләүче кеше я обыватель, яисә бюрократ булыр.

— Алайса — беренчесе сез! — дип, Мария Васильевна аңа бармак төртеп күрсәтте.

— Ә икенчесе — сез...ме?

Гариф әкә белән Мария Васильевна шыпыртрак кына әйткәләшсәләр дә, зал аны ишетми калмады. Чөнки халык зур дикъкать белән тыңлап утыра иде. Шул тын залда бу хәлгә ырҗаеп көлеп утыручы бер Зыяханов та, аның яраннары гына булгандыр. Иң беренче сүз алучы да Зыяханов булды. Мондый очракта беренче чыгыш, беренче сүз хәлиткеч булырга ихтимал. Зыяханов трибунага менгәч тә, аста утыручыларга мәгънәле генә карап куйды.

— Бик күп активларны, киңәшмәләрне күргәнбез. Ләкин әлегәчә болай әйткәләшүне күргәнебез юк иде, — дип, җыерчык баскан йөзен чытып алды. — Бу ике җитәкче иптәш арасында нидер бар икән, безнең монда ни гаеп? Җыелыш саен ул җәнҗалны тыңлап колакларыбыз тонмаганмы? Күпме чыдарга мөмкин? Бүген менә обком секретарен ачыктан-ачык бюрократ дип атадылар. Ул шулайдырмы-юктырмы, сүз ул хакта түгел. Ләкин без активның тәрбияви ролен...

Шулай итеп, Зыяханов бәхәснең, активка куелган җитди мәсьәләләрнең асылына кагылмыйча, бары тик «ике җитәкче иптәшнең» үзара мөнәсәбәтенә генә тукталып сүзне шул табан борып җибәрде. Гариф әкә күтәргән мәсьәлә тирәнрәк, катлаулырак һәм күпләр әле ул хакта фикер алышырга кыймый утыра иде. Кемнең ничек сүз башлавын көтә иде. Инде аларның да Зыяхановка иярүләре ихтимал бит.

Зыяханов сүзен дәвам иттереп:

— Җыелыш саен без үзара талашуларның шаһиты булабыз. Моңа чик куелырга тиеш. Инде төп мәсьәләгә килсәк, бик авыр шартларда, яңа җирдә, яңа тормыш башлап җибәргән ватанпәрвәрләр бүген Ачилов коткысы белән совхоздан кире китәргә җыена. Мәсәлән, Ачилов

үзе совхозда булганда шундый кешеләрне яклады. Алай гына да түгел, беркем белән киңәшмичә, берничә гаиләгә үзләренең кышлакларына кайтып китәргә рөхсәт бирде. Бу һич ярый торган эш түгел. Бик яман үрнәк бу. Ачиловның нәкъ менә шушы эшләре дәүләт мәнфәгатенә берьяклы карашын чагылдыра,— дип бетерде.

Аның артыннан ук атылып чыгучының кулында кәгазь — алдан ук «әзерләнеп» килгән, күрәсең.

— Без, арысландай батыр ир-егетләр, беренчеләрдән булып, карнай-сорнайлар уйнатып, ул буш далага күчеп килгәнбез. Иптәш Ачилов безгә, кире кайтып китәргә рөхсәт бирәбез, дип әйтте. Бу безнең өчен мыскыллау булып яңгырый. Безләрне кем дип уйлыйсыз, иптәш Ачилов? Без ул чүл-даланы чәчәк аткан бакча итү өчен... өчен... килгәнбез.

Гариф әкә бик шома язылган нотыгын кәгазьгә карап укучы бәрхет кәләпүшле бу көяз егетне дә таныды — Зыяханов совхозының клуб мөдире Убайдуллахан икән. Ул сүзен залдагыларга түгел, аерым кешеләргә — башта Мария Васильевнага, ул аңа игътибар итмәгәч, редактор Назаровка, аннан соң өлкә газетасы хәбәрчесенә карап сөйләде.

Аңардан соң Түләгән сүз алды. Башта ул оялчан кыз сыман аяк астына караган килеш ишетелер-ишетелмәс кенә сөйләргә кереште. Аның санга күмелгән бу чыгышыннан шунысы аңлашылды: бер-ике ел дәүләт планы үстерелмәсә генә үзкыйммәтне киметү мөмкин булачак; эчке резервлар хисабына совхоз, ниһаять, рентабельлелеккә ирешәчәк икән. Ул чакта планнан тыш табышны эшчеләрне материаль кызыксындыру өчен кулланып була. Шуннан соң «әфгани җиле» белән көрәшне дә ныклап башларга ярый. Аны җиңсәң, уңыш бермә-бер артачак.

— Коры даланы үзләштердек дип әйтәбез. Бусы хак. Инде алга ничек барасын уйлап эш итәсе кирәк. Минемчә, иң элек кешегә дә, уңышка да зыян китерүче котырынган җилгә киртә куярга вакыт,— диде ул.— Бу хаҗәттән чыгып караганда, бакча утырту, бакчачылык эше кемнеңдер шәхси ихтыяҗына гына кайтып калмый, бу — бик кирәкле эш. Безнең совхозның экономик советы басуларны ул давылдан урман кишәрлекләре белән ышыклау эшенә аерым бригада куярга дигән тәкъдим кертте. Бу ике эшне башкармый яшәү мөмкин түгел. Шуннан соң бездән китәргә теләүчеләр дә кимиячәк. Соңгы сүзем шул: йорт яны бакчалары шәхси ихтыяҗ, хосусый милек итеп кенә каралмаска тиеш. Ул безнең сәламәтлек өчен дә, күңел байлыгы өчен дә, хәтта уңыш өчен дә бик кирәк. Минемчә, Ачилов иптәшнең тоткан юлы заманча. Элекке Куйки районын кайтаруны да яклыйм. Ул — даланың калканы да, халыкның ял-бәйрәм урыны да. Гомерлек бакчаларны юк итү халкыбыз табигатенә ят нәрсә. Хак әйтте райком секретаре: кеше өчен, аның бәхете өчен! дип. Шул кешенең ихтыяҗы, кирәк-ярагы, теләк-таләбе белән исәпләшмәү җәмгыятебезгә хас түгел. Ә без кайвакыт бу хакыйкатьне онытабыз әле.

Активта булганнар арасында райком секретаре Ачилов эшенә теләктәшлек белдерүчеләр дә, аның тәкъдимнәреннән куркынып калучылар да барлыгы беленде. Шулай ук күпчелекнең әлегә кайсы якны кабул итәргә икәнлеген, кайсысының хаклылыгын ачыклап бетермәгәнлеген, шуңа күрә бу юлы дәшми калуны кулай күргәнлеген дә чамалап була иде.

Җыелыштан соң Гариф әкә, Мария Васильевна һәм тагын берничә кеше фойедагы буфетта лимонад эчеп калдылар.

— Җыелыш яхшы узмады,— диде Мария Васильевна. Аның төсе качкан, йөзе бик боек күренде.

Гариф әкә көлемсерәп:

— Зыяханов фикерен кабатлыйсыз шикелле? — дип куйды.

Сүзгә күрше өстәл янында сыра эчеп утырган Назаров та кушылды.

— Минемчә, уйландыра, активлаштыра торган активларның берсе булды. Моны инде ишектән чыгу белән онытмаячаксың... Эшлекле үтте, — диде. Аннан соң, өстендәге күбеген өреп, алдындагы сыраны сулыш та алмый эчеп җибәрде дә, «Газетаны өлгертәсе бар», дип, ашыгып китеп тә барды.

Кич булуына да карамастан, һава бөркү, сулу алуы авыр иде. Маңгаен бөрчек-бөрчек тир баскан Гариф әкә Мария Васильевнаны озата чыкты.

— Бәлки безгә кереп чәй эчәрбез, — диде ул.

Мария Васильевна Гариф тәкъдимен кабул итми, машинасына юнәлде: «Халык ни сөйли, ишеттегезме?»

— Халык дип кемне аласың бит. Убайдуллаханны булса... «Арысландай батыр»лар, имеш. Күңелендә бер, телендә икенче аның. Иң аяныч — андыйларны да үзебез тәрбияләгәнбез!

— Ай-яй... Миңа да бер шулай дигән идегез түгелме? Исегездәме?

— Ни әйтим? Андыйны яман күрәмен! — дип, Ачилов кулын күкрәгенә куйды. Машина янына килеп җиткәч тә, Мария Васильевна утырып китәргә ашыкмады, ерак тауларга карап, нидер уйланып торды.

— Бу Зыяханов та... Ни кирәк аңа?..

— Аңа элеккечә, боерык буенча эшләү кирәк. Эшкә кем кушса, шул җавабын да бирәчәк. Үзенә җаваплылык аласы килми, аңа өйрәнмәгән ул.

— Бүген үк ул бөтенесен дә Беренчегә җиткерәчәк. Бюрода тикшермәгәйләре...

— Һай, хәйләкәр бу Зыяханов... Тәҗрибәле, — дип, райком секретаре янә дүртенче совхоз директорын күз алдына китерде. — Эшеннән кузгатып кара аны хәзер, каршы чыкканым өчен үч ала диячәк...

— Эшеннән алырга уйлыйсызмы?

— Әйе, шулайрак иде. Сизенеп эш йөртә, төлке. Түләгәнгә җай бирми ни карышты, баксаң — чатаклыклары да байтак икән. Экономик совет аны ачты. Хәер, ул гына да түгел, Зыяхановта гомумән җитәкчегә хас сыйфатлар чикле.

Бу җыелыш хакындагы шау-шу шул көндә генә бетмәде. Элек аны берничә газета язып чыкты. Газеталар да, активта сөйләүчеләр кебек үк, капма-каршы фикер йөртә иде. Хәтта бер хәбәрче мәҗлеснең «җәнҗаллы ягына» үтә дә басым ясап, фельетон рухында язган. Назаров мәкаләсендә райком секретаре күтәргән мәсьәләләр дәлилләп, яклап язылган булса, өлкә вәкиле исә Убайдуллахан чыгышын тулаем күчереп, сүз башлаганда гына «ике җитәкченең җанга тигән низагы» дип әйтеп киткән иде. Шулай итеп, «җыелышның нәтиҗәсез үтүе», «анда Ачиловның килешмәгән яңалыклар белән чыгуы», «өлкә партия комитеты җитәкчеләреннән берсен «бюрократ» дип атавы тиз ара беренче секретарьга да мәгълүм булды. Әйтүләренә караганда, бу хәбәрдән соң беренче секретарь бик нык ачуланган. «Булды, күп түздек. Хәл итәргә кирәк, я анысы эшләсен, я монысы» дигән, имеш. Ачиловның тезисларын алдырып укыганнан соң, мәсьәләне ачыклау өчен алдагы бюрога куячагын әйткән икән. Шулай итеп, райком секретаре Гариф әкәнең хәл-әхвәле җитди иде.

Гариф әкә шушы хәлләр белән мавыгып Исраиловның барлыгын да оныта язган иде. Ул әлләһ үзе хакында үзе искә төшерде. Шул катлаулы, борчулы көннәрнең берендә аның, Анабибигә ата икәнлеген дәгъвалап, Ачиловны судка биргәнлеге беленде.

Моны Гариф әкәгә телефон аша өлкә судының тикшерүчесе хәбәр итте. Ул «сөйләшү» өчен килергә рөхсәт сорады.

— Килегез. Тик аңлашу, сөйләшүме соң, әллә сорау алумы?

— Без сезне гаепләмибез. Шулай да... райкомда очрашу килешерме?

Тикшерүче икеләнә калды. Ул Гариф әкәнең шәһәргә баруын тели иде шикелле. Ә аның болай да көне-көнгә ялганган чак.

— Килешер, ник килешмәсен, — диде ул. Шул ук вакытта аның әңгәмәне өйдә, Анабиби алдында да уздырасы килми; әлегә кызның берни белми торуы хәерле иде. — Без бит мөһим иҗтимагый мәсьәлә хакында сөйләшәчәкбез, нишләп килешмәсен,— дип өстәде Гариф әкә. Әлегә бу хәлгә әллә ни игътибар итмәскә тырышты. Әмма ләкин ачуын баса алмыйча, төне буе аяк өсте йөренеп чыкты. Гомерендә дә суд каршына бармаган кеше, инде үзен тикшерүче эзләп киләчәк. Алдына әнә шул вөҗдансыз Исраилов шәүләсе килеп басты. Тик бер дә күрмәве сәбәпле, ул аны анык бер шәхес итеп танымый иде. «Шуны табармын да, араны ачыкларбыз» дип никадәр йөрде. Бактың исә, таптан кеше Исраилов үзе булды. Ачиловның моңа да ачуы чыкты.

— Юк, аның белән нинди сүз булуы мөмкин! — дип уйлады ул.

Иртәгәсен ул тикшерүчене йокысызлыктан интеккән, борчулы бер кыяфәт белән каршы алды. Аның каршында пөхтә киенгән, чәчен туры юл калдырып пөхтә генә тараган, аксыл чырайлы ир утыра иде. Йөзендә, күз карашында һични чагылмый сыман. Гариф әкә аңа Анабибинең бөтен тарихын сөйләп бирде: баланың ятим калуын, Сарагөлнең үлемен, инде хәзер бер-берсеннән башка яши алмауларын әйтте. Үзе, шул гыйбрәтле, тетрәткеч вакыйгалар турында сөйләнгәндә, суд тикшерүчесе йөзендә һичбер үзгәреш күрмәвенә, аңарда бер нинди хис уянмавына кыйналып утырды. Шул кадәр битарафлык булса да булыр икән!

— Инде белдегезме Исраиловның кем икәнлеген? — диде ул соңыннан. Аның бу әйткәннәреннән күптән мәгълүм нәрсәне күпертеп йөрисе дә түгеллеге аңлашыла иде. — Хатыны үлде, баласы калды — ник бер хәбәр бирсен. Шуннан соң да унбиш ел үтте — ник бер мәртәбә «балам исән-саумы» дип кызыксынса икән. Хәзер аңа ни кирәк? Ике кешенең тик шул бала хәсрәтеннән гомере өзелгән. Инде Сарагөлем урынына ул калган... Әйтегез, ул ахмак минем белән булышмасын.

— Юк, мин аңа ни дип тә әйтә алмыйм, — диде тикшерүче. — Минем өчен ике як та барыбер.

— Барыбер?! Ай-һай...

— Шулай. Безгә ике якның фикере дә бертигез. Дәлил, документлар кыйммәт.

— Әйе, миндә нинди дә булса рәсми документ юк. Минем документым әнә — сау-сәламәт үстергән кызым. Мин аңа әти!

— Сез — карап үстергән ата, ә ул — тудырган ата. Безнең вазифабыз шуны ачыклаудан гыйбарәт.

— Сез һаман да аның белән мине бер урындыкка утыртмакчымы? Юк! Моңа Анабиби ни диячәк? Ә? — диде ачуы купкан Гариф әкә.

— Әлбәттә, аңардан да сорарбыз. Тик бүгенгә кадәр үз атасын күреп белмәгән бала ни дисен? Хәзергә аның ата мәсьәләсендә хаталануы бик мөмкин... Рөхсәт итсәгез, сез әйткәннәрне мин кәгазьгә теркәр идем.

Язасыларын язып эшен бетергәч тә, очрашкандагы кебек, салкын гына саубуллашып китәргә җыенды.

Бүлмә буйлап йөренгән Гариф әкә:

— Баланың үзеннән сорарсыз. Ул ни әйтер, — дип кабатлады.

— Әлбәттә. Ләкин аның ни әйтере безгә мәгълүм. Әйткәнемчә, үз атасын ул каян белсен ди?

— Шулай шул. Аны үзегез дә аңлыйсыз — каян белсен ул үз баласын?

Бу кеше чыгып киткәч тә тиз генә тынычлана алмады ул.

— Ике як та барыбыр, имеш! Шул кеше дә ата хокукын даулый бит, ә! Тыңлаштеручеләрен карасана, әвәрә булып йөрүләре тагын.

Соңыннан уйга талып байтак кына утырды. Кулы эшкә ятмый иде. Мария Васильевна белән киңәшәсе килде, тик телефон трубкасын кулына ике мәртәбә алгач та шалтыратырга базмады, кире куйды. Сызгырынгалап өстәлдә яткан кәгазьләрне әвеш-түеш китергәләде, тик ни өчен шулай иткәнен дә әйтә алмас иде. Аннары ашыгып кайтып китте.

— Дәдәҗан! — дип, шатланып каршы алды аны Анабиби. Чәче тузгыган, кулы корымлы иде. — Лагерьдан Тимер кайтты. Китапларыгызны карагыз әле, баскыч куеп барысын да яңабаштан тезеп чыктык... Әйдә, әйдә инде, карагыз инде, дәдә.

Шулай дип ул атасын эчкә сөйрәде.

— Башка һич кем килмәдеме?

— Килде, — диде Анабиби, шунда кинәт тавышы үзгәреп китте. — Бер кеше килде. Сорашты.

— Ниләр сорады?

Гариф әкә, ярсуын тыя төшеп, сабыр булырга тырышты.

— Әлегә ни... Үз дәдәңне беләсеңме? ди. Юк, дидем. Аннан соң: бу дәдәңне яхшы күрәмсең? диде. Әйе, дидем. Үз дәдәңне табышыйкмы? диде. Белмим, дидем. Тапсак, кайсы дәдәң белән торырсың? диде...

Гариф әкәнең маңгаена суык тир бәреп чыкты. Анабиби атасындагы үзгәрешне күреп шундук аның куенына атылды.

— Дәдәҗан, кирәкмәс! Кирәкмәс, борчылмагыз! Сез генә минем дәдәм! Сез, тик сез! — дип, өзгәләнә-өзгәләнә атасын кочты.

Инде Гариф әкә, җилкәсеннән сөеп, аны юатырга кереште:

— Вай, тинтәк, тинтәк... Әлбәттә, шулай, әлбәттә. Куй, кирәкмәгәнне уйлама. Кемдер юк-бар сөйләп йөри... Килештекме? — диде. Күзен каплаган яшь пәрдәсен күрсәтми генә сөртеп, эш киемнәрен салырга дип бүлмәсенә кереп китте.

— Тимер тазарганмы соң лагерьда? Һай, бигрәк матур тезгәнсез бу китапларны. Инде кирәккәнен дә табарлык түгел икән.

Анабиби йөгереп китапханәгә керде. Кычкырып көлеп җибәрде. Алар янә баскычны киштәгә сөяп куйдылар. Кызы, өскә менеп, китапларны нинди тәртип белән тезүләрен аңлатырга тотынды.

— Булдыргансыз, кызым, — дип, Гариф әкә аның күңелен күрде. Шулай гөр килеп көлешеп-сөйләшеп торганда, аларга күрше хатыны килеп керде.

— Кышлактан килендәшем килде, Арифҗан. Көлешүегезне ишеткәч исемә төште... Кунак күчтәнәче, авыз итегез,— дип, ул ашъяулык белән кат-кат чорналган ашлы табагын өстәлгә куйды.

Бу — Анабиби янына уйнарга керүче кечкенә Ярмәт белән Тимернең әбисе иде.

Ашап, чәйләр эчкәч, Анабиби ян сәкедә йоклап та калды. Күршеләрдә әле кунак шау-шуы тынмаган иде. Шунда ук Ярмәтнең чыр-чу килгәне ишетелә. Өйдә дә кычкырып сөйләшәләр, шау-гөр килеп көлешәләр иде.

— Ярмәт шул кадәр дә дәдәсенә охшаган, коеп куйган инде менә, килендәш!

— Үз атасына охшамыйни...

Гариф әкәгә, кеше сүзен тыңлар өчен чыккан кебек, уңайсыз булып китте. Ул бакчаның аргы башына үтте. Әмма колак төбендә һаман «Дәдәсенә шул кадәр охшаган» дигән сүзләр яңгырап ишетелгән шикелле иде. «Коеп куйган инде менә...» Нинди бәйләнчек сүз булды соң әле бу...

Ул, янә өйгә кереп, кызы янәшәсенә барып утырды. Кызы изрәп йокыга талган. Гариф әкә кагылыр-кагылмас кына итеп аның чәченнән сыйпады, сөйкемле, нәни иреннәренә карап: «Кызым... син соң, син кемгә охшаган?.. Миңа түгелсең, билгеле. Син матур, кызым». Гариф әкә ялгызлык тойгысына бирелеп утырды. Читләтеп кенә тагын Анаби-

биенә карап торды. «Мәрхүмә анасы да бу кадәр матур түгел иде. Сарагөл матур да бит, үз анасы түгел. Атасы Исраиловкамы әллә? Ни гомер ул аның күз алдында бер мәхлук җан булып тасвирланмыш иде. Шуңа да охшар микәнни бала? Ә шулай булса? Күрер күзгә матур булып та, күңеле яманнар азмы? Алайса, бел, син аңа матурлык бирсәң, мин миһербанлыгым бирдем. Янар йөрәк бирдем мин аңа! Белсәң әгәр...»

Гариф әкә үзен өстен итүче күп кенә башка дәлилләрне дә хәтерләде, тик аңа карап күңеле генә юанмады. Шулай да булсын, кызы Исраиловка да охшасын, ди. Барыбер аны ул тәрбияләгән түгелме соң?! Юк, юк, кызын ул һичкемгә бирмәячәк.

Шушы төннән соң аның Анабибиен яратуы тагын да арта төшкән кебек булды.

Бер-ике көн үткәч, әлеге суд тикшерүчесе районга килеп, Гариф әкәгә янә берничә сорау бирде. Ә китешли судка чакыру кәгазе калдырды. Гариф әкә эшнең кая баруын аңлады. Әлегә чаклы ул эш зурга китмәс диебрәк уйлый иде. Суд тикшерүчесе ишек төбенә җиткәч, туктатып, сорамый булдыра алмады:

— Ни өчен бу эш белән өлкә суды шөгыльләнә? — диде.

— Дәгъвачының үтенече шулай. Бу очракта район судының гадел хөкем итә алмавы ихтимал.

— «Дәгъвачы»? Димәк, мин суд каршында «гаепләнүче» дип аталам? Мәрхүмә хатыным белән без яхшылык эшләдек дип уйлый идек. Дистә ярым ел шул уйда күңелем үсеп, үз-үземнән канәгать йөргән мин... Сез, сез нишләп көләргә иттегез әле бу олы хистән?

— Әйтәсе сүзегезне судта әйтерсез.

— Ә бармасам? Төймәдән дөя ясап йөрмәгез! — дип, Гариф әкә, кызып, тегә чыгып китү белән чакыру кәгазен ерткалап, чүп савытына ташлады. Ул үзенең хаклы икәнлегенә ышанган иде. Шуңа күрә күңелендә гаҗәеп бер тынычлык урнашты...

Гариф әкә үзенең совхозлары, экономик советлары, «әфган»га каршы көрәш оештыру — урман кишәрлекләре, бакчалар утырту өчен бригадалар билгеләү эше һәм, ниһаять, элекке тау районын кире кайтаруга хәзерлек мәшәкатьләре белән мәш килеп, онытылып китте. Ә кичләрен ул Анабибие, Тимер белән Ярмәт кергәндә, аны да тезенә алып — шул бала белән юанып үткәрә иде.

Хәтерләсәгез, нәкъ шундый кичләрнең берсендә аларга көтмәгәндә генә Ачил баба белән Газыймҗан килеп керде. Ярмәт шундук сөенче алырга чыгып йөгерде. Ачил баба белән Анабибинең, Гариф әкә белән Газыймҗанның беренче күрешүен, танышуын онытмагансыздыр, шәт. Алар килде дип, йорт хуҗасы көне-сәгате белән дигәндәй күңелендәген сөйләп бирмәде. Хәер, алар әңгәмәсен ул кечне телефон шалтыратып бүлдерде бит. Ә әлегә без Ачил баба килгәнче булган хәлләр белән таныштык.

Исегездәме, Ачил баба ачуланып, ачынып:

— Обком секретаре белән шулай сөйләшәләрме? Үзең кем? — диде. Йөзе кинәт кырысланып, күз кабагы аска төшкән иде. Гариф әкә башын салган килеш утыра бирде. Байтак кына утырганның соңында:

— Обкомның бюросына куйганнар. Минем «башбаштаклык» тикшереләчәк, — диде ул. — Мәрьям докладчы икән, аңа кушканнар... Ишеттегезме... ни дип кычкыра?

Шуннан соң гына кунаклар өч-дүрт ай элек булып узган вакыйгадан хәбәрдар булдылар. Ә төн буе йокламаган Гариф әкә иртәдән бюро утырышына әзерләнергә кереште.

Тимер белән Анабибигә дә эш табылды. Алар Газыймҗан абыйлары белән китапханәгә кереп бикләнделәр. Кырык яшьлек Газыймҗан да кай ягы беләндер, шушы балаларга тиң кебек иде. Юк кына нәрсә-

гә дә исе китүчән. Очраган бер нәрсәгә хәйран кала. Әледән-әле китапханәдән аларның көлешкәне ишетелеп торды. Аеруча көр яңгыраганы — Анабиби авазы иде. Бу яктагыларга да ул һич тынгылык бирмәде.

— Дәдә, дәдә! Азимҗан әкәмнең анасы да Анабиби икән бит.

— Бабам, беләмсең, Тимер әле укытучысы белән дә бәхәсләшә...

Ләкин мондагыларның колагына аның сүзләре керми иде. Ата белән улның үз әңгәмәсе: Ачил баба улына үзен бюрода ничек тотарга кирәклеге хакында киңәш бирә.

— Ни булса да күңелеңдәгеп, үзең нык инанганны гына сөйләп бир. Кычкырынма. Сүзне акырып-бакырмыйча гына әйтеп тә аңлатып була. Кычкыру өстенлек билгесе түгел. Ә сабыр гына сөйләшү — шулай ук килешү дигән сүз түгел. Үз хаклылыгына ышанмаган кеше генә кычкыра ул, — дип үгетләде ул.

Моның белән ул улының күңеленә ышаныч салып, җилкәсеннән сөеп озаткан кебек итте. Гариф әкә урамга чыгышлый гадәтенчә ишек төбендәге почта ящигына үрелде. Көндәлек почта арасында ниндидер яшел кәгазь кисәге дә бар иде. Тагын судка чакырулары икән. Повестканы, нишләтергә белми кулында әйләндергәләгәч, бөтәрләп ян кесәсенә тыкты. Һаман тынмыйлар икән. «Юк, ул вөҗдансыз алдында гаепләнүче булып барып басу хурлык! Кирәк икән — үзе килсен аңлашырга», дип күңелен тынычландырды ул.

Берничә көн үткәч, Гариф әкә райкомнан аласы кирәк-ярагын алды да, машина чакыртып, өлкә шәһәренә китеп барды. Инде бөтен нәрсә онытылган, башында фәкать буласы бюро утырышы гына иде. «Активтагы сөйләгәннәремне генә тикшерәләрме? Әллә үземнеме? Сөйләгәннәремне булса — янә шуларны гына кабатлармын. Өлкә комитеты белән алдан киңәшмәгәнмен икән, район активы белән фикеремне уртаклаша аламдыр ич? Моңа хакым бар. Уйларымны да яшермәдем, һәммә җирдә ачык әйтә килдем. Кемгәдер ул ошамаса — түзсен, тузанын какканга рәхмәт әйтсен. Мәйле, тиеш тапсалар, мине дә орышсыннар. Мәрьям бүзәреп-чәчрәп чыгар инде. «Бюрократ» дигәнгә бәйләнер. Кызулык белән бик үк урынлы әйтелмәде әйтелүен, аның өчен гафу үтенәм, тик бюрократлык аңарда җитәрлек, белеп торсын диярмен».

Әмма бюро утырышы Гариф әкә көткәнчә булмады. Бердән, ул бик кичегеп башланды, Мария Васильевна да, Беренче үзе дә озак кына күренмәделәр. Шактый көтеп утырганның соңында гына Беренче, әчке ишектән чыгып, каефсез генә:

— Мария Васильевна бүген була алмый, утырышны икенче мәсьәләдән башлыйбыз, — дип игълан итте. Беренче секретарь тәбәнәгрәк буйлы, киң маңгайлы, үткен күзле кеше иде. Ул, Гариф әкәне күзе белән эзләп тапкач, тагы өстәп әйтте: — Иптәшләр, төрле имеш-мимешкә урын калмасын, Мария Васильевна каты авыру сәбәпле бюрога катнаша алмый. Районнан кайтышлый йөрәк авыруы тоткан, хәзер бер совхоз больницасында ята, — диде.

«Ахырынача үз сүземдә торам, бәхәсләшәм» дигәнрәк ният белән утырган Гариф әкәгә бу хәбәр бик яман тәэсир итте, ул аптырап калды. Күз алдына район җыелышыннан соң сулып, агарынып калган йөзле Мария Васильевна килеп басты. Кайда син Мәрьям, кайсы совхозда? Сулышны буган ком буранына юлыктыңмы әллә?

Ачилов бюро утырышыннан чыгып китмәкче иде, яхшысынмады. Утырыш башланып, кайсыдыр РТСның хәзерләгән тикшерергә керешкәннәр иде. Гариф әкә фикерен туплый алмыйча, ни сөйләгәннәрен тыңлап утыра бирде. Йөрәк авыруы, йөрәк өянәге... Ул нигәдер үзенең йөрәк турысын капшап алды. Йөрәге атылып чыгардай итеп сикерә иде. Ашыгыч ярдәм җибәрелде, диде кебек. Кайсы совхозда икән соң? Ярый ла, өченчедә булса — аның амбулаториясе бар.

Башкалар һични булмагандай бәхәсләшә, сөйләшәләр. Шул бер РТС мәсьәләсен карау ашкынып, янып утырган Гариф әкә өчен берничә сәгатькә сузылган шикелле тоелды. Ничек тә тизрәк китәсе иде. Мәгәр моннан кая барасы, шул совхозгамы, әллә өенәме? — үзе дә белми иде.

Ул шулай тәнәфес җитүен сабырсызланып көткәндә, Беренче секретарь, өстәл өстенә иелгән йөзен күтәрми генә:

— Иптәш Ачилов, бу мәсьәләдә сез ни уйлыйсыз? — диде.

Гариф әкә, үз уе белән мавыгып утырганлыктан, ни хакта сөйләргә дә белмәде.

— Минем... фикерем юк шикелле, — диде ул.

— Кызык. Шундый мөһим мәсьәлә, югыйсә?

Кабинетта тынлык урнашты. Бюрода утыручы һәркемнең үзенә төбәлеп карап торуын чамалады Ачилов. Бу уңайсыз кичерешне дә үткәзеп җибәрде. Тәнәфес игълан ителү белән тизрәк урамга ашыкты, машинасын эзләп тапты. Кайсы якка юл тотарга? Әллә яңадан бюрога кереп утырыргамы? Әлбәттә, аңа бу җыелышта булу кирәк. Шулай ук Мария Васильевна хакында кемнәндер белешәсе, аның хәлен, кайдалыгын ачыклыйсы да бар иде.

Рульгә утыргач, машина үзеннән-үзе өйгә тартты.

Өенә кайтып төшсә — һичкем юк, тып-тын. Кунаклары кая? Кызы нишләп юк? Шашынып бүлмәдән бүлмәгә йөренде. Юк! Өс-башын да салмый, хәле китеп Анабиби караватына ауды. Кайсы якка китеп олаккан соң болар?.. Йөрәк авыруы... Һич көтмәгәндә теге дөньяга алып китүе дә бар бит аның. Айлап кыймылдамый яткыруы бар... Мәрьям ни хәлдә икән?

Гариф әкә һич кенә дә берәр карарга килә алмый аптырап озак ятты. Үз хисенә үзең хуҗа булма, имеш... Җебеп кал, имеш. Үзен тирги-тирги инде кузгалырга ниятләгән иде, урам як ишегенең шыгырдап калганы ишетелде.

Эсседә әлсерәгән Ачил баба кайтып керде. Кергәч тә иң әүвәл чиләк күтәреп су эчте, аннан соң гадәтенчә сакалын сыпырып куйды. Аның бу тынычлыгы Гариф әкәгә дә тәэсир итте. Ул да сабырлана төште. Икесе дә кунак бүлмәсендәге өстәл янына килеп утырдылар.

— Кайларда йөрдегез, ата?

— Мәрьямнең хәлен белдем...

Гариф әкәнең йөзе ачылып китте. Күңеле тулып, бер ара карап торды да малай чагындагы кебек атасы күкрәгенә сыенды. Карт кытыршы кулы белән улының җилкәсеннән сыйпап сыпыра-сыпыра:

— Тинтәк... — диде. — Өстеңнән тузан бөркелеп тора.

Гариф этисе күкрәгеннән башын алмый гына:

— Хәле ничек соң? — диде.

— Ярыйсы, улым, ярыйсы. Шифаханәгә китерештек.

— Рәхмәт, ата...

Шул чак кайсы яктандыр берәүнең үксеп елаганы ишетелеп калды.

— Анабиби! — дип, Гариф әкә йөгереп ишегалдына чыкты. Тик нигәдер Анабиби үзе күренми иде. Ни булган аңа, нигә елый? Ары барды, бире килде — кыз күренмәде.

— Арифҗан, бире кер! — диде Ачил баба. Болай ашыгып чакыруыннан этисенең борчылганлыгы сизелде. Гариф әйләнеп кергәндә ул Анабиби бүлмәсендә, ниндидер кәгазь тотып тора иде.

— Менә моны күрдеңме? Бу өстәлдә яткан икән... Укы әле.

Гариф әкә аны алып укырга кереште. Суд хөкеменең аңа җибәрелгән нөсхәсе икән.

Суд ике якның да гариза-дәлилләрен тыңлап, документлар белән яхшылап танышканнан соң шундый карарга килгән: гражданин Ачилов Гариф баланы, туу белән үзенә алып, кулыннан килгәнчә тәрбия-

ләп үстергән. Моның белән ул совет кешесенә хас эш эшләгән. Әмма баланың үз атасы булган гражданин Исраилов Мөхәммәтәмин, ул вакытта шәхескә табыну чоры хаталарының корбаны буларак, нахак репрессиягә дучар ителгән, шул сәбәпле хатыны һәм баласы хакында бернинди дә хәбәр ала алмаган. Моның өстенә, бала укыган мәктәптән судка вәкил итеп җибәрелгән педагог Шәфигуллинаның сөйләвенчә, Анабибигә дөрес тәрбия бирү өчен ул торган өйдә кирәкле шартлар юк: «Гражданин Ачилов җаваплы эштә эшли, бик еш өйдән китеп йөри, бала кичен дә, көндезен дә бер ялгызы кала. Ул үз иркенә куелган. Укытучылар белән мөгамәләсе тупас, дорфа; баланы бу шартта калдыру педагогикага сыймастай бер хәл, яшүсмернең киләчәге өчен хәвефле... Гражданин Исраилов Мөхәммәтәминнең хәзер гаиләсе бар, өй шартлары яхшы. Башка барлык хокуклары кайтарылу белән бергә аның аталык хакын таләп итүе дә канунга туры килә... Шушы әйтеп үтелгән факт һәм фикерләрне искә алып, өлкә халык суды мәсьәләне гражданин Исраилов файдасына хәл итте...»

Гариф әкә бу хөкемне ахырынача укый алмады, күз аллары карангыланып китте. Йөрәге еш-еш тибә, ә колак төбендә һаман баягы елау авазы яңгырап тора иде. Инде: «Кая ул кыз, кем тигән?» — диясе, эзлисе юк иде. Үзе гаепле икән шул барысына да.

Ачил баба да, инде нишләргә белми, гаҗиз булып утыра бирде.

Гариф әкә, бердән хушына килгәндәй:

— Анабиби!!! — дип кычкырып куйды. Ишектән башта Тимер, аның артыннан Газыймҗан күренделәр.

Тимер, Гариф әкә алдына килеп, әмма күтәрелеп карамый гына:

— Без сезне эзләп шәһәргә бардык, — диде үпкәләп. — Сез, Ариф әкә, судка бармагансыз, Анабибине якламагансыз... баш тарткансыз.

Өзеп-өзеп кенә шулай үпкәсен әйткәннән соң, ул әчке якка кереп китте.

Гариф әкә, урыныннан кузгалып, «Анабиби!» дип чакыра-чакыра ишеккә таба омтылды. Ул инде Тимернең кызны каядыр яшереп, бикләп китүен чамалап алган иде.

Шул арада алар капкасы каршына такси килеп туктады. Аннан бер хатын, бер ир төште дә туп-туры Ачиловлар йортына таба юнәлде. Ишегалдына алар, эт юкмы дип шикләнгәндәй, карана-карана килеп керделәр. Боларның икесе дә урта яшьтә, килешле, пөхтә киенгәннәр иде. Аеруча ире затлы күренә: изүе ачык ефәк күлмәктән, яхшы пинжәге беләгенә эленгән. Беренче карашка гел көлемсерәп, күңелне үзенә тартып тора кебек иде. Гариф әкә аны хәтта кайчандыр, кайдадыр күргән дә шикелле булды. Хатыны да шактый интеллигентлы күренде, яхшы кием, колак яфракларын тартып торган авыр алтын алкалар, буяулы ирен. Тик бу очракта үзен ничек тотарга гына белми, ахрысы бер елмайган итә, бер җитди кыяфәткә керә иде.

Алар өйгә кергәч тә Гариф әкә баскан урыныннан кузгалмады. Каршында, һичшиксез, Исраилов үзе иде. Хатыны белән килгән. Анабибине алып китәргә килгәннәр... Алар исәнләште, тагын нидер әйтте шикелле. Гариф әкә һични ишетмәде. Моңа чаклы ул Исраиловны килбәтсез бер мәхлук җан итеп күз алдына китерә торган иде. Ә бу исә хатын-кыз кебек чибәр, һич кенә дә яман бәндәгә охшамаган.

— Мин кызымны алырга килдем, — диде ул.

Әчке ишекне ачып, каяндыр Анабиби килеп чыкты. Күзе кызарган, битендә яшь эзе, үзе чак кына калтырана сыман, ә кулында кечерәк төенчек. Чыкты да Исраиловка таба китте. Каршына җиткәч, күтәрелеп йөзенә карады. Исраилов, көтелмәгәнрәк бу очрашудан аптырап, ни әйтергә дә белми каушап калган иде. Ул арада Анабиби янә кискен борылып Гариф әкә ягына китеп барды. Сүзсез генә атасының сулган йөзенә текәлде. Инде ул еламый. Әчке, караңгы бүлмәдә иртәдән бир-

ле елый-елый күз яше кипкән иде. Гариф әкә ике кулын сузып аны кочып алмакчы итте. Шул чак кызы, төенчеген аның аяк астына ташлап, йөгереп ишеккә таба юнәлде, аны дыңк иттереп бәреп ачты да, урамга ук чыгып чапты. Өске киштәдән зур чемодан очып төшеп, аннан идәнгә елка бизәкләре чәчелделәр. Кыз артыннан кузгалган Исраиловлар исә аларны чатыр-чотыр изеп үттеләр.

Олылар өйдән чыккалаганчы, Анабиби, машина ишеген шап-шап китереп, аңа кереп тә утырган иде. Иң әлек аның янына йөгереп Тимер килеп җитте. Ул нишләргә дә белми машина тирәли уралган арада Исраиловлар да шунда утырып, машина кузгалып та китте.

Гариф әкәнең аларны озатырлык та, урыныннан кузгалырлык та хәле калмаган иде. Моны күреп торган Ачил баба аңа урындык сузды. Үзе, бу вакыйгадан аңына килә алмый, аптырап, баядан бирле бер читтә боегып басып торган оныгы янына китте.

Гариф әкә, аяк астындагы уенчыкларны баса-сыта, бүлмәгә керде. Башка вакытта ул нәни генә пыяла кыйпылчыгын да, кызы киселмәсен дип, идәннән иелеп алыр, читкә илтеп ташлар иде. Өстәл янындагы көрсигә утырып, башын өстәлгә салды.

— Атам, берәр сүз әйтче, — диде.

Ачил баба җавап бирмәде. Ул ишегалдында ук калган, үзе дә нишләргә белми арлы-бирле йөренә иде. Улы янына юри кермәде. Керсә бит аны я тиргисе, я юатасы була. Еласа — ялгыз елап алсын. Ничек юата аласың аны?

Чирек сәгатьтән соң Гариф янә:

— Әти! — диде.

Ачил баба бүлмәгә кереп, улы каршына килеп басты.

— Мәрьям бюро хакында берәр сүз әйтмәдеме?

— Юк... Менә бер хат тапшырган иде.

Ата кеше, биленә уралган яулык араларын актарып, бер конверт чыгарды. Гариф әкә ачмый гына хатны өстәл өстенә алып куйды: укыргамы-юкмы дип икеләнә иде ул.

Ачил баба, улының кайгыруын карап тормас өчен, яңадан чыгып китте. Бакчага кереп, авыр йөзем тәлгәшләрен учына алып караштыра-караштыра тәмнәрен татырга кереште. «Бу ялгыз-ятим йортта кем сөенеченә пешә болар, кемгә кирәгер инде алар?» Ул шулай әрнеп, ачынып йөргән бер мәлне өйдән Гариф улының шаркылдап көлгәнен ишетте. Карт үз колакларына үзе ышанмый өй ягына каерылып карады. Аяк астында коры яфрак кыштырдый иде. Көлү янә ишетелде. Инде Ачил баба куркына калды: ни булган моңа? Тилерәме әллә? Каушап, каударлап өйгә таба атлады.

— Атай! Ай-вай-вай! Атай!..

Ачил баба йөрәген totып өйгә керсә, Гариф әкә, аякларын селкеп, Анабибинең кечкенә караватында ята. Үзе һаман һа-һа көлә иде. Аяк очында Анабиби төенчеге. Ул чишелгән, аннан өр-яңа күлмәк белән Анабибинең бала чактагы курчагы күренеп тора.

Атасын күргәч, Гариф әкә тагын бер шаулатып көлде дә аякларын һавага чөеп җибәреп:

— Һай, кызый... Ни эшли бит, ишекне шап иттереп атып бәреп чыгып китә. Мә, укы әле, әти!

Мария Васильевна менә нәрсә яза иде.

«Өлкә судындагы эштән хәбәрдар булып, мин Исраилов хакында сораткан идем. Хәзергә сиңа кирәкле мәгълүмат шул: Исраилов оста аферист. Судка тапшырган документлары ялган. Ялган эшләре һәм алыш-биреш итүе, алдашулары өчен унике елга хөкем ителгән. Хәзер үзен «шәхес чоры корбаны» итеп күрсәтмәкче. Асылда бүген дә иске гадәтен ташламаган, алдашу юлы белән киткән. Монысы анык мәгълүм. Анабиби өчен бик кайгырма. Мин кичә шәһәр прокуратура-

сында булдым, тик эшне ахырынача җиткерә алмыйча, менә бу хәлгә юлыктым... Мәрьям».

Атасы хат укыган арада Гариф әкә идәндә аунап яткан әйберләрне урнаштырып, бүлмәдә мәш килеп йөри иде. Үзе һаман да:

— Вәт кызыкай, ә?! Ишекне бәреп чыгып китә бит, — дип әледән-әле кабатлый. Аны ул әйтерсең кызының гомерендә бер эшләгән иң зур яхшылыгына куанган сыман сөенеч белән тәкърарлый иде. Ачил баба хатны укып бетергәч:

— Тагын ниләр диде Мәрьям? Сезне шундук таныдымы соң ул, эти? Авыр ятамы? Бюро хакында бер сүз дә әйтмәдеме? — диде, анңары артык сүзчәнләнеп, сөенеп китүен үзе дә төшенеп, сабырлана төшеп дәвам иттерде: — Берәүнең әбләһ икәнлеген белеп шатлану шәп түгел, эти, аңлыйм. Тик бит мин анысына сөенмим. Күңелем күптән аның яман кеше икәнлеген сизенә иде. Ә сөенүем... Хәер, аны әйтеп аңлатып буламы соң, эти?

Ул ишегалдына чыкты. Газыймҗан әле дә булса капка төбендә боегып утыра иде.

— Тимерне чакыр әле,—диде аңа Гариф әкә. Үзе аш-су савыт-сабасына тотынды. — Туганым, кайтышлый кибеттән бер-ике чеметем бөтнек белән борыч та алып кайт. Пылау пешерәбез.

— Хуп, агай. Ә тегесе, ничек диләр әле сездә, кирәкмәсме соң?

Гариф әкә көлеп куйды.

— Һай, егет икәнсең син үзең дә! Әлбәттә, ал. Ирләр генә өелешеп калдык, бер сыйланырбыз, һич югы. — Ул атасына шуклык белән күз кысып куйды. — Вәт минем кызыкай, ишекне бәреп чыгып китте, ә? Төенчеген ничек атып бәрде?! Ай-ай, кызу син, Анабиби дускай...

Шулай сөйләнә-сөйләнә Гариф әкә кунак пылавы пешерергә керешТе. Ишегалдындагы учактан уралып-уралып төтен күтәрелә башлады. Ул төтен күрше-күләнгә, дус-ишкә бу йортта бүген кунак барлыгын, сөенеч-куаныч барлыгын хәбәр итә иде. Әйе, кызган таба өстендә суган турап торган Гариф әкә өчен сөенечле дә, көенечле дә булды бүгенге көн. Анабиби артыннан ишек шапылдап ябылганда аның күптәнге яра-җәрәхәтләре ачылып киткән кебек тоелса, Мария Васильевнаның язуы терелтүче дәва булды.

Иртәгесен кунаклар китәргә җыенды. Гариф әкә райком гаражыннан машина чакыртып, аларны аэропортка илтеп, озатып куюны шоферына йөкләде. Аерылышу һәр чак сагышлы була. Ул бигрәк тә Газыймҗанга күңелсез тоелды. Бернича көн эчендә ул Гариф әкәсенә ияләшеп өлгергән иде. Аңа хәзер туганының сөенече дә, көенече дә, хәтта тавышы да якын булып калды. Менә шулдыр инде ул кан тарту дигәннәре. Өстәвенә, шушы бернича көн эчендә никадәр вакыйга, кичерешләр булды бит. Газыймҗан күңелендә алар озак сакланыр. Шуңа да, саубуллашканда, агасының сурәтен йөрәгенә сеңдерергә теләгәндәй, аңа бик озак карап торды.

— Кабат күрешү насыйп булмаса — аман бул, туган. Үз илеңә исән-сау кайтып җитә күр. Бәхетең ташып торсын, — дип, Гариф әкә аңа хәерле юл теләде.

Ачил баба оныгын кочагына алып, аркасыннан сөя-сөя:

— Инде без Камиләләргә китәрбез. Аннан соң Әкбәралигә, алла боерса... Аны күрмәгәнгә дә алты-җиде ел узгандыр, шәт. Ятим үсте шул. Анасы да чирләшкә иде, никтер күптән хәбәрләре юк, — диде.

Ата белән ул кочаклашып саубуллаштылар.

— Әкбәрали туганыма күптин-күп сәлам ирештерерсез,— дип калды Гариф әкә.

Машина, тузанлы юлда яңа көпчәк эзләре калдырып, район үзәгенең такыр урамыннан басу юлына борылды. Төнге дым кибеп өлгер-

мәүгә карамастан, тигез дала өстендә җилнең өермә күтәреп уйнаганы күренә иде. Алар сузаеп, ерак офыкка таба йөгерешә-йөгерешә д юкка чыга кебек. Ачил бабалар машинасы ерактагы тау итәгенә чак лы бөтен тирәлекне биләп торган күм-күк пахта дингезеннән бара Ара-тирә ярылып киткән мамык кузаклары ак сәдәф кебек ялтырап күренеп кала иде.

Басуларда инде уңыш җыюга хәзерләнәләр. РТС ишегалларында өр-яңа буяулы комбайннар тезелешеп тора. Җәйге җиңел чапаннарының чабуын кыстырып алган бер төркем яшьләр, радиоалгыч такмагына туры китереп баса-баса, ындыр табагын таптый. Кыр станы ышыгына җыелышкан кызлар пырх-пырх көләләр.

Басу өстендә аэроплан айкала — ул пахтага дару сибә. Бер-ике көн дә үтмәс, ул дару пахтаның барлык яфракларын яндырып төшерер, сабакта кәса-кәса мамык тартмачыклары гына торып калыр. Ә тагын берничә көннән исә басулар танымаслык булып үзгәрәчәк: иң өске тартмачыклар ачылып тирә-юньне ап-ак итәрләр. Менә шунда инде басу кайнап торачак! Кешеләр һәм машиналар мамык җыя башлый. Әлегә эш кызмаган. Бары тик шул көннәргә хәзерләнәләр генә.

Ачил бабаларны илтә барган шадра шофер шаян күңелле егет икән. Дөньяның иркенлегенә, матурлыгына сөенеп туймый торган дәртле җан. Машинасы да җилләр уйнатып очып бара. Газыймҗанның кемлеген белгәч аеруча ачылып китте. Туып-үскән даласын ул шивилгәнләләр йөзем-чикләвекле тау илләрен яратканнан ким яратмый иде бугай.

— Безнең якларны белмисең әле, туган. Көз ул Үзбәкстанда иң дилбәр, иң соклангыч бер фасыл. Алтын көз диләр аны. Бу сүз көзен алтынланып саргайган Рәсәй урманнарына нисбәтән туган булса кирәк. Ләкин ул күбрәк безнең Үзбәкстанга хас. Ак алтын өлкәсе ич без. Хакикән алтын көз — ак алтын көзе ул.

— Бераз соңрак киләсе калган сезгә, — дип, шофер егет дәвам иттерде. — Бу чиксез басулар тоташтан акка күмелә. Ак болыт кебек ап-ак эскертләр калкып чыга. Бу юллар да, агач-куаклар да агарып кала. Телеграмм чыбыкларына тоташ-тоташ ак мамыклар асылып тора. Ак болыт төягән автопоездлар чабыша башлый. Машина көпчәгенә дә урала мамык, хатын-кыз итәгенә дә ябешә... Мамык белән дөнья тула. Төннәр салкынайган саен мамык тартмачыклары черт-черт итеп ачыла бара. Кичә генә җыеп алынган пахта кырын янә ап-ак мамык сырган була.

Көзнең соңгы атналары тагын үзенчә матур бездә. Кыр станы янәшәсендәге буалар чистарып кала. Су өстендә ялгыз каектай көзге яфрак йөзә. Ә кичке тынлык урнашты исә, ул буа тирәсендәге куаклыктан берәү моңсу гына итеп быт-былдык, быт-былдык дип аваз салырга тотына... Шул чак печән түшәгән куышта йоклаулары — әй рәхәт тә соң! Таң алдыннан дым тартып авырайган юрган эченнән баш калкытып тыңласагыз, өлгерүе җиткән кавынның шартлап ярылганын ишетерсез. Авызыгыз татлы кавын тәмен тойган кебек булыр... Шул сап-сары кавын телеменең тел өстендә эреп китүләре! Их, туган, белсәң икән син ул иртәнең гүзәллеген!

Шофер авыз суларын китереп телен чартлатып алды. Әйтерсең алдында сап-сары йомры кавын тора иде.

Газыймҗан боларның берсен дә күрмәгән — аңа бик кызык тоелды. Күз карашы янып, шоферның авызына керердәй булып утыра иде.

— Безнең якларга соңрак килгән булсагыз әле күп гаҗәеп хәлләр күреп китәр идегез, — дип сүзен төгәлләде шофер.

Аэропортта Газыймҗан бу шат күңелле егет белән һич аерылышасы килми генә аерылышты. Гомумән бер нәрсәне аңлады ул, бу илдә иң күңелсезе — очрашкан кешең белән аерылышу икән. Кая гына

бүлмасын — бәгыреңнең бер өлеше өзелеп кала кебек. Әллә кабат кайтылмас дип йөргәнгәме?

Аэропорт зур, кеше күп. Бик ыспай, тәртипле күренгән берничә егет килеп Ачил баба белән исәнләшеп киттеләр. Бала җитәкләгән бер карчык, бер кочак чәчәк күтәреп, перронга ашыгып үтте, залда көзге чәчәк хуш исе таралып калды.

Кашларын бер тиң итеп нечкәрткән, керфекләренә сөрмә тарткан стюардесса кызлар үтеп китте. Алар төс, кием белән дә бер тиң: маргелан атласыннан тегелгән кыска күлмәк кигәннәр, үзләре фәрештәдәй асыл... Зөһрәдер кебек аларның һәммәсе.

Кызык, бу илдә һәммә нәрсә иркен, киң, чиксез зур икән. Аэровокзал дисәң — хан сарае кебек. Кыр-басу, җәйләүләр дә, хәтта чүлләр дә иксез-чиксез. Газыймҗан янында утырган бабасы да шулар ише, мәңгелеккә килгән Алып батыр диярсең. Туксан дүрт яшь! Ә шулай да илдән-җирдән аерылган суфый-дәрвиш түгел, карашында бүгенге көн борчуы, күңелендә бүгенге көн гамәле. Шуның белән ул Газыймҗанга якын, тиң сыман иде.

Ачил баба белән Газыймҗан төшкелек ризыкны капкалап, пластмасс савыттагы чәйне эчкәнче самолет төшә дә башлады. Аста киң бетон мәйдан күренеп калды, гүя күк белән җир бергә тоташмакчы иде.

Ачил бабалар бу зур шәһәрнең кунак йортына урнашкан арада кич булды. Газыймҗан түземсезләнеп үзләренә билгеләнгән бүлмәнең балконына чыкты. Аста — кичке шәһәр. Менә нинди икән ул башкала! Каршыда театр, аның алдында су бөркеп торучы фонтан. Бакча тулы халык, мәйдан тулы, урам тулы халык. Газыймҗан боларны байтак тамаша кылды. Ниһаять: —

— Әйдә, чәй эчәргә кер, — дип, бабасы чакырып алды.

Ни гомер бергә килеп, бер авыз сүз сөйләшмәгәннәр иде. Ахры, икесенең дә күңелен бер нәрсә борчыган, чәйдән соң нигәдер тагын Гариф әкә хакында сүз башладылар. Әле дә булса Газыймҗан: «Агамның ул эше ничек бетәр икән? Анабиби кире кайтырмы, юкмы? Җыелышта эшеннән алмаслармы?» — дип, кайгыртып тора иде.

— Һаман төшенмим, ни дип каныга ул марҗа Ариф агама? — диде Газыймҗан ачынып.

— Мәрьямме? — дип көлде аякларын бөкләп караватында хәл алып утырган Ачил баба. — Һичкайчан дошманлашмас алар, балам, беләсең килсә.

Бабай сакалын сыпырып, күңел елмаюы белән балкып, берара уйчан гына утырды.

— Башкалар өчен ул сер, ә миңа калса, бердәнбер көнне алар, ир белән хатын булып, култыклашып китсәләр дә һич гаҗәпләнәсе түгел.

— Ариф агам белән шул хатынмы?

— Алар үзара әйтешсә дә, бер эш өчен янудан гына, балам. Алар арасына һичкем керә алмый. Сиңа моны аңлавы читен, белмисең әле син аларны. Башкалар да белми.

Карт янә уйга талып утырды. Газыймҗан, тәрәзә каршына килеп, аска карады. Ташкент урамнарында тормыш һаман кайный, мәйданда да халык көндезге кебек үк иде. Бер уйласаң, боларның бөтенесе Газыймҗанга чит-ят бит, ә карасана, шушыннан кадерле җир юк кебек, елыйсылар килә. Ул түбәтәйләр, эшләпә, яулык, чалмалар...

Ачил баба, ут алмыйча, урынында сузылып яткан килеш кенә баягы әңгәмәсен дәвам иттерде:

— Беләсеңме, балам, бу хәлләрнең кайчан башланганын? Күп су акты ул көннән бирле, бигрәк күп...

Бабасының сөйләгәнен йотлыгып тыңлап утырган Газыймҗан тәрәзәгә карап алды. Инде шәһәр урамнары тынып калган — төн урталары җиткән иде.

Газыймҗан Гариф әкә, Мария Васильевналарны — еракта калган дала вакыйгаларын янә күңеленнән кичерде. Ачил баба хикәясеннән соң инде ул аларны яңача күрде.

— Шулай ул, балам. Агаң белән Мәрьям һичкайчан да бер-берсенә канықмас, дошманлашмас. Бер-берсенең ялгышын кичерешмәсәләр генә. Дуслыклары — бик-бик күптән килә.

Иртәгесен чәй эчеп алгач, Ачил баба оныгына:

— Син нишләрсең, миңа Үзәк Комитетта булырга кирәк. Кызыксынсаң әйдә, — диде.

Икәү барырга уйлашкач, такси чакырттылар. Шофер кая барабыз, дигәч, Ачил баба:

— ЦКга, — диде.

Төз-төз ак тирәк, карагач сагында утырган өч катлы җыйнак йорт янында туктадылар.

— Мин Ачил баба булам, бу минем оныгым, — дип, вестибюльдә торган яшь-яшь милиционерга аңлатты бабай.

— Хуп-хуш, Ачил баба, үтегез, — диде милиционер.

Газыймҗан әле булса бабасының кем икәнен белеп бетерми иде. Әле ул далада туктап, куй авыруына игътибар итмәгәннәре өчен көтүчеләрне тирги. Совхоз директорының исем-атын сорап, аңа да шелтә әйтә. Зур бер районга, аның меңләгән кешесенә җитәкче булган Гариф әкәне, шулай ук олы яшьтә икәнлегенә дә карамастан, әйтик, орышып, хәтта тиргәп алуы да аңлашылсын ди. Үзенең дә чәче ап-ак булса да, ул барыбер Ачил баба өчен бала бит әле. Инде бу милиционер — әле генә берәүнең сузган документын әйләндерә-әйләндерә карады. Ачил бабага исә, мин фәлән-фәләнов диюгә, «Хуп, рәхим итегез» ди. Җитмәсә, үзе өченчә катка чаклы озатып та куйды. Баба белән оньк иркен, якты бүлмә ишеген ачтылар. Аларны яшь кенә сөйкемле кыз каршы алды.

— Кызым, Ачил баба килгән дип секретарьга кереп әйтче,— диде ул.

Берничә минуттан кыз өстәлендәге телефоннарның берсенә җан керде. Кыз, башын ия-ия кабатлап:

— Әйе, аңладым, аңладым. Шулай дип әйтермен, — диде. Һәм бабага таба борылып: — ул сезне җыелыш башланыр алдыннан кабул итә. Көтегез.

Секретарь аларны билгеләнгән вакытта кабул итте. Аның кабинеты тагын да иркенрәк, биек һәм якты иде. Ачил бабага аның үз төс-кыяфәте генә охшамады, ахрысы. Ул иң беренче итеп аның исәнлеген белеште.

— Йөрәк кыскалап тора шул, — диде секретарь.

— Ай-яй, саклан. Минем Өмидәмә әйттерәсең калган, — диде Ачил баба. — Кызым хәзер яхшы доктор булып танылды бит.

— Ә бу сезнең чит илдән кайткан оныгыгыз буламы? — дип, сүзне үз авыруыннан икенче мәсьәләгә күчерде хуҗа. Газыймҗан белән исәнләште. — Бөтенләйгә кайттыгызмы?

— Юк, күрергә, кунакка гына. Туган-тумачаларын күрсәтеп йөрим.

Ачил баба секретарь каршындагы йомшак креслога җайлабрак утырды, кулындагы төенчеген янына куйды.

— Арифка кагылышлы бер-ике сүзем бар иде.

— Чамалыйм, — диде секретарь елмаеп.

— Кемдер, имеш, Ариф Мәрьям белән эшли алмый дигән гайбәт чыгарган. Обкомнарында да шулайрак уйлыйлар, ахрысы. Ә бу ялгыш фикер. Туганкай, кемгә кирәк, син шуңа әйт инде — икесен аермасыннар. Үзара әйтешсәләр дә, эш өчен бит, хәер, үзең дә аларны яхшы беләсең.

— Хак. Тик сездән яхшы белмимдер дә әле, баба. Ә Гариф Ачиловның тәкъдимнәрен карап чыктым. Кызык кына фикерләре бар.

— Ариф та, Мәрьям дә бергә эшләсеннәр иде, — дип, тагын бер кабатлады бабай.

— Сезнең кирәкмәскә сорамавыгызны беләм, баба. Яхшы, аңладым. Өлкә комитеты җитәкчеләре белән киңәшермен.

— Рәхмәт, туган. Без сезне тоткарламадыкмы?

— Хәзер кая юл тотышыгыз, баба?

— Аэропортка дибез. Хөҗайлидә Камилә оныгым тора. Бик күптән күргән юк иде үзен.

Саубуллашканда Ачил баба белән секретарь, көрәшкә чыккан батырлар кебек, берара кочаклашып басып тордылар.

— Оһо, баба, сез гәүдәгә авыр икән. Билегез — егет биле, үзегез — чинардай әле сез, Ачил баба, — дип, секретарь картны мактап та алды.

Чыгып барышлый ишек төбендә тукталып, Ачил баба янә:

— Өмидәмә әйтермен, яхшылап карасын. Хәзер ул атаклы доктор бит, — дип кабатлады.

— Мин дә оныта язганмын, Гарифҗанга әйтерсез, аның Куйки районын кайтару хакындагы тәкъдимен тиздән Верховный Совет хәл итәргә тиеш.

Аэропортта алар тиз-тиз генә икешәр шампур кәбаб капкалап алдылар да, ярты сәгать тә тормастан, Нукуска дип юл тоттылар.

Шулай итеп, Ачил баба белән оныгы машинада, атта, самолетта, пароходта, поездда йөреп республиканың бер чигеннән икенче чигенә килеп чыктылар. Бу илнең әйтерсең бөтен тарихын үз җилкәсендә татып караган бабасы белән онык арасында әңгәмәнең төрлесе булды.

— Баба, Үзәк Комитет секретаре шаһка тиңме? — дип сорап куйды берара Газыймҗан.

— Юк.

— Ә баш вәзиргә?

— Юк, балам. Секретарьларны, эшенә, гакылына карап, халык сайлый. Аларга акыллы, гадел булу шарт.

— Алайса, Ариф агам да шундый зур кеше инде?

— Ул гадел кеше, балам... Тагын ул бала җанлы, бала ярата. Эш сөючән...

## Галимҗан Латыйп

### Яңгыр

Мал тоягы кысылырдай
Яргаланган иде җирләр.
Керде җанга энә булып
Мәрхәмәтсез кайнар җилләр...

Чыкты болыт. Ява яңгыр.
Ява. Ява.
Коеп ява.
Кирәклеген тоеп ява.
Җылы сөт эчкән кебек җир,
Иркенәеп китте һава.

Каз-үрдәкләр сөенеште,
Юды яңгыр көенечне.

Яңгырдан соң бал кортлары
Очты, очты —
Уйнап очты.
Җирне, күкне, тереклекне
Иксез-чиксез шатлык кочты.

Яраларга ит үскәндәй,
Йомылдылар ярык җирләр.
Китте сагыш чырайлардан,
Дөп-дөп басып йөрде ирләр.

Ачыласы серләр һаман
Бардыр әле,
Бардыр,
Бардыр.
Һәр нәрсәгә тормыш бирә
Кояш.
Һава.
Яңгыр.

## Юллар

Юлларымның
Очы-кырые юк,
Әйләнә ул,
Урый җир шарын:
Уңны-сулны күреп-карап үтә,
Хәл-әхвәлен белеп дөньяның.

Юллар, юллар!
Газиз җир әнкәнең
Кан юллары сыман сузылган.
Күпме юллар әле узылачак,
Ә күпмесе инде узылган.

Үткәнеңә бер әйләнеп кара,
Юлларыңны яңарт күңелдә.
Барысын да истә-хәтердә тот,
Үз рәхәтең белән күмелмә.

Яхшысын да күрдек,
Яманын да,
Хәтәрен дә үттек юлларның.
Яшел идеме соң һаман шулай
Бүген йөри торган урамың?

Ак юлларга,
Хак юлларда дошман
Үлем чәчте,
Кара таш куйды.
Юллар иркен, яшел булсын өчен
Күпме ир-ат җиргә баш куйды.

Хәерле юл сезгә, юлаучылар!
Әйләнегез, әйдә, җир шарын.
Үтeләчәк юллар сезне көтә
Иминлеге өчен дөньяның.

## Әнкәй

Себеркеләр бәйләп куйган әнкәй:
«Улым кайтса, мунча ягармын.
Үткән төнне төштә күрдем әле,
Йөзе боек иде баламның».

Оекбашлар бәйләп куйган әнкәй:
«Аякларың, улым, туңмасын,
Салкын килә кышлар...
Син гел юлда,
Минем янда бик аз буласың».

Миләш кагы коеп куйган әнкәй:
«Күңелең төчеп китсә, кабарсың,
Син аунаган урман миләшләре,
Истәлекләр бераз яңарсын».

Мәтрүшкәләр җыеп куйган әнкәй:
«Ал, улым, ал!
Ютәл төшкәндә
Шифасы күп аның...
Оныта күрмә
Сөтле чәйгә кушып эчәргә».

Ана күңеле —
Мәңгелек ут икән,
Яна шулай гомер-гомергә.
Ул һәрвакыт әзер
Балам диеп
Ярты җанын ярып бирергә.

## Әйт әле син миңа

Биекме, яктымы,
зәңгәрме күкләрең?
Әйт әле, йөкләрнең
ниндиен күтәрдең?

Җиңелме, авырмы
иңеңдә биштәрең?
Татлымы икмәгең,
тынычмы кичләрең?

Ялтырап, шалтырап
үтмиме көннәрең?
Булдымы җан атып —
тауларга менгәнең?

Дан өчен юргалап,
таммыймы җан тирең?
Анадан туганда
гөнаһсыз җан идең.

Рәхмәтме, нәфрәтме
җыйдың син үзеңә?
Хәлеңнән киләме
туп-туры карарга
дөньяның күзенә?

Хаклымы икән син
бу җирдән тынычлап,
елмаеп китәргә?
Күкләрең зәңгәрме,
биекме, яктымы?
Әйт әле син миңа,
Соң була күрмәсен иртәгә.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**НОЯБРЬ, 1975**

Ике зур гигантның — Түбән Кама нефтехимия комбинатының һәм Кама автомобиль комплексының бер-берләренә якын булуы шин заводын төзүне тизләтте. Чимал чыганагы янәшәдә, резина «аяк киемнәре» сорый башлаячак завод сафка басу алдында. Шулай итеп, артка калмас өчен, төзүчеләргә дә, шинчыларга да куәтләрне үзләштерү һәм эшкә җибәрү сроклары турында өр-яңадан уйланырга туры килде.

Беренче комплекс 1974 ел башында эшли башлаган иде, ә аның проектта билгеләнгән куәте графикта каралган унбиш ай урынына алты айда үзләштерелде. Җиңел автомобильләр өчен ике миллион ярым шин эшләп чыгарырга тиешле икенче комплексны үзләштерү сроклары ике тапкырга кыскарды. Шуның хисабына гына да түбәнкамалылар өстәмә рәвештә йөз меңнәрчә шин җитештерделәр. Завод камералар эшләү буенча беренче, покрышкалар җитештерү буенча дүртенче урынга чыкты.

Бүген Түбән Кама шинчыларының игътибар үзәгендә — заводның икенче чиратын төзеп бетерү. Хәзер анда җиһазларны урнаштыру һәм авыр йөк машиналары өчен шиннар эшләү бара. Әйе, цех инде продукция бирә. Монтаж эшләрен тулысынча тәмамлауны көтеп тормау — Түбән Кама шинчыларының традициягә әйләнгән эш алымнары әнә шул. Алар җиһазларны кору-урнаштыру барышында ук һәр станокны, әзер һәр линияне эшләтә башлыйлар...

Түбән Кама шин заводы үзенең төп продукциясен — Кама автомобиль гиганты өчен покрышкаларны серияләп чыгарырга кереште. Моның өчен алдан зур хәзерлек эшләре алып барылды. һәм коллектив үзенә йөкләнгән җаваплы заданиеләрне намус белән үтәп чыкты. Покрышкалар ГОСТның барлык таләпләренә җавап бирәләр.

**«Правда», Мәскәү.**

Кама автомобиль заводы — специальләшкән күп санлы предприятиеләрнең тулы бер бөтен комплексы ул. Аны төзү өчен билгеләнгән срок зур түгел. һәм әнә шул кыска вакыт эчендә югары үсешле производство белән идарә итә алырлык күп меңле бердәм коллектив тудыру ифрат авыр эш. Менә шуңа күрә дә комплексның партия оешмасы кадрлар туплау һәм хәзерләү мәсьәләләренә беренче чираттагы эш итеп карый. Автозавод өчен эшчеләр, инженер-техник работниклар сайлап алу, аларның белемнәрен автомобиль производствосының катлаулы шартлары таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә үстерүне оештыру буенча даими эш алып бара.

Эшчеләрнең, инженер-техник работникларның, хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү киң масштабларда тормышка ашырыла. Бүгенге көндә ике меңнән артык белгеч инде эшли торган предприятиеләрдә өйрәнү уза. Аерым алганда, Волжск автомобиль заводы КамАЗ өчен 340 кеше әзерләде. Бу елларда КамАЗ белгечләре

анда алдынгы тәҗрибә белән танышалар, илебездә һәм чит илләрдә эшләнгән ерңа җиһазларны өйрәнәләр, бүгенге технологик процессларны үзләштерәләр. Минавтопром квалификация күтәрү институтының Чаллыда ачылган филиалы КамАЗ өчен кадрлар хәзерләүдә зур роль уйнаячак. Шушы елның сентябреннән анда экономик белемнәр һәм хезмәтне оештыру пропагандистларының укулары башланды. Автомобиль комплексында, фәнни-тикшеренү институтларында эшләүче зур белгечләрнең тәҗрибәсен һәм белемен практикада киң куллану, КамАЗның бай техник базасы киләчәктә барлык белгечлекләр буенча җитәкче һәм техник персоналның укуын оештыруга мөмкинлек бирәчәк.

**«Коммунист Татарии», Казан.**

СКБ-3 карамагындагы Минск тәҗрибә заводы коллективы Кама автогигантының пресс-рам заводы өчен стенд төяп җибәрүне тәмамлады. Конвейерның баш өлеше булган җайланма беренче чиратта 75 мең автомобиль рамы җыюга исәпләнгән. Шушы елның сентябрендә пресс-рам заводы төзүчеләре һәм монтажчылары җыю стендын срогыннан элек эшләп бетерү һәм төяп озату турындагы мөрәҗәгать белән чыкканнар иде. Машина төзүчеләр удар төзелеш заказын намус белән үтәделәр.

**ТАСС, Минск.**

Азеево-Ерыклы участогындагы юлның соңгы метрларына асфальт түшәлде. Хәзер дүрт йөз километр озынлыктагы Казан—Чистай—Әлмәт—Бөгелмә—Баулы трассасы тулысынча асфальт-бетоннан тора. Магистраль, Татарстан территориясен төньяк-көнбатыштан көньяк-көнчыгышка кисеп, җиде зур район аша уза. Бу юл төзелгәч, Казан белән Чаллы, Нижнекамск, Оренбург, Уфа һәм башка шәһәрләр арасында элемтә яхшырды.

**«Известия», Мәскәү.**

Моннан нәкъ биш ел элек экскаваторчы Михаил Носков, киләчәктә автомобиль заводлары төзеләчәк мәйданда — Кама ярының җилләр уйнап торган урынында, экскаватор чүмече белән беренче тапкыр балчык чүмереп алды. Дистәләрчә һәм меңләгән төзүчеләрнең, монтажчыларның эзләнүләр һәм табышлар, борчылулар һәм шатлыклар белән тулы авыр хезмәт еллары иде бу.

Хәзер инде нәтиҗәләр күз алдында. Элек буп-буш яткан җирдә зур-зур алты корпус калкып чыкты. Аларда технологик җиһазларны монтажлау, җибәрү-көйләү эшләре бөтен көченә бара. КамАЗ төзүче коллективлар бишьеллык заданиеләрен октябрь аенда ук инде срогыннан элек үтәделәр... Илебезнең бөек төзелешендә — моңарчы күрелмәгән хезмәт күтәренкелеге. КамАЗның көйләү-җибәрү объектлары заказлары төгәл һәм югары сыйфат белән үтәлә.

Заводның Мактау тактасы янәшәсендә үк — производство алдынгылары белән таныштыручы махсус җайланмалар бар. Новаторның фамилиясе кырындагы кнопкага басуга, репродуктордан аның эше турында ике-өч минутлык язма тыңлыйсың. Шундый язмаларның берсе стандарт булмаган җиһазлар цехы слесаре М. Исламгалиев хакында. «Алты көнлек эшне — биш көндә!» дигән чакыру белән заводның барлык эшчеләренә нәкъ менә ул мөрәҗәгать итте. Ярты елдан артык инде ул үзенең вәгъдәсен үтәп килә. Новаторның бу чакыруына кушылучыларны предприятие цехларында йөзәрләп санарга мөмкин.

**«Правда», Мәскәү.**

Кама пароходчылыгы капитаны Евгений Сергеевич Симонов менә өч навигация инде үзенең капитанлык вазифаларына бөтенләй кермәгән бурычны үти. «Мулланур Вахитов» теплоходы чираттагы рейска чыгар алдыннан Евгений Сергеевич Чаллыга, сәяхәтләр һәм экскурсияләр бюросы директорына шалтыратырга һәр вакыт ара таба.

— Кабул итә алырсызмы?

— Әлбәттә!

Теплоходта капитан пассажирларга КамАЗ белән танышып чыгарга мөмкинлек барлыгын хәбәр итә. Бу хәбәрне һәркем зур шатлык белән каршылый. Шәһәргә якынлашуга капитан теплоходны причалга таба бора. Ә анда инде пассажирларны экскурсия өчен билгеләнгән автобуслар көтә.

...Чаллы турында китаплардан күпме генә укыма, анда барган төзелешне экраннардан күпме генә карама, КамАЗны үз күзләрең белән күрү сине барыбер таң калдыра. ГЭС поселогындагы Муса Җәлил проспекты, яңа шәһәр үзе, заводлар комплексы гаҗәеп соклангыч һәм реаль.

**«Советская культура», Мәскәү.**

Яңа урында төзү искиткеч кызыклы. Үзең планлаштырган нәрсәләрнең бүгенгесен һәм киләчәген күз алдына китерергә, экономистларның, социологлар һәм экологларның теләк-омтылышларын барысын уртак бер максатка юнәлтергә, узгандагы ялгышлыкларны исәпкә алырга тулы мөмкинлекләр бар... һәм хәзерге шәһәрләр киң колачлы, якты, уңайлы итеп төзеләләр.

Мисалга Чаллыны гына алып карыйк. Элек беркем дә диярлек белмәгән кечкенә район үзәгеннән ул зур шәһәр булып үсте.

Тугызынчы бишьеллык төзелештә яңа методларга канат бирде. Главмосстрой төзүчеләре Чаллыны нәкъ менә Злобин һәм Орлов методлары белән төзиләр: һәр көн саен йортның бер каты әзер була. Монда төзүчеләрнең хезмәт җитештерүчәнлеге соңгы биш елда 55 процентка үсте.

Илебез шәһәрләренең географиясе киң. Хәзер шәһәрләр зур юллар кисешкән урыннарда, су юллары өстенә, энергетик запаслар мул булган җирләрдә төзеләләр... Яңа Чаллы да юллар кисешкән урында үсеп чыкты.

...Яңа шәһәрләр киңлеккә генә түгел, биеклеккә дә үсәләр. Чаллыда ундүрт катлы «башня»ларны күреп хәзер инде беркем дә гаҗәпләнми. Андый йортлар бүгенге көндә бирелә йөзәрләп санала.

Әйе, Чаллы ул — типик яшь шәһәр.

**«Комсомольская правда», Мәскәү.**

------------

**Рәмзи Максудов**

# ҮЛЕМНЕ ҖИҢГӘН БАТЫР

*«1920 елның 21 сентябрендә акгвардияче офицерлар 202 нче татар укчы полкының өченче батальон командиры иптәш Вәлиәхмәтовны ерткычларча газапладылар һәм 18 кызылармеец белән бергә аттылар. Каһарманнарның гәүдәләрен чокырга ташладылар...»*

*Көньяк тимер юлындагы Синельниково станциясе эшчеләренең Минзәләгә язган хатыннан.*



Шушы хатка юлыккач, тетрәнеп киттем. Кем ул Вәлиәхмәтов? Үзем белгән шундый фамилияле бер ветеранны күз алдыма китердем дә: «Акгвардиячеләр аткан каһарманның туганы түгелме икән ул?» — дип уйлап алдым. Кызыл командирның батырлыгы һәм фаҗигале язмышы турында хәбәр-хатны алып, аның янына ашыктым. Бәхеткә каршы, ул өйдә иде. Газеталар караштырып утырган чагына туры килдем. Җаен-хикмәтен табып дигәндәй, күкрәк кесәмдәге хатны алып өстәлгә куйдым да сак кына сорашырга керештем. Ул мине бер сүздән аңлап алды.

— Әй, үлеп терелгән командир!.. — диде газеталарын бер читкә этәреп. Аннан күзлеген салып сөртте һәм өстәлдә яткан хатны зур кызыксыну белән укырга тотынды.

— Монысын белми идем әле, белми идем... Карасана, тарихи хат икән бит!..

— Ә командир?.. Командир Вәлиәхмәтов сезнең туганыгыз түгелме? — дип, мин аңа текәлдем.

— Туганым түгел, — диде ветеран. Тик шунда ук, мине тынычландырырга теләгәндәй, өстәп тә куйды: — Шулай да ул кеше турында кайбер нәрсәләрне беләм мин...

Мин, аның авызыннан кош тоткандай, тынып калдым. Карт ветеран хикәясе уйларны ерак үткәннәргә алып китте.

## Кая барсаң да бер кояш

Зур пароход, канатлы тәгәрмәчләрен шапылдата-шапылдата, Идел дулкыннарын ярып бара. Аның артында дәрья суы кайный, бөтерелә. Күперенке буразнадай булып кабарган зур дулкыннар өстендә ак күбекләр тирбәлә. Шул күбекләргә канатларын тидерә-тидерә, акчарлаклар оча. Аларның илереп кычкырулары йөрәгеңне парә-парә телеп ала.

Пароходның өске катларында — байлар. Ә түбәндә — жыен ярлыябагай. Шулар арасында, якорь чылбыры бәйләнгән чыгыр янында, бер карт утыра. Аңардан аз гына читтәрәк үсмер егет баскан.

Идел өстендә таң атып килә. Менә алда шәһәр күренде. Ул, гүя төнге караңгылыктан аерылып, таң белән бергә калкып чыкты да яр буенда төрле бизәкләр балкытып тора башлады. Әнә, зур чиркәүнең алтын түбәсе ялтырый. Әнә, йортларның зур-зур тәрәзәләрендә утлар җемелди. Әнә, Кремльнең ак ташпулатлары, биек стеналары таң нурларына чумган.

— Безнең Әчтерхан менә шушы була инде, улым, — диде карт.

Ә үсмер егет шәһәр ягыннан күзен алмады. Мондый яктылык диңгезен, мондый ташпулатларны беренче күрүе бит әле аның. Шуңа күрә күңеле күтәренке, борын салындырырлык түгел, эшләре майлагандай бара. Өйдән чыгып киткәннән бирле төртелеп калганы юк Мөдәрриснең. Хәтта әтисе дә аның сәфәр чыгуына каршы төшмәде.

— Хәерле сәгатьтә булсын, улым! Кая гына барсаң да бер кояш диләр дөньяда, шулай да бәхетеңне эзләп кара. Өйдә ятып май чыкмас, — дип озатып калды.

Пароходка да бик җиңел кереп утырды Мөдәррис.

— Чыксаң чык, керсәң кер! — диде дә бер матрос аны басмадан эчкә этеп тә җибәрде. Казан пристаненда биштәрен чәлдерделәр чәлдерүен, әмма анда кырык ямау белән өч-дүрт кисәк сохаридан башка берни дә юк иде. Шулар өчен гамь кичереп тормас бит инде. Пароходта аны Әстерханга баручы бер бабай үз итте. Икәүләшеп пароход ресторанында савыт-саба юарга ялландылар. Юан гәүдәле пешекче сүзне кыска тотты:

— Тамак ялына булса, юыгыз. Риза булмасагыз, бүтәннәр табылыр...

Карт мөсафир белән яшь юлчы җиң сызганып савыт-саба юдылар. Аннары тагын бабай аны калада эшкә урнаштырырга да вәгъдә итте. Күрәсең, уңарга ошый юлы Мөдәрриснең.

Шул чак аның уйларын тупас тавыш бүлдерде:

— Бәбәкләрең чыкканмы әллә?.. Чыгырны әйләндерергә комачаулыйсың бит, сыпырт тизрәк моннан!..

Җирән чәчле матрос аны этеп җибәрде. Үзе, бар көченә селтәнеп, юан бауны пристаньда торучы икенче матроска томырды. Тегесе бау очын эләктереп алды да тимер казыкка кидереп куйды.

Пароход туктауга, Мөдәррис халык арасына чумды. Бабайны яр өстендә көтеп алды. Башта такталар түшәлгән урыннардан үттеләр. Урамга чыккач та пычрак башланды. Яртылаш җиргә иңгән тәбәнәк йортларга карап: «Безнең Әлкәйдә дә мондый өйләр бар лабаса. Шушы булдымы инде шәһәр?» — дип уйлап алды Мөдәррис. Шул ук мизгелдә аның уенда әтисе әйткән сүзләр яңгырап узгандай булды:

— Кая гына барсаң да бер кояш, диләр дөньяда, шулай да бәхетеңне эзләп кара...

Әзерләп куйганнар ди монда сиңа бәхетне, тот капчыгыңны. Шәһәрендә булса гына инде.

— Бабай, Әстерханга кайчан барып җитәбез соң инде? — дип сораганын сизми дә калды Мөдәррис.

Карт аңа сәерсенебрәк карап куйды:

— Соң... шушы бит инде Әчтерхан.

— Без пароходтан күргән ак матур ташпулатлар кайда соң?

Бабай кулын гына селтәде.

— Ул ак таш кала безнең өчен түгел, балакаем. Безгә, ә-әнә, Татар базары артындагы бистә бар...

Ике-өч көннән карт аны Әстерхан мөселманнары арасында саранлыгы белән дан тоткан Галәветдин хаҗига алып килде. Хаҗи әфәнде үсмер егетне баштанаяк күздән кичерде дә карарын әйтте:

— Калып торсын. Кулыннан эш килерлек булса, карарбыз. Хода язган ризыгы шушында булса, белмәссең...

«Ходай язган» ризык шушында булып чыкты. Сукыр тиенгә эшләргә әзер булган егетне кулдан ычкындырмады хаҗи. Мөдәррис икенче көнне ук «һөнәргә» өйрәнә башлады. Иртән кояш белән тора, төн уртасы җиткәнче кухня белән аш залы арасында чабып йөри. Хаҗиның өендә ничә кеше булса, шуларның һәркайсы Мөдәррискә баш, Мөдәррискә әмер бирә ала:

— Мөдәррис, утын алып кер!..

— Савыт-сабаны юып бир!

— Мөдәррис, самаварларны яңарт!..

— Кунакларның атына солы сал!..

— Мөдәррис!..

Шулай җәй үтеп китте. Көзге суыклар башланды. Ә көне-төне чабып йөргән егетнең өстендә күлмәктән гайре нәрсә юк. Сатып алыр иде — кесәсеннән җилләр исә. Хаҗи абзаң эш хакы түләү турында авыз да ачмый. Ул ачмаса ачмас, Мөдәррис бу хакта үзе башлап сүз катарга булды. Хаҗидан эш хакы сорарга керде.

— Һе... Бишмәт алырга дисеңме?.. Ә эшкә өйрәнүеңне түләүгә санамыйсыңмы? Юктыр! Анысын аңларлык зиһенне бирмәгәндер сиңа ходай тәгалә. Аннары тагын, күпме савыт-саба кырдың син! Бөтенесен исәпли башласаң, үзеңнән тиешледер әле...

Мөдәррис аның симез битенә карап торды. «Алдады бу чалмалы дуңгыз!» дип уйлап куйды ул эченнән. Хаҗи хәтле хаҗины чучкага тиңләү шәригатькә сыеп ук бетми бетүен — монысын бик яхшы аңлый Мөдәррис, әмма ачуын тыеп кала алмады. Хуҗаны үткен күз карашы белән көйдереп алды да чыгарга борылды.

— Тукта... — Хаҗи, чапан кесәсендә озак кына капшанып аңа бер көмеш акча сузды. — Талчуктан бишмәт алып киярсең. Ә аякларыңа... минем иске кәлүшләрне бирерләр.

## Мөгаллим кызы Гайшә

Мөдәррискә бишмәт алып киярга язмаган икән. Хаҗидан илле тиенлек көмеш эләктергән көнне үк, кич белән, күкрәге бик яман кыса, башы авырта башлады. Икенче көнне ул яткан урыныннан да кузгала алмады. Бөтен тәне ут кебек яна, күзен ачарлык та хәле юк иде. Шулай миңгерәүләнгән шикелле ятканда, кемдер аның маңгаена юеш сөлге куйды. Мөдәррис күзләрен ачты. Аның янында яшь кенә бер кыз басып тора иде. Авыруның күзләрен ачып җибәрүе булды — кыз читкә китте. Мөдәрриснең күз алдында аның мөлаем карашы һәм чем-кара озын толымнары гына шәүлә булып калды. Ул янә күзләрен йомды. Үзен каядыр төпсезлеккә очкандай тойды. Туктарга теләсә дә булдыра алмый. Гүяниндидер көч аны һаман аска, караңгы упкынга сөйри. Ул да түгел, әлеге мөлаем кыз аңа ярдәмгә килә, аның кулларыннан тотып ала. Егетнең бушлыкта очуы төш кенә икән. Ә өендә әлеге кыз бар да, аның йомшак куллары бар.

Озак авырып ятты Мөдәррис. Озын толымлы кыз һәр вакыт диярлек аның янында була. Кереп тәрәзә янына утыра да китап укый. Сирәксирәк кенә Мөдәррис ягына күз сала, хәле ничек, янәсе. Ә егетнең кәефе инде яхшырып бара. Ул хәзер авыз ачып, тел тибрәтерлек хәлгә килде. Кызның исемен сорарга да өлгерде. Гайшә атлы икән. Мөдәрриснең яшьтәше булып чыкты үзе. Егет моңа бик тә куанган иде. Шатлыгын трактир хезмәтчеләреннән берсенә әйтми түзә алмады. Тик анысы Мөдәрриснең сөенечен кулагә ташлады.

— Һе, яшьтәш, имеш! — дип үчекләде ул Мөдәррисне. — Мыегына

яшьтин-яшь кәләше булыр синең яшьтәш дигәнен...

Егетнең аркасына бозлы су койдылармыни! Ул хәтта бу чынлык белән килешергә дә теләмәде. Мондый гүзәллекнең хаҗи кулында бер уенчык булуын башына сыйдыра алмады. Бер көнне, хәле шактый әйбәтләнгәч, кыздан әкренләп кенә төпченергә тотынды:

— Бу сүз... дөресме, Гайшә?

Гайшәнең күзләрен яшь томалады.

— Әйе, — дип пышылдады ул, битен китап белән каплап.

Шактый ара сүзсез тордылар. Егет авыр тынлыкка түзмәде:

— Якынрак килегез әле, Гайшә, — диде. — Нигәдер, маңгаем тагын кызыша...

Савыга башлаган егетнең кечкенә генә хәйләсе иде бу. Гайшә, шундук урыныннан торып, аның янына килде һәм нәфис кулын Мөдәррибнең маңгаена куйды. Аннары елмайды да бармак янады:

— Ялганлашып ятсаң, хаҗи абзыеңның каргышы төшәр башыңа, бел аны! — диде.

— Ә син ул каргышны юеш тастымал белән сөртеп алырсыңмы? — дип сорады Мөдәррис. — Әйт, алырсың бит?

Гайшә эндәшмәде. Аның янынарак күчеп утырды. Маңгаена кулын янә куйды. Мөдәррис ул кулның дерелдәвен тойды.

— Тынычлан, Гайшә, зинһар тынычлан...

— Ә мин тынычландым инде, Мөдәррис,— дип җавап бирде Гайшә.— Каһәрләнгән бу язмыштан күз яше белән дә, татлы хыял дәрьясына чумып та котыла алмыйсың. Мин моны бик яхшы аңладым...

Мөдәррискә ул кич буе үзенең шул «каһәрләнгән язмышы» турында сөйләде. Егет җитди карашын Гайшәнең моңлы күзләренә төбәп ятты.

Гайшәнең әтисе укытучы булган. Аларга кешеләр җыела, китап укып, төрлесен сөйләшеп,ниләрдер киңәшеп утыралар икән. Ярлылар, байлар турында да сүз йөрткәннәр. Гайшә аларын бик томанлы гына хәтерли. Ә караңгы төннәрнең берсе аның күңеленә бик тирән сеңеп калган. Алар өенә полиция бәреп керә. Бөтен нәрсәнең астын-өскә китерәләр. Әтисен алып китәләр. Шул китүдән ул әйләнеп кайтмый. Берничә елдан аның каторгада үлүе хакында хәбәр килә. Гайшәнең әнисе, шәһәр үзәгендәге йортны сатып, кечкенә генә квартирага күчеп китә. Хәсрәт диңгезенә, хәерчелек дәрьясына баткан гаиләгә ниндидер карчыклар килеп йөри башлый. Димчеләр икән, Гайшәне кулга төшерергә йөрүләре булган. Шул карчыкларның берсе, кызның әнисен ризалатып, Гайшәне хаҗи йортына китерә.

— Хәзер менә хаҗи оҗмахында яшим, — дип тәгәлләде сүзен яшь хатын. Күзләренә килеп тыгылган яшьләрен тыеп калды да урыныннан торып басты. — Телисеңме, Мөдәррис, мин сине русча укырга-язарга өйрәтәм. Имтихан тапшырып, укытучылар мәктәбенә керерсең. Аннары, минем әтием кебек, мөгаллим булырсың...

Көзге һәм кышкы айларда трактирга кеше аз йөри. Мөдәрриснең буш вакыты җитәрлек булды. Гайшә аңа китаплар китерә торды. Ә егетнең белемгә сусаган күңеле комсызланганнан-комсызлана бара. Шифалы яңгырны озак көтеп алган, кипшенеп беткән җир шикелле иде ул: һәр тамчыны сеңдереп кенә торды. Язга кадәр бик күп китаплар укырга, бик күп нәрсәне белергә өлгерде Мөдәррис.

— Болай булгач, мөгаллимнәр мәктәбенә керә аласың инде, — дип сөендерде аны Гайшә.

«Укыйсы иде дә бит!.. Алырлармы бит әле?.. Кабул итсәләр дә, бу өрәк сыман кыяфәтең белән ничек йөрерсең? Өстеңдә иске бишмәт, аякларыңда хаҗи абзыйның иске каләшләре булсын да — мөгаллимлек турында хыяллан, имеш».

берендә аңа трактирда эшләүче чулак Мөхәммәт дигән кеше ярдәмгә килде. Мәдәрриската үтә дә кирәкле киңәш бирде ул:

— Өркет син хаҗи капкорсакны. Промыселга китәм, диген. Шулай итсәң, хак билгеләр үзеңә. Күрерсең менә. Җәй көне трактирда эшләргә кемне дә таба алмый ул.

Дөрес булып чыкты аның әйткәне. Каш җыерса җыерды Галәветдин хаҗи, әмма Мәдәррискә яз һәм җәй айлары өчен эш хакы түләргә риза булды.

— Ярар, унбиш тәңкә бирермен, — диде ул. — Тик шуны бел: мөселман кардәш булганың өчен генә юмартланам. Югыйсә, эшең ул хаклык тормый.

Торамы, тормыймы — көз җитүгә Мәдәррис, унбиш тәңкәне хаҗидан каерып, өс-башын караштырды. Ялтырап торган итекләр, сукно чалбар һәм әйбәт күлмәк алып киде.

— Ярыйсы гына егет икәнсең үзең, — дип шаяртты аны бергә трактирда эшләгән иптәшләре.— Хаҗи абзыйның борынына чиртмәслек түгел.

Мәдәррис, уку теләге белән янып, Әстерханнан китте. Аны Гайшәнең моңлы карашы озатып калды. «Ичмасам, син бәхетле бул, Мәдәррис!» — дигән кебек иде ул караш...

Мәдәррисне имтиханга бик белеп әзерләгән булып чыкты Гайшә. Мөгаллимнәр мәктәбенә имтиханнарны менә дигән итеп тапшырды аның «шәкерте». Ул гына да түгел, ике еллык укуны бер елда тәмамлап, укытучы таныклыгы алып чыкты. Егетнең түбәсе күккә тиде. Әтисен инде әйтеп тә торасы юк — сөенеченнән зур мәҗлес уздырды. Соңгы сарыклары китсә китте, аның каравы, тантанасы олы булды. Башкача ярамый да иде, Вәлиәхмәтовлар нәселеннән беренче мөгаллим чыкты бит!

Мәдәррискә бирелгән таныклыкны, бер могҗиза күргәндәй, кулдан кулга йөртеп карадылар. Яшь мөгаллимнең әтисе Вәлиәхмәт агай һәркайсын кисәтеп торды:

— Саграк тот, ипләбрәк!.. Таплана-нитә күрмәсен!..

## Әйдә балыкка, мөгаллим!

Мәҗлесләр узды, Мәдәррис өяз шәһәренә барып кайтты, бик күп авылларны йөреп чыкты. Әмма берсендә дә укытучы урыны буш түгел иде. Аның мөгаллимлек таныклыгын ачып караучы да булмады. Егет яңадан Әстерханга юл алды.

Галәветдин хаҗи өендә Гайшә юк иде инде.

— Каядыр китте дә батты, — дип аңлаттылар аңа элеккеге хезмәттәшләре. Сөенеп куйды егет. «Югала торганнардан түгел, берәр җаен табар», — дигән уй белән үз-үзен юатты. Ләкин күңеле аны бик тә, бик тә юксына иде.

Галәветдин хаҗига кабат эшкә ялланып торырга туры килмәде аңа. Трактирда иске танышын — якындагы авылларның берсендә яшәүче матрос Василий Тереховны очратты. Кайчандыр гвардия крейсерында хезмәт иткән диңгезче хәзер балык тотып көн итә, ә Мәдәррис аңардан балык сатып ала торган иде.

Василий аны шундук таныды.

— Ну, браток, тазаргансың син! — дип, аның кулларын кысты. — Килешкән, килешкән үзеңә атаң икмәге...

Матрос аны үз янына утыртты да төпченергә тотынды.

— Хәзер ничек соң, браток, исәпләрең? Якорьны кайдарак ташларга ният? Монда түгелдер бит? — Василий трактир кухнясы ягына ымлады.

нам. — Һәм ул, куен кесәсеннән алып, мөгаллим таныклыгын Василийга сузды. — Менә, мәктәп тәмамладым...

Күпне күргән матрос әлеге мөһерле кәгазьне кулында бераз әйләндерде-боргалады да Мөдәррискә кире сузды:

— Котларга да була икән, алайса, үзеңне. Мөгаллимлек эшендә уңышлар теләргә дә ярый икән. Әгәр бу кәгазең ярдәм итмәсә, туп-туры үземә кил, браток. Адресымны беләсең. Җәтмәм шәп — балык тотарбыз, мөгаллим!

Василийның тәкъдиме бик ярап куйды. Бөтен каланы урап чыкса да, укытучы эшенә урнаша алмады Мөдәррис. Озак уйлап торасы юк иде — Терехов яшәгән авылга юл тотты.

Аның килүенә Василий бер дә гаҗәпләнмәде.

— Көттем мин сине, — дип каршылады ул аны. — Мөгаллимлек эшенә үтү өчен синдәге ул кәгазь генә җитми торгандыр дип уйладым никтер.

— Ялгышмагансыз. Тормышта юл яру өчен бүтән нәрсәләр дә кирәк икән шул. Мин дә аңлый башладым хәзер.

Василий тәмәке кабызды.

— Эш турында килешик башта, браток. Мин теге трактир хуҗасы түгел, үзең беләсең. Балаларым да бар. Аларны үстерергә кирәк. Син башлы егет, үзең дә уйла: көймә белән җәтмә — минеке, эшебез — икебезнеке. Озын сүзнең кыскасы шул: диңгездән эләктергән байлыкны дүрткә бүләбез. Өч өлеше — безнең гаиләгә, берсе — сиңа. Риза булсаң — кул сугыштан.

Һәм шулай килештеләр дә. Таңнарны алар диңгез өстендә каршылый иде. Мөдәррис тырышып ишкәк ишә, Василий җәтмәләрне суга ташлый. Диңгездә Вася дәдәй үзе генә белгән балыклы урыннар бар икән. Кайчан чыксалар да табышсыз кайтмадылар. Берничә атнадан Василий аңа балык сатудан кергән өлешен бирде. Җитмеш биш тәңкә!

Мөдәррис өчен бу зур акча иде. Әстерханга кайту белән шуның илле сумын авылга җибәрде. Шул инде — ат алырга җыенган көннәре бит.

Үзе шәһәрдә фатирга урнашты да янә эш эзләргә керешге. Мөгаллим таныклыгын инде ул бөтенләй диярлек онытты. Теләсә нинди хезмәткә риза булырга әзер иде Мөдәррис. Ләкин кая гына барса да — бер җавап: хәзергә эш юк. Көтегез, түзегез, бәлки берәр җае чыгар...

Ә җае күренмәде. Атналар, айлар эшсез үтте. Кесәдә дә бакыр тиеннәр генә шалтырап калды. Инде нишләргә, кая сугылырга? Урамда очраткан таныш балыкчыга хәлен сөйләп биргән иде — тегесе киңәш итте:

— Син, малай, казакъларга яллану ягын кара. Кыш көне Әстерханда эш табуы — ай-һай! Безнең кебекләр меңләгән бит монда.

## Камыш ура беләсеңме?

Иртәгесен, таң беленер-беленмәс, Мөдәррис базарга чыкты. Гадәттә, казакъ авылларыннан килүчеләр монда бик күп була. Белмәссең, арада хәллерәге табылып, берәрсе эшкә дә яллап куяр. Егет шундый өмет белән базар буйлап ничә кат үткәндер — эзләгәнен тиз генә таба алмады, «Монда да булмады, ахрысы!» — дип, борын салындырып, базардан чыгып китәргә җыенганда гына бер казакъ агайның кычкырып торганын ишетеп алды. Шул аваз килгән якка ашыкты.

— Күшче кирәк!.. Күшче кирәк!..

Казакъ агай арбага менеп баскан да, шул сүзләрне кабатлый-кабатлый, әле уңга, әле сулга борылып кычкыра. Мөдәррис аның янына килде дә:

арбадан сикереп төште, егетне баштанаяк карый башлады. Мөдәррис-нең кыяфәте, көч-куәте аны канәгатьләндерерлек иде булса кирәк — агай туп-туры ярып салды:

— Миңа булышчы кирәк... Камыш ура беләсеңме? — дип сорады.

— Беләм!

— Яшьрәк түгелме икән син? — дип, казакъ агай шикләнүен дә белдереп куйды. — Бик авыр эш бит ул камыш уру.

Мөдәррис аның тел төбен шундук аңлап алды.

— Диңгездә балык тоткан бу куллар камыш урырга гына ярардыр, абзый.— Һәм ул сөяլләнеп беткән учларын ачып күрсәтте.

— Хакың күпме? — диде казакъ агай, аңа кулын сузып.

Мөдәрриснең бу сорауга җавабы әзер иде.

— Айга ун тәңкә көмеш,— диде ул.— Ашау байдан, эшләү миннән.

— Нинди бай булыйм ди мин!.. Айга ун тәңкәне үзем дә төшерә алмыйм, туганкай.

Сатулаша торгач, казакъ агай айлыкны алты тәңкә түләргә риза булды. Камыш урган чакта кияргә киемне дә бирәчәк.

Мөдәрриснең бар әйбере — бер төенчек — үзе белән иде. Казакъ агайның арбасына утырды да китте. Хуҗа аңа ниләр эшләргә тиеш булачагын аңлатып барды. Кышын казакъ даласында әллә ни майтарырлык эш булмый. Камыш урырга гына мөмкин. Аны кирпеч заводы сатып ала. Шуны ягып эшли икән ул. Шул камышка тотынсаң, аз-маз акча төшереп була. Иделбайның аты бар, арбасы бар — кирпеч заводына камышны ташы да ташы. Тик берүзенә авырга килә икән. Булышыр кешесе юк, балалары кечкенәләр. Менә хәзер алар икәүләшеп камыш әзерләрләр, аны заводка ташырлар. Ни әйтсәң дә тик яткан ише булмас.

Казакъ агай үз тормышы турында шулай гади һәм эчкерсез итеп сөйләде. Мөдәррис аны балыкчы Василий Тереховка да охшатып куйды. Ул да шундый гади һәм турыдан бәреп әйтә иде бит.

Шәһәрдән чыгып җитүгә, казакъ җыр сузып җибәрде. Аның көе дә барасы юллары кебек үк озын, казакъ даласыдай иркен иде. Мөдәррис аны онытылып тыңлады. Күз алдына үзенең туган якларын китерде. Ихтыярсыздан, ул якларны казакъ далалары белән чагыштырып карады. Бер-береннән ничәмә-ничә мең чакрымда булсалар да, бу җирләр өчен ниндидер уртаклык бар иде шикелле. Дала киңлекләреме бу, әллә буш булып күренгән шул киңлекләргә хас горур моңсулыкмы — нәрсәдер Мөдәрриснең күңелен йомшартып, уйларын еракларга алып китте...

— Килеп җиттек, егет, — диде хуҗа.

— Ә авыл?.. Авыл кайда соң? — дип сорады Мөдәррис. Бу мәлдә ул үзен беренче тапкыр Әстерханга килгән малай сыман тойды.

Казакъ агай кулындагы чыбыркы сабы белән дала киңлегендә аз гына калкыбрак торган урыннарга төртеп күрсәтте:

— Әнә безнең землянкалар...

Хуҗа күрсәткән яктагы землянкаларның берсеннән бер төркем балачага йөгереп чыкты.

— Минекеләр! — диде казакъ агай.

— Камыш ташырлык түгел икән шул, — димәкче иде дә Мөдәррис, хуҗаны үпкәләтүдән шикләнеп, тыелып калды.

Икенче көнне, дала киңлекләренә кояш нурлары төшә башлаганда, алар инде эшкә чыкканнар иде. Хуҗа атын тугарып утлауга куйды да Мөдәррискә урак сыман кәкре пычак тоттырды. Үзе дә шундый ук пычак алып камыш арасында селтәнә башлады. Бер уч камышны эләктереп ала да пычагы белән селтәп җибәрә — камыш учмасы аның кулында кала. Берничә тапкыр шулай селтәнгәч, көлтә итеп бәйли һәм арба янынарак илтеп ташлый.

Мөдәррис казакъ агайның эшенә сокланып карап торды. Аның кул-

лары камыш учмаларын очыртып кына тора шикелле тоелды. Аларны көлтәгә дә уйнап кына бәйли казакъ. Ә Мөдәрриснең эше алай җиңел бармый. Пычак белән сугып карый егет — камыш киселеп бетми. Мөдәррис аны сындырып алырга мәҗбүр була. Көлтә итеп бәйләгән чакта исә, киресенчә, камышлар үзеннән-үзе сынып бетә.

Иделбай беравык карап торды да Мөдәррис янына килде.

— Уракны тарткандай итмә син, егет. Сугып кисәргә кирәк камышны,— диде ул һәм берничә учма кисеп тә күрсәтте.— Менә шулай...

Төш җитеп килгәндә, Мөдәррис инде камыш кисү һөнәрен ярыйсы ук үзләштереп өлгергән иде. Ләкин кичкә хәтле эшләгәч куллары ут кебек яна башлады. Ул аларны көч-хәл белән генә күтәрә иде.

— Күнекмәгән эш авыр була, — диде казакъ, аның хәленә кереп. — Бүгенгә җитеп торыр, алайса.

Хуҗа икенче көнне дә шәфкать күрсәтте. Мөдәрриснең кыяфәтенә карады да:

— Камыш кисәр хәлдә түгелсең, егет, — диде. — Бүген өй катында гына эшләштер...

Мөдәррис аның бу игелеген дә Василий күрсәткән яхшылыклар белән чагыштырды. Ул да шундый бит: арыганыңны күрсә — ял итәргә кушар, борының салынса — күңелеңне күтәрер сүз табар иде. Үз көче белән дөнья көтүче кешеләр башкаларның да хәлен белә торганнардыр, күрәсең. Моны аңлау Мөдәрриснең көчен арттырып җибәргәндәй булды. Бу минутларда ул үзен озын юл үтеп сусаган һәм чишмәгә тап булып сусынын басу бәхетенә ирешкән кеше итеп хис кыла иде.

Янә камыш кисәргә чыккач ул инде, үзе өчен тырышудан бигрәк, Иделбайга булышырга теләп, бөтен көчен биреп эшләде. Аена алты сумга ялланып килүен дә онытты. Ике-өч көн дигәндә, камыш әзерләү эшендә ул Иделбайның үзен дә узып китте.

— Ай-вай, егет, болай булса кирпеч заводына ташып та өлгерә алмыйбыз камышны, — дип, шелтә белдергән булып кыланды хуҗа. Ә үзе бик тә канәгать иде.

## «Безгә мөгаллим кирәк...»

Иделбай белән Мөдәррис камыш кисеп мәш килгән көннәрнең берсендә, дала юлында ниндидер җайдак күренде. Ул юыртып килде-килде дә болар ягына борылды. Шактый өлкән яшьтә булуына карамастан, ат өстеннән җиңел генә сикереп төште һәм камыш кисүчеләргә сәлам бирде:

— Ходай куәт бирсен үзегезгә!

— Рәхмәт! — диде Иделбай. Алар сүзгә керешеп киттеләр. Дала киңлегендә очрашкан ике казакъның сүзе бетәме соң? Һава хәлләрен сораштылар, мал-туар хакында гәпләштеләр, бала-чагаларының исәнлеген белештеләр. Шактый озак сөйләшкәч кенә, кунак агай Мөдәррискә эндәште:

— Мин сиңа якташыңнан сәлам алып килдем, егет.

— Сәлам китергән кешенең гомере озын булсын! — дип җавап бирде аңа Мөдәррис.— Тик мине исендә тоткан ул адәм кем булыр икән?

— Заһидулла дигән адәмне беләсең булыр, — диде казакъ. — Ул юллады мине бу якларга.

Күрше авыл малае Заһидулланы ничек белмәсен ди Мөдәррис! Ике еллык мәктәптә бергә укыдылар. Дөресрәге, Заһидулла ике, ә Мөдәррис бер ел укыды. Шуннан юллары аерылды.

— Шул Заһидулла мөгаллим синең монда эшләвеңне белеп алган, — дип, янә үз сүзен ялгап китте казакъ. — Бик әйбәт мөгаллим

ул, — диде. — Ә безнең авылда балалар укытырга кеше кирәк. Барасыңмы, мөгаллим Мөдәррис?

Мөгаллим Мөдәррис! Бу сүзләрне ул беренче тапкыр ишетә һәм алар шактый сәер булып яңгырый иде. Камыш кисә торган пычагын кулында тоткан килеш, ул башта аптырабрак торды. Мондый тәкъдимне һич тә көтмәгән иде ләбаса.

— Ялланган кеше бит әле мин, — дигән булды аннары. — Хуҗам Иделбай ни әйтер тагын?

Үзен шулай олылап әйтелгән сүзләр Иделбайның күңеленә хуш килде, ахрысы, ул шундук риза булды.

— Мөгаллим башың белән камыш җыеп йөрмәссең бит инде. Бар, улым, бар! Укыт балаларны...

Иделбай аны күрше авылга озатып та куйды.

— Андый-мондый кыенлык булса, үземә кайт, улым, — диде ул саубуллашканда. — Бары бергә, югы уртак булыр.

— Рәхмәт, рәхмәт! — диде аңа Мөдәррис. Мондый игелекле кеше белән аерылышу аның күңелен йомшартып ук җибәрде.

Мөдәррис килгән авылда зур гына тирмәдә мәктәп ачып җибәрделәр. Егермеләп малай укырга килде. Елтыр күзле, бөркет карашлы казакъ балалары. Мавыгып, яратып дәрес бирде аларга яшь мөгаллим. Шәкертләренең хәлфәне яратулары, авыл халкының хөрмәт итүе — барысы да аның күңелен күтәрә, үзен эшкә дәртләндерә иде. Ләкин Мөдәрриснең күптәнге хыялы бар. Дөрес, ул әллә ни зурдан түгел: ат алырлык акча юнәтеп, туган якларга кайту... Бары шул гына. Бирелә моңа ирешә алмаслыгын аңлагач, Мөдәррис Донбасска китеп барды. Шахтага төште, забойда эшләде. Ат алырлык акча эшләү уе тиз генә чыкмады башыннан. Татар шахтерларының берсенә шул хакта тел ачкан иде, тегесе рәхәтләнеп көлде. Аннары Мөдәрриснең иңенә күмер тузаныннан каралып беткән кулын салды да болай диде:

— Турысын әйткәнгә үпкәләмә, якташ: монда ат сатып алырлык акча тоттырмаслар сиңа. Мин дә заманында шундый ук ният белән килгән идем. Атлык акча эшли алмадым, үзем шахта алашасына әйләндем. Монда бүтән юл күренми, земляк!..

Дөресен әйткән дә биргән карт шахтер. Берничә ел рәттән тирләппешеп күмер чапса да, атлык акча кермәде кесәсенә. Үзенә унтугыз яшь тулган көнне дә забойда каршылады Мөдәррис. Ә тагын берничә атнадан аны солдатка алдылар. Мең тугыз йөз унбишенче ел бара иде.

## Бетәрме бу зилзилә?

Кайдадыр окопларда солдатлар кан түгә...

Ә монда — казармаларда һәм плацларда — сугышка яңадан-яңа отрядлар, батальоннар әзерлиләр. Көннән-көн буе «айт-два» атлатып, солдатның җан тирләрен чыгаралар. Унтерлары белән офицерлары — бәйдән ычкындырылганнардан бер дә ким түгел. Адымыңны ялгышрак атладыңмы — шалт берне ипи шүрлегеңә! «Патша хәзрәтләре»нең нәсел-нәсәбеннән берәрсенең исемен оныттыңмы — тагын шалт! Ничә тешеңне җимерәләр — анысын сорап торучы юк.

Мөдәррискә дә унтер йодрыгын татырга туры килгәли. «Айт-два»ны да дөрес атлый Вәлиәхмәтов, патша нәселенең җиденче бабасына чаклы да белә — шулай да бәргәләп ала аңа взвод командиры. Үч саклый кабахәт. Бер тикшерү вакытында Мөдәррис аны авыр хәлдән чыгарган иде. Салган баштанмы, фуражка асты такырлыктанмы — унтер иң кирәкле чакта уставның бер җөмләсен онытты. Кызарынды, бүртенде, ә исенә төшерә алмый. Мөдәррис аңа шуны әйтеп җибәрмәсенме!.. Унтер,

ул әйткәнне кабатлап, авыр хәлдән котылды, әмма Вәлиәхмәтовка бүре күзләре белән карый башлады. Ләкин Мөдәррис тә алай тиз генә бирешә торганнардан түгел иде. Ул Иван Жернов дигән солдат белән дуслашып китте. Ә Жерновка унтер-мунтерларның теше үтми. Путилов заводында эшләгән егет. Аның күз карашы ук унтерны калтырата иде.

Кичләрен, офицерлар казармалардан китеп беткәч, солдатлар гәп куертып җибәрә. Махра кабызалар да уфтана-көрсенә башлыйлар. Берсе туган якларын исенә төшерә, икенчесе балаларын сагына...

Күбесе Жернов тирәсенә җыйнала. Карсак кына буйлы, корычтай нык беләкле, керсез күңелле һәм җор телле бу солдатны бөтен взвод үз күрә, якын итә. Ул бер вакытта да зарлануны белмәс. Бушрак сәгатьләрдә мәзәк сөйләп көлдерер. Аннары үзенең заводы турында сөйләп китәр.

— Бердәмлектә ул гади кешеләрнең көче, егетләр, — дип башлый ул сүзен. — Менә мисалга путиловчыларны алыйк. Бервакыт безне завод хуҗалары кыса башлады. Штраф белән интектерәләр. Бөтен кеше өчен тырышып йөргән эшчеләрне эштән чыгаралар. Бервакыт шулай забастовка ясадык: эштән куылган кешеләрне кайтаруны, штрафларны бетерүне таләп итәбез. Барыбыз да завод йортына җыелдык. Я хода! Нихәтле халык!.. Зур дингезмени!.. Бөтенебез дәррәү купкач, хуҗалар биреште. Бердәмлеккә каршы торыр көч юк бу дөньяда! Шуны мыекларга урап куярга кирәкмиме икән, дим...

Мөдәррис аны тыңлап утыра, ә күз алдыннан туган авылы, Әстерхан балыкчылары уза. Василий ерактан елмаеп карый шикелле. «Гади кешегә кая да бер ул, брат!» — ди ул. Тавышы колакта яңгырагандай була. Дөресрәге, ул булып Жернов сөйли кебек.

Мөдәррис тагын уйлана. Каршысына, корсагын киереп, Галәветдин хаҗи килеп баскандай тоела. Шул комсызга һәм кансызга кол ителгән Гайшә... Ягымлы, акыллы, укымышлы Гайшә... Ачы язмышыннан качып котылдымы икән ул? Әллә шул караңгылыктан чыгу юлын таба алмадымы һаман?..

Гайшә сурәте ераклаша, томанга урала. Аның урынына каяндыр Иделбай калка. Һаман камыш урып көн итә торгандыр, мескен. Тирмәсендә берсеннән-берсе бәләкәйрәк балалар. Тормышын әйтәсе дә юк — газаплы, авыр... Ә Донбасс шахтерлары соң?.. Бер якташы Мөдәррискә ничек дигән иде әле: «Атлык акча эшли алмадым, малай, үзем шахта алашасына әйләндем. Монда бүтән юл күренми, земляк!..»

«Нигә болай соң бу дөнья? — дип уйлый солдат Мөдәррис.— Чынлап та бит, әй, бик сәер, гайре табигый хәл: берәүләр эшнең ни икәнен белми, типтереп яши, икенчеләре көне-төне тир түгеп тә игелек күрми. Әстерханда Галәветдин хаҗи йомышчы малайны эт итеп кыйный, монда унтерлар солдатның тешен сындыра. Кая гына барсаң да бер кояш дигәне шулмы икән әллә?..»

Уйларның очы-чиге юк...

Сугыш зилзиләсенең дә азагы күренми.

1915 нче елның июль аенда аларны, бер батальонга әвәләп, фронтка — ут эченә ыргыттылар. Яу кырында кан түгә-түгә, армия чигенде. Аннары һөҗүмгә күчте. Стахот дигән елга буенда авыр сугышлар барды. Батальоннары елганы кичкән чакта, Вәлиәхмәтов яраланды. Тылга озатырга җыенганнар иде — үҗәтләнде. «Батыр ярасыз булмас», дигәннәр безнең бабайлар, шуны гына раслый минем бу җәрәхәтем», — дип, полк лазаретында гына дәваланып йөрде. Ярасы төзәлер-төзәлмәс яңадан взводына кайтты. Ни өчен, нәрсә хакына сугышуын аңламаса да, үлемнән курыкмады. Дошманга каршы һөҗүмнәрдә күрсәткән батырлыгы өчен күкрәгенә көмеш Георгий медале тактылар. Ә Мөдәррис-нең йөрәге әрни иде. Күпме иптәшләре чигенү юлларындагы сазлыкларда, канлы окопларда мәңгегә ятып калды. Аларны югалту хәсрәтен

бернинди медаль дә, бернинди юату сүзе дә баса алмас иде. Хәер, андый сүзне аларга әйтүче дә, әйтергә атлыгып торучылар да күренми кебек.

Юеш, салкын, карлы окопларда йөри-йөри, Мөдәррис солдат тормышының бөтен авырлыкларын сыкранмый күтәрергә өйрәнде. Дошман ядрәләре астында үткән көннәр һәм төннәрнең чуты җуелды. Мөдәрриская бөтен дөнья шулай ут эчендә калган сыман, барлык кешеләр дә газап кичереп көн итәләр шикелле тоела иде. «Кайчан бетәр бу зилзилә?.. Кайчан бетәр?» дип тынгысызланган акылга җавап бирүче табылмады.

1917 елның феврале җитте.

Солдатлар бөтенесен каһәрли: үзләрен дә, язмышларын да, командирларын да. Җае чыккан чакларда мылтыкны җилкәгә алып фронттан тыйтаклаучылар да ишәя башлады. Өйрәнүләрдә йодрык уйнатырга яраткан унтерлар йомшарды — солдатка кул күтәрү түгел, сүзне дә уйлап кына әйтәләр. Офицерлар окоплар тирәсендә бөтенләй диярлек күренми. Солдатлар арасында «патша хәзрәтләре» турында анекдотлар китте, төрле хәбәрләр йөрде. Фәлән заводта эшчеләр баш күтәргән, полиция белән бәрелешләр булган... Фәлән губернада крестьяннар алпавыт утарына кызыл әтәч җибәргәннәр... Капйотның ил талап җыйган маллары җилгә очкан ди!.. Шул кирәк үзенә!..

Ә бер көнне окоплар буйлап полк командирының вестовое узды. Аның сүзләрен күбесе аңлап та җитмәде.

— Урман аланлыгына җыелырга! — дип кычкыра-кычкыра узды ул.— Коралларны алмыйча барыгыз. Революция турында сүз булачак...

Кем сөйләр, ни әйтер — белгән кеше юк. Ләкин барысы да әйтелгән урынга төркем-төркем булып килде. Коралны берсе дә калдырмаган. Тычкан таяктан йөргән мондый чакта солдат мылтыксыз кала димени? Штыклары ялтырап торган винтовкаларын алларына куеп, тезләре арасына кыстырып утырыштылар. Полк командиры килеп чыккач та аягүрә торып басучы булмады. Тик берничә офицер гына аңа честь бирде. Полковник, аларга игътибар да итмәгәндәй, солдатларга мөрәҗәгать итте:

— Россия бөек вакыйгалар кичерә. Шулар хакында сөйләр өчен безгә Вакытлы хөкүмәт вәкиле килгән... Шушындый тарихи көннәрдә хөкүмәт вәкиленә сүз бирүне үземә зур бәхет дип саныйм. Сезгә дә аны тыңлау... ни... бәхет булачак.

Вакытлы хөкүмәт вәкиле дигәне бүкән кебек юан гәүдәле иде. Мөдәррис аны Галәветдин хаҗига да охшатып куйды. Аш мәҗлесләренә барганда, ул да шундый ук кыйммәтле мех якалы пальто кия торган иде. Аяклары да кыска...

— Туганнар! Солдатлар! — дип сүзгә кереште вәкил. Аннары кисәк кенә кычкырып җибәрде: — Гражданнар! Хода ярдәме белән изге ватаныбыз Россиядә чын демократия урнашты. Патша хәзрәтләре тәхеттән ваз кичте. Бөтен власть хәзер халык кулында. Сез барыгыз да ирекле гражданнар хәзер, туганнар. Вакытлы хөкүмәт — сезнең үз хөкүмәтегез. Ул сезнең мәнфәгатьләрегезне яклаячак...

— Сайрый бу! — дип, Мөдәрриснең кабыргасына төртеп куйды аның янында утырган Жернов.

— Көендә яңалык юк,— диде аңа Вәлиәхмәтов. Жернов елмайды:

— Бу кәрләдән ни көтәсең тагын. Кичә монархияне яклап төкерек чәчкәндер, бүген Вакытлы хөкүмәткә табына.

Жернов икенче ягында утырган солдатларга ниндидер ым какты. Тегеләр аны шундук аңлап алдылар. Арадан берсе утырган урыныннан сикереп торды да вәкилгә сорау бирде. Аның калын тавышы бөтен аланны тутыргандай булды:

— Вәкил әфәнде, сезнең ул хөкүмәтегез сугышны кайчан бетерә? Шуны гына көткәннәр диярсең — төрле яктан сораулар ява башлады:

— Крәстияннәргә җир бирәләрме?..
— Безне кайчан өйгә кайтаралар?..
Вакытлы хөкүмәт «сандугачы» әллә ни аптырап калмады. Күрәсең, мондый сорауларның буласын алдан ук чамалагандыр. Аларны читләп кенә узарга тырышты.
— Әфәнделәр!.. Гражданнар!.. Солдат туганнар!.. Болар барысы да булыр. Министрлар эшкә кереште инде. Һәркайда комитетлар төзелә. Сез куйган бу сорауларны алар тиз көндә карарга тиеш...
— Безгә министрлар түгел, солых кирәк!..
— Комитетларда үзегез җенләнеп ятыгыз, ә безгә җир бирелсен!
Тыңлаучы калмагач, Вакытлы хөкүмәт вәкиле, калкулыктан төшеп, офицерлар арасына чумды. Шуннан чыгуга, полковник тарантасына утырып китеп тә барды. Офицерлар да төрлесе төрле якка таралыштылар. Солдатлар исә, шау-гөр килеп, полк комитеты сайларга керештеләр.
— Рәисе Жернов булсын! — дип тәкъдим итте солдатларның берсе.— Ул махы бирмәс...
— Комитетка Вәлиәхмәтов та кертелсен. Башлы егет...
— Барыбыз да риза!..— дигән авазлар аланлыкны яңгыратты.
Солдатлар ихтыяры Жерновны полк комитетының рәисе, ә Вәлиәхмәтовны аның ярдәмчесе итеп куйды. Аларга ныклы наказ бирделәр: офицерлар чанасына утырмаска, Вакытлы хөкүмәт «сандугачлар»ын тыңламаска, югарыдан килгән һәр приказны уртага салып тикшерергә! диделәр. Комитет председателе Жернов бу наказларны кабул итүен белдерде һәм үз теләген дә әйтте:
— Иң мөһиме шул: безнең көч — бердәмлек һәм революцион тәртип булыр, иптәшләр, — диде ул. — Вакытлы хөкүмәткә без ышанмыйбыз, сезгә дә сак булырга киңәш итәбез. Тагын бер таләп: полк комитетының рөхсәтеннән башка генерал әмере дә үтәлмәсен. Бердәм булсак кына эшебез уңачак безнең...

## Петроградтан килгән кунак

Шул көннән башлап полкта бөтен эшләрне комитет хәл итә башлады. Беренче араларда полковник моңа каршы төшеп тә караган иде — аның сүзләрен дә, приказларын да колакка элмәделәр. Офицерлар полк комитеты белән исәпләшергә мәҗбүр булды. Солдатлар исә аның һәр кушканын үтәделәр. Тик аларның үз таләпләре дә бар иде. Сугыштан барысы да гарык — аны тизрәк бетерергә кирәк, диделәр. Шинель кияргә мәҗбүр булган игенчеләр җир даулый. Ә бу эшләр полк комитеты гына хәл итәрлек түгел иде. Ләкин солдатларга моны аңлатуы кыен. Алар полк комитетына гаҗәеп зур ышаныч һәм өмет белән карыйлар. Жерновка һәм Вәлиәхмәтовка эшне шул мәсьәләләрдән — солых, җир турында аңлатулардан башларга туры килде.
Июль ахырлары иде. Иван Жернов полк комитеты членнарын үз землянкасына җыеп алды. Анда озын буйлы ят кеше дә бар иде. Аның өстендә китель. Озын соры шинелен иңнәренә салган. Комитет членнарының барысы белән дә кул биреп күреште.
— Иптәш Шокин безгә Петроград эшчеләреннән вәкил булып килгән,— дип таныштырды аны Жернов.— Петроград Советының большевиклар фракциясеннән...
Шокин, металл карасы сеңгән зур кулларын өстәлгә куйган килеш, фронт хәлләре турында сорашып утырды. Солдатларның большевикларга карашы ничегрәк? Аларга таянырга мөмкин булачакмы?..
— Боларның барысы да җир һәм солых мәсьәләсенә бәйле, минемчә,— диде аңа Вәлиәхмәтов.— Әгәр мин дөрес аңласам...

— Бик дөрес куела мәсьәлә,— дип күтәреп алды аны Шокин.— Вакытлы хөкүмәт шуны хәл итә алмады. Дөресе, хәл итәргә теләмәде дә. Чөнки контрреволюцион хөкүмәт ул. Без, большевиклар, аңа каршы. Җир һәм солых мәсьәләсендә безнең платформа мондый...

Шул мәлдә землянкага бер төркем унтерлар белән полк командирының адъютанты килеп керде.

— Гражданнар!.. Комитет членнары!.. Сезнең полкта большевиклар тарафыннан җибәрелгән коткычы йөри. Безгә аны кулга алырга боерык бирелде. Менә ул боерык,— дип, адъютант полк комитеты рәисенә пакет сузды. Жернов аны ашыкмыйча гына алды, землянкада утырган комитет членнарына күз йөртеп чыкты. Азрак шул алар. Нишләргә? Петроградтан килгән большевикны ничек коткарып калырга? Хәзер үк чарасын тапмасаң, аны алып чыгып атачаклар.

Мөдәрриснең башында да шундый ук уйлар кайный иде. Жерновның аңа күз сирпеп алуы булды — ул шундук аның ни әйтергә теләгәнен аңлап алды һәм унтерлар абайлап өлгергәнче землянкадан чыгып китте.

— Туктагыз!..

Унтерларның берсе аның артыннан чыгарга теләгән иде, тышкы яктан часовойның кискен тавышы аны кире кертте.

— Утырыгыз, адъютант әфәнде,— диде Жернов.— Безгә полк командирының приказын кычкырып укырга кирәк,— дип уйлыйм. Аннары карар чыгарырбыз...

Бу вакытта Мөдәррис, уктай атылып, үз взводының солдатлары урнашкан окопларга килеп төште.

— Алыгыз мылтыкларыгызны, егетләр, әйдә, киттек!..

— Кая?

— Тизрәк!.. Соңга калуыбыз бар.— Мөдәррис ике-өч сүз белән хәлне аңлатып бирде.

Солдатлар вакытында килеп өлгерде. Вәлиәхмәтов землянка бусагасында адъютант белән йөзгә-йөз очрашты.

— Юл бир!— дип акырды адъютант, револьверын сузып.

Вәлиәхмәтов кулындагы мылтык түтәсе белән аның алтатарын читкә тибәрде дә үзе кире землянкага этеп кертте. Шул ук мизгелдә ишектән биш-алты штык эчкә таба сузылды. Мөдәррис, адъютантның револьвер тоткан кулына җиңелчә генә кагылып, шул штыкларга ымлады.

— Башта әнә солдатлардан рөхсәт сорарга кирәк, адъютант әфәнде.

— Гражданнар, солдат туганнар!.. Мин таләп итәм... Революцион дисциплина таләп итәм!— дип кычкырына башлады адъютант.

Ишек төбендә киң җилкәле, көрәктәй сакаллы баһадир солдат пәйда булды.

— Заманалар үзгәрә, ваше благородие,— диде ул.— Хәзер сез түгел, без таләп итәбез. Рәхим итеп, землянкадан сыпыртыгыз. Югыйсә, солдатларның бик кырыс чагы.

Икенче бер солдат, землянкага кереп, Жерновка винтовка сузды.

— Ниткән хәл бу, председатель? Сугышта мылтыксыз йөриләр димени? Бүтән чакта калдырып йөрмәгез!— диде ул, унтерларга карый-карый.— Күрәсез, әфәнделәр барысы да кораллы...

— Хак сүзгә җавап юк,— дип елмайды Жернов, винтовканы кулына ала-ала. Адъютант револьверын кобурасына тыгып куйды.

— Без китәбез, ләкин килми калмабыз!

— Менә, ниһаять, аңлаштык та,— дип көлемсерәде Жернов.— Килегез, адъютант әфәнде, теләсә кай вакытта килегез...

Мөдәррис землянка ишегеннән эчкә таба тырпаеп торган штыклар арасыннан тышка атлады. Ул да чыкты — штыклар да артка чигенде. Адъютант белән унтерлар тизрәк ычкыну ягын карадылар.

Ә Питер эшчесен — большевик Шокинны тыңларга бөтен полкны

жыйдылар. Революция, жир, солых турында сөйләде ул. Ярты сәгать чамасы уздымы икән, кунакны тыңлап утырган солдатлар янына атын җан-фәрман куып килгән җайдак туктады.

— Комитет председателе бармы биредә?

Иван Жернов сикереп торды.

— Бар андый кеше.

— Преображенский полкыннан мин... Комитет члены,— диде җайдак.— Безнең полкта тревога уйный калдылар. Ишетүемчә, сезне коралсызландырмакчы булалар. Дивизия командиры шундый приказ биргән...

Ике уйлап торырлык вакыт юк иде. Полк комитеты председателенең башында минуты белән кирәкле карар җитлекте.

— Син биредә каласың, Вәлиәхмәтов,— диде ул.— Кара аны, күзең дүрт булсын. Бүтән полкларны да безгә каршы куюлары мөмкин. Мин Преображенский полкын каршыларга киттем.

Мөдәррис комитет членнарын роталарга җибәрде. Питер эшчесен озатып куйдылар.

Жернов хаклы булып чыкты. Дивизия командиры тагын Измайловский полкын да тревога буенча кузгатып, Вәлиәхмәтовлар частен коралсызландырырга дип җибәргән икән. Монысын каршыларга Мөдәррис китте.

Бу ике полкның солдатлары үзләрен кая алып баруларын белмәгәннәр. Аларга хәлне аңлатып бирү белән, ротадан ротага комитетның боерыгы тапшырылды.

— Хәл ачыкланганчы, туктап торырга!

Полк комитетларында хәлне сөйләп биргәч, солдатлар офицерларга буйсынудан баш тартты. Чамадан тыш җикеренә башлаган берничә офицерны һәм унтерны, полк комитеты карары белән, коралсызландырып сак астына да куйгач, бүтәннәре май капкандай булды.

Октябрь көннәрендә бу полклар большевикларның кораллы таянычы иде.

## Хәвефле таң

1918 ел башында солдат һәм мөгаллим Мөдәррис Вәлиәхмәтов туган авылына кайтты. Бераз дәваланырга, хәл алырга да балалар укыта башларга иде исәбе. Ләкин бу ниятен тормышка ашыру тиз генә буласы түгел икән. Совет иленә һәр яктан дошманнар ябырылды. Түзмәде солдат йөрәге — окопларда яулаган ирекне саклап калу өчен көрәшкә ашкынды. Кызыл гвардия отрядына язылды Вәлиәхмәтов. Георгий медале кавалерын Көнчыгыш фронтына җибәрделәр. Тагын авыр сугышлар башланды. Башта аңа чигенү әрнүләрен татырга туры килде. Ул хезмәт иткән полк унтугызынчы елның беренче кичен Уфа янында барган каты сугышларда каршылады. Мөдәррисләр часте акгвардиячеләрне Благодаровка дигән авылдан куып чыгарды һәм дошманның үкчәсенә басып ары таба һөҗүмне дәвам иттерде. Беренче январь көнендә, сугыш тынып торган арада, Мөдәррис Вәлиәхмәтовны партиягә кабул иттеләр. Дивизия комиссары аңа «бүтән юнәлештә хәрәкәт итә башларга әзер торырга» кушып китте. Озак та үтми, полкка приказ килде. Тәҗрибәле сугышчы Мөдәррис Вәлиәхмәтовны командирлар әзерли торган курсларга җибәрергә кушылган иде анда. «Бүтән юнәлеш» дигәне шул икән. Солдат биштәрен асты да Мөдәррис, полкташлары белән саубуллашып, китеп барды. Еллар хәтәр, командирлар җитешми иде — курсларда ин кирәген өйрәттеләр дә яңадан хәрәкәттәге армиягә озаттылар. 1920 елда ул 202 нче татар укчы полкының өченче батальон командиры итеп билгеләнде.

Сугыш юллары полкны көньякка алып килде. Вәлиәхмәтов батальоны акгвардиячеләрне Синельниково дигән станциядән бәреп чыгарды. Озакка сузылган каты сугышлардан соң сугышчыларга кыска вакытлы ял бирелде. Алар станция янында гына урнашкан бер хуторда төн үткәрделәр.

Батальон командиры ул төнне бик начар йоклады. Синельниково станциясен алу өчен кичә генә барган канлы бәрелешләр китмәде аның күз алдыннан. Ак генерал Дроздов дивизиясенең офицерлардан гына торган батальоны станцияне бирмәс өчен җан тартышты. Ләкин кызыл гаскәрләрнең һөҗүменә түзә алмады — чигенергә мәҗбүр булды. Вәлиәхмәтов батальонына да кыйммәткә төште бу станция. Йөзләгән сугышчыны туганнар каберлегенә күмделәр.

Ул урамга чыкты. Таң беленеп кенә килә иде әле. Аның беренче нурлары хутор йортларының түбәләрен генә яктырта. Һава шундый саф, күк шундый биек — яшәп туймаслык дөнья! Шул дөньяда көнетөне сугыш баруына да ышанасы килми. Атышлар, ядрәләр, туп гөрселдәүләре — барысы да гайре табигый шикелле. Шушы тынлыкта берничә минут кына булса да киләчәк турында уйга чумып утырасы иде менә. Вәлиәхмәтов сиртмәле кое бурасы читенә килеп таянды. Ничек башланыр да ничек төгәлләнер бүгенге көн? Сугышта бит төрлесе була. Разведка мәгълүматларына караганда, акларның чигенүе көчләрен саклап калу өчен генә булырга тиештер. Аларга ярдәмгә яңа частьлар көтелә. Әсирләр кичә шулай диделәр. Әгәр бу дөрес булса?..

Вәлиәхмәтов, авыр уйларын башыннан качырырга теләгәндәй, коедан бер чиләк су алды да иелеп юынырга тотынды. Салкын су кайнарланган башны суытып, аны сафландырып җибәргәндәй булды. «Суы йомшак икән, безнең яклардагы кебек»,— дип уйлады ул. Тагын бер чиләк су алып башына ук койды.

Шуны гына көтеп торган диярсең — болдырда хуҗа хатын күренде. Аның кулында бик матур украин бизәкләре чигелгән сөлге иде.

— Йокысыз кеше булыр икән,— диде ул, йомшак тавыш белән.— Ял итәр идегез, ичмасам... Менә тастымал белән сөртегез битегезне.

— Рәхмәт,— диде Мөдәррис, сөлгене алып.— Ялны сугыш беткәч итәрбез инде, сеңелкәш. Насыйп булса...

Хуҗа хатын өйгә кереп китте. Ә капка төбендә бер кызылармеец күренде.

— Сезне полк командиры чакыра, иптәш командир!..

Вәлиәхмәтов штабка килеп кергәндә, барысы да җыелып беткән иде инде. Полк командиры батальоннар алдында торган бурычларны аңлатырга тотынды.

— Кичә генә безнең кулга күчкән Синельниково станциясенең стратегик әһәмияте яхшы беләсез, иптәшләр. Харьков юлы дигән сүз ул. Алай гына да түгел, икмәкле районнарга да, Донбасс күмеренә дә шушы юл илтә. Акларның бу юлга тагын бер өмете бар: ул аларны Дон буендагы контрреволюцион көчләр белән тоташтырачак. Күрәсез станцияне кулда тоту бик әһәмиятле. Ләкин безнең көчләр чикләнгән. Ә акларга яңа частьлар килеп кушылды. Генерал Дроздов үз дивизиясен шактый ныгытты. Ул станцияне алу өчен һөҗүмгә әзерләнә. Безгә дә ярдәм килә. Тик ул частьлар юлда әле. Алар килеп җиткәнче, станцияне ничек тә саклап торырга кирәк...

Һәр батальонга бурыч билгеләп, полк командиры киңәшмәне тәмамлады. Кешеләр тарала башлагач, Вәлиәхмәтовны туктатты:

— Сезгә берничә сүзем бар әле, китмәгез...

Икәүдән-икәү генә калгач, полк командиры Мөдәррискә беравык сүзсез генә карап торды. Аннары болай диде:

— Дөресен әйткәндә, Мөдәррис, хәлебез авыр безнең. Сафларыбыз сирәгәйде, кораллар аз. Ни барын синең батальонга тупларбыз. Ярдәм

килеп өлгермәсә, станцияне саклый алуыбыз икеле. Чолганышта калу ихтималы зур. Аңа юл куя алмыйбыз. Төп көчләрне саклап калырга кирәк безгә. Димәк, вакытлыча чигенү ихтималы туа. Ул чагында синең батальон чигенүче көчләрне каплап торыр...

— Аңлашыла,— диде Мөдәррис.— Бу соңгы боерык, алайса?

— Соңгы,— дип җавап бирде полк командиры. Алар кочаклашып хушлаштылар. Берсе дә сүз әйтмәде, тик карашлары гына бер-берсенә текәлде: «Сынатмассыңмы, Мөдәррис?» «Сынатмам, иптәш командир!»..

## Соңгы сугыш

Кызыл полк акларны тиешенчә каршыларга әзерләнде. Офицер батальоннарының берничә атакасы кире кайтарылды. Ләкин акгвардиячеләрнең һөҗүм көче кимемәде. Аларның артиллериясе төрле яктан ут ачты. Полк командиры акларның ниятен алдан сизгән икән: алар чыннан да станцияне камап алырга омтыла иде. Бер яктан җәяүле гаскәр һөҗүм итә, икенче тарафта атлы казаклар пәйда булды. Кызыл полкның төп көчләренә станцияне калдырып чигенергә приказ бирелде. Ә Вәлиәхмәтов командалыгындагы 202 нче батальон сугышчылары окопларыннан кузгалмадылар.

Көн уртасына кадәр дошман уңышка ирешә алмады. Ләкин кызыл батальон тирәсендәге утлы боҗра һаман кысыла барды. Полкның төп көчләре инде хәвефле төбәктән чыгарга өлгерделәр. Батальонга мондый мөмкинлек калмаган иде инде. Вәлиәхмәтов соңгы патронгача сугышырга боерык бирде. Сугыш кызганнан-кыза барды.

— Патроннар бетте!— дип пышылдады командирларның берсе.

— Штык сугышына әзерләнергә!— Батальон командирының бу приказы окоплар буйлап китте. Шул минутта Вәлиәхмәтов окобы янында гына снаряд шартлады. Һава дулкыны Мөдәррисне күтәреп алды да кабат җиргә ыргытты.

Аңына килгәндә ул сугыш кырында түгел, вокзал каршындагы мәйданда ята иде. «Станция аклар кулында!»— Мөдәррис тагын һушын җуйды. Бераздан кабат күзләрен ачты. Ул кан эчендә иде. Күктә түбәнәеп барган кояш күренде. Колагына казакларның сөйләшүе ишетелде:

— Әнә, командирлары аунап ята...

— Дөмеккәндер инде...

— Юк, өстенә салкын су койгач, селкенде.

— Селкенмәслек итәргә кирәк үзен,— диде калын тавыш. Икенчесе аңа каршы төште:

— Ярамый. Подполковник әфәнде үзе боерды: аңына килсә, миңа житкерерсез, диде.

Казакларның берсе Вәлиәхмәтов янынарак килде дә аның муен тамырына типте. Мөдәррис хәлсез генә ыңгырашып куйды.

— Ә, аңга килдегезме, князь? Бик яхшы, бик яхшы. Подполковник әфәндегә киттек, алайса.

Мөдәррисне күтәреп торгыздылар да вокзал каршындагы эскәмиядә утырган офицер янына алып килделәр. Каршыга тимер юлчылар узды. Мөдәррис исенә төшерде: әле кичә генә ул аларга митингта речь сөйләгән иде. Ә бүген менә нинди хәлдә!.. Вәлиәхмәтов аларны күрмәмешкә салынды.

Әсирне якын ук китергәч, подполковник урыныннан торды.

— Хәлегез авыр сезнең,— дип сүз башлады ул.— Аңлыйм, бик яхшы аңлыйм. Ләкин аны яхшырту үз ихтыярыгызда. Госпитальгә озатып куярбыз менә... Тик берничә сорау бирәсе бар үзегезгә. Шул гына тоткарлый гуманлы бу адымны.— Подполковник аңа папирос

сузды.— Рәхим итегез!.. Тартмыйсызмы?.. Бик яхшы... Карагыз әле, Вәлиәхмәтов әфәнде, сезнең Георгий медалегез кайда?

Мөдәррис, гаҗәпләнүдән аптырап, офицерга карап алды. Фамилияне дә белә, Георгий медален дә... Кем булыр бу? Офицер да аның халәтен аңлады. Сүзен дәвам иттерде:

— Бу сорауны көтмәгән идегезме? Юкка... Без үзебезгә каршы сугышучы командирларны беләбез. Сезнең кызыллар ягында нинди батырлыклар эшләгәнегез дә безгә мәгълүм. Сез батыр солдат, Вәлиәхмәтов әфәнде. Кызыллар андый кешеләрнең кадерен белми. Ә бездә... Безнең арада сезнең мөселман кардәшләрегез дә бар. Алар белән сөйләшеп карагыз әнә...

Подполковник читкәрәк китеп утырды. Мөдәррис каршына яшь кенә купшы офицер килеп басты.

— Әссәламәгаләйкем, кордаш!.. Без ике мөселман кардәш уртак телне тиз табарбыздыр, шәять...

Ул нәрсәдер сөйләргә кереште. Ләкин Вәлиәхмәтов аны ишетмәде. Артында басып торган казаклар Мөдәррисне төрткәли башладылар. Берсе йодрыгын төйнәп килде дә кизәнеп аның авызына сукты. Мөселман офицер елмаеп куйды:

— Бездә шулай да тел яздыралар... Шәригатькә сыймаган нәрсә юк монда...

«Галәветдин хаҗиның улы ич бу!» Шушы уйдан тетрәнеп китте Мөдәррис. Аның авызы тулы кан иде. Әлеге офицер якынрак килгәч, Вәлиәхмәтов аның йөзенә төкерде. Хаҗи малаеның купшы киеме, битебашы канга буялды. Ул кинәт артка сикереп китте дә кыныннан кылычын тартып алды. Аны Мөдәррриснең башы өстенә күтәрде. Вәлиәхмәтов та́ кулын өскә чөйде һәм ак офицерның кылычы Мөдәррриснең беләзек сөяген ярып читкә сугылды, урам ташына бәрелеп чыңлады.

— Отставить!— дип кычкырды моны күзәтеп утырган подполковник. Хаҗи малае, кылычын кынына тыгып, читкәрәк китте. Подполковник әсир янынарак килде дә:

— Кызганыч, уртак тел таба алмадыгыз,— диде. Аннары часовойларга кычкырды: — Атарга үзләрен!.. Хәзер үк алып китегез!..

Аларны шәһәр читенә алып чыктылар. Тирән генә чокыр кырыена тезеп бастырдылар. «Пли!» дигән команда тавышы ишетелде. Мөдәррис чокырга ауды. Мылтыклар шартлады һәм тирә-юньдә тагын тынлык урнашты. Тик монысы нинди тавыш соң тагын:

— Сез исәнме, иптәш?

Мөдәррис көч-хәл белән генә күзләрен ачты. Аның янына яшь кенә кыз иелгән иде. «Гайшә?.. Юк, каян килсен ул монда!..» Вәлиәхмәтов тагын һушсыз калды. Аңына килә алмый ике көн саташып яткан, дип сөйләделәр. Шуннан соң гына күзләрен ачкан. Шулай үлгән җирдән терелде ул командир...

Ветеран агаем, сүздән тукталып, миңа текәлде. «Бөтенесе шул, тагын ни телисең?»— янәсе.

— Шуннан соңгы язмышы ничек булды икән Вәлиәхмәтов аганың? Исәнме икән ул?— дип сорадым мин.

Карт торып басты. Күзләрендә ниндидер хәйләкәр-шаян очкыннар күренде аның.

— Таныш булыйк,— диде ул, честь биреп.— 202 нче татар укчы полкы составындагы өченче батальонның элекке командиры Мөдәррис Вәлиәхмәтов бабагыз сезнең каршыгызда басып тора...

Мин өнсез калдым. Сокланып аңа карап тордым. Менә кем икән ул — үлеп терелгән батыр. Минем күптәнге танышым. Кем уйлаган бит аны!

Фатих Шәрәфиев

# КҮРКӘМ ИҖАТ, БӘХЕТЛЕ ЯЗМЫШ

Татарстанның халык артисты Хәким ага Сәлимҗанов бәхетле иҗат гомерә кичергән кешеләрнең берсе: чөнки театр сәхнәсенә аяк баскан көннәреннән башлап аңа Һади Такташ, Таҗи Гыйззәт, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшев, Зәйни Солтанов, Шакир Шамильский, Гөлсем Болгарская, Мохтар Мутин, Фатыйма Ильская кебек атаклы әдәбият-сәнгать эшлеклеләре белән кулга-кул тотынышып эшләргә туры килә.

Менә ярты гасыр буе инде ул театрыбыз ирешкән казанышларның тере шаһиты, аның актив иҗатчыларыннан берсе буларак сәнгатьнең алгы сафында атлый.

Хәким Сәлимҗановны сәхнәбездә үзенчәлекле образлар галереясе тудырган оста артист, дистәләрчә спектакльләр куйган режиссер, күренекле нәфис сүз остасы, татар театрлары өчен берничә драма әсәре язган драматург һәм, ниһаять, «Артист язмалары», «Нәфис сүз» исемле китаплар авторы буларак беләбез. Бәхетле гомер димичә, моны ни дисең?!

Хәким Сәлимҗанов 1903 елда Оренбург өлкәсенең Орск шәһәрендә Борнаевларның сәүдә йорты хезмәткәре Йосыф ага гаиләсендә туа. Әтисеннән ул бик яшьли ятим кала һәм Мөхәммәтҗан белән Закирҗан абыйсы тәрбиясендә үсә.

Хәкимҗан башта Өрәште мәдрәсәсендә укый. Аннары церковно-приходская школада рус телендә башлангыч белем ала. Тора-бара, укырга һәвәслеге барлыгын белгәннән соң, абыйлары аны шәһәрдәге рус училищесына укырга бирәләр. Әмма училищены ул тәмамларга өлгерми. Империалистик сугыш башлану белән, абыйлары солдатка алыналар. Шушы көннән башлап Хәкимҗанга үз тамагын үзе туйдырып, семьясына да ярдәм итәргә туры килә — ул бер кибеткә өйрәнчек булып керә...

Театр сәнгате белән ул бик иртә очраша. «Артист язмалары» исемле китабында бу хакта болай дип яза: «Бер көнне Закир абый каяндыр ашыгып кайтты да миңа ниндидер иске-москы тоттырып шуларны кыйраәтханәгә (уку залына) Мөхәммәтҗан абыйга илтеп бирергә кушты. Кыйраәтханә ишегеннән керүгә, күзләрем дүрт булды. Минем абый, гайрәт орып, кем беләндер ду кубып сугыша иде. Түәнчекләрем кулымнан төшеп китте. Абыйның якларга ташландым. Ниндидер бер олы гәүдәле кеше аның якасыннан эләктереп тоткан да зур йодрыкларын Мөхәммәтҗан абыйның баш түбәсенә китергән. Барып аягын тешли башладым. Шунда ук аерылыштылар. Рәхмәт урынына абыйның шелтәле сүзләрен ишетергә туры килде. Ул гына булмады, шаярып колагыма тотындылар, берни аңламый артка чигендем һәм абыйга түәнчекне биреп чыгып та йөгердем. Кире чакырып керттеләр. Шунда гына аңладым: репетиция бара икән. Шулай итеп, мин бу театрның йомышчы малаена әйләнеп киттем».

1919 елның җәй ахырында Орск шәһәренә атаклы артист, режиссер Габдулла Кариев килеп чыга. Җирле һәвәскәрләрне үз тирәсенә туплап, Г. Кариев кыска гына

вакыт эчендә «Галиябану», «Ачлык кушты», «Хаҗи әфәнде өйләнә», «Казанга сәяхәт» дигән әсәрләрне сәхнәгә куя. Үзешчән түгәрәкләрдә эшләү «стажлары» зур булган Закирҗан белән Мөхәммәтҗаннар да бу спектакльләрдән читтә калмыйлар. Егет булып үсеп килә торган Хәкимҗан исә, юк-бар сәбәпләр табып, абыйлары тирәсендә орчыктай бөтерелә, ни белән булса да аларга ярдәм итәргә, ярарга тырыша. Таза гәүдәле, яңгырап торган көр һәм калын тавышлы, бераз шадраррак, әмма ирләрчә сөйкемле йөзле остаз Кариевка ул шунда ук гашыйк була. Г. Кариев Казанга киткәч, труппа башлыгы булып яшь артист Мифтах Әбсәләмов кала һәм Г. Кариев башкарган рольләрне дә ул башкара башлый. Мифтах Әбсәләмов спектакльләрдә Хәким Сәлимҗановка да «өлеш» чыгара — аны эпизодик рольләрдә генә түгел, зуррак рольләрдә дә уйнатып карый.

1920 елда Оренбург өлкәсенең күп кенә өязләрендә кулаклар фетнәсе кабынып китә. Фетнәчеләр авыл коммунистларын, совет властен яклы кешеләрне, ярлылар комитеты вәкилләрен ерткычларча җәзалыйлар, йортларына ут төртәләр. Орск өяз партия комитеты, ашыгыч рәвештә шәһәр коммунистларын һәм комсомолларын мобилизацияләп, коммунистик отряд төзи. Җитмеш тугыз коммунардан торган бу отряд составында комсомол ячейкасы секретаре, унҗиде яшьлек Хәким Сәлимҗанов та була. Коммунарлар Кызыл Армия частьлары белән берлектә фетнәчеләрне тар-мар итәләр.

1923 елның җәй башында Орскига язучы Садри Җәләл белән Мифтах Әбсәләмов килеп төшәләр. М. Әбсәләмов һәвәскәрләр көче белән Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә» трагедиясен сәхнәгә куярга әзерләнә башлый. Таһир ролен ул ышанып Хәким Сәлимҗановка, Зөһрәне аның булачак тормыш иптәше Галия Нигъмәтуллинага тапшыра. Гарәп ролен Рәфкать Фәйзи (соңыннан Башкортстанның халык артисты) уйный. Ханны Мифтах Әбсәләмов үзе башкара. «Бу спектакль өстендә эшләү дәвере минем өчен хәзер татлы бер төш кенә булып тоела. Ләкин ничек кенә булмасын, спектакль дөньяга чыкты һәм ул Орск тамашачыларында зур уңыш казанды»,— дип сөйли Хәким ага.

Мифтах Әбсәләмовка да яшьләрнең уены ошаган булса кирәк. Ул аларның һәр икесен дә Казанга алып китә һәм театр техникумына укырга кертә. Техникумда татар әдәбиятын Фатих Әмирхан, музыканы композитор Салих Сәйдәшев укыта. Актерлык осталыгы дәресләрен З. М. Словянова, А. М. Кречетов һәм Кәрим Тинчурин (ул елларда Татар дәүләт театры директоры да) алып бара.

Студентларга театр ишекләре һәр вакыт ачык. Аларны репетицияләргә, ә кичләрен спектакльләр карарга, шулай ук еш кына масса күренешләрендә катнашырга да чакыралар. Бу исә яшьләргә Г. Болгарская, З. Солтанов, Ш. Шамильский, М. Мутин, Б. Тарханов, Н. Сакаев, Ф. Ильская һ. б. лар кебек атаклы сәхнә осталарының иҗатлары белән якыннан танышырга мөмкинлек бирә. Алар өлкәннәрдән сәхнәдә үзүзеңне тоту, хәрәкәт итү, тавышның көченнән төгәл файдалану серләренә өйрәнәләр.

«Безнең вакытыбызның иң күп өлеше актерлык осталыгы дәресләренә бирелә иде. Шунда инде безнең укытучыларыбыз Кәрим ага һәм башкалар «кәҗә маебызны» чыгара иделәр. Бигрәк тә миңа, һәвәскәр артист буларак берничә роль уйнап «бозыла» башларга өлгергән егеткә, эләгә иде. Аларның: «Хисләрне йолыккалама, нәрсә аяк-кулларыңны таяктай катырып тотасың!» — дигән кисәтүле сүзләре хәзер дә колак төбендә тора әле... Хисләр уйната башласак, остазларыбыз безне шунда ук туктата торган иделәр. «Хисләр уй һәм йөрәк аша узган теләкләр нәтиҗәсе буларак туарга тиешләр»,— дия иде алар». Ул көннәрне Хәким ага шулай искә ала. Театр техникумын 1926 елның маенда тәмамлап, ул Татар дәүләт академия театрында артист булып эшли башлый.

Бу елларда режиссерлык вазифасын үтәүчеләр арасында Кәрим Тинчурин үзенең үзенчәлекле иҗат алымнары, сәхнә осталыгы, фантазиягә бай булуы, таләпчәнлеге һәм гаделлеге белән аерылып тора. Татар дәүләт академия театрында беренче ролен дә Хәким Сәлимҗанов К. Тинчуринның үзе үк сәхнәгә куйган әсәре — «Җилкәнсезләр» комедиясендә уйный. Остазы аңа күләме ягыннан кечкенәрәк, ләкин әсәрнең идея эчтәлегендә ачуда зур әһәмияткә ия булган яңа заман кешесе — революционер Сәнгать ролен тапшыра. Рольне йөкләгәндә, ул аның алдына җитди бурыч куя: «Син үз тирәңдәге кешеләрнең барысыннан да өстен булырга тиеш. Син — туып килә торган

яңа көн кешесе, киләчәк — синеке. Образың белән син тамашачыларда зур симпатия тудырырга тиеш!»

Остазының ышанычын яшь артист шөйлә аклаган булса кирәк. Спектакльгә карата тәнкыйтьче Фатих Сәйфи-Казанлының «Кызыл Татарстан» газетасында басылган рецензиясендә Хәким Сәлимҗановның уены уңай бәя ала.

Әйтергә кирәк, техникум тәмамлаган яшь артистлар арасында сәхнәдә иң күп «иләнгәне» Хәким Сәлимҗанов була. Рольне кулына алу белән, режиссерга ул бары тик бер генә сорау бирә: «Булдыра алырмынмы?..» 1926—1927 елгы беренче сезонда ук ул алты ай эчендә сәхнәгә куелган утыз өч спектакльнең егерме бишендә катнаша. Ә бу атнага бер яки ике премьера дигән сүз.

Һәм аны нәкъ менә шунда уңышсызлык та сагалап тора...

1927 ел. Татар дәүләт театрында Кәрим Тинчурин М. Фәйзинең «Галиябану» драмасын сәхнәгә куя.

Галиябану ролен бу спектакльдә гаҗәеп моңлы тавышы белән даны таралган, табигате белән нәфис, хисләргә бай артистка Рокыя Кушловская уйный. Исмәгыйльне татар театрының атаклы трагигы Мохтар Мутин башкара. Хәлил — җырга шулай ук бик оста булган һәм инде бу рольне күптән уйнап килгән Ситдыйк Айдаровка тапшырыла. Әмма Галиябануны сәхнәдә тиңдәшсез башкаручы Әшраф Синяева вафат булганнан соң, Ситдыйк Айдаров Хәлил ролен уйнаудан, әйткән сүзе булганга, баш тарта. Аны Хәким Сәлимҗановка тапшыралар. Сәхнәгә яңа аяк баскан яшь артист өчен рольдән баш тарту мөмкин булмаган нәрсә... Х. Сәлимҗанов рольгә алына, аны әзерли, уйный. Тик... уены тамашачыларны шаккаттыра алмый.

1932 елда Кәрим Тинчурин «Галиябану»ны яңадан сәхнәгә чыгара, Хәким Сәлимҗанов спектакльдә Исмәгыйль ролен башкара һәм ул аны егерме ел рәттән уйнап килә һәм, әйтергә кирәк, бу — аның зур иҗат уңышы. Замандашлары да, газета-журнал битләрендә чыккан мәкалә авторлары да бердәм рәвештә шуны раслыйлар.

Ә Фәтхи Бурнашның «Яшь йөрәкләр» әсәре спектаклендә (1927 һәм 1934 еллар) Х. Сәлимҗанов җор күңелле, шаян һәм шук табигатьле Сәйфулла ролен уйный. Шулай ук замандашларының әйтүенә караганда, роль шактый табигый һәм ярыйсы ук шома килеп чыга. Тик ул башкаручының... үзен генә канәгатьләндерми. Артист үзе тудырган образның камил түгеллеген, ролен тулысынча үзләштереп җиткермәгәнлеген сизә. Һәм бу гаҗәп тә түгел. Чөнки спектакльне алар, ул вакытлардагы тәртип һәм мөмкинлекләр буенча, бары тик өч репетиция белән уйныйлар.

1938 елда «Яшь йөрәкләр» спектаклен Хәким Сәлимҗанов үзе сәхнәгә куя һәм Сәйфулланы үзе уйный.

Беренче пәрдәләрдә ул көр күңелле һәм тапкыр сүзле, эчкерсез табигатьле, әмма үз язмышына буйсынып яшәгән бер ярлы егете булып күзаллана. Ә спектакльнең соңгы пәрдәсендә исә бөтенләй башка кешегә — империалистик сугышның газапларын татыган, акны карадан аера белгән, үз көченә ышанган чая һәм кыю солдатка әверелә. Кемнең дус, кемнең дошман икәнен ул инде хәзер бик яхшы аңлый. Беренче империалистик сугыш алды, сугыш вакыты һәм революция чорларындагы татар авылының тормышын һәм андагы сыйнфый мөнәсәбәтләрне матур һәм тулы канлы образлар аша тасвирлаган әсәрдә бу рольне Хәким ага үзенә генә хас дәрт һәм осталык белән ике дистә ел буена уйный һәм тамашачыларның мәхәббәтен казана.

1968 елда шушы ук «Яшь йөрәкләр» әсәрен Х. Сәлимҗанов Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында яңадан сәхнәгә куйды һәм аның режиссерлык таланты биредә җәүһәр ташы кебек кабат ялтырап күренде. Артистларның рольләргә дөрес сайлануы, гади авыл кешеләренең эчке дөньясы, аларның уй-кичерешләре табигый һәм дөрес ачылуы — һәммәсе дә спектакльне озын гомерле итте.

Хәким Сәлимҗановның сәхнәдә үз иҗат йөзен, үз почеркын, стилен эзләгән чорындагы җитди уңышларыннан берсе «Ревизор» спектаклендә Хлестаков образы була. Н. В. Гогольнең бу әсәрен 1931 елда К. Тинчурин әзерли. Ул спектакльдә катнашучы артистларның тамашачыларны көлдерү юлына басу ихтималын алдан күрә, алар алдында персонажның бер генә сыйфатына басым ясап уйнамыйча, образларның асылына тирәнтен үтеп керү бурычын куя. Хлестаков кебек рольгә алыну Х. Сәлимҗанов өстенә авыр һәм җаваплы бурыч йөкли. Н. В. Гогольнең: «Пьесада

бик авыр роль — Хлестаков роле бар. Мин бу роль өчен бик куркам. Бу рольне уйнау өчен зур талант кирәк»,— дигән сүзләре аны аеруча нык уйландыра.

«Мин башкарган Хлестаков,— дип сөйли соңыннан Хәким Сәлимҗанов,— хәрәкәтләргә җитез, бер халәттән икенчесенә бик тиз күчүчән. Бер карасаң, ул авызын ачып, аптырап кала, икенче карасаң, өтәчләнә башлый, күркә кебек кабара... Булдыксыз, җилкуар, алдакчы һәм җилбәзәк Хлестаковны мин образымның күзләре аша таптым. Кеше алдашканда яки үзенең көчсезлеген яшерергә теләгәндә гадәттә янындагы кешесенең күзләренә туры карамый. Мин дә каршымда басып торган партнерымның күзләре белән очрашудан качарга тырыша идем...»

Әйтергә кирәк, Городничий ролен уйнаучы атаклы артистларның һәр икесе Хлестаков ролен үзләштерүдә яшь артист Хәкимгә зур ярдәм күрсәтәләр: Зәйни Солтанов аны эчке кичерешләрнең дәреслеген табу, бер халәттән икенче халәткә күчү серләренә, табигыйлеккә өйрәтсә, Мохтар Мутин шушы кичерешләрне тышкы ишарә һәм хәрәкәтләр аша чагылдыру осталыгына өйрәтә.

Инде оста актер булып танылган Хәким ага 1934 елда Шекспирның «Отелло» трагедиясендә Яго ролендә чыгыш ясый.

Аның моңа кадәр дөнья классиклары әсәрләрендә җаваплы рольләрне башкарганы булмый әле. Шунлыктан Шекспир, Шиллер кебек драматургларның трагик һәм романтик әсәрләрен уйнап тәрбияләнгән Мохтар Мутин репетицияләр вакытында яшь артистны классик сәхнә кануннарына өйрәтә. Үзенең бу роле турында исә Хәким ага Сәлимҗанов түбәндәгеләрне сөйли: «Яго ролен мин зур рух белән, ләззәт табып уйнадым. Чөнки партнерың никадәр көчле булса, образның эченә керү дә шул кадәр җиңел була — син үзең дә партнер дәрәҗәсенә күтәрелергә омтыласың. Отелло ролен Мохтар ага иҗатының чәчәк аткан вакытында башкарды һәм тиңдәшсез, кабатланмас образ тудырды. Отеллоның көнчелек хисләре ниндидер бер дәһшәтле көч белән тышка бәреп чыга иде... Спектакль барышында ул Ягоны күтәреп идәнгә бәрә дә өстемә ташланып чынлап торып буа башлый иде. Авыр хәлдән котылу өчен мин аның кулын каты итеп чеметергә мәҗбүр булгаладым».

Егерме елдан соң Х. Сәлимҗанов шушы ук Яго ролен кабат башкара. Артист инде аның түбән җанлы кабахәт бер кеше булуына гына басым ясауның җитмәвен аңлый. Отеллоның кан дошманы Яго үз хисләрен җиде катлы җир астына яшерергә тиеш. Х. Сәлимҗанов башкаруында ул чыннан да яшь, чибәр, көр һәм шат күңелле кеше булып күренә. Сәхнәдәге беренче сүзләреннән соң ук аның үз көченә ышанган, үз сәләтен, үз мөмкинлекләрен яхшы белгән кеше икәнен тоясың.

Сугыш эшендә тәҗрибәсе булмаган Кассионы Отелло үзенә урынбасар итеп сайлагач, Яго чыгырыннан чыга. Юк! Хәзер ул беркемгә дә ышанмый һәм ышанмаячак! Аның күңелендә үч алу теләге кайный... Күренештән-күренешкә, пәрдәдән-пәрдәгә Ягоның Маврга булган нәфрәте көчәя бара. Юк, Яго ярты юлда туктап кала торганнардан түгел! Ике дөнья көрәше, ике дөнья бәрелеше бара. Бер якта — тугрылык, сафлык, кешелеклелек, икенче якта — хыянәт, икейөзлелек, карьеризм.

Утызынчы елларда Академия театрында Ш. Камалның «Томан арты» драмасы куела. Совет чынбарлыгының үзендә үсеп җиткән яңа геройны, яңа тип кешеләрне гәүдәләндергән бу спектакльне җәмәгатьчелек алкышлап каршы ала. Әсәрнең төп герое Габбас Галинны Х. Сәлимҗанов башкара һәм зур уңышка ирешә. Габбас Галин — коры фразалар кешесе генә түгел, ә яңа социалистик тормышның төзүчесе, аның актив иҗади көче дә булып гәүдәләнә. Спектакль хакында «Кызыл Татарстан» газетасы битләрендә басылган мәкалә авторының сүзләре белән әйткәндә, «тамашачы аның һичшиксез җиңеп чыгачагына нык ышана. Шуңа күрә дә ул, эшләнеп беткән рецептын Кузнецовка биреп, авыру атасы яткан бүлмәгә ташлангач та, тамашачы, пәрдәнең ике яклап акрын гына сәхнәне каплый баруын сизмичә, Габбас кергән ишектән аның атасы белән бергә шатланып килеп чыгуларын көтеп утыра, тамашачының аларның бәхетләрен күрәсе, алар белән бергә шатланасы килә». (С. Гыйльфан. «Кызыл Татарстан».)

Ш. Камалның «Козгыннар оясында» — Мәхмүт, Г. Камалның «Бәхетсез егет» әсәрендә — Камали, Т. Гыйззәтнең «Чаткылар»ында — Гаяз һәм Рамай, «Ташкыннар»ында — Мирзахан, М. Әмирнең «Миңлекамал»ында — Гыйльманов, Н. Исәнбәтнең «Зифа» комедиясендә — Айдар, «Хуҗа Насретдин»да — Алчын, Гогольнең «Реви-

зор»ында — Хлестаков, Горькийның «Тормыш төбендә» — Васька Пепель, «Дошманнар» драмасында — Николай, А. Островскийның «Яшенле яңгыр»ында — Кудряш, «Гаепсездән гаеплеләр»ендә — Незнамов һәм Муров, В. Гюгоның «Анджело» драмасында — Омодей һ. б. образларны да Х. Сәлимҗанов зур осталык белән иҗат итә. Аның уены турында төрле елларда газета-журнал битләрендә әйтелгән кайбер фикерләрне китереп китик:

«...«Анджело» спектаклендә инквизиция агенты Омодей ролен... ничек иркен һәм оста итеп уйный ул!.. Аның кулында — гитара, йөзендә елмаю балкый, хәрәкәтләре җиңел, тыштан караганда чак кына тинтәгрәк, татлы телле. Ә никадәр явызлык белән тулган аның йөрәге, нинди мәкерле ул!?» (Г. Минский. «Совет Татарстаны».)

«...Вәзирне артист Х. Сәлимҗанов дөрес планда уйный. («Мәхәббәт хикәясе». Н. Хикмәт әсәре.) Артист тышкы буяуларга саран. Ул һәр вакыт бөтен нәрсәдән читтә тора төсле, аз хәрәкәтчән, салкын канлы, тыштан кешелекле булып күренергә тырыша. Ләкин кирәк моментта ул шундый итеп эшли, шундый сүз әйтә — дошманы я чигенергә, я уйланырга мәҗбүр була». (Х. Кумысников. «Совет Татарстаны».)

«...Татарстанның атказанган артисты Х. Сәлимҗанов көр күңелле, шаян табигатьле матрос Дымовны (Н. Погодин. «Мылтыклы кеше».) истә калырлык итеп бирә алды». (Г. Кашшаф. «Социалистик Татарстан».)

«...ТАССРның атказанган артисты Х. Сәлимҗанов Боровский образының (Б. Лавренев. «Диңгездәгеләр өчен».) үзенчәлекле характерын дөрес ачкан. Карьеризм, интәшлелекне оныту, ялгыш омтылыш корбаны булуы аркасында үз героеның зур җинаятькә барганлыгын тамашачыга аңлаешлы итеп җиткерә». (Х. Бикбулат. «Совет Татарстаны».)

Хәким аганың роль өстендә эшләү ысулы гыйбрәтле. Эшне ул беркайчан да рольнең сүзләрен ятлаудан башламый, ә текстны күңел күзе аша үткәреп, әсәр авторының шушы роль аша әйтергә теләгән фикеренә төшенергә тырыша. Образ аның хыялында акрынлап үзенең эчке һәм тышкы формаларына керә башлый. Артист әнә шул хыялый шәүләне үзенә акрынлап якынайта, үзенеке итә бара, күзаллау нәтиҗәсендә уйнаячак образының калыбына керә. Берничә репетициядән соң ук ул үз роленең генә түгел, партнерларының сүзләрен дә яттан белә. Хәтере яхшы! Берәр артист авырып спектакльгә килми калды исә, теләсә нинди озын текстлы булмасын, роль Х. Сәлимҗановка тапшырыла. Репетициягә килгәндә Х. Сәлимҗанов образның теге яки бу ягын ачыклаган була, шушы персонаж өчен генә хас булган үзенчәлекле билгеләр, характерлы сызыклар табып килә.

Режиссерлык эше белән Хәким Сәлимҗанов 1930 елларда шөгыльләнә башлый. Аның Татар дәүләт академия театрында куйган беренче спектакле Һади Такташның «Камил» драмасы була. Спектакльне әзерләгәндә Ш. Шамильский һ. б. кебек иҗат тәҗрибәләре һәм сәхнә осталыклары белән үзеннән шактый югары торган өлкән остазлары ярдәменә таяна. Артистлар әсәрнең төп идеясен ачу, образларның характерларын билгеләү һәм конкретлаштыру буенча яшь режиссерга файдалы киңәшләр бирәләр. Ә инде художник Петр Сперанскийның отышлы сәхнә оформлениесе, композитор Салих Сәйдәшев язган лирик көйләр спектакльнең уңышлы килеп чыгуына ярдәм итә.

Спектакль пьеса авторының үзенә дә ошаган, күрәсең. Һ. Такташ, сайланма әсәрләренең беренче томы басылып чыккач, аны Хәким Сәлимҗановка: «Сәлимҗан, сиңа, Камилнең режиссерына, дуска. Һади Такташ», дигән автограф белән бүләк итә.

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия һәм Әлмәт театрларында Хәким Сәлимҗанов төрле елларда Ш. Камалның «Таулар», В. Кудринның «Давыллар арасында», Ф. Бурнашның «Лачыннар», «Яшь йөрәкләр», Бель-Белоцерковскийның «Чик сакчылары», Һ. Такташның «Югалган матурлык», Ә. Атнабаевның «Ул кайтты», К. Тинчуринның «Кандыр буе», Г. Минскийның «Бөдрә тал» кебек әсәрләрен сәхнәгә куя. Хәким Сәлимҗанов шулай ук дистәләрчә радиопостановкалар да куйган режиссер. Аларның күбесендә үзе автор, үзе режиссер һәм артист буларак та катнаша. Аның «Галиябану», «Анна Каренина», «Козгыннар оясында», «Павлик Морозов», «Корыч ничек чыныкты», «Рус мәсьәләсе», «Тукай», «Чапаев», «Газинур», «Намус» һ. б. постановкаларын радиотыңлаучылар яратып кабул иттеләр.

Татар артистлары арасында әдәбиятны чиксез яраткан һәм аны пропагандалауда

өзлексез эшләп килгән нәфис сүз осталары аз түгел. РСФСРның һәм Татарстанның халык артистлары Габдулла Шамуков, Шәүкәт Биктимеров, РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артистлары Рәшидә Җиһаншина, Ринат Таҗетдинов, Татарстанның халык артистлары Хәким Сәлимҗанов, Айрат Арсланов, Татарстанның атказанган артистлары Фәйзи Йосыпов, Әзәл Яһүдин һ. б. лар нәфис сүз сәнгатен үстерүгә зур өлеш керттеләр. Аларның өлкәннәреннән һәм активларыннан берсе, әлбәттә,— Хәким ага Сәлимҗанов. Бу өлкәдә ул кырык елдан артык эшли. Габдулла Тукайның «Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш», «Шүрәле», Һади Такташның «Киләчәккә хатлар», Муса Җәлилнең «Хат ташучы» кебек зур күләмле әсәрләрен, Фатих Кәрим, Әхмәт Фәйзи һәм башка татар совет шагыйрьләренең поэмаларын, шигырьләрен беренче тапкыр артист Хәким Сәлимҗанов үзенә генә хас җылылык һәм юмор белән укый. Бу өлкәдәге зур тәҗрибәсе белән ул 1959 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Нәфис сүз» исемле китабында уртаклаша.

Безнең татар театр сәнгате дөньясында тамашачыларның кайнар мәхәббәтен казанган, исемнәре алтын хәрефләр белән язылырга лаеклы сәхнә йолдызлары шактый күп. Аларның иҗаты, тормышлары, сәхнәдәге уен үзенчәлекләре белән меңнәрчә театр сөючеләрнең танышырга теләве бик табигый. Татар театр тарихында беренчеләрдән буларак, Х. Сәлимҗанов әнә шул сәхнә йолдызларын «Артист язмалары» китабында яңадан «терелтте», иҗат иткән образларын, яшәгән чорларын күз алдыбызга бастырырга ярдәм итте. Аның истәлекләрендә без Габдулла Кариев, Нури Сакаев, Мифтах Әбсәләмов, Бари Тарханов, Мохтар Мутин, Зәйни Солтанов, Шакир Шамильский кебек атаклы сәхнә осталары, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Салих Сәйдәшев кебек классикларыбыз белән күзгә-күз очрашабыз, алар белән аралашкандай булабыз. Хәким ага бу изге эшен киләчәктә дә дәвам итәр дип ышанырга кирәк.

Үзен татар, рус һәм бөтендөнья классик әдәбияты дөньясына алып кергән әдипләребез Фатих Әмирхан һәм Галимҗан Ибраһимов әсәрләренә гашыйк Сәлимҗанов шушы ике әдипнең әсәрләрен татар сәхнәсенә күтәрү турында күптәннән хыяллана. Бөек каләм осталарына шушы зур ихтирам һәм мәхәббәте аны, ниһаять, драматургия өлкәсенә дә китерә. Ул Ф. Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт», Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми», «Тирән тамырлар» әсәрләре буенча инсценировка-пьесалар язды һәм алар озак вакытлар сәхнәдән төшмичә уйналдылар.

Сәхнә остасы, әгәр гомере буена үз театры белән янып, шушы театрның язмышы һәм киләчәге өчен борчылып яши икән, алмашка килә торган яшь буын турында уйламый булдыра алмый. Хәким ага да үз иҗат тәҗрибәсен яшь артистлар белән уртаклашырга гаять тырыша. Академия театры сәхнәсендә Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр», М. Фәйзинең «Галиябану» спектакльләрен куйганда, мәсәлән, барлык рольләрне дә ул ышанып яшьләргә тапшырды һәм алар белән армый-талмый эшләде. Ә инде олыгая төшкәч, бөтен көчен, энергиясен татар театр училищесында яшь артистлар тәрбияләү эшенә багышлады. Училище педагогы Хәким Сәлимҗанов, яшьләрне сәхнә осталыгына өйрәтү белән бергә, аларны үз иленең тугрылыклы уллары һәм кызлары итеп тәрбияләргә омтыла.

Менә Казан театр училищесы укучыларының диплом спектакле афишасы. Ул Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасында «Ике хуҗаның хезмәтчесе» (К. Гольдони әсәре) куелуы турында хәбәр итә. Остазлары Хәким Сәлимҗановка истәлек итеп бирелгән бу афишадан түбәндәге сүзләрне укырга мөмкин: «Хәким ага! Безгә биргән белемегез өчен сезгә бик зур рәхмәт. Сезне беркайчан да онытмабыз»... «Әле бездән соң да татар сәнгатенә үзегез үстергән җимешләрне бүләк итегез»...

Мондый сүзләрне шәкертләреннән ишетү педагог өчен бик-бик күңелледер, әлбәттә. Без дә, аларга кушылып: «Яшәгез, Хәким ага! Изге эшегезне шулай һаман уңышлы дәвам иттерегез»,— дип әйтәбез.

# САТЛЫК ҖАН — АРТЫК ҖАН

Мюнхенда яшәүче берәүгә алтмыш биш яшь тулган. Көнбатыш Германиядә шул яшьтә пенсиягә чыгалар. Ләкин аңарга хуҗалары пенсия түләүдән баш тартканнар. Тамак туйдырырга, өс-башка кием алырга, торак өчен түләргә акча кирәк бит... Бәлки Советлар Союзына язып карарга дыр? Бик күптән булса да, ул Чаллы такта яру заводында инженер булып эшләп йөргән бит. Бик аз эшләгән эшләвен — нибары ярты ел чамасы гына. Аның кадәр генә стажның тияре дә шул чаклы гына, билгеле. Ләкин алай да язарга кирәк, дигән фикергә килә ФРГда яшәүче кеше.

Менә ул юка зәңгәр кәгазьгә юллар тезә. Заманында Чаллыда хезмәт иткәнлеге турында белешмә сорый. Кәгазенә фоторәсемен дә терки. Рәсемнән мөлаемрак йөзле абзый көлемсерәп карый. Чал чәчләр аның зур тормыш юлы узганлыгы турында сөйли, зур борыны сабырлык, киң күңеллелек турында кычкырып тора сыман. Асылынып төшкән зур ияге исә ихтыяр көчен күрсәтәдер кебек.

Мюнхенлы үзенең таушалган-чуалган хәтерендә казына, күптән уралган еллар йомгагының очын эзли. Ләкин ул заманнардан соң бик күп сулар аккан шул инде, бик күп болытлар агылып узган һәм бик күп каннар аккан...

Ул хәтта заводта эшләгән елын да төгәл генә хәтерләми. «1930—1931 нче еллар арасында түгел микән?» — дип яза. Шуның белән бәйләнешле берәр хатирәне исенә төшермәкче була. Бәлки шул әйтелгән булса, аның монда чыннан да эшләвен һәм эшләгән елларын раслаучы дәлил була алыр иде. Әмма бергә хезмәт иткән иптәшләренең исеме дә, истә калырлык вакыйгалар да онытылганнар. Берсен дә хәтерләми мюнхенлы. Әһә, тапты бит... Нечкә генә, алама гына булса да җеп очы. Яңа директор аны кыерсыта башлаган. Ни өчендер яратмаган. Шуның өчен ул бу эштән, үз сүзе белән әйткәндә, «тайган».

Бик авыр язмышлы икән ул Мюнхендагы чал чәчле кеше. «Таулар, сулар, утлар кичәргә туры килде миңа. Ләкин тормышта үзалдыма куйган максатыма ирешә алмадым. Аның урынына мин башка кешеләр белмәгәнне белдем», — дип яза ул хатында. Кызык. Күпне күргән кеше күп белә. Тик ни белә икән соң ул?

Шуларга өстәп, мюнхенлы үзенең тагын бер уңай сыйфатын бәян итә. Ул, баксаң, бөтен кешелек язмышы өчен борчылып яшәүче кеше икән. Борчылып кына да калмый, җиң сызганып, кешелекне дөрес юлга бастыру өстендә эшли, имеш. «Хәзерге заманда кешеләрнең хәле аяныч. Халыклар үз хәлләрен үз куллары белән начарлатканнан-начарлата баралар. Ул хакта үзләре белмиләр. Ялгышларын күрсәтсәм, ачулары килә. Менә кыенлык нәрсәдә». Шактый томанлы сүзләр. Алай да тагын бер уңай сыйфаты барлыгына ышаныйк. Ни әйтсәң дә, нияте яхшы бит.

Хатын язып бетерә. Имзасын куя. Ильяс Шәрифулла улы Габидуллин ди һәм шунда ук искәрмә дә бирә: «Мине Германиядә Ильяс Абдулла дип йөртәләр».

Аяныч хәл, әлбәттә. Кызганыч. Җитмәсә, үзенең сүзләренә караганда, яхшы гына кеше булырга охшый. Әмма хатны укыгач, чаллылылар утырып күз яшьләрен түкмәгәннәр. «Сездә бик зур автозавод төзиләр. Бу хәл миңа бер дә ошамый», дигән сүзләреннән соң җиң сызганып КамАЗны сүтәргә дә ашыкмаганнар. Бер елмаеп куйганнар да эшләрен башкара биргәннәр.

«Чаян»ның баш редакторы чагымда былтыр Чаллыга барып чыккач, андагы иптәшләр әлеге хатны исләренә төшерделәр. Эзләп таптылар да:

— Кызыкны әллә каян эзләп йөрисе юк. Мә менә, бас та чыгар. Мюнхеннан торып безгә акыл өйрәтеп ята. Берәр сатлык җандыр әле шунда, — диделәр.

Чаллылыларның шундый кискен нәтиҗә чыгарулары аңлашылды, әлбәттә. Мәһабәтлеге һәм төзелү сроклары белән бөтен дөньяны таңга калдырган, барыбызның да горурлыгы булган КамАЗ кадәр КамАЗга теләсә кем тел тидерсен дә, тыныч кына тыңлап тор, имеш.

Ләкин телдән әйтелгән — беткән. Ә миңа, журналга басып чыгаргач, һәр юлы өчен җавап бирәсе була бит. Өзеп кенә бер фикергә килү өчен исә материал җитенкерәми иде. Хат өстәл тартмасында ятты да ятты. Көндәлек ыгы-зыгыдан бушаган арада мин аны тагын бер мәртәбә укып чыктым. «Чаллыдан тайгач, төзелеш трестының Кама Тамагындагы алебастр заводына эшкә кердем», дигән юлларына игътибар иттем. Бәлки Ильяс Абдулла анда да белешмә сорап хат язгандыр? Язган булып чыкты. Хатны эзләп табып редакциягә җибәрделәр. Ул хаттан мин аның Казан Вахитов заводында һәм Свердловск өлкә башкарма комитетының хезмәт бүлегендә эшләп чыкканлыгын белдем. Алар белән дә элемтәгә кердем. Анда да хатлар килгән булып чыкты.

Ильяс Абдулла Урта Азиядә һәм Сарман районында үзенең ерак туганнары барлыгы турында да язган. Күптән түгел, юл уңае туры китереп, мин дә Сарман районының Карашай-Саклау авылына барып чыктым. Ерак туганы дигән егет ферма хезмәткәре, таза беләкле, көләч, авылда мактаулы колхозчы булып чыкты. Хәйдәр Галәветдинов мине Мюнхеннан килгән дүрт хат белән таныштырды. (Хатлар Хәйдәргә очраклы рәвештә килеп кергән. Ильяс Абдулла аларны Хәйдәрнең бабасы фамилиясенә салган булган. Бабасы дөнья кую сәбәпле, аңарга тапшырганнар.)

Шулай итеп, минем кулда акрынлап булса да шактый материал тупланды. Ул материал берәүнең язмышын тулысы белән күз алдына китерүләре белән кызыклы булып тоелды. Ләкин, чаллылылар киңәш иткәнчә, көләрлек әйбер яза алмадым. Темасы ул булып чыкмады.

Кем соң ул Ильяс Абдулла? Ни өчен бездән пенсия сорый?

Ул, чыннан да, безнең илдә хезмәт иткән тугыз елы эчендә сигез заводта эшләп чыккан кеше икән. Күбесендә үзен бер-ике ай, яртышар ел гына асрый алган. Ләкин, әйтүенә караганда, бер урыннан икенчесенә күчеп йөрүенә үзе һич тә гаепле түгел икән. Баксаң, ул, инженер дипломы алу белән үк, үзендә иҗади чыганак зур икәнен сизеп алган. «Мин бик сәләтле кеше идем. Галим-физик, уйлап табучы булырга ниятләдем. Мин үземне гади эштән азат итүләрен, галим булу өчен уңайлы эш шартлары тудыруларын таләп иттем, тудырмадылар», — дип яза бу хакта Ильяс Абдулла. Ул бу заводтан «таеп», икенчесенә барып кергән. Ләкин аңардан галим ясаудан баш тартучы «юньсез» директорлар ул заводта да утыралар икән. Габидуллин өченчесенә, дүртенчесенә барып кергән. Бер адәм рәтле кеше очрата алмаган. Аңа, кая барса да, сөйләшеп куйгандай, үз вазифаларын үтәргә кушканнар. Шулай итеп, яп-якты фикерле яшь сәләт иясенең тәмам нервларын какшатып бетергәннәр, янәсе.

Өстәвенә, Габидуллин бары тик чат корама заводларга гына тап була килгән. Заводларның берсе башына ишелеп төшәр өчен аны гына көтеп торганнар, икенчеләренең станоклары аның бармагын кыстырырга ашкынып торган («станокларның исәбен алган вакытта мин станокка бармагымны кыстырдым»), өченче берсендә кием тегүчеләр качышып беткән, шул сәбәпле «ялга чыккан да кире әйләнеп кайтмаган».

Менә бит ничек газаплаганнар бөек талант иясен. «Бөек» дип көлеп әйтүем түгел. Үзе турында ул Свердловскига язган хатында: «Минем бер иҗат җимешем генә дә бөек Ванкер двигателеннән шәбрәк иде», — ди.

Габидуллинның бер уйлап табу җимеше чыннан да кабул ителгән. Димәк, ул чыннан да башсыз кеше булмаган дигән сүз. Шактый файдалы эшләр эшли аласы булган икән дә бит... Әмма аның якты башы бөтенләй башка юнәлештә уйлаган. Талап итү белән үк аңа, үзе әйткәнчә, Эдиссон, Томас, Ванкерга тудырылган уңайлы шартлар, мөмкинлекләр тудырырга тиешләр кебек тоелган. Габидуллин, бөтен дөнья-сын тирги-тирги, үз файдасын кайгыртып йөргән.

Беләбез, кыенлыклар да, авырлыклар да кичерде совет халкы. Ләкин ул кыенлыкларны җиңә-җиңә, халык илнең индустриаль куәтен арттыру өчен армый-талмый көрәште. Габидуллин башта ук үзенә бер үзгә юл сайлаган.

Бер карашка нәни генә күренгән эгоизмның куркыныч ягы да шунда шул — бер шытып чыкты исә, чүп үләне кебек ашкынып үсәргә омтыла ул. Эгоизм характер сыйфаты гына түгел. Дөньяга караш ул. Үзгә караш. Безнең социалистик җәмгыятькә дошман караш. Шуны ачар өчен фәкать уңай шартлар көтеп кенә ята торган хәтәр сыйфат.

Габидуллин Бөек Ватан сугышына кадәр үк туган илендә үз көнеләнә хуш килә торган бер генә нәрсә дә күрә алмый. Күп еллар үткәч, яшьлегендә откан җырларын хәтеренә төшерә. Аларны хатларына яза. Ләкин шул заманда җырланган гүзәл җырларның берсе генә дә хәтерендә сакланмаган. Һади Такташ «Түн трагедиясе» исемле сатирик шигырь яза. Габидуллин шагыйрь исемен дә, шигырь исемен дә оныткан. Әмма эчтәлеген хәтерли. Әлбәттә, үзенчә төп мәгънәсеннән аерып, үз агуын салып үзгәртеп кабатлый. Ул үзенең эшләгән вакытларыннан фәкать тискәре, кара вакыйгаларны гына исендә калдырган. Хәтта дәлилгә китерер өчен бер генә матур вакыйга да таба алмаган. Һәм бу хәл аңлашыла да. Аның күңелендә сакланган хатирәләр арасында шатлык, тантана белән бәйләнгәннәре булмаган. Чөнки Габидуллин кебек кешеләрнең шатлыгы андый зур масштабларга чыга алмый. Тантаналар аның өчен булмаганнар. Шуның өчен ул вакыйгалар күптән хәтереннән юылганнар. Мәңгегә онытылганнар. Әмма усаллык, башкалар бәхетсезлегенә сөенү хисе тирәнлекләре, куәтләре белән үзләренә бәйле булган вакыйгаларны бик яхшы саклаганнар.

«Бәлки мин үзем гаепле булганмындыр. Мин кешеләр белән аралаша алмадым», — дип, бик дөрес яза ул үзе турында. Әмма анда да Ильяс Абдулла үзе гаепле түгел икән: «Безне мәктәптә ул эшкә өйрәтмәделәр», — ди.

Кыскасы, Габидуллин үзен бөтен куркәмлеге белән ачу өчен уңай шартлар гына көтеп ята.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Габидуллинны командирлар курсына укырга алалар һәм ул аны тәмамлый.

Әмма, кирәк бит, фронтта да аңарга гел яман кешеләр генә очрап тора. «Курстан кайберәүләрне тылга озаттылар. Хәрби дәрәҗәләре күтәрелде. Ә мине алгы сызыктагы батальонга җибәрделәр», — дип зарлана ул Свердловск каласына язган хатында. (Бу хатта «Минем әсирлеккә төшүемнең тарихы» дигән махсус бит бар.)

Менә бит ничек. Тагын җәберләгәннәр бәндәне. Тылга башкалар белән озаткан булсалар, Габидуллин әллә Габидуллин булып калган да булыр иде. Әмма миномет-тан, автоматтан атып торган урынга барып керү аның планнарына һич кенә дә туры килми. Ул эчтән мыгырдый-мыгырдый гына булса да, алгы сызыкка китәргә мәҗбүр. Ә анда — сугышырга кирәк.

Аның «якты башы» ашкынып иҗат итә башлый: я башкалар белән бергә пуля эченә керергә, я әсир төшәргә, үзеңне саклап калырга!

Һәм ул әсир төшә.

«Мин миналар кырына килеп чыкканмын. Шуларның берсе шартлагач яраланганмын», — дип яза ул әсир төшүе турында. Бәхәсләшмик. Бәлки шулай да булгандыр. Бәлки чыннан да концлагерьда да ятып чыккандыр... Тик күптән зарыгып эзләгән яхшы кешеләрен ул нәкъ менә шунда, концлагерьда таба.

«Миңа, алланың рәхмәте төшеп, бер бик яхшы немец полковнигы ярдәм итте. Мин исән калдым. Мин аңарга хәзер дә чын күңелдән рәхмәтләр укыйм», — дип дәвам итә ул шул ук хатында.

Әмма полковник ярдәменең нәтиҗәсе турында сөйләгәндә, төрле цитаталар, җырлар аша кинаялап алдалый — күзгә томан җибәрә башлый.

Габидуллин — Ильяс Абдуллага әверелә.

Сармандагы чыбык очы туганы Хәйдәр Галәветдинов үзенә ят кешенең хатына җавапта бик табигый сорау бирә: «Әгәр үзеңне гаепсез кешегә санынсың икән, кайт, күреп китәрсең. Ник кайтмыйсың соң? Синең ил алдында гаебең бардыр, ахрысы?» — ди.

«Кайтыр идем дә, борын бозга каткан, койрык — сумалага», — дип, киная белән булса да, шактый кистереп җавап бирә Ильяс Абдулла.

Әмма койрыкның сумалага кату дәрәҗәсе дә төрле була бит әле. Шуны беләсем килеп, мин тиешле оешмага мөрәҗәгать иттем. Алар:

— Ильяс Абдулланымы? Ничек кенә беләбез әле, — диделәр миңа һәм өстәлгә бер кочак трофей документлар, хәтта немец телендә ул язган бер юка китап та чыгарып салдылар.

«Саксонияле Шломс Конрад[1] (милләте — немец, югары юридик белеме бар) допроста менә нәрсәләр сөйләгән: «Габидуллин Ильяс «Идел-Урал» легионында 1943 елның 20 маенда хезмәт итә башлады. Муллалар мәктәбен (муллашууле) тәмамлаганнан соң ул шунда ук укытырга калды. Анда полк муллалары укытып чыгаралар иде. Ул легионерлар арасында Советка каршы лекцияләр сөйләп йөрде... Муллашууледа чакта ук аны фашистлар эшкә тартты. Шулай ул «Ф-638» кличкалы агент булып китә. Бер үк вакытта Габидуллин «Татар-башкорт» легионының «1-Ц» бүлеге белән дә элемтәдә торды. («1-Ц» бүлегенең бурычлары: 1. Дошман армиясен өйрәнү. 2. Патриотик рухтагы кешеләргә каршы көрәшү. 3. Дошман гаскәре арасында сугышчанлык дәрәҗәсен төшерү һәм таркату максаты белән пропаганда алып бару иде.)

Трофей документларының берсендә — Габидуллинның шәхси агент карточкасында — бик аңлаешлы мондый характеристика бар: «Габидуллин агент эшенә бик яраклы. Бик күп кыйммәтле мәгълүматлар бирде. Ул биргән мәгълүматлар шунда ук гамәлгә ашырылдылар».

Фашистлар телендә «гамәлгә ашырылды» дигән сүзнең ни аңлатканы барыбызга да мәгълүм булса кирәк. Муса Җәлил һәм аның сугышчан дуслары турында да фашистлар «гамәлгә ашырылды» дип язып куйганнар бит.

Менә ни дәрәҗәдә каткан Ильяс Абдулланың койрыгы сумалага! Менә нинди зур ярдәм күрсәткән аңарга «яхшы немец полковнигы».

Ильяс Абдулла шушы немец полковнигына әле дә чын күңелдән рәхмәтләр укый. Ягъни Ватанга хыянәт итүен дөрес эшләренең берсе итеп саный. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Аның хыянәте тормыш сукмагының очы түгел, ә нибары бик күп борылышларның берәве генә. Тормышка караш логикасының төп сызыгы бары тик «минем өчен»нең бер чагылышы гына.

Хуш. Ә шуннан соң ул үзенең максатына ирешә алганмы соң? Бөек ачыш иясенә тыңлаешлек яңалыклар уйлап тапканмы?

«Ислам һәм Көнбатыш Германия»[2] дигән әлеге юка китабында ул, ниһаять, үзен күрсәтә алган. Анда төшерелгән һәр рәсемгә диярлек бөтенләй кирәкмәскә үзенең портретын китереп тыга, ә уйлап табу өлкәсендәге «уңышлары» турында ул үзе менә нәрсә яза. («Ильяс Габид Абдулла» исемле мәкалә): «Ул сугыштан соң исламны фәнни нигезгә салу һәм яңарту максаты белән берничә китап язган иде. Ләкин берсен дә бастырып чыгара алмады». Үзенең бу уңышсызлыкларында да ул янә дә элеккечә үк башкаларны гаепли. «Тормыш хәле авыр булганлыктан, ул (Ильяс Абдулла — А. Я.) америкалыларның УНРРА ИРО һәм АЦЛ предприятиеләрендә электрик булып эшләде. Ләкин ислам дине тоту сәбәпле, бик күп күңелсезлекләргә очрады. Хәтта сәламәтлегенә зыян китерде». (10 бит.) Таныш логика.

Бәлки кинәт чыннан да изгегә әверелеп, диндар буларак ихтирам казангандыр? Юк икән. Хөрмәт итүче кешесе дә калмаган. Сарманга салган хатларының берсендә (1973 ел, 8 февраль) болай яза: «Мине немецлар мөселман булганым өчен яратмый-

---

[1] Шломс Конрад Германия капитуляция ясаганга кадәр Дрезденда «Арбайтсгемайншафт-Туркестан»да эшбашкаручы була.

[2] И. Абдулланың бу китабы «Islam in West Deutschland» дигән исем белән Мюнхенда немец телендә басыла.

һәм алдауга гына оста».

«Мин аллаһе тәгаләнең үземне хәшәрәт җеннән саклавын эзлим», дип башлый ул китабын. Бәлки соң булса да Ильяс Абдулла канлы гөнаһларын юарга керешкәндер? Бәлки күптән, бик күптән йөрәгенә кереп утырган җенне соң булса да куып чыгарырга ниятлидер? Ләкин китаптагы әлеге җөмләне дәвам итик: «Фәкать чын ислам кабул иткән халыклар гына... кешелекне һәлакәттән коткарып кала ала... Минем фикеремчә, моның өчен, беренче чиратта, немецлар, руслар һәм кытайлар ярыйлар. Ислам динен кабул итәргә баш тартсалар, тормышка карашы буенча дөрес юлдан китәчәк яңа милләт төзергә кирәк булачак».

Әнә бит нәрсәдән гыйбарәт икән Ильяс Абдулланың дин өлкәсендәге яңалыгы! Немецлар белән кытайларны аның гомумилек буявы төшерү өчен генә атавын искә алсак, төп фикере Советлар Союзы халыкларының дөньяга карашларын үзгәртү максаты кала.

Ләкин бу «яңалыкны» Советлар Союзының кан дошманнары Бөек Октябрь революциясенең икенче көнендә үк уйлап чыгарганнар иде бит инде. Чит илләрдә төрле почмактан «Азат Европа», «Азатлык», «Би-би-си» кебек дистәләрчә радиостанцияләр, фәкать шул максатны гына күздә тотып, гомерләре буена җыен тузга язмаган ялганнарны лыгырдыйлар. Юк, һичнинди яңалык уйлап тапмаган Ильяс Абдулла. Бар хикмәт шунда ки, ул күп еллар буена ЦРУ акчасына яшәп килгән «Азатлык» радиостанциясенең татар-башкорт редакциясе редакторы Шиһап Нигъмәтинең [1] ара-тирә биргән вак-төяк йомышларны үтәп тамак туйдыра. Шуның җырын җырлый да. Изге булып кыланулары да, динне яңарту турында сөйләнүләре дә шул җырның бер сюжеты гына.

Хәзер, яше олыгайгач, вак-төяк йомышлар да тәтеми башлаган. Дөрес, ул монда үзенең бик яхшы белгән шымчылык һөнәрен дә дәвам итә. Ләкин күпме генә тырышса да, элеккеге сизем дә, күзләр дә юк инде. Эшнең нәтиҗәсе шаптан түгел. Ә америкалылар бары тик эшнең нәтиҗәсенә карап кына түлиләр. Картайган Ильяс Абдулла. Берәүгә дә кирәк булмый башлаган. «Мин акчаны америкалылардан алам. Ләкин алар бик аз түлиләр,— дип зарлана ул Сарманга язган хатында.— Шул сәбәпле кечкенә генә сувенир да җибәрә алмыйм. Гафу итәрсез дип уйлыйм. Хатыным да юк, балаларым да, торыр урыным да. Мин үзалдыма куйган максатларымның берсенә генә дә ирешә алмадым. Германиядә яшәгән ярты гомеремне эшсез үткәрдем. Минем яшьтәгеләргә исә монда эш юк та юк инде»,— дип өсти ул шул ук хатта.

Ильяс Абдулланың иҗат җимеше — менә шул. Үз язмышы. Сатлык җаннар язмышы.

Хәзер ул эш табуына да ышанмый. Туган иленә кайту турында да хыяллана алмый. Хәзер аны бер генә нәрсә борчый: ачтан үлмәс өчен, аз гына булса да, каян булса да пенсия әвәлисе килә. Немецлар түләмиләр, америкалылар баш тарткан... Бәлки Советлар Союзыннан чеметеп булыр...

Шуңа күрә тырышып-тырышып зәңгәр кәгазьләргә хатлар яза Ильяс Абдулла. Кәгазенең читенә үзенең фоторәсемен ябыштыра: «Мин бит сезнең элеккеге хезмәткәрегез». Күрәсезме, янәсе, сурәтемне, мин бит инде күпне күргән карт... Аллага гыйбадәт кылып кына көн күрәм... Мин бит кешеләр белмәгәнне беләм...

Ялгыша Ильяс Абдулла. Үзе белгәнне башкалар белми дип бик нык ялгыша. Элек кем булганлыгы да, ни эшләгәнлеге дә, хәзер ни белән шөгыльләнгәнлеге дә — барысы да билгеле.

**АЛЬБЕРТ ЯХИН,**
**филология фәннәре кандидаты.**

[1] Шиһап Нигъмәтинең чын йөзе турында журнал бер язып чыккан иде. Ренат Харисның «Мескенлектән килгән аваз» (1972 ел, 4 сан) мәкаләсен карагыз.

Нурихан Фәттах

# ЕРАК ГАСЫРЛАР АВАЗЫ

## «Җәнлек стиле»

Скифлар һәм скиф чоры, Алтай, Себер, Урта Азия халыкларының сәнгатендәге «җәнлек стиле» турында галимнәр күп хезмәтләр язганнар. Борынгы сәнгатьне, тормыш-көнкүрешне өйрәнүдә «җәнлек стиле» төп күрсәткечләрнең берсенә әверелгән. «Җәнлек стиле»нә бәйле рәвештә археологлар яңа культуралар ачалар, «җәнлек стиле» үрнәкләре буенча тарихчылар борынгы халыкларның аң, культура үсеше турында фикер йөртәләр... Тик менә ул телчеләр тарафыннан гына ачылмаган. «Җәнлек стиле»н калдырган халыкларны һинд-европа телле ираннар дип уйлау һәм шул карашның катып калган канунга әйләнүе тел белемендә «җәнлек стиле»нең табылмавына төп тоткарлык булып тора. Чөнки иран телләре ярдәмендә скиф, массагет кебек атамаларны гына түгел, бәлки гомумән «җәнлек стилен» дә аңлатып булмый. Ә бит «җәнлек стиле» төрки телләрнең канына сеңгән, һәрбер күзәнәгенә үтеп кергән! Югарыда китерелгән мисаллар аның нәкъ менә төрки телләрдә яшеренеп ятуы турында сөйли.

Телдәге «җәнлек стиле»нең ачылмавы топонимик атамаларны аңлатуда һәр төрле ялгышлар, хаталар тууына сәбәпче була. Александр Гумбольтның «Үзәк Азия» (1915) дигән китабында: «Тау тезмәләренең һәм зур елгаларның иң борынгы исемнәре һәркайда диярлек иң әүвәл бары тик тауны һәм су мәгънәсен генә белдергән», дигән искиткеч сүзләр («замечательная фраза») бар», дип яза Э. М. Мурзаев үзенең «Очерки топонимики» китабында.

Бүгенге топонимия белгечләре, чыннан да, елга һәм тау исемнәрендә бары тик тау һәм су төшенчәләрен генә эзлиләр. Һәм табалар да. Әйтик, иранча Обь та — су, Дон да — су, дәрья да — су. Төркичә су, елга мәгънәсендәге атамаларның исәбе-хисабы юк. Сай-чай-шай-тай-зәй — су, үгез — су, ман — су, ан — су, сөн — су, ык — су, идел — су; Урал — тау, Алтай — тау. Фин-угор телләрендә Кама шулай ук су дигәнне аңлата, имеш.

Болай караганда моның берние дә юк сыман. Ләкин бу принципиаль мәсьәлә. Таулар, елгалар исеме астында борынгы халыкларның

---

Ахыры. Башы 9, 10 саннарда.

аңлатмыйча торып, тарих та дөрес аңлатылмаячак.

Тауларга, елгаларга исем куша алу дәрәҗәсенә күтәрелгән кешенең суны — су дип, тауны — тау дип атавы, йомшак кына итеп әйткәндә, ышандырмый. Иҗтимагый үсешнең иң түбән баскычында торган кеше дә, хәтта кыргый булуына да карамастан, беркайчан да алай беркатлы булмаган. Ул, елганың сумы-түгелме икәнлеген тикшереп торудан элек, аны **минеке** дип игълан иткән һәм үзе яулап алган яңа җиренсуын ничек тә кулыннан ычкындырмаска тырышкан. Хәзерге заман фәне исбат иткәнчә, хәтта кыргый хайваннарның да үзләре генә били торган территорияләре бар.

Җир йөзендәге бик күп елгаларның, тауларның, катау-кандларның исемнәре менә шул **минеке** һәм **безнеке** принцибында барлыкка килгән дә инде. Бүгенге көндә сакланып калган борынгы топонимик атамаларның күпчелеге элекке ырулар, кабиләләр исеменә туры килә. Эт-ил (Идел) мисалында без моны күреп үттек инде. Без телгә алган башка бик күп атамалар да, елга-су исеменә әверелүдән элек, теге-бу ыруның, кабиләнең биләмәсен белдерүче атама — ыру-кабилә атамасы булган. Ләкин Урал атамасын, мәсәлән, без Курал дигән ниндидер җәнлек исеменнән чыгарабыз икән, бу әле барлык Урал тау тезмәсе дә Курал ыруының яисә кабиләләр берләшмәсенең биләмәсе булган дигән сүз түгел. Хәзерге Уралның ниндидер бер төбәгендә Куралга табынучы ниндидер ыру-кабилә яшәгән дип, бөтен тауга карата Курал атамасы соңгырак чорда һәм икенче төрле шартларда кулланыла башлагандыр дип фараз кылу дөресрәк булачак. Зур елгаларның исемнәре дә шулайрак барлыкка килгән булырга тиеш.

Бер урыннан икенче урынга күченә-күченә терлек асрау һәм шул рәвешчә мал-туар санын, димәк, азык запасын арттыру мөмкинлеге бары тик атны кулга ияләштергәч һәм аны йорт малына әйләндергәч кенә барлыка килә. Атны кулга ияләштерү һәм күчмә тормыш белән яши башлау үз заманында иң зур прогрессларның берсе була. Атка атланган кораллы кеше, усал күршеләреннән һәм һәр төрле ерткычлардан курыкмыйча, шул ук вакытта төп байлыгы — мал-туарын да исәнимин саклап, ерак җирләргә барып чыга, элек файдаланылмыйча яткан болыннарны, көтүлекләрне үзләштерә. Яңа гасыр кешесе яңа шартларга яраклашырга мәҗбүр була. Ул арба өстенә утыртылган җиңел өй — киез өй уйлап таба.

Атны берәүләр иң элек Үзәк Азиядә, я булмаса җылы климатлы Урта Азиядә, икенчеләр Көньяк Урал белән Каспий һәм Урта Азия арасындагы далаларда кулга ияләштергәннәр һәм йорт хайванына әйләндергәннәр дип уйлыйлар. Хәзер инде ышанып әйтергә була: беренче булып атны **төркиләр** йөгәнләгәннәр. Төркиләрдә ат изге санала. Алар атны корбанга чалалар. Массагетлар, мәсәлән, атны кояшка багышлыйлар һәм иң җитез аллага иң җитез хайван корбан ителәргә тиеш дип уйлыйлар. Атларны һәм ат тарихын яхшы белүче В. О. Витт: бары тик атны кулга ияләштергән халыклар гына атны корбанга чалганнар, дигән фикер әйтә [1]. Көньяктагы, төньяктагы, көнбатыштагы, көнчыгыштагы барлык утрак һәм күчмә халыкларны ат җигәргә, атка атланып йөрергә төркиләр өйрәтәләр. Атка атланган килеш сугышу алымын беренче булып төркиләр кулланалар һәм атлы сугыш, атлы гаскәр мәсьәләсендә күп төрле яңалыклар башлыча төрки халыклар арасында барлыкка килә. Тыныч хезмәттә һәм хәрби максатларда ат көченнән файдалану өч-дүрт мең ел эчендә бөтен җир йөзенең төсенкыяфәтен үзгәртә һәм кешелекнең үсешен тизләтә. Шулай ук башка кайбер хайваннарны да, күрәсең, беренче буларак «Азия балалары» —

---

[1] С. А. Плетнева. От кочевий к городам. Мәскәү, 1967 ел, 176 бит.

мә төркиләр җәнлек, кош-корт, балык, елан, бөҗәк атамаларына һәм сурәтләренә нигезләнгән оригиналь «язу системасы» булдыралар.

Балалар бакчасында кечкенә шкафларның капкачларына ябыштырылган төрле рәсемнәрне күргәнегез бармы? Хәреф таный белмәгән балалар үзләренең кием шкафларын буташтырмасын өчен, берсенең капкачына — гөмбә, икенчесенекенә — алма, өченчесенекенә — куян һ. б. рәсемнәр ябыштырылган була. Борынгы төркиләрдә ыру-кабилә мөнәсәбәтләре чәчәк аткан вакытта барлыкка килгән «җәнлек стиле» дә менә шундыйрак «язу системасы» ролен үтәгән. Төсе-бите, киеме-салымы, теле белән, күчмә тормышы белән бер-берсенә охшаган күп төрле, күп санлы ыруларны бер-берсеннән ничек аерырга? Аларның ырулар, кабиләләр берләшмәсендәге урыннарны, дәрәҗәләрен ничек билгеләргә? Бит һәр төрле погоннар, орденнар, титуллар, мундирлар соңгы гасырларда гына барлыкка килгән. Кабиләләрне, ыруларны бер-берсеннән аеру кирәклеге бигрәк тә сугыш вакытларында үзен сиздергән.

Төрки халыкларның телендәге, дини идеологиясендәге, сәнгатендәге «җәнлек стиле»н мин шулайрак итеп күз алдына китерәм.

Бу «язу системасы», бу «стиль» өч баскычлы булган, ахрысы. Беренче баскыч: һәр ыруның үз онгоны — табыну кошы һәм тамгасы була. Икенче баскыч: ырулар берләшмәсе (кабиләнең) барлык ырулар өчен уртак эмблемасы — шулай ук табыну җәнлеге була. Иң югары баскыч: кабиләләр берләшмәсе (илнең, дәүләтнең) барлык кабиләләр өчен изге абасы — мифик ата-анасы була. Сакал дигән ерткыч (эт), әйтик, барлык скифлар өчен изге аба булса, бүре Аш барлык Алтай төрекләре өчен изге инә (аба) булган.

Менә мондый өч баскычлы дәрәҗә елан культында аеруча нык чагыла. Елан — бар нәрсәгә тереклек бирүче иң югары алла Яшен (Бабай) символы һәм шул ук вакытта барлык төркиләр өчен уртак аба булган. Юха елан һәр вакыт өч башлы. Бу исә борынгы төрки иерархия системасының өч баскычка һәм өч терәккә нигезләнүен белдерә. Скифларның Геродот язмасындагы легендаларын хәтерлик: Таргитайның өч углы була, тау куышындагы елан-хатын өч угыл таба. Сөннәрдә дә, Урта Идел буе болгарларында да аксөяк ырулар өчәр була. Мифик Нухның да Хам (Кам?), Сам һәм Яфет исемле өч углы була. Монда тагын: өч таган таймас, тайса берсе дә калмас, дигән мәкальне дә искә төшерү урынлы булыр. Нәрсә ул **өч таган**? Моны соңыннан ачыкларбыз. Хәзергә шуны гына әйтә алабыз: «өч баш» теориясе ул өч баскычлы дәрәҗәне һәм өч терәкне генә түгел, гомумән бердәмлекне дә гәүдәләндергән.

## Ай күрдем аман белән

Дингә ышанучы барлык кешеләр (барлык дин вәкилләре) барлык чорда алланы бар дип һәм аны күктә яши дип уйлаганнар. Күккә карап дога кылганнар, иң авыр һәм кыен вакытларында күктән ярдәм һәм юату көткәннәр. Борынгы Сумер патшалары һәм Мисыр фиргавеннәре һәм гомумән барлык патшалар, ханнар, каганнар, императорлар, корольләр күктәге алланың «җирдәге уллары» булганнар. Үлгәч барлык изге кешеләрнең җаны күккә аша, яманнарныкы — җир астына төшә дигән караш була: янәсе күктә — оҗмах, җир астында — тамуг. Төркичә оҗмах **очмактан**, ягъни күккә **ашудан** үзгәргән. **Тамуг** та төрки сүз.

Төркиләрнең бердәнбер «исән» аллалары тәңре дип атала. **Тәңре** сүзен галимнәр **күк** мәгънәсендә аңлыйлар һәм **диңгер-диңгез** сүзеннән

чыгаралар. Борынгы Сумердә дингез **дингер** дип аталган. Дингер-дингез — күкнең капма-каршысы, һәм алла да күктә яисә дингездә генә булырга мөмкин. Гарәпчә дип уйланылган дин сүзе менә шушы дингер-дингез сүзенең беренче иҗеге булса кирәк. Тик шулай да тәңре дингердән алынмаган.

Безнең тагын **кот** дигән нәрсәбез дә бар. Моны гадәттә **җан** сүзенең төркичәсе дип аңлаталар. Җан, имеш, фарсы сүзе. Ә чувашча ул **чун** дип атала икән. Чувашларга мөселман дине кермәгән, фарсылар белән алар җан-чун алышыр дәрәҗәдә аралашмаганнар. Чувашлардагы менә шундый чун сыман сүзләрне аңлатканда, гадәттә аларны татардан кергән дияргә яраталар. Ләкин җанның, чунның нәселе ерак Ираннан түгел, үзебезнең **сан**нан башлана. Бүгенге телдә дүрт **саным төгәл** дигән хикмәтле сүз бар. Таза, сау-сәламәт кешенең дүрт саны төгәл була. Дүрт сан — ике аяк, ике кул. Баш монда исәпкә керми. Аяк-кулны борынгы кеше җанлы дип, ниндидер магик көчкә ия дип уйлаган.

Шулай итеп, **сан** ниндидер **җанлы**, изге нәрсә булып аңлашылган. Бүгенге телдә **сан**ның күп төрле мәгънәләре мәгълүм. Әдәпсез, тыйнаксыз кешегә **сансыз!** диләр. Санлы кеше, димәк, әдәпле, яхшы кеше була. **Җан, җаным** нигездә уңай мәгънәдә кулланыла. Бик яхшы, матур әйбергә **җан кебек!** диләр. Сан үзенең гади, прозаик мәгънәсендә аяк-кулны белдерсә, җан кешенең үзендә яшәүче **изге рух**ны белдерә. Сан үзе чынында **кош** дигән сүз. Сандугачтагы **сан** менә шуның бер мисалы. Шонкар-сункардагы **шон-сун** да, **сөн** дә әлеге сан оясына карый. **Сан**ның **т** варианты **тан**, ягъни **таң** булачак!

Санның тагын **сын** дигәне дә бар әле. Ул да кешедә яши. Кешегә суккач кинәт ул телсез-өнсез калса, **сыны катты** диләр. Сын, димәк, имгәнергә, хәтта үләргә дә мөмкин. Санның игезәге **җан** булса, сынның (дөресрәге, сөннең) игезәге **җен** булачак. Халык аңында **җен** бер генә төрле түгел. **Җен кебек!** дигәндә **җен** уңай мәгънәдә килә. **Җене котырган, җене кузгалган** дигәндә кире мәгънә төсмерләнә. **Җен-пәри** дигәндә инде ул бөтенләй кире тип.

Шулай да **кот** нәрсә соң? Бүгенге телдә: **котлы, котсыз, котлау, котым очты, котым ботыма җитте** һ. б. сүзләр бар. Котым очтыда котның төп мәгънәсе ачык төсмерләнә. Кот ул оча торган кош булган. Нинди кош дигәндә, мин аны **бөркет** булган дип уйлыйм. **Бөр-бүр** тамырын (**бүре** дигәндәге сыман) ак, изге, бөек дип беләбез. **Кет-кот — кот-кут**ның нечкә әйтелеше. Бөркет сүзенең мәгънәсе: ак, изге, бөек **кот** булачак. Котым очты дигәндә, кот кешенең эченнән очып чыгып киткән кебек аңлашыла. Котым ботыма җитте дигәндә дә кот кешенең боты буенча шуышып төшкән сыман тоела. Ләкин бу беренче карашка гына шулай. Кот очу ул өйдән очып чыгып киткән котны белдерә. Өйдән кот очса, бәхет китә. Котым ботыма дигәнне **бодыма** дип аңларга кирәк булачак. **Бод** — гәүдә, тән. Ул минем **башыма җитте** дигәндәге кебек, кот та (очып чыгып киткәч) бодыма җитте, мине бәхетсез итте, мине ташлап чыгып китте булачак.

Кот (бөркет) шулай итеп кешенең эчендә түгел, аның янәшәсендә, аның өендә булган. Кот чыгу куркуны гына белдерсә, **җан чыгу** үлүне белдерә. Мәсәлән: җаны чыкты, җан бирде, җан тәслим кылды, һ. б. Кот, күрәсең, һәрбер өйдә булган һәм булырга тиеш булган. Коты булмаган өй нурсыз, бәхетсез, ярлы өй саналган. Кот сүзе **кос-кош**ның икенче төрле әйтелеше генә. Кос-кош үзе, белгәнебезчә, кор-кур оясыннан очып чыккан — менә без тагын изге ояга кайтып төштек. Кот ул, кайберәүләр уйлаганча, тормышның башлангычы, орлыгы, яралгысы түгел, бәлки сакчы кош, изге кош — бөркет дигән сүз булачак. Абул Гази огузлардагы 24 ыруның «онгон»нарын **кош** дип атый. Һәрбер ыру-

ның үзенең сакчы рухы, изге кошы — **бүз коты** бар. Һәм аларның барысы да — ертҗыч кошлар.

Бөркетнең төркичә берничә төрле атамасы мәгълүм. Төрекчә ул, мәсәлән, **доган** дип атала. Менә бу доганнан **дога, дага, дуга** сүзләре ясалган. «Кыпчак телләре» дип аталган төрки телләрдә доган-**тоган, туган** булачак. (Ләкин сандугач дигәндәге **дуг** иҗеге бездә дә кайчандыр **доган** булуы турында сөйли.) Шулай итеп, безнең гап-гади **туган** сүзебез **бөркет кош** булып чыга. Урта гасырларда байракны төркиләр **туг** дип атаганнар. Байрак хәзер дә кайбер төркиләрдә (мәсәлән, казакъларда) **ту** дип атала. Бу туг-ту, күрәсең, чын мәгънәсендә байрак түгел, бәлки озын сапка беркетелгән бөркет сурәте булган. **Токым**, туган, туг-ту гына түгел, **таган** да бөркет белән мәгънәдәш сүз. Югарыда телгә алынган «өч таган таймас, тайса берсе дә калмас» дигән мәкальдә ул нәкъ шундый мәгънәдә килә. Ачык җирдәге учак өстенә сузылган һәм ике казыкка куелган таяк та **таган** дип атала. Югары очлары бергә бәйләнгән, түбән очлары (аяклары) бер-берсеннән аерылып, җиргә терәтеп куелган өч казык та **таган** дип атала. Мондый өч аяклы таганга салам, печән ише нәрсә өяләр. Зур кибән үзәгендә дә шундый таган була. Өч казыктан торган менә бу таган-терәк борынгы кеше өенең, алачыгының нигезен тәшкил иткән. Алачыкны тотып торучы казыкларны безнең дәү бабаларыбыз доган-туган-таган дип аталган кош белән тиңләгәннәр. Өч башлы елан белән өч таганлы өй-алачык арасында тирән мәгънә уртаклыгы бар.

Һәрбер өйнең коты-кошы булган кебек, барлык өйләр, барлык кешеләр өчен уртак кот та булган. Анысы **Ходай (Кодай, Кот-ай, Кот-ас, Кур-ас)** дип аталган.

Бүгенге телдә бик борынгы дога сүзләре дә яшәп килә. Кичләрен күктә ай күренү белән, минем әни, мәсәлән, күккә карап шундый дога укый:

Ай күрдем аман белән,
Эчем тулды иман белән,
Бу ятудан торалмасам,
Кичер, Ходай, иман белән!

Айның туган көнен, тулган көнен, кимегән көнен ул белеп-тикшереп кенә тора. Аның һәрбер эше ай белән «киңәшеп» эшләнелә: айның фәлән көнендә — ярый, фәлән көнендә — ярамый. Моннан ике мең ике йөз еллар элек Сөн иленең ишханы да барлык эшләрен ай белән киңәшеп эшләгән. Яңа ай башында һәм тулы айда сөннәр яу чапканнар, башка зур эшләрен башкарганнар, ай кимегәндә берни эшләмәскә тырышканнар.

## Тоссызны күзсез дә күрә

Бүгенге телдә **төсе качкан, төсе киткән, төссез** дигән сүзләр яши. Ябык, чырайсыз, нурсыз, курыккан кешегә карата гадәттә әнә шулай диләр. Төссезнең **тоссыз** варианты да мәгълүм. Тоссыз — белексез, мәгънәсез кеше була. Тоссызны күзсез дә күрә, имеш. Тоссыз кеше начар булган, тослы кеше, күрәсең, яхшы кеше булгандыр. Төсе качкан, төсе киткән кеше ябык, чырайсыз, куркынган кеше булгач, төсе качмаган, төсе китмәгән кеше тулы канлы, яшь, чибәр, кыю булгандыр дип әйтә алабыз. Тосның **чос** варианты да исән. Чос ул уңган, тапкыр, булдыклы кеше булачак. Тоз да, туз да (тузбаш елан) менә бу төс-тос белән тугандаш сүзләр.

Төсе качкан сүзе буенча без **төснең** кемлеген ачыклый алабыз. Качканны без **очкан** сүзенең әүвәлге формасы дип аңлыйбыз. Ул чагында төсе качкан кеше — төсе очкан кеше булачак. Ягъни бу шул ук кош, кот булып чыкты.

Төснең оча торган кош булуы безнең өчен бик әһәмиятле. Төсне без югарыда төр-түр оясыннан чыгарган идек. Төр-түр оясы үзе таш-тас оясына барып тоташа. Бу оядан без **тасны** гына аерып алабыз. **Тас** тувалыларда **грифон** дигән ярым мифик кошны белдерә. Тас — изге кош. XX гасырның 30 елларында гына әле тувалылар үлгән кешеләрен авылдан читкә, далага илтеп ташлаганнар, 49 көн үткәч, мәетне кам белән бергәләп барып караганнар. Мәетнең тәнендә тас кошының эзләре булса, бу изгегә юралган һәм мәет яткан җир дә саф, арыг дип исәпләнелгән. Мәетнең тәнендә тас эзләре булмаса, яманга юралган [1].

Мәетне тасларга, төсләргә, котларга һ. б. биреп ашату белән бер үк вакытта яисә аннан соңрак шул ук изге кошларга **корбан бирү йоласы** барлыкка килгән. Корбан бирүнең мәгънәсен фәндә болайрак аңлаталар: корбан ул изге һәм яман рухларның күңелен күрү өчен бирелә. Корбан алгач, изге рухлар кешегә ярдәм итәчәкләр, яман рухлар аны тынычта калдырачаклар, юк-бар нәрсә белән борчымаячаклар.

Ник ашатырга кирәк булган соң бу «изге» кошларны? Чөнки тау башларындагы кошларны кеше Кояш һәм Айның җирдәге вәкилләре дип, ягъни кечерәк дәрәҗәдәге аллалар дип аңлаган. Дөньяда яман көчләр җиңмәсен өчен, яктылык, тереклек бирүче көчләр — Кояш һәм аның төнге вәкиле Ай **һәрвакыт яшь, тулы канлы, көчле** булырга тиеш дип исәпләнелгән.

Бөркетнең **көн-күн** дигән атамасы да бар. Акча чөеп уйнаганда тәңкәнең бөркетле ягы төшсә — **күн** була. Көн-күн сүзе күпчелек төрки телләрдә турыдан-туры **кояш** дигәнне аңлата. Татар әкиятләрендә әкият герое диңгез аша чыкканда каракошкамы, сәмруг кошынамы утырып оча. Диңгез уртасына җиткәч, кошның хәле бетә һәм «герой» үз ботыннан ит кисеп алып кошны туйдыра. Димәк, корбан бирүнең төп мәгънәсе шунда: көн дә җир өстенә чыга торган кояшның яңадан җир астына ялга төшеп җиткәнче хәле бетмәскә тиеш. Ай тотылу беткәч, кешеләрнең сөенеп: **котылды! котылды!** дип кычкырганын ишеткәнегез бармы? Татарда ай, кояш **тотыла**, руста ул караңгылык белән каплана (затмение). Ни өчен **тотыла** да, ни өчен **котыла?** дигән сорауга без инде берникадәр җавап бирдек: чөнки ул җанлы, чөнки ул — кош.

Кеше атны кулга ияләштереп аны йорт малына әйләндергәч, Кояш алласы яисә Кояш символы зур үзгәреш кичерә. Кояш алласы бөркеттән **атка** әйләнә. Ат тоягына **дага** (бөркет «тырнагы») кагу менә шул үзгәрешкә бәйле рәвештә барлыкка килгәндер сыман. «Бөркет тырнагы» — дага әле дә булса изге санала һәм аны тышкы ишек катына яисә капка баганасына кагып куялар.

Ат кыяфәтендәге Кояш алласының нindirәк булуы да мәгълүм: атның арт саны елан булып тәмамлана. Атка ниндидер кеше атланган. Ул каядыр чаба. Без югарыда күп тапкырлар телгә алган Кур-ас, Хор-ас, Хер-ос менә шул булыр инде. Шундый елан-атка атланган җайдак төшерелгән таш тәлинкәләрне археологлар Таҗикстанның көньягында, Горав-кала дигән кала-тауда да, Пакистанның төньягында Таксила хәрабәләрендә дә тапканнар [2].

Атның елан гәүдәле булуы аның гади, гадәти ат булмавын күрсәтә. Изге еланның, мең яшәр юханың татарча исеме — **курыс**. Фракияле-

---

[1] Л. П. Потапов. Очерки народного быта тувинцев. Мәскәү, 1969 ел, 381 бит.
[2] Борис Литвинский. Преодолевая Памир, Гиндукуш, Гималаи. «Курьер «ЮНЕСКО». 1974 ел, апрель-май саны, 38—45 битләр.

ләрдә атка атланган алла — Херос булган. Атның бөркет кебек үк кояш символы булуы мәгълүм нәрсә. Тагын шунысы да бар: **кояшның** да исеме **курыс-курас** бит! Кур-ас, кой-ас, кой-аш... Авазларның күчешү законы буенча, **р** белән **с** кенә түгел, **р** белән **й (е)** дә бер-берсен алыштыра ала. **Куйның** кор-кур оясыннан икәнлеген без әйтеп киткән идек инде. Шулай итеп, **куй-аш**, **кой-аш**, шул ук **кур-аш**, **кур-ас**, **хор-ас** һ. б.— болар барысы да бер оядагы «изге» сүзләр.

Көнбатыш диалектта Курас-Курыс дип аталган Кояш алласы көнчыгыш диалектта **Тәңре** дип аталган. Тәңре, якут галиме Н. К. Антонов исбат иткәнчә [1], **Таң ире**, Таң сугышчысы. Җиргә һәр көнне яктылык алып килүче батыр ир ханнар, каганнар гына түгел, бүре дә (корт та) менә шушы Тәңренең балалары булганнар инде.

Иң ахырда без скифларның **Гойтосир** дигән аллаларын искә төшерәбез. **Гой** тамырын без берниндн икеләнүсез **кой** дип үзгәртәбез. Гойтосир, белгәнебезчә, грекларның кояш алласы Аполлонга тиң. Тосны **төс** дип төзәтәбез. Төс монда алла мәгънәсендә килә. Ире — ир, бүгенгечә, нәкъ безнеңчә. Шулай итеп, Гойтосир дигән алла чынында **Кой-төс-ир** булган дип әйтә алабыз.

# КАЗАН

## Оча торган коштанмы, аш пешерә торган казаннанмы?

**Казан**ның берничә мәгънәсе бар һәм аларның күбесе безгә таныш. Безгә хәзер күп мәгънәле казан кирәкми, Казан шәһәрен аңлаткан конкрет **казан** кирәк.

Казанның кайчан салынуын, ни өчен шулай аталуын белергә тырышуның гына да кимендә өч гасырга якын тарихы бар икән.

Татарстан топонимиясен өйрәнүгә күп көч куйган Гомәр Саттаров Казан атамасын **каз кошы**на бәйле рәвештә аңлата. Кайчандыр Казан (Казанка) суы буенда **Каз** дип аталган төрки кабилә яшәгән һәм Казан елгасының да, Казан шәһәренең дә исеме шуннан алынган икән.

Формаль-теоретик яктан караганда, бик дөрес фикер бу. Бу әлеге «җәнлек стиле»нә туры килә торган теория. Ләкин шунысы кызганыч, борынгы төркиләрдә казның ыру-кабилә атамасы булуын Г. Саттаров төрки телләрдән түгел, бәлки фин-угор һәм самодий телләреннән алынган мисаллар белән исбат итмәкче була. Дөрес, кайбер төрки халыкларда Казаяк, Казаяклы ырулары булган булуын, тик шулай да Казаяк, Казаяклы ырулары мисалында гына Каз ыруы яисә Каз кабиләсе булуын исбат итеп булмый. Ни өчен? Чөнки Казаяк, Казаяклы инде саф **каз**дан гына тормый — аларга **аяк** кушылган. «Җәнлек стиле»ндәге борынгы төрки ырулар, кабиләләр исеме бөтенләй икенче төрле принципта төзелгән. Мәсәлән, башкорт, болгар, сакмар, массагет дигәндә атама үзе дә, аның аерым кисәкләре дә нинди дә булса җәнлекне, җанварны аңлата. Казаяктагы аяк сүзенең җәнлек, җанвар, балык, кош мәгънәләре юк.

Шулай итеп, Казаяк, Казаяклы атамаларында «җәнлек стиле»нең формасы бозылган һәм, димәк, аның эчтәлеге дә әлеге стильгә туры

---

[1] Филология фәннәре кандидаты Марсель Бакиров мәгълүматы.

килми. Аннары, Казаяк һәм Казаяклы ул гомумән Каз атамасына тәңгәл килә алмый.

Шулай да нинди каз һәм нинди Казан соң бу? Әлеге **каз** без тикшергән **кор-кур** оясыннан түгел микән? Билгеле, шул оядан булачак... әгәр ул оча торган **кош** булса һәм **ашарга** яраклы каз булса. Әйтергә кирәк, борынгы төркиләрдә каз да изге саналган. Ибн Фадлан заманында башкорт ыруларының берсен, әйтелгәнчә, сугыш вакытында кычкырган торналар коткарып кала һәм шуның өчен әлеге ыру торналарга табына башлый.

Конкрет тарихны, конкрет җирлекне исәпкә алмаганда, безнең Казандагы **казны** да менә шул «изге», сугышчан казлар чорына илтеп ялгарга булыр иде, әлбәттә. Ләкин безнең Казан белән скифлар чоры казлары арасында күп гасырлар белән билгеләнә торган зур вакыт арасы ята. Һәм без моны исәпкә алмый булдыра алмыйбыз.

Тарихчы Альфред Халиков каз тамырлы географик атамаларның төрки халыклар биләгән яисә яшәгән территорияләрнең чик буйларына урнашуына игътибар итә һәм каз сүзе, күрәсең, **чик, кырый** мәгънәсен белдерәдер дигән фикергә килә. Казанның һәм каз тамырлы башка кайбер атамаларның этимологиясен аңлатуда бу принципиаль яңа караш булып тора. Альфред Халиков сүзнең тышкы формасыннан бигрәк аның эчтәлегенә күз сала һәм, гасырлар буена беркем күтәрә алмаган серле пәрдәне күтәреп, күп кенә буталчык мәсьәләләрне чишәргә юл ача.

Каз сүзенең чынлап та чик мәгънәсе бармы һәм булса, каян килгән аңа шундый «тузга язмаган» мәгънә? Барлык төрки сүзлекләрне карап чыксагыз да, сез аларның берсендә дә каз сүзенең чик, кырый мәгънәсенә ишарәле торган аңлатма таба алмассыз. Ләкин казның **кас, каш, кач** вариантлары да бар ич әле! Тик монда бер искәрмә ясап китәргә туры килә — без башка бүлекләрдә тикшергән бүре, ерткыч мәгънәсендәге кас-кашларны монда онытып торырга кирәк булачак. Чик мәгънәсендәге каз-кас-кашлар ерткыч, бүре мәгънәсендәге кас-кашлар белән туганмы-түгелме — әлегә без анысын хәл итмибез. Чик мәгънәсендәге кас-каш ерткыч кас-кашның туганы булган очракта да, ул инде беренче мәгънәдә түгел, бәлки икенчел, хәтта өченчел мәгънәдә булачак.

Урта гасырлардагы төрки телләрдә **каш** кырый җирне, яр читен, калку җирне һәм **чик** буен аңлаткан (ДТС, 431). В. В. Радлов сүзлегендә дә кашның **кас** варианты: калку җир, кырый җир, **чик**, зур елга яисә диңгез яры, калкулык, балчык өеме мәгънәләрендә күрсәтелгән (Рдл, 11, 345). Шул ук сүзлектә тагын **качы** дигән сүз дә бар. Бу качы су басуга каршы өелгән балчык өемен (дамбаны) белдергән.

Димәк, **каш** сүзе кайчандыр элек **чик, кырый, дамба** мәгънәләрендә дә йөргән икән. Хәер, элек кенә түгел, бүгенге көндә дә **каш** шундыйрак мәгънәләрне аңлата түгелме соң? Татар телендә каш, мәсәлән, күз өстендәге кашны да, калкулыкны, тау битендәге ачык (кашлак) җирне дә белдерә. Хәтта күз өстендәге каш үзе дә шул ук чик сызыгы лабаса инде!

## Атым юк аранда

Каш-кас-каз тамырының чик мәгънәсендә килгән очракларын без бүгенге телдәге башка сүзләрдә дә очрата алабыз. **Кәс** яисә **кәз** дигән сүз бар. Бу — җирнең өсте, чирәмле катламы була. Кәс-кәз — каскаэның нечкә әйтелеше һәм бу сүз нигездә җирнең тышчасын, сүрүен, димәк, шулай ук чиген-кырыен белдерә. «Борынгы төрки телләр сүзлеге»ндә **касның** беренче мәгънәсе: кора, кожура (каеры, кабык) дип би-

релгән (ДТС, 430). Нәрсә ул каеры яисә кабык? Агачның, үсемлекнең, җимешнең тышы, «күлмәге» һәм, әлбәттә, чиге, кырые!

Мәгълүм булганча, Идел буе болгарларының телендә берничә диалект булган. Бер диалектка **«з»**ләштерү, икенчесенә — **«р»**ләштерү хас. Моны без Казан сүзе мисалында да ачык күрәбез. Казан сүзенең элек **каран** формасы да кулланылган. Караннан берникадәр читкә авышкан кыран чуваш теле диалектларында **чик, ызан** мәгънәсен белдерә. Каранның татар телендә **аран** варианты бар. Аран — ат абзарындагы бүлем. Дөрес, аран монда турыдан-туры чикне түгел, **чикләүне** аңлата. Ә менә аранның **з** варианты **азан** вакыт чиген күрсәтсә, азанның игезәге **ызан** җир өстендәге **чикне,** чик сызыгын белдерә.

Мичнең чирек кирпеч киңлегендә чыгып торган сырын хәтерлисезме? Менә шул чыгынты телдә **кучкар** дип атала. Ләкин мичнең куеңлы төше дә кучкар була. Кучкардагы **кар**ны без аерып куябыз һәм **каз** дип үзгәртәбез. Казны чик дип аңлаганда, кучкар мичнең чиге, чик сызыгы булырга тиеш. Ләкин мичнең нинди чиге булыр икән? Моны аңлау өчен безгә беренче иҗек **куч**ны сүтеп, таркатып карарга туры киләчәк. Куч, бәлки, **куз**дыр ул? Куз исә утлы күмер булачак. Бүгенге телдә **ут-күз** дигән парлы сүз бар. Менә бу парлы сүздәге **күз** әлеге куз (куч)ның нечкә әйтелеше инде ул. Кучның къ авазын алып ташласак, **уч** кала. **Учка** ак(ык) кушсак, һәркемгә мәгълүм учак сүзе килеп чыгачак.

Димәк, учак сүзе куч-куз тамырыннан ясалган һәм кайчандыр **кучак** дип аталган. Куч(ак)кар сүзенә килгәндә, ул чыннан да учакның (борынгы мичнең) чиген, кырыен аңлаткан булырга тиеш. Бит элекке заманнарда хәзерге кебек кирпечтән өеп мендерелгән мичләр булмаган. Ут-учак туп-туры идән уртасында яисә берәр почмакта янган. Ут-күз чыкмасын өчен учакны таш беләнме, катырылган балчык беләнме чикләп куйганнар. Менә шул кучкар дип аталган һәм кучкар термины кирпечтән өелгән мичкә дә ягылып калган.

Шушы уңайдан **аш пешерә** торган казан турында да бер-ике сүз әйтеп китик. Бу казанның әүвәлге формасы казан түгел, **кузан** булгандыр кебек. Ягъни бу кузга (утка) куела торган **ан**ны (нәрсәне) белдергән булып чыга.

Монда шул нәрсә ачыкланды: каз тамыры ан белән дә, ансыз да чик төшенчәсен белдерә ала икән. Мондагы **ан** инде без белгән ерткыч **ан** түгел, әлбәттә. Ул конкрет йөзен, мәгънәсен югалткан формаль кушымчага әйләнгән.

Мәсьәлә ачык: каз яисә казан сүзе X—XI гасырларда (бәлки аннан элегрәк тә) төркиләр телендә чик мәгънәсендә кулланылган. Башта, әлбәттә, чик буендагы елганы Казан дип атаганнар. Казан елгасы буенда, чик буе ныгытмасы буларак, Казан каласы барлыкка килгән.

## Каз-казан җирдә кемнәр яшәгән?

Казан турындагы бу кечкенә язмага шушы урында нокта да куярга мөмкин булыр иде, ләкин, нокта куйганчы, кайбер нәрсәләрне ачыклап китәсебез бар. Мәсьәләнең иң зурысы шул: моннан мең еллар элек бу Казан суы буенда, дөресрәге Кама-Чулманның уң ягы белән Казан елгасының сул ягы арасындагы киң территориядә (Татарстанның төньяк-көнчыгыш өлешендә) кемнәр, ягъни нинди болгарлар яшәде икән?

Г. Саттаров бу сорауга ап-ачык итеп: бу җирдә Каз дип аталган төрки кабилә яшәгән һәм мондагы Казиле, Казанбаш, Кариле, Казан кебек авыл, елга, шәһәр исемнәре дә менә шул Каз кабиләсенә бәйле рәвештә барлыкка килгән дип җавап бирә. Мин дә, Г. Саттаров фике-

рен яклап, әлеге территориядә **Каз кабиләсе** яшәгән дип әйтмәкче булам. Ләкин, югарыда күреп үткәнчә, безнең каз — кош түгел. Безнең Каз кабиләсе — **Чик буе** кабиләсе. Чик буе кабиләсенең нәрсә икәнлеген тулырак күз алдына китерү өчен безгә борынгы төрки җәмгыятьләрдә җир биләү тәртибе белән танышып китәргә туры киләчәк.

Хәзерге замандагы кебек, элек тә хуҗасыз җир булмаган. Борынборыннан килә торган йола һәм түрә буенча, җир биләү хокукы төркиләрдә ыру кулында булган, ягъни җир хосусый милек булып түгел, бәлки ыру милке булып саналган. Кабилә-ыру җирендәге барлык нәрсә: таулар, урманнар, елгалар, күлләр — барысы да уртак милек булган һәм күп кенә атамалар, югарыда әйтелгәнчә, шул нигездә барлыкка килгән. Җирне ыру-кабилә (коллектив) белән биләү тәртибенең калдыклары татарларда XX гасыр башларына кадәр сакланган (мәсәлән, революциягә кадәр җир авыл җыены кулында булган һәм җир бүлүне авыл җыены башкарган).

Шул рәвешле, безне кызыксындырган Казан елгасы да, хәзерге Татарстанның төньяк-көнчыгышындагы башка барлык елгалар, күлләр, урманнар, таулар да, әлбәттә, Каз иленең (кабиләсенең) милке саналган. Мондагы **каз-кар, каш** тамырлы атамалар нәкъ шул турыда сөйли. Шулай итеп, Болгар дәүләтенең марилар белән чиктәш җирләрендә (хәзерге Казан артында) Каз иле яшәгән. Каян килгән андый кабилә (ыру) бу якларга һәм гомумән нинди кабилә-ыру булган ул Каз иле?

Без моны ике төрле аңлата алабыз. Беренчедән, әлеге җирләр, дәүләтнең чик буе территориясе булганлыктан, башта ук **каз җир** янсә Каз иле җире дип һәм мондагы халык та Каз иле кешеләре дип аталган булырга мөмкин. Икенчедән, Болгарның ачык дала җирләрендә куркыныч яулар булган саен, халыкның күпмедер өлеше, яудан-үлемнән качып, шушы чик, кырый җирләргә омтылган һәм дәүләтнең чик буе территориясендә болгар качакларыннан (бәлки хәтта болгарларга кадәр үк!) әкренләп-әкренләп Каз иле (ыруы-кабиләсе) кешеләре оешкан. Яу вакытларында дәүләтнең көньяк, көнбатыш якларыннан бу җирләргә әледән-әле төркиләрнең күченеп килүләре тарихи фактлар белән да раслана. Болгар башкаласы Биләр җимерелгәннән соң XIV—XV гасырларда политик үзәкнең төньякка — Казан шәһәренә күчүе һәм Казан ханлыгы оешу нәкъ менә шул туктаусыз яулар аркасында халыкның күпләп Кама аръягына качып китүе белән аңлатыла да.

Бер халык белән икенче халык, бер дәүләт белән икенче дәүләт арасында бик борынгы заманнарда ук чик төшенчәсе, әлбәттә, булган һәм гадәттә зур елгалар, таулар, чүлләр ике арада табигый чик сызыгы ролен үтәгәннәр. Ләкин дошман гаскәрләрен табигый чик сызыклары гына туктатып тора алмаган. Шуңа күрә дәүләт чигенең аеруча тынгысыз өлешләрендә ил башлыклары күп санлы чик сакчылары тотканнар. Элекке заман чик сакчыларын хәзерге заман чик сакчылары кебек итеп күз алдына китерергә ярамый, әлбәттә. Элекке чик сакчысы чик буе җирендә (илендә) үзенең мал-туары, хатыны, бала-чагалары белән бергә яшәгән. Дәүләт башында торучылар чик буена гадәттә аерым ыруларны, кабиләләрне күчереп утыртканнар. Бу эш сугышта җиңелгән һәм буйсынган **кара** ыруларга (сөякләргә), я булмаса яллаңып хезмәт итүчеләргә йөкләтелгән. Чик буен саклау иң авыр, иң куркыныч, тынгысыз хезмәт саналган, ләкин шул ук вакытта кеше (сугышчы) монда үзен күпмедер дәрәҗәдә ирекле сизгән, чөнки күп очракта ул һәр төрле түләүләрдән, салымнардан азат ителә торган булган. Борынгы Кытайда (мәсәлән, Чин, Хань династияләрендә) төрле җинаятьчеләрне чик буена сөрергә хөкем итә торган булганнар.

Элекке төрки халыклар да чик саклауга нык игътибар иткәннәр. Артык тирәнгә кереп тормастан, X—XII гасырларда яшәгән **чигил, чик** дигән халыкларны искә төшереп үтәргә була. М. Кашгари заманында төрки халыклар яшәгән җирләрдә Чигил балык, Чигил кант дигән шәһәрләр булган. Чик сүзенең мәгънәсе бездә бернинди шик-сорау тудырмый. Чигилне без Чик-ил, ягъни Чик буе иле, Чик сакчылары иле дип аңлыйбыз. Кыскасы, Чигил шул ук Казилнең ниндидер икенче бер кабилә телендәге икенче төрле әйтелеше генә ул.

Без тикшерә торган Казан арты территориясе дә тынгысыз чикләрнең берсе булган, ахрысы, һәм шуңа күрә дә дәүләт башлыклары бу җирләрдә **чик сакчылары иле** тотарга мәҗбүр булганнар да. Әлеге җирләрдә гасырлар буена чыннан да чик сакчылары яшәвен раслый торган ышанычлы дәлил дә бар. Ул да булса — Казаклар атамасы.

## Татарстан казаклары

Татарстанның төньяк-көнчыгышында, ягъни каз-кар тамырлы атамалар күп булган җирдә **Казаклар** дигән алты-җиде авыл бар. Нинди казаклар ул Татарстан җирендә?! Хәзерге казакъ халкының бер кыйпылчыгымы алар, әллә соң Дон, Кубань, Җаек казакларының татарлашкан нәселләреме?

**Казакъ-казак** сүзе Казан сүзенә караганда да киңрәк таралган икән. Бу сүз урта гасырлардан алып бүгенге көнгә кадәр бик актив кулланыла. Иң атаклы тел галимнәре казакъ-казак сүзенең төрле чорда, төрле халыкта кулланылган мәгънә төсмерләрен барлаганнар, ачыклаганнар. Барлык атамалар да нигездә шуңа кайтып кала: казакъ-казак ул атлы, кораллы кеше; сакчы, өйләнмәгән, сукбай, җилкуар, юлбасар. Бу мәгънәләрнең һәркайсына тукталып торуның хаҗәте юк, шулай да татар телендә кулланылышта булган **казакъ** сүзенең кайбер мәгънәләрен искә төшереп үтү зыян итмәс. Казак сүзенең Радлов язып калдырган «буйдак кеше, өйләнмәгән кеше» мәгънәсе бүгенге көндә онытылган, ахрысы. 1966 елгы «Татарча-русча сүзлек»тә аның мондый мәгънәсе теркәлмәгән. Ләкин Гәйнә татарларында **казакъ** сүзе әле дә шундый мәгънәдә йөри икән. Безнең тагын **атлы казак, атлы казак кебек** дигән сүзләребез дә бар. Бер урында тик кенә басып торган, катып калган, аптырап калган кешегә карата шулай дип әйтәләр һәм күп очракта яратмыйча әйтәләр.

Казак ул төрки телләрдә иң әүвәл чик сакчысы, чик буенда яшәүче коралллы ир мәгънәсен белдергән. Башка төрле мәгънәләр аңа соңгырак чорларда өстәлгән. Шуңа күрә дә казакъ-казак нигездә буйдак, җилкуар, юлбасар, сукбай, сакчы, ирек сөюче булып танылган да. Борынгы чик сакчыларының чыннан да шундыйрак кешеләр булуын без инде бераз күреп үттек. Казак сүзенең бездә тагын **карак, качак** дигән вариантлары да бар әле. Бу карак-качак элекке чик сакчыларының нинди күркәм сыйфатларга ия булуларын тагын да ныграк ачыкларга ярдәм итә булса кирәк. Казан арты территориясендә моннан берничә гасыр элек яшәгән **болгар казаклары** да шундый ук чик сакчылары булмагандыр дип әйтергә безнең бернинди дәлилебез юк.

Соңыннан **казанлылар, казаннар** дип йөртелгән Казан халкының күпмедер өлеше менә шундый казаклардан формалашкан. Казан (татар) халкы гына түгел, хәзерге **казакъ, украин, кыргыз, хакас** халыклары да кайчандыр каз җирдә (Каз илендә) яшәгәннәр һәм гасырлар үтү белән, яңа этнос (халык) буларак формалашкан казакъ-казаклар түгелме соң?!

Татар телендә **Каф-тау** дигән бер хикмәтле сүз бар. Каф-тау дөньяның читен, беркем барып җитә алмастай ниндидер төбәген аңлата. Дөньяның чите булуына инде беркем дә ышанмый, шуңа күрә бу сүз ниндидер дини, мифик карашларны чагылдыра сыман тоела.

Ләкин ни өчен мифик соң ул? Татарларда яисә башка төрки халыкларда Каф тавына бәйле берәр миф, легенда, дини ышану бармы, булганмы? Әллә соң бу миф безгә янә дә гарәп-фарсыдан керде микән? Нишләптер бу хакта китапларда берни әйтелми. Алайса, бары тик аңлашылмаган өчен генә мифик булып чыга түгелме соң бу Каф тавы дигән тау? Һәрбер аңлашылмаган серле нәрсә мифик була аламы һәм булырга тиешме?

Каф тавының **Кавказ** икәнлеген без күптән беләбез. Мондый белем безнең аңыбызда саклана, тик безнең бу турыда ныклап торып уйлаганыбыз гына юк бугай. Кавказ атамасы белән кызыксынып киткәч, миңа П. К. Услар дигән баронның «Древнейшие сказания о Кавказе» («Кавказ турында иң борынгы хикәятләр») дигән кирпеч калынлыгы китабын актарып чыгарга туры килде. Китап 1881 елда Тифлис шәһәрендә басылган. Автор дөнья яратылган көннән алып XIX гасыр азакларына кадәрге чорда Кавказга тегe-бу яктан катнашы булган мәгълүматларны бергә туплаган. Барон Услар бик тенденциоз. «Көнчыгыш халыкларында» Каф тавы турында ниндидер ышанулар барлыгын ул да телгә ала. Ләкин бары «телгә генә ала». Аның «көнчыгыш халыклары» дигәндә кайсы халыкларны күз алдында тотуын аңлап булмый. «Көнчыгыш халыкларының» Кавказ белән кызыксынулары мөмкинлеген ул башына да китереп карамый. Шулай да П. К. Усларның Кавказ турындагы кайбер мәгълүматлары игътибарга лаек. Менә алар. Көнбатыш Азия дәүләтләре өчен Кавказ борын-борыннан **капка** хезмәтен үтәгән. Борынгы патшалар, барон Услар сүзләре белән әйткәндә, «төньяк ерткычларын» көньякка — үз җирләренә үткәрмәс өчен, Кавказ тарлавыкларын капка итеп нygытырга, сакларга тырышканнар. Борынгы греклар Кавказны Европа белән Азия арасындагы чик сызыгы дип уйлаганнар. Кавказ (Kaukasos) сүзе беренче мәртәбә Эсхилның безнең эрага кадәр 479 елда язылган һәм «Кыяга бәйләп куелган Прометей» дип аталган әсәрендә телгә алына. Европа халыкларына бу сүз греклардан күчкән. Кавказдагы җирле халыкларга Кавказ дигән гомуми атама мәгълүм түгел. Кавказ сүзенең беренче иҗегендәге **кав** (кау) иран телләрендә тауны аңлаткан кух, кох, коф, хох, хоф, гауг сүзләреннән алынган булырга мөмкин. Икенче иҗек **каз**ны берничек тә аңлатып булмый.

Кара диңгез белән Каспий диңгезе арасындагы биек таулар тезмәсен күз алдыгызга китерегез. Бу — Кавказ таулары. Борын-борыннан Кавказ таулары артында, Месопотамиядә, Кече Азиядә югары культуралы утрак дәүләтләр яшәгән. Кавказның бу ягында иксез-чиксез киң далаларда шулай ук борын-борыннан күчмә халыклар яшәгән. Кавказ аша ике генә юл бар. Аларның берсе — Терек белән Арагва елгаларының үзәннәре арасындагы тарлавык, икенчесе — Кавказ таулары Каспий диңгезе ярларына килеп терәлә язган җирдә, хәзерге Дербент шәһәре янында. Борынгы заманнарда көньяк дәүләтләренең хәле йомшару белән, яисә башка төрле сәбәпләр туу белән, төньяктагы сугышчан күчмә халыклар шундук әлеге тарлавыкларга омтылганнар һәм көньяк җирләргә басып кергәннәр. Тарихта мондый хәлләр күп кабатланган.

Шулай итеп, көньяктагы греклар һ. б. халыклар өчен дә, төньяктагы күчмәләр (киммерләр, скифлар, сарматлар, аланнар һ. б.) өчен дә

Кавказ таулары, дөресрәге, әлеге тарлавыклар чыннан да ике арадагы табигый **чик**, табигый **капка** булып хезмәт иткән.

Урта гасырлар тарихында Дербент яисә Каспий тарлавыгы ешрак телгә алына. VI гасырда Иран шаһы Хөсрәү I Ануширван (531 — 578) менә шушы тарлавыкка җиде фарсах (40 км чамасы) озынлыгында биек, киң таш койма салдыра. Койманың бер башы диңгезгә, икенче башы текә тауларга барып терәлә. Коймада җиде юл (ачыклык) калдырыла. Ачыклыкларның һәркайсына тимер капка куела. Койма буена, әлеге капкалар янына җиде шәһәр салына. Бу шәһәрләрдә койма (капка) сакчылары яши. Алар Әрмәнстандагы **сөннәр** булалар. Шулай итеп, Дербент тарлавыгы туры мәгънәсендә капкага әйләнә. Греклар, гарәпләр менә бу Дербент капкасын **Төньяк капка** дип тә, **Уннар** (сөннәр?) **капкасы** дип тә атаганнар. Әрмәннәр исә **Чор** капкасы дип йөрткәннәр. Чор әрмәнчә тарлавык дигән сүз.

Чор тамырлы сүзләр татар телендә дә бар. Мәсәлән, **чорсыз, чорсызлану.** Сүзлекләрдә бу сүзләрнең мәгънәсе русча: озорной, озорник дип, татарча: тыйнаксыз, тәртипсез, әдәпсез, хәрәкәтендә яки кыланышында чик белмәүче дип аңлатылган. Русча да, татарча да мәгънә бер үк.

Каян килгән чор бу? Моны **чыр** (чырай, төс, йөз) белән аңлатып булмый. Чырайсыз кешенең һичшиксез тәртипсез, әдәпсез булуы мәҗбүри түгел. Шулай ук бу сүзне вакыт мәгънәсендә **чор** белән дә якынайтып булмый. Әлеге чорсызның **чордан тыш кылана** дигән варианты да бар. Бу сүз дә кирәгеннән артык кылanучы, тәртипсез, әдәпсез кешегә карата кулланыла.

Чор тамырлы әлеге сүзләрне әрмәнчә **чор**га якынайтып карасак, мәгънә ачыклана төшәчәк. Чор тарлавыгы аша үткәч, Чорның тышына, икенче ягына чыккач (Чорсыз калгач), борынгы сугышчы нишләде икән дисезме? Анда ул үзен, әлбәттә, иркендәрәк сизгән һәм һәртөрле тәртипсезлекләр эшләгән. Менә шушы ерак гасырлардагы күренеш телдә гомумән тәртипсезлекне, хулиганлыкны аңлата торган сүз буларак чагылыш тапкан. Русның **чересчур** (кирәгеннән артык) дигән сүзе дә мәгънәсе буенча чордан тыш, чорсыз сүзләренә тәңгәл килә.

Шулай итеп, Кав тавы сүзен без **Каб-Кап (Капка)** тау дип аңлыйбыз. Димәк, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән «мифик» Каф-тау ул әлеге **Чор** яисә **Дербент (Каспий) капкасын** аңлаткан булырга мөмкин.

Ләкин Кавказны урталай кисеп үтә торган икенче тарлавык та капка хезмәтен үтәгән бит әле! Каф-тау дигән тау бәлки шул тирәдә булгандыр? Борынгырак заманнарда (мәсәлән, скифлар чорында) менә шушы уртадан үтә торган тарлавык аша ешрак чыгып йөргәннәр, ахрысы. Беренчедән, теге якка юл моннан кыскарак, икенчедән, ул заманнарда тарлавык янында ныклы сак та булмаган. Менә бу тарлавыкны элекке заманнарда **Кавказ капкасы** дип тә, **Сармат капкасы** дип тә, сарматлар хакимлегеннән соң — **Алан капкасы** дип тә атап йөрткәннәр.

Төрки телләрнең барысында да диярлек капка сүзе **капуг-капу** дип атала. **Каб-капны** мин авыз, башлангыч, юл башы мәгънәсендәге аб-ам белән янәшә куеп карыйм. Капуг юл башының, авызның ниндидер ныгытмасын белдерә. Капка бары татар, башкорт телендә генә **капка** дип атала. Чувашча — **хапка.** Аннары капка Себер татарларында һәм казакъларда бар. Казакълар капканы **какпа** диләр.

Татар телендә **капкалы** берничә сүз бар: **авыл капкасы, басу капкасы, кыр капкасы, ындыр капкасы, җил капка, олы капка, кече капка, кала капка, урыс капка** һ. б. **Урыс капка** дигәннән, бу урында бераз гына читкә тайпылырга туры килә. Урам капканы гадәттә рус капкасы, русча капка дип аңлыйлар һәм русчага **русские ворота** дип тәрҗемә

итэлэр. Лэкин бу алай ук түгел. Урыс капка **рус** капка булган булса, аның капма-каршысы — татар капка дигэне дэ булыр иде. Белгэнебезчэ, **татар капка** дигэн капка **юк.** Шулай булгач, **рус капка да юк.** Мин бу урыс капканы **Курыс капка** дип аңлыйм. (К)урыс капка ул бай итеп бизэлгэн, буялган һэм ике яисэ өч ягына да кояш эмблемалары ясалган **изге капка** булачак. Ике якка ачыла торган урыс капка һэм кала капканың «ишек»лэре **канат** дип атала. Монысы да игътибарга лаек. Канатларның бары изге котларда — бөркетлэрдэ генэ булганлыгын без инде бик яхшы белэбез.

Шулай итеп, капканың әүвэлге формасын без **каб-каз** булгандыр дип әйтэ алабыз. Каб-каз ул — чик, башлангыч (авыз, ярык, тарлавык), лэкин шул ук вакытта бу: **чик буе капугы. Kaukasos** сүзен греклар, элбэттэ, төркилэрдэн, конкретрак итеп әйткэндэ, Казан татарларының бик борынгы бабаларыннан алганнар. Бүгенге татар телендэ Каф-тауның да, капка(з)ның да шул килеш диярлек сакланып калуы шул турыда сөйли дэ инде. Дөрес, гасырлар үтү белэн, капказ сүзендэге **з** авазы кайдадыр төшеп югалган. Һэм телдэ бик гадэти **капка** сүзе генэ торып калган. Лэкин ике-өч мең ел эчендэ бер **з** авазы гына югалту шулай да эллэ ни зур югалту түгел! Хэер, капканың кечерэйтелгэн варианты **капкач** (каб-кач) сүзендэ «з» авазы шул көе сакланган, тик монда ул бераз төсен генэ үзгэрткэн (Кабказ-капкас-кабкач; башкортча: **капкас**).

## Хазарлар

VI — VII гасырларда хэзерге Дагстанның дала җирлэрендэ, Түбэн Идел буйларында **Хазар** дип аталган төрки дэүлэт барлыкка килэ. Заманында иң көчле империялэрнең берсе булган Хазар каганлыгына Идел буе болгарлары да шактый вакыт буйсынып яшилэр. Хазар дэүлэте X гасырда юкка чыга.

Хазар тарихының күп кенэ сэхифэлэре ачыкланган булса да, **хазар халкының** килеп чыгышы эле булса томанлы килеш кала бирэ. Язма чыганакларда хазарларның теле болгар теленэ охшаш булуы турында әйтелэ. Шулай да хазар теле бүгенге көнгэ кадэр билгесез тел санала. Хазарларның бары кайбер кеше исемнэре, титул атамалары гына мэгълүм. Лэкин бу исем-атамаларның барысы да — гомумтөрки.

Хазарлар турындагы беренче тарихи мэгълүматлар эрмэн язмаларында очрый. Моисей Хоренский китабында 193 һэм 213 елларда хазарларның басиллар **(барыс-иллэр)** белэн бергэлэп Чор капкасы аша үтүлэре һэм Кура елгасының уң ягына чыгулары турында әйтелэ. Шул ук эрмэн чыганакларында һэм гарэп язмаларында элеккерэк заманнар (Александр Македонский заманнары) турында сүз барганда да хазарлар телгэ алына икэн. Хазар тарихын тикшерүгэ чирек гасыр гомерен багышлаган һэм 1962 елда «История хазар» («Хазарлар тарихы») дигэн китабын бастырып чыгарган совет галиме М. И. Артамонов мондый хэбэрлэрнең барысын да фантастик, анохронизм дип атый. Ул хазарларны Көнчыгыш Европага VI гасырдан да элегрэк килеп чыга алмаганнар дигэн фикердэ тора, чөнки Көнчыгыш Европада, Төньяк Кавказда VI гасырга кадэр башка көчле кабилэлэр (барсиллар, суарлар, болгарлар) хакимлек иткэннэр һэм бу турыда Византия чыганакларында ап-ачык әйтелгэн.

**Хазар** сүзенең этимологиясен кайбер чит ил галимнэре **каз** тамырыннан чыгып аңлаталар. Казны алар **күченү, йөрү** мэгънэсендэ аңлыйлар (гиз-кэз-каз). Хазар-Казар, шулай итеп, «күчмэ халык» булып чыга. Урта гасыр төркилэрнең барысы да диярлек күчмэ булганнар

һәм аларның исеме шулай күченү-йөрү мәгънәсеннән алына торган булса, барлык төркиләр дә **казар** яисә **казак** булмаслар иде микән? Күченү (гизү) мәгънәсендәге каз теориясен М. И. Артамонов кире кага һәм хазар этимологиясен ачыкламаган килеш калдыра. Әйтергә кирәк, венгр галиме Гомбоцның гиз-кәз-каз теориясен А. С. Самойлович инде 1927 елда ук тәнкыйтьләп чыга.

Хазар сүзенең төркичәсе чыннан да **казар** булган, ахрысы. Хазарлар белән ныграк аралашкан руслар аларны **козар, козаре** дип атаганнар. Рус елъязмаларында хазар шулай языла. Ләкин без хазардагы каз тамырын, Гомбоц тәкъдим иткәнчә, йөрү, күченү дип түгел, бәлки, **А.** Халиков тәкъдим иткәнчә, **чик** мәгънәсендә аңлыйбыз. **Ар** кушымчасына килгәндә, мәсьәлә болайрак тора.

Төрки этнонимнарның берничәсе **ар-әр** иҗеге белән тәмамлана. Мәсәлән, **хазар, татар, болгар, авар.** Менә бу **арны** кайберәүләр иранча арий сүзеннән алынган диләр, ләкин күпчелек моны **ир-әр** тамырына илтеп тоташтыра. Татар дигән сүз, мәсәлән, **тат дигән ирләр** (сугышчылар) кебегрәк аңлатыла. Киңрәк мәгънәдә бу **тат халкы** булып чыга. Хазар да шул рәвешчә аңлатыла, ягъни хазарлар — хаз-каз (күченүче) халыклар була. Акылга ятышлы бүтән аңлатма булмаганда мондый аңлатма да ярап тора иде. Ләкин Олжас Сулейменов[1] **ар-әрне** яңача аңларга тәкъдим итә. **Ар-әр,** аныңча, ирне түгел, **җирне** белдерә. Минемчә, бу игътибарга лаек фикер. Тик шулай да О. Сулейменов тәкъдимен дә искәрмәсез генә кабул итеп булмый. Сибирь-Себер, Тавыр-Тауер кебек атамаларда **ер-җир** яхшы төсмерләнсә дә, болгар, татар кебек атамаларда ер-җир бөтенләй күренми. **Болгардагы ар-(гар),** әйтелгәнчә, **җиргә** түгел, **кор-курга** якынрак. **Татардагы ар** да әлеге кор-кур **ыры** сымаграк.

Хазар этнонимын аңлатуда исә О. Сулейменов тәкъдиме үзен тулысынча аклый. Хазарны мин **Каз җир** дип аңлыйм. Ягъни бу шул ук Чик буе җирләре булачак. Төньяк Кавказдагы, Дагстандагы җирләр хазарлар чорында нәкъ менә шундый тынгысыз Каз җир булган да. Казар-хазар атамасы баштарак (ихтимал, хәтта Александр Македонский заманнарында ук) социаль термин буларак кулланылгандыр. Бу вакытта болгарлар, савирлар, барсиллар, шулай ук сөннәр дә — барысы да **казар (казакъ)** дип аталганнар. Бары тик берничә гасыр үтеп, казарлар аерым ил (кабилә) булып оешкач кына (VI—VII гасырларда гына) бу сүз халык атамасын белдерә башлаган. Югарыда күреп үткәнчә, казакъ, украин һәм казан халыклары да шул рәвешчә формалашканнар. Тик шулай да **хазар** сүзе безнең көннәргәчә килеп җитә алмаган — Хазар дәүләте таркалгач, аның исеме дә онытылып юкка чыккан.

Төрки халыкларның теленә, тарихына кагылышлы бу сөйләшүне шушында туктатып торабыз. Югарыда мин бүгенге фәндәге кайбер карашларны, мәсьәләләрне үземчә аңлатырга тырыштым. Үз халкымның үткәне белән, теле һәм культурасы белән якыннан кызыксынучы кеше буларак, минем моңа тулы хакым бар дип исәплим. Ләкин шулай да мин яңача аңлатылган һәрбер мәсьәләнең һичшиксез дөрес һәм соңгы сүз дип кабул ителүен дәгъваламыйм. Тел, тарих гыйлеме өлкәсендәге бу беренче язмаларым тюркологиядә бәхәссез булып исәпләнгән кайбер нәрсәләргә укучыда яңача караш һәм гомумән иҗади эзләнү дәрте уятса, мин үземнең бурычымны үтәлгән дип санаячакмын.

*Мәкалә кыскартып басылды.*

---

[1] Олжас Сулейменов. Аз и Я. Алма-Ата, 1975 ел.

**Шәмси Хамматов,**
тарих фәннәре кандидаты

# ТӨП ЮНӘЛЕШ, ТӨП МАЯК

Партиянең XXV съездында КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре Л. И. Брежнев, әдәбият-сәнгать әһелләренең иҗат эшчәнлегенә бәя биреп, болай диде: «Мөгаен, һәркем хәтерлидер: XXIV съезд әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә җитди игътибар бирде. Оста, талантлы иҗат ителгән әсәрләргә уңай бәя бирү белән бергә, съезд теге яки бу әдипләрне, сәнгать эшлеклеләрен иҗади перспективаны югалту юлына этәрүе мөмкин булган кайбер тайпылышларны күрсәтеп үткән иде.

Без бүген, XXIV съездның әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә якын килүе үзен тулысынча аклады, дип әйтә алабыз. Үткән еллар эчендә коммунистик җәмгыять төзү буенча гомумпартия, гомумхалык эшенә һаман күбрәк өлеш кертүче иҗат интеллигенциясенең эшчәнлеге тагын да активлашты» [1].

Культура эшлеклеләре, әдипләр, журналистлар, барлык идеология хезмәткәрләре һәм иҗат оешмалары алдына КПССның XXV съезды олы бурычлар куйды. Ул бурычларны үтәүдә съезд барган көннәрдә Татарстан китап нәшрияты чыгарган «К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында» дигән китап [2], һичшиксез, зур ярдәм күрсәтер.

Җыентыкка марксизм-ленинизм классикларының әдәбият һәм сәнгатькә караган хезмәтләре, әдәбият һәм сәнгать әсәрләренең җәмгыять үсешендә тоткан роле турындагы фикер-карашлары тупланган. В. И. Ленин хезмәтләренең тәрҗемәсе нигездә 45 томлык «Әсәрләр»нең татарча басмасыннан алынган, ә К. Маркс һәм Ф. Энгельс хезмәтләре татарчага беренче мәртәбә тәрҗемә итеп кертелгән. Марксизм-ленинизм классикларының әдәбиятка һәм сәнгатькә караган хезмәтләрен аерым бер җыентык итеп татар телендә бастырып чыгару, сүз дә юк, культурабыз үсешендә яңа бер үр ул. Аның дөньяга чыгуы — культурабыз тормышында зур вакыйга, марксизм-ленинизм классикларының әдәбият-сәнгатькә караган хезмәтләре — мәңге яшәр мирас, мәңгелек иҗат чишмәсе.


Без бу мәкаләдә юлбашчыларыбызның әдәбият, сәнгать, культура, матбугат мәсьәләләренә караган кайбер фикерләренә тукталабыз, практик эшебез өчен кулланма булган бу китапның бик вакытлы чыгуын билгеләп үтәбез.

Совет әдәбиятына һәм сәнгатенә юл күрсәтеп, юнәлеш биреп барган, әдәбият һәм сәнгать кешеләрен иҗат эшенә рухландырып торган марксистик-ленинчыл күрсәтмәләрнең ролен безнең идеологик дошманнарыбыз кечерәйтеп күрсәтергә, шик

---

[1] КПССның XXV съезды материаллары. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976 ел, 79 бит.

[2] К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976 ел, күләме 560 бит. Төзүчеләре һәм редколлегия членнары: философия фәннәре кандидаты М. М. Мусин, филология фәннәре докторы М. З. Зәкиев, филология фәннәре кандидаты А. Г. Әхмәдуллин, Н. К. Габитов.




астына алырга тырышалар. Алар, К. Маркс, Ф. Энгельс экономик проблемалар белән генә шөгыльләнгәннәр, шунлыктан әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә аз игътибар биргәннәр, дип әллә кайчан фаш ителгән уйдырмаларны күтәреп чыга. Чынлыкта исә пролетариат юлбашчылары әдәбият һәм сәнгатьне идеологик һәм политик көрәш барикадасының аерылгысыз өлеше итеп санаганнар, бу өлкәдә дә гаять зур тарихи мирас калдырганнар. Бу мирас коммунистлар һәм эшчеләр партияләренең идея коралы булып хезмәт итә.

Маркс һәм Энгельс үзләренең хезмәтләрендә, таныш-белешләренә язган хатларында пролетариат әдәбияты һәм сәнгатенең партиялелеген һәрвакыт яклаганнар. «Капиталистик җитештерү, — дип яза К. Маркс, — рухи җитештерүнең аерым тармакларына, мәсәлән, сәнгатькә һәм поэзиягә дошман»[1]. Марксизм бу дошманлыкның сәбәбен хосусый милекчелек хакимлек иткән капиталистик стройның яшәвеннән күрә. Буржуаз әдәбият һәм сәнгать, аның әһелләре капитализм мәнфәгатьләренә хезмәт итә, әдип нәшрият хуҗасы таләпләренә буйсына. Буржуаз җәмгыятьтә яшәүче прогрессив культура вәкилләре өчен иҗат мәйданы кысынкы, алар чикләнгән рамкаларда эшлиләр.

Капитализм белән социализм лагере арасындагы идеологик көрәш һаман көчәя бара. Күп кенә буржуаз матбугат җитәкчеләре, нәшриятлар әле бүген дә алдынгы совет әдәбияты белән үз укучыларын таныштырудан баш тарталар. Ә советка каршы кешеләрнең, һәртөрле эмигрантларның «хезмәтләрен» зур тиражларда бастырып тараталар. Америкада, Англиядә, Германия Федератив Республикасында, Италиядә һәм башка көнбатыш илләрдә совет язучыларының китаплары бик аз чыга. Безнең илдә исә аларның классиклары һәм прогрессив язучылары бик күп һәм бик еш басыла. Совет власте яши башлаганнан бирле бездә йөздән артык илнең бик күп язучылары иҗат иткән әсәрләр басылып чыккан: соңгы берничә ел эчендә генә дә Американың меңнән артык, Англия һәм Франция язучыларының тугыз меңләп әсәре басылган. Чит ил язучыларының безнең илдә чыккан китапларының гомуми тиражы 600 миллионнан артып китә[2]. Бу фактлар күп нәрсә хакында сөйли. һәм беренче чиратта алар К. Маркснең капитализм чын әдәбият һәм сәнгатькә дошман, хосусый милекчелек культура үсешен тоткарлый, дигән фикерен бик ачык итеп раслыйлар.

К. Маркс һәм Ф. Энгельс үзләре яшәгән чордагы әдипләр белән элемтәдә торалар, аларга киңәшләр бирәләр, әсәрләре турында фикерләрен әйтәләр. Журналист И. Вейдемейерга язган хатында К. Маркс шагыйрьләргә, бу очракта шагыйрь Фрейлигратка карата игътибарлы булырга куша: «1) Шигырьне тиешенчә итеп бастырырга тырыш. Строфалар арасында бушлык калсын, гомумән, урын кызганма. Буш юл калдырмыйча берсе өстенә берсе өелгән шигырьләрнең тәэсир көче кимиюгала сыман. 2) Фрейлигратка дусларча хат язып сал. Комплиментларга да саранланма, чөнки шагыйрьләрнең барысы да, хәтта яхшылары да, узынган булалар, җырлатыр өчен аларны иркәләргә кирәк. Безнең Ф[рейлиграт] шәхси тормышында бик ягымлы, эчкерсез гади бер кеше, ул үзенең зирәк, мыскыллап көлүчән акылын киң күңелле булуы белән каплый; аның пафосы «дөрес», ул аны «тәнкыйтьсез» һәм «юкбарларга ышанучы» итеп күрсәтми. Ул чын революционер һәм кристаллдай саф намуслы кеше — мондый мактау сүзләрен мин бик аз кешеләргә генә әйтәм. Шуңа карамастан, шагыйрь, нинди генә кеше булмасын — мактауларга мохтаҗ һәм үзенә табынуны ярата. Мин аларның табигате шундыйдыр дип уйлыйм. Мин боларны

---

[1] К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр. Рус телендә, 26 том, 1 кисәк, 280 бит.
[2] Правда о культурном обмене. Рус телендә, Политиздат, Мәскәү, 1976 ел, 16—17 битләр.

Фрейлигратка хат язганда «шагыйрь» белән «тәнкыйтьче» арасындагы аерманы онытып җибәрә күрмә дип кенә әйтүем»[1].

К. Маркс матур әдәбият китаплары яраткан, күп шагыйрьләрнең шигырьләрен яттан белгән, башка халыклар әдәбиятын өйрәнгән. Поль Лафаргның шушы җыентыкка кергән истәлегендә «Аның өчен китаплар зиннәт әйберсе түгел, ә бәлки рухи азык булды», — дигән юллар бар. «Алар — минем колларым, — дигән Маркс, — һәм ничек теләсәм, миңа шулай хезмәт итәргә тиешләр». Ул Гейне белән Гетены яттан белгән, сөйләшкән чакта еш кына алардан өзекләр китергән. Ул шагыйрьләрне даими рәвештә укып, аларны бөтен Европа әдәбиятыннан сайлап алып өйрәнә барган. Ул Эсхилны грекча оригиналында ел саен кат-кат укыган, Эсхилны һәм Шекспирны кешелек дөньясы тудырган бөек әдипләр, драма даһилары дип санаган[2].

«Чит ил теле — тормышта көрәш коралы» дияргә яраткан К. Маркс. Ул барлык Европа телләрендә укый белгән, ә немец, француз һәм инглиз телләрендә дөрес һәм оста итеп яза алган. Үзенә инде 50 яшь тулгач Маркс рус телен өйрәнә, бу телнең авыр булуына карамастан, күп дигәндә ярты ел эчендә аны үзләштерә, рус шагыйрьләрен һәм прозаикларын рәхәтләнеп укый башлый. Ул бигрәк тә Пушкин, Гоголь һәм Щедринны ихтирам итә[3].

Типография эшчесе, испан социалисты Ансельмо Лоренцо Карл Маркснең испан әдәбиятын да бик яхшы белүе турында яза: «Маркс испан әдәбияты турында сөйли башлады. Әйтергә кирәк, ул аны бик яхшы белә икән. Мин аның борынгы театрыбыз турындагы мәгълүматларына хәйран калдым, ул бу театрның тарихын һәм үсеш юлын энәсеннән җебенә кадәр үзләштергән. Аның фикеренчә, Кальдерон, Лопе де Вега, Тирсо де Молина испан театрының гына түгел, бәлки бөтен Европа театрының бөек әдипләре; ул аларга кыскача һәм, әйтер идем, гаять дөрес характеристикалар бирде»[4].

Ф. Энгельс та дөнья халыклары әдәбияты белән якыннан кызыксына, төрле милләт әдипләренең әсәрләренә карата үз фикерләрен әйтә. Ф. М. Кравчинская Энгельс турындагы истәлекләрендә аның А. Пушкинның шигырьләреннән өзекне яттан, гаҗәеп матур яңгырашлы рус телендә укуын яза[5].

К. Маркс һәм Ф. Энгельснең аерым әдипләргә язган хатлары — әдәби тәнкыйтьнең оста үрнәге. Ул хатларда алар әсәрләргә тирән һәм төпле анализ ясыйлар, объектив бәя бирәләр. Ул рецензияләрдә гадел тәнкыйть ярылып ята, аларны әдәбият әсәрләрен тормыш белән бәйләп тикшерүнең матур үрнәге дип санарга була. Пролетариат юлбашчыларының Фердинанд Лассальнең «Франс фон Зиккенген» дигән трагедиясе уңае белән әйткән фикерләре шул хакта сөйли. Бу трагедиянең нигезе итеп Лассаль Шваб һәм Рейн рыцарьларының 1522—1523 елларда булган восстаниесе белән бәйле вакыйгаларны алган. Франц фон Зиккенген һәм Ульрих фон Гуттен шул восстаниенең юлбашчылары була. Ф. Лассаль революциянең уңышы юлбашчыларның героизмына һәм «рухлануына» бәйле дип санаган. Маркс һәм Энгельс исә революцион трагедия киң халык массаларының революцион көрәшенә таянырга, бу массаларны шул эпохада аларга хас булган барлык интереслар һәм идеяләр белән сурәтләргә тиеш, диләр.

Ф. Энгельс Ф. Лассальгә язган хатында «Зиккенген» әсәрен берничә кат укып чыкканнан соң туган фикерләре белән уртаклаша һәм авторга: «Сезнең «Зиккенген»нең тәнкыйтькә түзәрлек булуына ышанып, аның турында Сезгә берничә «җылы сүз» әйтмәкче булам»[6],— дип яза. Ф. Энгельс үзенең хатын мондый сүзләр белән тәмамлый: «Күрәсез, мин Сезнең әсәрегезгә һәм эстетик, һәм тарихи караштан гаять югары, хәтта **иң югары** таләпләр куям, һәм тик шундый караш гына минем нинди дә булса каршы фикерләр әйтә алуым Сезнең өчен минем хуплавымның иң яхшы дәлиле булып хезмәт итәр. **Безнең арада** тәнкыйть партиянең үз интересларында, зарурлык буенча күптәннән иң ачык характер алды бит инде. Ләкин партиябез, нинди генә өлкәдә чыгыш ясамасын, аның һәр вакыт үзенең өстенлеген күрсәтүенә яңа

---

[1] К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында, 238 бит.
[2] Шунда ук, 399 бит.
[3] Шунда ук, 401 бит.
[4] Шунда ук, 403 бит.
[5] Шунда ук, 404—405 битләр.
[6] Шунда ук, 33 бит.

дәлил алуыбыз мине һәм безнең барыбызны да һәр вакыт шатландыра. Һәм бу очракта Сез дә шуңа ирешкәнсез...»[1].

Ф. Энгельс әдәби әсәрләргә зур такт, игътибар һәм сабырлык белән бәя бирә. Моны аның Минна Каутская әсәре уңае белән әйткән фикерләреннән ачык күреpгә була. Ул аның «Гриллeнгоф Стефаны» дигән романын укый. Танышудан алган тәэсире турында Энгельс Лаура Лафаргка язган хатында болай ди: «Каутская апа — немец язучысы өчен гадәттән тыш эчкерсез хатын. Мин аның бер романын укып чыктым, ул һич тә начар түгел. Ләкин мин Каутскаяга Бальзакны өйрәнергә киңәш иттем...»[2].

Ф. Энгельсның Каутскаяга язган хатында реализм теориясен тагын да тирәнәйтә һәм үстерә төшәргә ярдәм итәрдәй кызыклы фикерләр очрый. «Бик яхшы романнар яза торган хәзерге рус һәм норвегия язучылары, — ди Ф. Энгельс, — барысы да тенденциоз язучылар. Ләкин, минем уемча, тенденция шартлардан һәм вакыйгалардан үзеннән-үзе килеп чыгарга тиеш, аны махсус рәвештә басым ясап күрсәтеп торырга кирәкми, һәм язучы үзе сурәтли торган иҗтимагый конфликтларның киләчәктәге тарихи хәл ителешен укучыга әзер килеш бирергә бурычлы түгел. Өстәвенә тагын безнең шартларда роман күбесенчә буржуаз даирәләрдән булган укучыларга, ягъни турыдан-туры безнең якта булмаганнарга мөрәҗәгать итә, шуңа күрә, минем карашымча, социалистик тенденциоз роман, — гәрчә автор һичнинди ачык карар тәкъдим итмәсә дә һәм хәтта кайвакыт ачыктан-ачык кемнеңдер ягына басмаса да,— чын мөнәсәбәтләрне дөрес сурәтләп, бу мөнәсәбәтләрнең табигате турында өстенлек алып торган шартлы иллюзияләрне җимерсә, буржуаз дөньяның оптимизмын какшатса, яшәп килә торган дөнья нигезләренең үзгәрешсезлегенә шик тудырса, үз бурычын тулысынча үти»[3].

Минна Каутскаяга Энгельс хаты гаять зур тәэсир ясый, ул аңа җавап хатында болай дип яза: «Сез җылы эчкерсезлек белән сугарылган хатыгызда, минем хезмәтләремне җентекләп тәнкыйть итүгә лаек дип санап, аларны шул кадәр ихлас күңел белән тикшерәсез, бу хат, шушындый кеше тарафыннан язылганга күрә, минем өчен моңа кадәр үзем алган барлык хатлардан иң күңеллесе, иң эчтәлеклесе, шулай ук иң мактаулысы булды»[4].

Шулай итеп, Маркс һәм Энгельсның әдәбият һәм сәнгать турындагы хезмәтләрендә, хатларында, рецензияләрендә аларның дөнья халыклары культурасын яхшы белүләре, әдәби процессны тирән өйрәнүләре, революцион хәрәкәт тудырган әсәрләрне, андагы образларны, поэзияне, җырларны оста пропагандалаулары, аларны эшчеләр сыйныфы мәнфәгатьләрендә оста файдаланулары күренә.

Күп милләтле совет әдәбияты һәм сәнгате — Октябрь социалистик революциясенең гаять зур казанышы. Яңа дөньяның әдәбияты һәм сәнгате ленинизмның партиялелек һәм халыкчанлык принциплары белән коралланган социализм төзелешенең иҗтимагый көченә әйләнгән. Ул, Ленин әйткәнчә, гомумпролетариат эшенең аерылгысыз өлеше.

Үзенең байтак мәкаләләрен, чыгышларын һәм хатларын В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать эшенең үсүе һәм оештыру проблемаларына багышлаган. Җәмгыятебезнең социализм юлыннан үсешендәге күп бурычларны хәл иткәндә без һәрчак Ленин өйрәтмәләренә таянып эш итәбез.

Ленин, иҗат эшенең аерым бер үзенчәлеккә ия булган тармак, танып-белүнең үзгә бер формасы икәнлеген, моны һәрчак истә тотарга кирәклеген аңлап, әдәбият һәм сәнгатьнең сыйнфый табигатен, художникның иҗтимагый-политик позициясен, дөньяга максатлы фәнни карашын яклап чыкты. Җыентыкта В. И. Ленинның әдәбият һәм сәнгать хакындагы фикерләренә, әдәбиятның партиялелеге, сыйнфыйлыгы турындагы тәгълиматына киң урын бирелгән.

Яңа философия, ике мең ел элек булган кебек үк, партияле, ди юлбашчы. Аның бу фикере бер философиягә генә карамый. Ленин алга сөргән сыйнфыйлыкның идея-

---

[1] Шунда ук, 37 бит.
[2] Ф. Энгельс. Әсәрләр. Рус телендә, 36 том, 301 бит.
[3] К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында. 28—29 битләр.
[4] Шунда ук, 503 бит.

се һәм критерийлары әдәбият белән сәнгатьнең дә бөтен күренешләрен аңларга, аларга дөрес бәя бирергә булыша, бу — безнең өчен төп принцип. Үткән чорларны аңлауда булсын, хәзерге заман әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең көндәлек эшендә булсын, — бу безнең өчен төп маяк.



Даһи Ленин Беренче рус революциясе елларында матбугат битләрендә пролетариат партияле әдәбият принцибын алга сөрергә, аны үстерергә, тормышка ашырырга, әдәбият партия эшенең состав өлеше булырга тиеш, дип чыга. Юлбашчының мондый фикере, мондый күрсәтмә белән чыгуы әле әдәбиятка карата яшәп килгән «партиясезлек», «катнашмау» идеяләрен өстерәп йөрүче, партиялелек принцибы ирекле идея көрәшен, тәнкыйть ирекен, әдәби иҗат ирекен түбәнәйтә, җансызландыра, «бюрократлаштыра» дип тавыш күтәрүче күп кенә культура әһелләренә, интеллигенция вәкилләренә куәтле удар була. В. И. Ленинның «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» дигән мәкаләсе 1905 елның ноябреннан бирле культурабызга, әдәбиятыбызга мәңге сүрелмәслек көрәш рухы биреп килә. Ул — әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә партия политикасының төп нигезе.

Социалистик әдәбият һәм сәнгать, матбугат үсеше өчен көрәш программасы булып саналган әлеге хезмәтендә В. И. Ленин болай ди: «Әдәбият партияле булырга тиеш. Буржуаз гореф-гадәтләргә каршы буларак, буржуаның предприниматель, сәүдәгәр матбугатына каршы буларак, буржуаз әдәби карьеризмга һәм индивидуализмга, «барин анархизмына» һәм табыш артыннан куугa каршы буларак, — социалистик пролетариат **партияле әдәбият** принцибын алга сөрергә, бу принципны үстерергә һәм аны мөмкин кадәр тулырак һәм бөтенрәк формада тормышка ашырырга тиеш.

Партияле әдәбиятның бу принцибы нидән гыйбарәт соң? Социалистик пролетариат өчен әдәбият эшенең аерым кешеләргә яки группаларга табыш коралы була алмавыннан гына түгел, гомумән пролетариатның гомуми эшенә бәйсез, индивидуаль эш була алмый. Кирәкми партиясез литераторлар! Кирәкми үтәкеше литераторлар! Әдәбият эше гомуми пролетар эшнең **бер өлеше** булырга, барлык эшчеләр сыйныфының бөтен аңлы авангарды тарафыннан хәрәкәткә китерелүче бер бердәм, бөек социал-демократик механизмның «кечкенә тәгәрмәче һәм кечкенә шөребе» булырга тиеш. Әдәбият эше оешкан, планлы, берләшкән социал-демократик партия эшенең состав өлеше булырга тиеш»[1].

Юлбашчыбыз, пролетариат әдәбияты азат әдәбият булачак, аның сафларына яңадан-яңа көчләрне комагайлык та, карьера да түгел, бәлки социализм идеясе һәм хезмәт ияләренә теләктәшлек җыячак, ди. Җәмгыятьтә яшәп тә, ди Ленин, җәмгыятьтән азат булу мөмкин түгел, ә буржуаз язучының, художникның, актрисаның азатлыгы пәрдәләнгән (яки риячыл пәрдәләнә торган) бәйлелек, акча капчыгына, сатып алынуга, тамак ялына бәйлелек кенә ул. Ильичның моннан җитмеш ел элек әйткән сүзләре капитализм шартларында яши, эшли торган әдипләргә хәзер дә хас нәрсә.

Юлбашчыбыз горурлык белән пролетариат әдәбияты турында болай дип белдерә: «Бу азат әдәбият булачак, кешелекнең революцион фикеренең соңгы сүзен социалистик пролетариатның тәҗрибәсе һәм җанлы эше белән җимешләндерәчәк, үткәннең тәҗрибәсе (социализмның примитив, утопик формалардан алып үсешен тәгәлләгән фәнни социализм) белән хәзергенең тәҗрибәсе (эшче иптәшләрнең хәзерге көрәше) арасында үзара даими тәэсир булдырачак.

Эшкә керешик, иптәшләр! Безнең алда кыен һәм яңа, ләкин бөек һәм игелекле бурыч — социал-демократик эшчеләр хәрәкәте белән тыгыз һәм өзелмәс бәйләнештә әдәбият эшен киң, төрле яклы, төрле рәвештә оештыру бурычы. Бөтен социал-демократик әдәбият партияле булырга тиеш»[2].

В. И. Ленинның «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» дигән бөек хезмәтендә әйтелгән сүзләр Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә безнең илебездә тормышка ашырылды, совет әдәбияты һәм сәнгатенең чәчәк атуына китерде. Юлбашчыбыз күрсәтмәләренә таянып, партиябез иҗат интеллигенциясенә гаять зур игътибар бирә.

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 10 том, 30—31 битләр.
[2] Шунда ук, 34 бит.

«Совет язучылары, художниклары, композиторлары, театр, кино, телевидение работниклары,— диде КПССның XXV съездында Л. И. Брежнев,— талантын һәм профессиональ осталыгын халыкка, коммунизм эшенә бирүчеләрнең һәммәсе зур хөрмәткә лаек»[1].

Ильич әдәбиятта һәм сәнгатьтә партиялелек принципларын газеталарда язган мәкаләләрендә, язучыларга адресланган хатларында тагын да нигезле һәм конкретлаштыра төшә, художникларга карата бик игътибарлы булырга өнди, әдәби хезмәтнең катлаулы, үзенчәлекле, индивидуаль эш булуын басым ясап әйтә. «Сүз дә юктыр, — дип яза ул, — әдәбият эше механик рәвештә тигезләүгә, нивелировкага, күпчелекнең азчылык өстенннән хөкем сөрүенә иң аз бирешә. Сүз дә юктыр, бу эштә шәхси инициативага, индивидуаль һәвәсләкләргә күбрәк иркенлек, фикергә һәм фантазиягә, формага һәм эчтәлеккә иркенлек тәэмин итү һичшиксез кирәк. Болар бар да бәхәссез, ләкин болар бар да тик шуны гына исбат итәләр ки, пролетариатның партия эшенең әдәбият өлеше пролетариатның партия эшенең башка өлешләре белән шаблонлы рәвештә тиңләштерелә алмый. Болар бар да буржуазиягә һәм буржуаз демократиягә ят һәм сәер положение: әдәбият эше һичшиксез һәм мәҗбүри рәвештә социаль-демократик партия эшенең башка өлешләре белән аерылгысыз бәйләнгән бер өлеше булырга тиеш, дигән положениене һич тә кире какмый»[2].

Партиябез В. И. Ленинның бу күрсәтмәләрен һәрчак истә тота, иҗат интеллигенциясе эшенә идея юнәлеше бирә, әдәби иҗат кебек өлкәдә администраторлык итүгә юл куймый, әсәрләрнең сыйфатына партиялелек, халыкчанлык принцибыннан чыгып бәя бирә. Әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә партияле караш кирәклеге КПССның XXV съездында да бик ачык итеп әйтелде. «Әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә партияле караш, — диде Л. И. Брежнев XXV съездда, — художество интеллигенциясенә игътибарлы булуны, аның иҗади эзләнүләрендә ярдәм итүне принципиальлек белән бергә бәйләүне күздә тота. Теләсә кайсы әсәрнең иҗтимагый әһәмиятен бәяләүнең төп критерие, әлбәттә, аның идея юнәлеше булды һәм шулай булып кала да. Идеология эшчәнлегенең бу сферасында зур эш башкаручы Үзәк Комитет, партия органнары әнә шулай ленинча эшлиләр дә. Юк дигәндә дә булгалый әле: кайбер работниклар эшкә артык гадиләштереп карыйлар, художество иҗатына, форма төрлелеге һәм стиль индивидуальлегенә кагылышлы мәсьәләләрне административ методлар белән хәл итәргә тырышалар, партия исә мондый хәлләрне читләтеп үтми, аларны төзәтә»[3].

В. И. Ленин партияле газеталарда прогрессив язучыларның, публицистларның актив катнашуын, матбугат битләрендә әледән-әле тәнкыйть материаллары биреп торуны таләп иткән. М. Горькийга язган хатында ул аны политик газета тонында язылган, партия эше белән бәйләнешле мәкаләләр белән катнашып торырга чакыра. Большевистик «...газета аркылы, — дип яза Ленин, — партия эше дә, әдәбият эше дә бик күп отар иде, ул партия эше белән тыгыз бәйләнеп, партиягә системалы тестә, өзлексез йогынты ясар иде!.. Әдәби тәнкыйтьне дә партия эше белән, партиягә җитәкчелек итү белән **тыгызрак** бәйләү яхшырак булыр иде...»[4]

Юлбашчыбыз газета сотрудникларына, журналистларга әдипләр белән дусларча мөнәсәбәттә булырга куша. «Правда» газетасы редакциясенә 1912 елның ноябренда язган хатында ул М. Горькийның газетага карашы яхшы, дусларча икәнен әйтеп, сез «үзегез дә аның белән шулай дусларча мөнәсәбәттә булырсыз һәм аңа **«Правда»ның** тәртипле җибәрелеп торуын игътибар белән күзәтерсез дип ышанам»[5], ди. Ә 1913 елның маенда язган хатында «Правда» редакциясеннән шагыйрь Демьян Бедныйга дикъкатьле булуны таләп итә. «Кешегә, — дип яза В. И. Ленин, — йомшак яклары өчен бәйләнмәгез, дуслар! Талант — сирәк була торган нәрсә. Аңа әледән-әле һәм саклык белән булышлык күрсәтеп торырга кирәк. Әгәр сез талантлы сотрудникны тартмасагыз, аңа **булышлык күрсәтмәсәгез,** гөнаһлы булырсыз, эшчеләр демократиясе алдында **зур гөнаһлы** булырсыз...»[6]

---

[1] КПССның XXV съезды материаллары. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976 ел, 80 бит.
[2] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 10 том, 31 бит.
[3] КПССның XXV съезды материаллары, 80 бит.
[4] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 34 том, 360—361 битләр.
[5] Шунда ук, 36 том, 167 бит.
[6] Шунда ук, 35 том, 73 бит.

Владимир Ильич үзе әдипләргә карата гаять игътибарлы була, алар белән принципиаль мөнәсәбәт урнаштыра. Моны без аеруча М. Горький мисалында ачык күрәбез. М. Горький В. И. Ленинның дусты һәм көрәштәше була. Ул язучы хезмәтенә зур бәя бирә, аның турында буржуаз матбугатның ялган хәбәр таратуына каршы баш күтәрә. «Буржуаз газеталар, — ди Ленин, — юкка гына көчәнәләр. Иптәш Горький үзенең бөек художество әсәрләре белән үзен Россиядәге һәм бөтен дөньядагы эшчеләр хәрәкәте белән нык бәйләгән, ул буржуаз газеталарга нәфрәт белән генә җавап бирәчәк»[1].

Совет власте елларында бөек юлбашчы М. Горький тарафыннан кертелгән бик күп тәкъдимнәрне яклап чыга, барлык әдәби мәсьәләләрне хәл иткәндә аның белән сөйләшергә киңәш бирә, аның китаплары басылуы һәм таралуы белән кызыксынып тора. Әмма М. Горькийга зур ихтирам белән карaса да, В. И. Ленин аның идея ялгышуларын, булган хаталарын гафу итү юлына басмый, ул аларны дусларча, изге ният белән каты һәм принципиаль тәнкыйть итә.

М. Горькийның совет әдәбиятын, культурасын үстерүдә, художество интеллигенциясен тәрбияләүдә роле гаять зур була. Җыентыкка кергән истәлекләрдән күренгәнчә, Владимир Ильич Горький турында сөйләгәндә: «һәр вакыт Горькийның культура биеклекләренә килгән гаять ачык һәм сокландыргыч хезмәт юлы аны культура хәзинәләрен шундый ук тырыш хезмәт һәм каты көрәш белән үзләштерә торган яңа эшче-крестьян интеллигенциясенә якынайтырга тиеш,— дип күрсәтә иде»[2] ди.

Җыентыкка В. И. Ленинның Октябрь революциясенә хәтле Герцен, Толстой турында язган хезмәтләре кертелгән. Ул аларның иҗатына тирән анализ ясый, культура байлыгына сак карарга өйрәтә. Ленин культура һәм художество мирасы мәсьәләсен гаять киң тарихи перспективада ала, кешелек җәмгыяте тудырган бөтен рухи кыйммәтнең эшчеләр сыйныфы тарафыннан ничек кабул ителергә тиеш икәнлеген бик тирәнтен тоеп фикерли. Культура һәм сәнгатьнең иң катлаулы проблемалары хакында фикер йөрткәндә Ленин аның халык мәнфәгатьләренә ничаклы тәңгәл килүеннән чыгып эш итә.

В. И. Ленин декабристлар Герценны уяттылар, ул революцион агитация җәелдерде, дип яза. «Герцен, халыкка **иркен рус сүзе** белән мөрәҗәгать итеп, беренче буларак, патша монархиясе дигән хәшәрәткә каршы көрәшнең бөек байрагын күтәргән иде, һәм бу сабаклар белән баеган пролетариат, хәшәрәтне сытып, үзенә барлык илләрнең социалистик эшчеләре белән иркен союзга юл салыр»[3].

Л. Толстой үлгәннән соң буржуаз газеталар аңа төрлечә яла ягалар. В. И. Ленин үзенең хезмәтләрендә Толстойның бөеклеген ача, аның әдәбият тарихында тоткан урынын билгели, аны даһи художник дип атый.

«Толстой үлде, — дип яза Ленин, — һәм революциягә кадәрге Россия — зәгыйфьлеге, көчсезлеге даһи художникның философиясендә гәүдәләнгән, аның әсәрләрендә сурәтләнгән Россия үткән заманда калды. Ләкин Толстой мирасында, үткән заманда калмыйча, киләчәккә хас булган нәрсә бар. Бу мирасны Россия пролетариаты үзенә ала һәм шул мирас өстендә эшли»[4].

Җыентыкка Ленинның пролетариат культурасына, матбугатка, тел үсешенә кагылышлы хезмәтләре дә кертелгән.

В. И. Ленин һәм Коммунистлар партиясе нигилизмга, сектантлыкка, культура, сәнгать, әдәбият өлкәсендә төрле бозып аңлатуларга каршы кискен көрәш алып барлар. Пролеткульт дип аталган оешма җитәкчеләренең сектантлык тенденцияләре, «саф» пролетариат культурасы булдырырга маташулары Ленин тарафыннан каты тәнкыйтьләнә. «Пролетариат культурасы турындагы резолюциянең караламасы»нда Ленин безнең бурыч «яңа культура уйлап чыгару түгел, бәлки пролетариат диктатурасы чорындагы марксистик караштан, тормыш һәм көрәш шартларыннан чыгып карала торган гамәлдәге культураның иң яхшы үрнәкләрен, традицияләрен, нәтиҗәләрен үстерү»[5], дип яза. Классик мирас, Ленин фикеренчә, үткән дәверне билгеләгән категория, академик төшенчә түгел. Ул — иҗади тормышның халык рухы бөек-

---

[1] Шунда ук, 16 том, 101 бит.
[2] К. Маркс, Ф. Энгельс. В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында, 455 бит.
[3] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 18 том, 16 бит.
[4] Шунда ук, 16 том, 332 бит.
[5] В. И. Ленин. Әсәрләр. Рус телендә, 5 басма, 41 том, 462 бит.

легенә омтылыр кыйммәте, көндәлек иҗади тормышның тиңләшер максаты. Чөнки бит, классик мирас кебек үк, бүгенге әдәбият һәм сәнгатьтә дә киләчәктә социалистик культура мирасы дип каралырдай үрнәкләр күп, алар да бит бер вакытны үткән заман мирасы дип каралачак...

«Яшьләр союзларының бурычлары» дигән хезмәтендә Ленин бөтен культура мирасын үзләштерү нигезендә социалистик культураны төзүнең тулы программасын аңлата. Ул болай ди: «Кешелек дөньясының бөтен үсеше тудырган культураны төгәл белү юлы белән генә, аны эшкәртү юлы белән генә пролетариат культурасын төзергә мөмкин икәнен ачык аңламаганда, без бу бурычны хәл итә алмыйбыз. Пролетариат культурасы әллә кайдан килеп чыккан нәрсә түгел, үзләрен пролетариат культурасы белгечләре дип атаучы кешеләр уйлап чыгарган нәрсә түгел. Болар барысы да бөтенләй юк сүз. Пролетариат культурасы капиталистик җәмгыятьнең, алпавытлар җәмгыятенең, чиновниклар җәмгыятенең изүе астында кешелек дөньясы барлыкка китергән белем запасларының закончалыклы үсеше булырга тиеш» [1].

В. И. Ленин газеталарның характеры турында кыйммәтле фикерләр әйтә. Матбугатның, публицистларның бурычы **«массаларны** тормышның барлык өлкәләреннән алынган җанлы, конкрет мисаллар һәм үрнәкләр нигезендә **тәрбияләү»** [2]. Тормышка якынрак килик, әдипләр, күбесенчә, кәгазьгә күмелеп, тормышны күрми калалар, эшчеләр һәм крестьяннар массасы чынлыкта үзенең көндәлек эше белән төзи торган яңа һәр нәрсәгә игътибар күбрәк бирелсен, ди Ленин.

Владимир Ильич «матбугат иреге» мәсьәләсенә төгәл аңлатма бирә. «Бөтен дөньяда, капиталистлар булган җирләрдә, — дип яза ул, — матбугат иреге — газеталарны **сатып алу**, язучыларны **сатып алу**, «җәмәгать фикерен» **буржуазия файдасына сатып алу** һәм бозып күрсәтү ул» [3].

«К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында» дигән китапка марксизм-ленинизм классикларының тел турындагы хезмәтләрен кертеп төзүчеләр бик дөрес эшләгәннәр.

Карл Маркс бу җыентыкка кергән язмаларында идеяләр телдән башка яши алмый, ди. «Аң кебек үк,— ди ул,— тел дә борынгы; тел башка кешеләр өчен дә булган һәм тик шуның аркасында гына минем үзем өчен дә булган практик, чын аң ул, һәм, аң шикелле үк, тел дә ихтыяҗдан, башка кешеләр белән аралашу зарурлыгыннан гына килеп чыга» [4].

Мәгълүм булганча, Маркс һәм Энгельс, Россия халыкларын, аларның культурасын һәм әдәбиятын ихтирам итеп, рус телен өйрәнәләр. Нинди матур ул рус теле! «Рус теленең хәзерге теллләрдән иң җанлы, иң көчле, иң бай тел булуы, ул телдәге әдәбият өчен генә дә рус телен өйрәнергә кирәклеге немец социаль-демократларына яңалык түгел» [5], — ди Энгельс.

Владимир Ильич «Мәҗбүри дәүләт теле кирәкме?» дигән мәкаләсендә буржуазия вәкилләренең, либералларның матбугатта тел мәсьәләсенә карата әйткән фикерләренә тирән анализ ясый һәм Пуришкевич кебек әфәнделәрнең бу хактагы фикерләрен кискен тәнкыйть итә. Алга таба исә бу фикер болай дәвам иттерелә: рус теле бөек һәм куәтле, диләр безгә либераллар. Шулай булгач, сез Россиянең теләсә кайсы окраинасында яшәүче һәрбер кешенең бу бөек һәм куәтле телне белүен теләмисезмени? Сез рус теленең инородецлар әдәбиятын баетачагын, аларга бөек культура кыйммәтләрен үзләштерергә мөмкинлек бирәчәген һ. б. ларны күрмисезмени? Болар барысы да дөрес, либерал әфәнделәр, дип җавап бирәбез без аларга,— ди Ленин.— Тургенев, Толстой, Добролюбов, Чернышевский теленең бөек һәм куәтле икәнен без сездән яхшырак беләбез. Россиядә яшәүче барлык милләтләрнең — бөтенесенең изелгән сыйныфлары арасында мөмкин кадәр тыгызрак аралашу һәм туганнарча бердәмлек урнашуын без сездән артыграк телибез. Һәм без, әлбәттә, Россиянең һәрбер кешесенә бөек рус телен өйрәнү мөмкинлеге булдыру ягында торабыз.

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 31 том, 283 бит.
[2] Шунда ук, 28 том, 86 бит.
[3] Шунда ук, 32 том, 515 бит.
[4] К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында, 135 бит.
[5] Шунда ук, 206 бит.

Без, дип яза аннары Ленин, бер генә нәрсәне: ирексезләү элементын гына теләмибез. Без оҗмахка кусәк белән куып кертергә теләмибез. Чөнки сез «культура» турында күпме генә матур фразалар әйтмәгез, мәҗбүри дәүләт теле ирексезләү белән, көчләп кертү белән бәйләнгән. «Безнең уебызча, бөек һәм куәтле рус теле кемнең дә булса аны **таяктан куркып** өйрәнергә тиешлегенә мохтаҗ түгел... Тормыш һәм эш шартлары буенча рус телен белүгә мохтаҗ кешеләр аны таяксыз да өйрәнерләр. Ә ирексезләү (таяк) бер генә нәрсәгә китерәчәк: ул бөек һәм куәтле рус теленең башка милли группаларга керү юлын кыенлаштырачак, ә иң мөһиме — дошманлыкны кискенәйтәчәк, миллион яңа низаглар тудырачак, ризасызлыкны, үзара аңлашмауны һ. б. ны көчәйтәчәк» [1].

Рус марксистлары: «Мәҗбүри дәүләт теле булмаска тиеш, халык барлык җирле телләрдә укыта торган мәктәпләр белән тәэмин ителергә, конституциягә милләтләрдән берсенең нинди генә булмасын привилегияләрен һәм азчылык милләтләрнең хокуклары ничек кенә булмасын бозылуны бетерүне игълан итә торган төп закон кертелергә тиеш», диләр. Ленинның бу күрсәтмәләре безнең илебездә тормышка ашырыла.

Америка журналисты сорауларына җавабында В. И. Ленин: «Без, мәсәлән, башкорт мисалында Россиядә автономияле республика төзергә мөмкинлек бирдек, без һәрбер халыкның мөстәкыйль, ирекле үсешенә, һәркемнең үз **ана телендә** әдәбиятны үстерүгә һәм таратуга төрле юллар белән ярдәм итәбез» [2],— дип белдерә.

В. И. Ленин рус телен бозуга каршы сугыш игълан итә. Рус **телен** без бозабыз, ди ул. Чит сүзләрне кирәксезгә, ялгыш кулланабыз. Газета **теленең** шулай бозыла башлавы, кайбер литераторларның чит сүзләрне урынсыз куллануы Ленинны бик нык борчый. Мондый хәл әдәбиятның, публицистиканың, матбугатның хезмәт ияләренә тәэсир, йогынты ясавын киметә, ди.

«Дөресен әйтим, — дип яза Ленин, — әгәр чит сүзләрне кирәксезгә куллану минем ачуымны китерә икән (чөнки бу безнең массага йогынты ясавыбызны кыенлаштыра), газеталарда язучыларның кайбер ялгышлары инде мине бөтенләй чыдап тормаслык хәлгә китерүе мөмкин...

Рус телен бозуга каршы сугыш игълан итәргә вакыт түгелме икән?» [3].

Владимир Ильичның егерменче елларда әйткән бу сүзләре хәзер дә бик урынлы яңгырый, партиябезнең халык белән аралашуда иң үткен коралы — телгә карата әдәбият, матбугат сак, ихтирамлы булырга тиеш.

В. И. Ленин язучының матбугатта популяр чыгыш ясавына да игътибар итә. Аның «Свобода» журналы турында әйткән сүзләре шуны раслый. Бу журналда,— дип яза Владимир Ильич, бер генә гади сүз дә юк, барысы да кыланчык сүзләр, фикерләр бозык тел белән аңлатыла. Популярлаштыру вульгарлаштырудан, популярлык кыланышыннан бик ерак тора бит... «Популяр язучы, иң гади һәм бөтен кешегә билгеле мәгълүматларга таянып, катлаулы булмаган фикерләр яки уңышлы сайланган мисаллар ярдәмендә бу мәгълүматлардан килеп чыга торган төп **нәтиҗәләрне** күрсәтеп, укучының уен яңадан-яңа сорауларга этәреп, үзенең укучысын **тирән** фикергә, тирән тәгълиматка китереп җиткерә. Популяр язучы уйламаучы укучыны, уйларга теләмәүче яки уйлый белмәүче укучыны күздә тотмый, — киресенчә, ул аңы үсеп җитмәгән укучыда башын эшләтергә җитди теләк булуын күздә тота һәм аңа шушы җитди һәм кыен эшне эшләргә **ярдәм итә**, аны җитәкләп алып бара, аңа беренче адымнарны ясарга булышлык итә һәм мөстәкыйль рәвештә алга барырга **өйрәтә**» [4].

Җыентыкка кертелгән истәлекләрдән күренгәнчә, Владимир Ильич матур әдәбият белән бик нык кызыксынган. Үзенең яраткан язучылары Салтыков-Щедрин, Некрасов, бигрәк тә Чернышевский хакында сөйләргә яраткан. Гоголь, Герцен, Толстой, Тургенев, Достоевский, Успенский әсәрләре турындагы фикерләрендә В. И. Ленинның рус әдәбиятын яхшы белүе — әдәбиятны тормышны танып-белү коралы дәрәҗәсендә оста куллануы күренә.

Совет власте елларында язучыларның иҗаты аның игътибарыннан читтә калмый. Н. К. Крупская үзенең истәлекләрендә Владимир Ильичның Маяковскийга булган ка-

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 20 том, 1 бит.
[2] Шунда ук, 29 том, 512 бит.
[3] Шунда ук, 30 том, 294 бит.
[4] Шунда ук, 5 том, 317 бит.

рашын яза. Бу исемне телгә алганда, — дип яза Надежда Константиновна, — ул тормыш һәм шатлык белән тулы, Совет власте өчен үләргә әзер торучы, хәзерге телдә сүзләр таба алмыйча, моны Маяковскийның аз аңлаешлы шигырьләреннән эзләүче Мәскәү художество театры артистлары, ВХУТЕМАС студиясендә укучы яшьләрне исенә төшерә иде.

Соңрак Ильич В. Маяковскийны совет бюрократларыннан көлгән, «Утырыш җене кагылганнар» («Прозаседавшиеся») шигыре өчен мактый, аның политик әһәмиятен билгели. «Кичә мин очраклы рәвештә генә «Известия»дә Маяковскийның политик темага язылган бер шигырен укыган идем. Мин аның шигъри талантына баш иючеләрдән түгел, хәер, бу мәсьәләдә белдексезлегемне тулысынча таныйм. Шулай да минем, политик һәм административ күзлектән караганда, мондый ләззәтне күптән татыганым юк иде. Маяковский ул шигырендә утырышлардан бик каты көлә һәм утырыштан утырышка йөрүче коммунистларны хурлый. Поэзия ягыннан ничектер, анысын белмим, ә политик яктан моның бик дөрес икәнен ышанып әйтәм» [1], — ди В. И. Ленин.

Милли әдәбият, матбугат үсеше Ленин игътибарының үзәгендә була. Моны без язучы, вакытында безнең республика газетасы редакторы булган В. Бахметьевның бу җыентыкка кертелгән истәлегеннән күрәбез. Партиянең X съездында катнашучы бер төркем Казан делегатлары Владимир Ильич белән очрашалар. Ул татар әдәбияты, журналистика, газета эшләре хакында сораша, аларның үсеше белән кызыксына: «...Безнең татар әдәбияты ни хәлдә? Әлеге... ни атлы соң... Мулла улы, шагыйрь... Пушкин, Лермонтов әсәрләрен үз туган теленә тәрҗемә иткән... Габдулла, Габдулла...

— Тукаев! — дип әйтеп куйдым.

— Шагыйрьнең эшен лаеклы рәвештә дәвам иттерүчеләр бармы соң?..

Мин кечкенә куен дәфтәрем белән карандашны кесәмә яшерә-яшерә берничә яшь татар язучысының исемен әйттем.

— Димәк, базда дары бетмәгән әле! — диде Ильич елмаеп. — Ә сездә журналистика, газета эшләре ничек тора?

Владимир Ильич миңа газета тиражы турында, анда милли интеллигенциянең ничек катнашуы, хәтта полиграфик база турында берничә сорау бирде...» [2].

В. И. Ленинның бөек Тукай исемен атавы, аны Пушкин һәм Лермонтов әсәрләрен пропагандалаучы буларак искә алуы безнең әдәбиятыбыз, культурабыз эшлеклеләрендә горурлык хисләре уята, аларны яңа иҗади эшкә рухландыра.

Юлбашчыбыз В. И. Ленин сәнгать — халыкныкы дип өйрәтте. Бу нәрсә, аның уйлавынча, сәнгатьнең халыкка хезмәт итүендә генә түгел, бәлки аның халык тормышы җирлегендә булуыннан, халыкның рухи тәҗрибәсе белән бәйләнгән булуыннан килеп чыга. Шушыны истә тотып, Коммунистлар партиясе әдәбият һәм сәнгатьнең халыкка хезмәт итүе өчен, коммунистик төзелеш интересларына эшләве өчен өзлексез кайгырта, иҗат интеллигенциясенә сизгер карый, идея юнәлеше, партияле, ленинчыл киңәш биреп тора.

Моны без Татарстан өлкә партия оешмасы эшчәнлегеннән дә ачык күрәбез. Партия өлкә комитеты культураны үстерүгә, художество иҗатына партия йогынтысын көчәйтү мәсьәләләренә җитди игътибар бирә. КПСС өлкә комитеты соңгы елларда иҗат яшьләре белән эшне көчәйтүгә юнәлдерелгән чаралар тормышка ашырды, бу мәсьәлә буенча махсус карар кабул итте. КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары актылыгында бу программ документны үтәү барышын карады, иҗат һәм фән учреждениеләренең, матбугатның шактый эш башкарганлыгы күрсәтелде. Партиянең Татарстан өлкә комитетының 1975 елгы отчет докладында әдәбиятның һәм сәнгатьнең совет кешеләрен тәрбияләүдә роле сизелерлек үсүе, иҗат интеллигенциясенең халык тормышы, аның партия билгеләгән бөек планнарны үтәү өчен көрәше белән элемтәсе ныгуы билгеләп үтелде [3].

Байтак еллардан бирле партиянең Татарстан өлкә комитеты каршында иҗат интеллигенциясенең теоретик семинары эшләп килә. Семинар утырышларында әдәбият

---

[1] Шунда ук, 33 том, 206—207 битләр.
[2] К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында, 473 бит.
[3] «Татарстан коммунисты» журналы, 1976 ел, 1 сан, 40—41 битләр.

һәм сәнгать алдында торган мөһим бурычлар кузгатыла, марксистик-ленинчыл эстетиканың актуаль мәсьәләләре күтәрелә.

КПССның XXV съездында Л. И. Брежнев, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә ирешелгән уңышларга тукталып, иҗат интеллигенциясе адресына болай диде: «Талантлы әдәбият һәм сәнгать әсәре — милли байлык ул. Без яхшы беләбез: нәфис сүз, төсләрнең җемелдәве, ташның җанландырылуы, тавышлар гармониясе замандашларыбызны рухландыра һәм киләчәк буыннарга безнең буын турында, заманыбыз турында, аның мәшәкатьләре һәм уңышлары турында йөрәк һәм күңел хатирәләрен тапшыра. Культура эшлеклеләренең — партия членнары һәм партиясезләрнең — тарихыбызга, бүгенге көнебезгә һәм киләчәгебезгә, партиябез һәм халкыбызга, Бөек Ватаныбызга лаеклы яңа әсәрләр иҗат итүен телик» [1].

Марксизм-ленинизм идеяләре белән коралланган партияле совет әдәбияты — социалистик реализм әдәбияты КПССның XXV съезды куйган бурычларны тормышка ашыруда яңа үрләр яулар. СССР язучыларының VI съездында катнашучылар КПСС Үзәк Комитетына язган хатларында аларның иҗади таланты халкыбыз, Ватаныбыз интересларына хезмәт итәчәген белдерделәр.

«Безнең әдәбиятыбыз, социалистик реализм әдәбияты үзенең партиялелеге, идеялелеге, тормышчан пафосы, кешегә, аның иҗади көчләренә ышануы белән көчле. Анда илебез яшәгән, миллионлаган совет кешеләренең тормышы һәм көрәше асылын тәшкил иткән иң мөһим нәрсәләр һәр вакыт чагылыш табачак.

Хәзер Советлар Союзы буенча унынчы бишьеллык — нәтиҗәлелек һәм сыйфат бишьеллыгы атлый. Язучы хезмәте корыч коючы һәм игенче, инженер һәм галим хезмәтеннән аерылгысыз. Сыйфат турында кайгыртуларыбыз да уртак. Менә шуңа күрә безнең съездда әдәби әсәрләрнең идея-эстетик дәрәҗәсен күтәрү, безнең эш нәтиҗәләрен бәяләгәндә таләпчәнлек һәм принципиальлек турында җитди сөйләшү булды. Без әдәби иҗат сыйфатының югары критерийларын аның дөрес идея юнәлешендә, партиялелегендә, социаль фикернең өлгергән булуында, язучы карашының сизгерлегендә, зур профессиональ осталыгында күрәбез. Бу критерийларны җитәкче кулланма итеп алып, күп милләтле совет әдәбияты яңа үрләр яулар, аның алдына КПССның XXV съезды куйган җаваплы идея-иҗат бурычларын үтәр» [2].

Марксизм-ленинизм классикларының әдәбият һәм сәнгатькә караган әсәрләре татар телендә беренче тапкыр зур җыентык итеп чыгарылуы интернациональ сыйфатларга бай булган, милли үзенчәлекләрне исәпкә алып, башка халыклар казанышы белән һаман күбрәк сугарыла барган социалистик культурабызның — татар әдәбияты һәм сәнгатенең алга таба үсешенә зур өлеш кертер.

Җыентыкны төзүчеләр, редколлегия членнары марксизм-ленинизм классикларының әдәбият һәм сәнгатькә караган хезмәтләрен, истәлекләрне, документларны русчадан татарчага төгәл итеп тәрҗемә иткәннәр, аларны бер системага салганнар. Нәтиҗәдә җыентык укучылар ихтыяҗын канәгатьләндерерлек булып чыккан. Бу китап иҗат интеллигенциясенең активлыгын тагын да арттырырга булышыр, аларга дөрес юл күрсәтә торган маяк — идея коралы булып хезмәт итәр.

------------

[1] КПССның XXV съезды материаллары, 80 бит.
[2] «Правда» газетасы, 1976 ел, 26 июнь саны.

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Атилла Расих

# ЯҢА ҮРЛӘРГӘ

„Без бүген, диде партиянең XXV съездында КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре Л. И. Брежнев, — XXIV съездның әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә якын килүе үзен тулысынчааклады, дип әйтә алабыз. Үткән еллар эчендә коммунистик җәмгыять төзү буенча гомумпартия, гомумхалык эшенә һаман күбрәк өлеш кертүче иҗат интеллигенциясенең эшчәнлеге тагын да активлашты.

Бу уңай, рухландыргыч процесс, әлбәттә, илебездә соңгы елларда иҗат ителгән яңа, социалистик реализм әсәрләрендә чагылыш тапты».

Хезмәтебезгә партия тарафыннан бирелгән югары бәя һәр совет язучысын яңа иҗади эзләнүләргә, барлык йөрәк кайнарлыгын салып, туган илгә хезмәт итәргә рухландыра. Шул ук вакытта әлеге бәя, үзүзеңә һәм каләмдәшләреңә тагын да зуррак таләпләр куеп, әдәби хәрәкәттә әле файдаланмаган мөмкинлекләрне эшкә җигүне сорый.

Шул уңайдан минем, каләмдәш дусларым иҗатына күз ташлап, аларның соңгы елларда дөнья күргән роман-повестьларына тукталып узасым килә. Соңгы берничә ел вакыт эчендә милли прозабызның казанышы булып саналырлык байтак әсәрләр язылды. Мисал төсендә Ш. Бикчуринның күптән түгел ВЦСПС премиясенә лаек булган «Каты токым» романын, М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар» һәм Х. Камаловның «һәркемнең гомере бер генә» романнарын, Г. Ахуновның «Ардуан батыр», Ә. Маликовның «Яшьлек утравым», Х. Хәйруллинның «Канатлар талмасын», М. Әмирнең «Балыкчы ялганнары» кебек повестьларын һәм башка әсәрләрне китерергә мөмкин. Төрле алым белән язылган һәм төрле темага караган бу әсәрләрне киң катлау укучылар яратып кабул итте, алар безнең әдәби хәзинәбезгә керде.

Инде узган елда һәм быелгы ел башында басылып чыккан прозабызга күз салсак та, без алар арасында шактый уңышлы әсәрләр очратырбыз. Язучыларыбыз иҗатына югары идеялелек хас, бүгенге әсәрләрдә халыкчанлык рухы көчле. Безнең роман, повесть һәм хикәяләребез хезмәт ияләрен, аерата яшьләрне, коммунистик рухта тәрбияләүдә, һичшиксез, гаҗәеп зур эш башкаралар. Әдәби тел һәм әдәби осталык җәһәтеннән дә үсә баруыбыз ачык күренә.

Ләкин бу әле прозабыз бөтен мөмкинлекләрдән ахырынча файдаланган, әдипләребез камиллекнең иң югары ноктасына менеп җиткән дигән сүз түгел. Әдәби хәрәкәт өзлексез дәвам итә, һәм тормышның үзе кебек үк, ул — бетмәс-төкәнмәс процесс, тукталмый торган күренеш.

Яңа әсәрләр арасында иң күләмлесе Мөсәгыйть Хәбибуллинның «Чоңгыллар» романы булды. Әсәрдә, мәгълүм булганча, бүгенге авыл тормышы, колхоз производствосына алдынгы ысуллар кертү өчен барган көрәш күренешләре сурәтләнә. Тагын шул кадәресе дә бар, моңарчы язган әсәрләре белән чагыштырганда, «Чоңгыллар» романы аның һаман үсүен, әдәби осталыкның яңа биеклекләрен яулау өчен армый-талмый эшләвен күрсәтә. Автор шактый әйбәт әдәби тел белән яза, ул ясаган сурәт төгәл, күркәм чыга. Язучы шулай

үк персонаж теле өстендә дә нык эшли, үзенең тормышны күзәтүләреннән оста файдалана. Аның, вакыйгалар динамикасы белән кызыксындырып, укучыны тиз арада әсир итеп алу сәләтен дә инкарь итеп булмый. М. Хәбибуллин бу әсәрендә табигатьне дә шактый оста итеп сурәтли.

Инде алда бүтән кайбер фикерләрне дәлилләү өчен, аерым детальләргә күз салыйк. Романда вакыйга Татарстанның көнчыгыш районнарының берсендә, гүзәл Ык елгасы буендагы колхозда бара. Әсәрнең беренче битләреннән үк укучы үзен хезмәт, производство конфликтларына корылган роман укырга көйләп куя. Ул әсәрнең өчтән бер өлешенә кадәр әле шундый настроениедә кала бирә, аның игътибарын хуҗалыктагы хезмәт пафосы, фәнни-техник прогресс өчен башланган көрәш кызыксындырганнан-кызыксындыра бара. Укучы шул юнәлештәге коллизияләрнең кульминациясен, чишелешен көтә. Мәгәр берәздән болытлар тарала, күк күкрәү дә, яшен яшьнәү дә булмый кала. Әсәрнең эчтәлеген, су баскандай, башка тема, башка сюжет басып китә, андагы барлык персонажлар уптым-илаһи гашыйк кешеләр булып китәләр, я булмаса тарихи вакыйгаларга кереп баталар. Башта умыртка сөяге итеп куелган төп мәсьәлә, шул рәвешчә, әкренләп сүнә, ә янса — чак сизелерлек булып, пыскып кына яна.

Ә бит әсәрне укыганда техник прогрессның кешеләргә нинди психологик үзгәрешләр китергәнлеген, авыл кешеләренең нинди авырлыклар, нинди каршылыклар кичерүләрен беләсе килгән иде. Ниһаять, алар техник прогресс көн тәртибенә куйган бик катлаулы проблемаларны ничек хәл иттеләр икән? Укучы буларак, боларның барысын да күрәсе килә. Чөнки безнең халык хуҗалыгында барган бу процесс — тарихта моңарчы күрелмәгән бер күренеш. Һәм художникның моны образлар аша күз алдына бастыруы әдәбиятыбыз өчен зур казаныш булыр иде. Романны укып чыкканнан соң, мин ни өчен автор әнә шул юл белән китмәгән, ни өчен ул безгә яңа, тансык бер аш вәгъдә итеп тә, авызга тәме күптән мәгълүм булган, хәтта инде җепкертә башлаган ризык каптыра икән, дип уйланып утырдым. Ниһаять, нинди сәбәпләр аркасында ул баштагы ниятеннән чигенергә мәҗбүр булган? Без бәлки күләмле әсәрнең тоташ бер организм булуын онытып җибәрәбездер? Бәлки романдагы һәрбер сюжет сызыгы, хәтта һәрбер персонаж автор хәл итәргә алынган төп проблемага хезмәт итәргә тиешлеген истән чыгарабыздыр? Минемчә, әсәрдәге һәрбер «чүкеч» бер үк сандалга сугарга тиеш, һәм бу һич тә формаль бер кагыйдә түгел. Моны әсәрнең эмоциональ тәэсире, шул тәэсирнең көчле булырга тиешлелеге таләп итә. Шуңа күрә зур әсәрдәге һәрбер вакыйга, һәрбер сюжет сызыгы органик рәвештә бер-берсен тулыландырырга, автор куйган төп бурычны ачыкларга хезмәт итәргә тиеш. М. Хәбибуллинның хатасы шуннан гыйбарәт: аның әсәр аша укучыга җиткерергә теләгән төп фикере конкрет төс алмаган, тиешенчә формалашып җитмәгән. Төп фикере конкрет булмау аркасында, ул, үзе өчен кызык тоелса да, чынында прозабыз өчен һич яңалык булмаган вакыйгалар белән мавыккан. Нәтиҗәдә әсәрдә чишелергә тиешле сюжет сызыклары колач җитмәс дәрәҗәгә җитеп калынайган. Бу исә, үз чиратында, авторны вакыйгалар өстеннән «юртаклап узарга», информация ысулына күчәргә мәҗбүр иткән. Укучысын кулдан ычкындырмас өчен булса кирәк, автор детектив вакыйгалар белән мавыга, семья, мәхәббәт тирәсендә артык күп чуала башлый.

«Чоңгыллар» романы турында җыеп кына шуны әйтергә мөмкин: вакыйгаларның «бер кояш» тирәсендә әйләнмәве аркасында әсәр шактый нык оттыра. Эшне архитектоник диспропорция боза. Әмма шул кадәресен дә инкарь итәргә ярамый, романда бүгенге авылның сулышы, андагы хәлэхвәлләр шактый ачык сизелә. Әсәрне укыгач, авыл эшчәннәренең фидакарьлекләрен, тырышлыкларын ачык тәсмерләргә була. Әле генә әйтеп узган кимчелекләре булуга да карамастан, «Чоңгыллар» — авторның уңышы, алга баруы.

Хәниф Хәйруллинның «Картлык... кемгә шатлык» исемле повестен да заман темасына язылган җитди әсәрләр исәбенә кертергә була. Бу автор үзенең «Канатлар талмасын» исемле әсәре белән, әйтелгәнчә, безне бер шатландырган иде инде. Яңа повестенда да ул үзе яхшы белгән авыл тормышына мөрәҗәгать иткән. Әсәрдә сүз нигездә ике авыл карты турында бара, аларның мөнәсәбәтләре, язмышлары тасвирлана. Картларның Хәсән исемлесе янып яши, безнең уртак эшебезгә актив катнаша. Икенчесе исә — мыгырданып, сукранып, һәр эштән наразыйлык күрсәтеп яшәүче кеше.

Анысы — Асыл исемле, анысын авыл халкы «контр» дип йөртә. Әйтергә кирәк, повесть Хәниф Хәйруллинга хас куе, җете буяулар белән язылган, үткен сюжетка корылган. Әсәр, шулай ук, гомумән әйбәт тәэсир калдыра. Автор чама хисенә дә тиешенчә ригая күрсәтсә, минемчә, тагы да шәбрәк булыр иде. Бу әсәрдә дә эшне диспропорция боза. Әгәр М. Хәбибуллин романында диспропорция үзәк проблеманы икенче дәрәҗәдәге сюжет сызыклары күмеп китү рәвешендә булса, биредә ул тискәре образның артык үзенчәлекле, артык колоритлы фигура булып чыгуында күренә. Аңлашыла ки, автор үзенең Асылы аша уңай персонаж булган Хәсән бабайны калкурак итеп бирергә тырышкан. Ләкин, кызганычка каршы, нәтиҗә киресенчә килеп чыккан. Асыл үзенең карачкыдай котсызлыгы белән бөтен әсәргә күләгә ташлый. Ул, авторның теләгенә буйсынмыйча, алгы планга бәреп чыга һәм әсәрнең төп атмосферасын беркадәр бозып ташлый. Шуның аркасында уңай персонаж Хәсән шактый пассивлашып, мескенләнеп кала.

Асыл — ачу китергеч дәрәҗәдә кире беткән бәндә. Ләкин ул нинди сәбәпләр аркасында шундый кешегә әйләнгән соң әле? Аның социаль йөзе нидән гыйбарәт? Бу сорауларга әсәрдән җавап табу кыен. Авторга ышансак, моңа төп сәбәп — Асылның батрак чагындагы кичерешләре. Явыз авыл байгурасы Габдрахман вакытында Асылга карата зур гаделсезлек күрсәткән — ул һич гаепсезгә вәхшиләрчә җәзаланган. Шуннан соң Асыл кешеләргә карата ышанычын югалткан. Аның «канатлары» сынган, янәсе. Ул шундый ерткычка әйләнә ки, хәтта авыру әнисенең һәм сеңлесенең ризыкларын талап ашау дәрәҗәсенә җитә. Ярлылар комитетының җитәкчесе булып эшләгәндә авылдашларына карата төрле гадәтсезлекләр күрсәтә. Инде картаймыш көннәрендә дә ул бөтен тирәюненә агу чәчеп яши. Ул безнең кимчелекләребезне чәйнәү белән хозурлана, шуннан үзенә җан азыгы таба...

Менә шушы кеше үлгәч, гомере буена мәрхүмгә ярдәм итәргә тырышкан Хәсән өчен күңелсез булып китте, ди автор. Чөнки Хәсән шул Асыл белән бәхәсләшә-бәхәсләшә җенләнеп эшли иде әле, ди. Янәсе, Асыл үлгәч аны илһамландыручы көч беткән. Сәер нәтиҗә, минемчә! Сүз дә юк, авторның таланты тирән психологик анализга омтыла. Ләкин аның артык рационалистик карашлары күренешне дөрес бәяләүгә комачау ясый булса кирәк.

Яшь язучы Әхәт Гаффаров «Теге гозер» исемле яңа повестен бастырды. Мин бу яшь, сәләтле һәм эзләнүчән авторны, Хәниф Хәйруллин кебек үк, иҗатында психологизмга омтылучы авторларыбызның берсе дип әйтер идем. Моны авторның 1975 елны дөнья күргән «Әҗәт» исемле җыентыгы раслый. Яңа әсәрендә дә ул шул үзенчәлеген күрсәтергә тырышкан.

Сыер сатып алырга теләп, авылдан-авылга йөри торгач, Җиһангир карт бер рус авылында Наталья исемле рус хатынын очрата. Баксаң-күрсәң, алар бу хатын белән күптән танышлар икән. Карт кайчандыр аңа печән калдырган булган, тол хатын исә шуның өчен аның «күкрәгенә капланган... суырып үпкән.»

Ләкин Җиһангирның Натальяга мөнәсәбәте моның белән генә бетми әле. Ул фронтка, Бөек Ватан сугышы елларына барып тоташа. Җиһангир Натальяның ире белән бергә хезмәт иткән, бу хатынның ире аны үлемнән коткарган. Соңыннан Җиһангирга: «Минем гаиләмне ташлама» дип үзенең үтенечен, гозерен әйтеп калдырган. Ә Җиһангир фронтовик дусына карата зур хыянәт эшләгән, аның гозерен үтәмәгән. Карт фронтовик дустының стенадагы фотокарточкасын күргәч кенә үзенең нинди зур җинаять ясаганлыгын аңлый. Җиһангир карт вөҗдан газабы кичерә башлый. Хатынга берәр яхшылык эшләү нияте белән ул сыерны сатып ала, акчаны тиешеннән артыгы белән бирергә тели. Ләкин болар берсе дә вакытында эшләнмәгән...

Ниһаять, чишелеш. Юлда зоопарктан чыгарылган бүреләр очрап Җиһангирга да, сыерга да һөҗүм итәләр. Карт бирешмәскә тели, ләкин соңыннан бер бүре белән көрәшкән арада сыерын ычкындырырга мәҗбүр була. Сыерны бүреләр ботарлап ташлый. Карт битен сыдыртып мең бәла белән өенә кайтып егыла. Менә хикәянең кыскача эчтәлеге.

Автор сөйләнгән вакыйгаларны узгандагыларны искә төшерү, уйланулар, кичерешләр белән бәйләп бирә. Авторның эзләнүе, ниндидер яңа форма табарга тырышуы хәтта үзе дә сизмәстән, күрәсең, кайбер көнбатыш язучыларына ияреп куюы сизелә. Мин яшьләрнең эзләнүенә һич каршы түгел. Без барыбыз да яшьлектә эзләндек. Әгәр ул талантлы булса, эзләнә торгач, яшь кеше күп очракта үзенең стилен, үз алымын таба. Ләкин эзләнүләр, минемчә,

гасырлар буе сыналган, табылган магистраль кагыйдәләр рамкасында булырга тиеш. Яшь әдип иң беренче чиратта гади итеп язарга өйрәнсен. Максим Горькийның мәрхүм Кави Нәҗмигә «гадирәк язарга тырышыгыз» дип әйткәннәрен онытмаска кирәк безгә. Телебез берсе өстенә икенчесен, өченчесен атландырган авыр, катлаулы эпитетларны яратмый. Шулай ук чагыштыруларның да хәл-шәкелне күз алдына төгәл китерү чарасы икәнен онытмыйк. Инде Әхәт Гаффаров «хатынның пышылдавы, миләшкә сарышкан колмакның уч-уч эре яфрагына шыбырдап яуган яңгыр шавы кебек, җанны изрәтеп ишетелде», дип яза икән, ул бу чагыштыруы белән, минемчә, куйган максатыннан ераклаша гына. Чөнки мин ниндидер хатынның пышылдавын җанландыру өчен, миләш агачын, эре яфраклы колмакны, шыбырдап яуган яңгырны күз алдына китерергә тиеш булам. Прозада катлаулы итеп, кыландырып, чәчәкле-чуклы итеп язуга каршы без кискен сүзебезне әйтергә тиеш. Чөнки мондый чир аерата йогышлы. Ә сүз уйнату белән шаккатырырга тырышу әдәбиятта иң ансат, ләкин бәрәкәтсез бер юл.

Моңарчы сүз әсәрнең формасы, аның язылу манерасы хакында барды. Инде эчтәлеккә, автор куйган төп максатка күз ташлыйк. Җиһангир карт, Натальяның сыерын алып кайтканда бүреләр өеренә очрап, әйткәнебезчә, казалы була. Нәрсә бу, аңа җәзамы? Автор шуны әйтмәкче буламы? Җәза булса, ни өчен ул сукыр язмыш тарафыннан эшләнә?.. «Теге гозер» повестен укыганда туган тагы бер фикер белән уртаклашасы килә. Минемчә, без кайчагында матур әдәбиятның сәнгать икәнлеген, нәфасат дөньясы икәнлеген онытып җибәрәбез. Әлбәттә, без эстетлар түгел, без реалистлар. Ләкин шул ук вакытны әсәрләребезнең укучыга эстетик тәрбия бирергә тиешлеген дә онытмыйк. Ә инде язылганнар тормышчан булсын дип, тормышта була торган һәрбер күренешкә әсәрдә юл ачыла икән, моның белән укучының эстетик зәвыгын үстереп булыр микән? «Сыер аркасын бөкрәйтеп, койрыгын күтәрде дә туктап калды», — диелә повестьта. Аннан: «Ерак юлга чыгар алдыннан кеше дә йортында бер эшен эшләүчән, — дип уйлана карт. — Малныкы да кешечә. Сизә, күрәмсең.» Аннан карт үзе дә, бияләйләрен салып, аларны билендәге шарфка кыстыра да, тун итәкләрен кайтарып сала. Бу детальнең әсәргә ямьсезлектән башка берни дә өстәмәве бәхәссез нәрсә.

Яңа проза әсәрләребезнең байтагы тарихи материалга нигезләнгән. Шартлы рәвештә аларны ике төркемгә: совет чорына һәм революциягә кадәрге көннәргә багышланган әсәрләргә бүлеп йөртергә мөмкин. Сүзне якынрак тарихтан башласак, без иң элек Аяз Гыйләҗевның «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» дип исемләнгән әсәренә тукталырга тиеш булырбыз. 1974 елда Аяз Гыйләҗев безне «Язгы кәрваннар» исемле шәп повесте белән шатландырган иде. Бу повесть та А. Гыйләҗев иҗатына хас булганча, романтик планда язылган. Берникадәр серлелек, бераз гына моңсулык аңкый әсәрдән. Әйе, шундый манерда язу А. Гыйләҗевка хас нәрсә. Аның хикәяләү үзенчәлеге шул. Бу очракта да авторның үз алымыннан оста, такт белән файдалана белүе күзгә ташлана. Повестьта әйбәт эшләнгән детальләр күп, образларның тормышчанлык дәрәҗәсе дә тел-теш тидерерлек түгел. Сюжет та бик тыгыз һәм төгәл эшләнгән. Хикәяне укыгач, мәхәббәт белән нәфрәтнең янәшә яши алмавына, кагыйдә буларак, я теге, я бу якның җиңелүе белән бетәчәгенә ышанасың. Әсәрнең кыйммәте тагын шунда, ул укучыда якты хисләр, оптимистик тойгылар уята. Әсәр чын мәхәббәтнең тантанасы белән тәмамлана.

Аяз Гыйләҗевның элеккерәк еллардагы әсәрләренең теле берникадәр шивәчелек һәм жаргончылык белән чуарланган була торган иде. Бу әсәрендә ул, сүз сайлауда талымлылык күрсәтеп, сүзнең яңгырашы, мәгънәлелегә һәм шулай ук киң катлау укучыга үтемлелеге турында уйлап эш итә. Кыскасы, повесть — авторның уңышы. Минем биредә Аяз Гыйләҗевка бер теләк белдерәсем килә. Аның соңгы еллардагы проза әсәрләре тематик яктан чикләнә башлады, алар барысы да нигездә сугыш елларындагы авыл тормышына кайтып калалар. Күрәсең, бу чор Аязлар буынына героик эшләре белән дә, үзенең трагизмы белән дә бик якын. Ләкин шуны да онытмаска кирәк, сугыш елларындагы үсмерләр турында байтак язылды бит инде. Укучы тематикабызның төрләнүен көтә.

Вакыйф Нуруллинның «Яшьнәп үткән яшьлек» исемле яңа әсәрендә автор бөтенләй яңа чорга, яңа темага мөрәҗәгать итә. Повестьта гражданнар сугышы еллары,

авыл җирендә Совет властен урнаштыру өчен барган героик көрәш сәхифәләре чагыла. Дөрес, бу — безнең әдәбият өчен яңа тема түгел. Гражданнар сугышы елларының пафосын Галимҗан Ибраһимовтан алып безнең замандашыбыз һәм каләмдәшебез мәрхүм Ибраһим Газига кадәр чорда яшәгән бик күп татар язучылары әйбәт итеп чагылдырдылар, классик әсәрләр язып калдырдылар. Ләкин гражданнар сугышы ул — бетмәс-төкәнмәс бер тема. Бүгенге каләм остасы, шул материалдан дөрес файдаланып, укучы өчен шәп яңа әсәр яза икән, без моны хуплап каршы алырга тиеш. Хикмәт шунда, һәр язучы бер үк тарихи этапны үзенчә күрә, үз художниклык призмасы аша чагылдыра. Бу әсәрдә дә без шул искиткеч вакытларның яңа чагылышын тоябыз: вакыйгаларның кискен, югары темптагы агышы, үткен сюжет, беркадәр шартлылык...

Автор бу әсәрен яшь укучыга адреслап язган төсле. Әсәрнең маҗара жанрына хас алымы повестьны укый башлау белән үк күзгә ташлана. Минемчә, бу бер дә начар түгел. Безнең олы яшьтәге балалар әдәбияты нәкъ менә шундый маҗаралы әсәрләргә аеруча мохтаҗ. Әмма монда бер «ләкин» бар, автор моны аңлы рәвештә эшләмәгән булса кирәк. Ул үзеннән-үзе шулай килеп чыккан кебек. Әгәр башта ук шундый максат куелган булса, Вакыйф Нуруллин повестен эпик әсәрләргә хас документлар белән артык җитдиләштерергә тырышмас иде.

Әсәр гомумән җиңел укыла. Теле — Вакыйфка хас төгәл, образлы тел. Кимчелекләргә килгәндә, мин, адресаты анык булмаудан тыш, тагы информациянең күбрәк булуын да әйтеп узар идем. Шулай ук очы-очка ялганмаган тарту-сузулар да, шартлылык та чамадан артыграк булса кирәк. Инде килеп, кемгә генә адресланмасын, әсәргә дигән материал, вак детальләренә кадәр, автор тарафыннан бик нык өйрәнелергә тиеш. Әйтик, автор, «жандарм Миңнулланы бер хатынның акчасын тартып алган өчен кулга алды» — дип яза икән, мин инде әсәрне сагаеп, андагы вакыйгаларга ышанмыйчарак укый башлыйм, чөнки беләм, жандармерия вак уголовный эшләр белән шөгыльләнмәгән. Аның эше — политик җинаятьчеләрне эләктерү. Әсәрдә әнә шундый характердагы кимчелекләр дә очрый.

Тагын ике авторыбыз безнең өчен бик кадерле ике тарихи шәхес турында әсәрләр иҗат иттеләр. Мин биредә Г. Мөхәммәдованың «Яшьлек көннәре» дигән повестен һәм Ә. Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе»н күздә тотам.

Гөлсем Мөхәммәдованың әсәре бөек әдибебез Галимҗан Ибраһимовның яшьлек чорын тасвирлауга багышланган. Повестька материал булып бөек язучының истәлекләре, биографик материаллар гына түгел, хәтта әдәби мирасы да хезмәт иткәнлеге шактый ачык күзгә ташлана. Әсәрдә шул заманның мохиты, тормыш детальләре, хосусән, Уфа, Оренбург шәкертләре тормышы шактый тулы чагыла. Әсәрнең кыйммәте, минемчә, хәзерге укучыга ул заманның татар тормышына кагылышлы бик күп үзенчәлекләре турында фактик материал хәбәр итүендә. Әсәрдә биографик детальләрнең дөрес, төгәл чагылуы бик нык күздә тотылган. Ул хәтта Галимҗан Ибраһимовны, образ буларак, күз алдына бастыру, аның эчке дөньясын күрсәтү өчен тырышмый да кебек. Күрәсең, шуңа күрәдер, повесть, сәнгать әсәре булудан да бигрәк, төп персонажның тормыш юлын чагылдырган очеркка тартым булып чыккан.

Бу әсәр уңае белән берничә мәсьәләгә игътибарыгызны юнәлтәсе килә. Әсәрләребезнең жанрын билгеләү эшенә без кайчак җиңелрәк карамыйбызмы икән? Шулайрак кебек. Нәтиҗәдә кулына яңа каләм алган кеше, әйдә, роман дип куйсам да, повесть дип куйсам да ярый бит дип уйлый башлый. Роман язу ни өчендер (сыйфатын исәпкә алмаган хәлдә) повестьтан мәртәбәлерәк бер эш санала. Шуңа күрә, кайбер авторлар повестена роман, очеркына повесть дип куюны бернигә санамыйлар.

Икенче бер мәсьәлә шуннан гыйбарәт: без, минемчә, тарихи әсәрләрдәге тискәре персонажларны артык ахмакландырып, карикатуралаштырып сурәтлибез. Мәсәлән, «Картлык... кемгә шатлык» әсәрендә Габдрахман бай Асылны кое сиртмәсенең очына бәйләп өч тапкыр җиргә китереп бәрә. Әле сүз алып барган повестьта Заһидулла хәзрәт, Галимҗан Ибраһимовны хурлыкка калдыру өчен, аның сандыгына бер шешә аракы һәм шәрә марҗа рәсеме сала. Һәм болар барысы да кеше күз алдында диярлек эшләнә. Минемчә, сыйнфый дошман вәкилләре үзләренең ахмаклыкларын, ерткычлыкларын шулай ачыктан-ачык күрсәтеп торганнар икән,

кемнәрнеңдер аларны фаш итү өчен гасыр буе көрәш алып баруы нигә кирәк булган соң?!.

Әмирхан Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» дөньяга килергә тиешлелеге укучыга күптән мәгълүм иде. Чөнки автор эшкә керешкәч тә, матбугатта аның хәбәре чыгып өлгерде. Шуңа күрә дә бу әсәр зарыгып көтеп алынды. Моның, әлбәттә, сәбәбе дә бар иде. Чөнки әсәрдә сүз Сәйдәш турында барачак — үзенең кабатланмас, тылсымлы көйләре белән күңелләребезне яктыртып торучы бөек композитор, татар профессиональ музыкасына юл салучы Сәйдәш турында барачак иде. Ниһаять, әсәр басылып чыкты, укучы аның белән танышты һәм әсәр турындагы фикерләр ишетелә башлады. Берәүләр, әсәр уңышлы, ди, икенчеләре исә, җилкәләрен җыерып, анда Сәйдәш юк бит, диләр. Ни өчен шулай килеп чыкты соң әле?.. Сүз дә юк, әсәр Әмирхан Еникигә хас зур осталык белән язылган. Берниндиартыклык, берниндидорфалык күзне тырнамый, һәрбер хәл-вакыйга — камил, ышандырырлык, төгәл. Әсәр җиңел укыла. Гөләндәм туташ, аның әти-әнисе, аларның асрау кызлары — барысы да истә кала торган персонажлар. Яшь Салих Сәйдәшев образы да истә кала. Ләкин, кызганычка каршы, ул менә без, укучы масса, күз алдына бастырган рәвештә җанланмый. Ул, минемчә, әсәрдәге төп персонажның саф, эчкерсез мәхәббәтен күрсәтү өчен бер сылтау гына кебек төсмерләнә. Бирелә хикмәт авторның факт дөреслеге белән сәнгать дөреслеге арасындагы аермага тиешле игътибар биреп җиткермәвендә булса кирәк. Әсәргә искәрмәдән мәгълүм булганча, бу кыска романның нигезендә бер ханымның истәлекләре ята. Язучы әсәрнең шул язмаларга туры килүен төп максат итеп куймадымы икән? Юкса, ул чорның сулышы, илдә барган революцион яңарыш давыллары күбрәк, көчлерәк сизелер иде кебек. Бер генә мисал: сак астында яшәгән диндар бер кешенең кызы Гөләндәм, беренче тапкыр сәхнәгә чыгып, халык алдында җыр җырлый. Бу бит кимсетелгән татар кызы өчен искиткеч бер каһарманлык. Ул гомерендә беренче тапкыр иҗтимагый әһәмияткә ия булган эш башкара. Ләкин язучы моңа тиешле бәяне бирми, ул турыда сүз кузгатмый, истәлекнең авторына иярә, кызны сырхауландыра, укучыга вакыйганың иң мөһим ягы турында уйлану өчен азык бирми. Әсәрдә Сәйдәшнең артык тыйнаклыгы, шома интеллигентлыгы да авторның шулай ук тышкы кабыкка, күзгә ташланган беренче фактка артык ригая белән каравыннан килеп чыкмадымы икән?

Көндәлек матбугатта һәм нәшриятыбызда күп булмаса да хикәяләр басылды. Сүз хикәя турында кузгалган саен без хикәя аз басыла дип зарланабыз. Күрәсең, хикәяне сөюче һәм оста итеп яза белүче талантлы әдипләребез азрактыр. Һәркемнең үз амплуасы. Инде әдәби журналыбыз «Казан утлары»нда бер ел эчендә басылган биш хикәяне күздән кичерсәк, без анда теманың төрлелеген абайларбыз, биш авторның бишесе дә үзенчәлекле манерада язганлыгын күрербез. Бу, әлбәттә, күңелле күренеш. Хикәяләр гомумән әйбәт тәэсир калдыра. Әмма баштаук гомуми бер нәтиҗә ясыйсы килә. Хикәяләребез күп очракта повестька тартым артык күп планлы булып чыгалар. Без, минемчә, әйтеләсе саллы сүзебезне бер сюжет фокусына җыеп әйтүгә тиешле игътибар биреп бетермибез. Шуның аркасында хикәянең эмоциональ тәэсир көче җитәрлек булмый.

Үзенең җыйнаклыгы белән бу җәһәттән Фатих Хөснинең былтыргы «Мичче Гыйният» исемле әсәре аерыла. Анда сүз гаиләсенә җиңелрәк караучы, дуамалрак табигатьле мич остасының акылга утыруы, шактый «хикмәтле» эшләр башкарганнан соң өенә, хатыны янына кайтып тынычлануы турында бара.

Барлас Камалов үзенең төзек һәм матур тел белән язылган «Җир хакы — ир хакы» исемле хикәя-монологында Минһаҗ картның кичерешләре, кызының акылсызлык эшләп, семьясын җимерүе аркасында туган көенүләре тасвирлана. Күрәсез, хикәяләрнең икесе дә совет семьясын ныгыту проблемасын күтәрәләр. Кирәк, файдалы тема. Ләкин, минемчә, Барлас Камалов хикәясенә бераз гына җыйнаклык һәм сюжет киеренкелеге җитенкерәми. Габдулла Шәрәфинең «Аккошлар кайтыр әле» исемле хикәясе табигатьне саклау, бу эштә җәмәгатьчелекнең һәм җирле совет оешмаларының роле турында. Ул җанлы, күңелле, матур детальләр белән бизәкләнгән. Тик автор аны артык озынга сузган. Җыйнаграк булса, әсәр тагы да тәэсирлерәк булыр иде.

Саналган хикәя авторларының байтагы — шагыйрьләр. Шигырь осталарының проза бакчасына килүен без дүрт куллап, шатланып каршылыйбыз. Алар арасында

прозага шактый өлеш кертүчеләр аз түгел. Шундыйларның берсе — Сәҗидә Сөләйманова. Ул менә берничә елдан бирле инде шәп кенә хикәяләр дә биреп килә. Аның аерым китап булып чыккан «Мәхәббәт сынавы» исемле хикәяләр җыентыгы шул турыда сөйли. «Казан утлары» журналында аның «Сагы барның сагы ятар» исемле хикәясе чыкты. Хикәядә миңа ошаган нәрсә — ул да булса бүгенге эшче образының гәүдәләнеше. Әгәр дә автор ул персонажны алгы планга чыгарып күрсәтсә, әсәр тагы да отышлырак булыр иде.

Проза өлкәсендә шактый актив эшләүче тагын бер шагыйрь бар. Ул — Фаил Шәфигуллин. Фаил, ике жанрга да тирән мәхәббәт белән карап, соңгы вакытларда аларның икесендә дә билгеле бер дәрәҗәдә уңышка ирешә. «Әкълимәгә исле май» исемле хикәясе, мәсәлән, лирик планда язылган, саф мәхәббәткә дан җырлый һәм укучыда әйбәт тәэсир калдыра. Авторга бер теләк белдерәсе килә: ул тематикасын киңәйтә төшсен иде. Без, мәсәлән, аның эшчеләр тормышы белән яхшы таныш булганлыгын беләбез бит...

Эшчеләр тормышы димәктән, бу уңай белән мин «Казан утлары»нда басылган бер әсәргә тукталмый кала алмыйм. Ул — Җәмит Рәхимовның «Өлешемә тигән көмешем» исемле повесте. Билгеле, әсәр аерым җентекләп тикшерүне сорый. Ләкин башта ук әйтәсе килә: ул — безнең прозабыз өчен сөенечле бер күренеш. Кайбер кимчелекләренә дә карамастан, яшь авторның нефтьче эшчеләр тормышына багышланган әсәре үзенең кешелеклелеге, сафлыгы белән күңелне җылыта, рәхәт бер тойгы калдыра.

Бүгенге прозабызның җитлеккәнлеге һәм бөтенсоюз әдәбиятында күренекле бер урын тотканлыгы да мәгълүм. Бу, минемчә, югарыда саналган әсәрләр исемлеге белән дә расланa ала. Ләкин минем ихлас күңелдән ышануымча, безнең мөмкинлекләребез тагын да зуррак. Без идея җитлеккәнлеге һәм художество осталыгы җәһәтеннән тагы да югарырак үрләр яулап алырга сәләтле. Моны бездән укучыбыз һәм партиябезнең XXV съезды күрсәтмәләре таләп итә.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

СССР язучыларының VI съезды йомгаклары һәм республикабыз әдипләре алдында торган бурычлар... Татарстан язучыларының июль аенда уздырылган партия җыелышында сүз әнә шул турыда барды. Съезд материаллары яктылыгында әдипләребез алдына куелган бурычлар хакындагы докладны съезд делегаты, Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ясады. Аның докладында күтәрелгән мәсьәләләр буенча фикер алышуда язучылардан Атилла Расих, Сибгат Хәким, Ләбибә Ихсанова, Рафаэль Мостафин, Мирсәй Әмир иптәшләр катнашты һәм ул бурычларны ничек тормышка ашыру юнәлешендә конкрет тәкъдимнәр керттеләр. Шулар нигезендә җыелыш тиешле карар кабул итте.

Шул ук җыелышта Тынычлыкны яклауның Бөтендөнья Советы Өндәмәсе турында да җитди һәм эшлекле сөйләшү булып, республикабыз әдипләре барысы да бертавыштан ул Өндәмәне хупладылар һәм имзаларын куйдылар.

## ИДАРӘ УТЫРЫШЫНДА

Язучылар союзы идарәсенең чираттагы утырышында идарәнең ярты еллык (июль-декабрь) эш планы тикшерелде һәм расланды, союз каршындагы пропаганда бюросы директоры Эльс Гаделевнең отчеты тыңланды. Аның отчеты буенча фикер алышуда идарә члennарыннан Мирсәй Әмир, Зәки Нури, Гомәр Бәширов, Азат Әхмәдуллин, Гариф Ахунов, Вакыйф Нуруллин, Туфан Миңнуллин һәм Әхсән Баянов иптәшләр катнашты. Алар әдәбиятны пропагандалау эшендә уңай якларны күрсәтү белән бергә, күп кенә җитешсезлекләр булуын да искәртеп киттеләр. Бюроның директоры идарә членнары тәнкыйтенең урынлы булуын әйтте һәм күрсәтелгән кимчелекләрне бетерү өчен бөтен көчен куеп тырышырга сүз бирде.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ АРХИВЫ ТУЛЫЛАНДЫРЫЛДЫ

Муса Җәлил шәхси архивының күп өлешен шагыйрьнең хатыны Әминә ханым 1957 елда ук Казанның Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтына тапшырган иде инде. Бу елның август аенда шагыйрьнең институттагы архивы тагын да тулыландырылды: Әминә ханым Җәлилова Муса Җәлил кульязмаларының моңарчы үзендә сакланганнарын да институтка тапшырды. Ул тапшырган кульязмалар арасында шагыйрьнең «Илдар» поэмасының либреттосы, «Авыру комсомолец» поэмасының оригиналы, «Алтынчәч» операсының караламалары һәм әлегә кадәр басылмаган күп кенә шигырьләре бар.

Муса Җәлилнең кульязмаларын институт архивына тапшыру тантанасында язучылардан Гариф Ахунов, Сибгат Хәким, Мөхәммәт Гайнуллин, Нил Юзиев, Вакыйф Нуруллин, институт директоры урынбасары Азат Әхмәдуллин һәм институтның күп кенә фәнни хезмәткәрләре катнашты. А. Әхмәдуллин, Г. Ахунов, С. Хәким, М. Гайнуллин шагыйрьнең кульязмаларын тапшыру вакытында чыгыш ясап, Әминә ханым Җәлиловага шагыйрьнең архивын кадерләп саклаганы өчен рәхмәт әйттеләр һәм тапшырылган кульязмаларның киләчәктә Муса Җәлил иҗатын тулыландыруга ярдәм итәчәгенә ышаныч белдерделәр.

Соңыннан А. Әхмәдуллин Әминә ханым Җәлиловага Муса Җәлилнең институт галимнәре тарафыннан әзерләп бастырып чыгарылган дүрт том әсәрләрен бүләк итте.

## ШАГЫЙРЬГӘ ҺӘЙКӘЛ

Шушы елның 25 августында Минзәлә шәһәренең Ленин комсомолы исемендәге паркында Ленин премиясе лауреаты, Советлар Союзы Герое шагыйрь Муса Җәлилгә һәйкәл куелды. Ул һәйкәлне ачу тантанасында, Минзәлә районы укытучылары, шәһәрнең күп санлы хезмәт ияләре һәм район җитәкчеләре белән бергә, драматург Риза Ишморат һәм шагыйрь Рәшит Гәрәй дә катнаштылар. Р. Ишморат тантанага килгән кешеләргә шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында сөйләде, Р. Гәрәй үзенең М. Җәлилгә багышлап язылган шигырен укыды.

## БАЙКАЛ — АМУР МАГИСТРАЛЕ

Июль азагында илебезнең төрле республикаларыннан һәм өлкәләреннән җыелган 40 язучы Иркутск өлкәсендә совет әдәбияты көннәрендә катнаштылар. Бу — СССР язучыларының VI съездыннан соң зур төзелешләргә әдипләрнең беренче мәртәбә чыгуы булды.

Делегацияне СССР Язучылар союзы секретаре шагыйрь Роберт Рождественский җитәкләде. Әдәбият көннәрендә катнашучылар арасында Социалистик Хезмәт Герое, Ленин премиясе лауреаты М. Стельмах (Украина), грузин шагыйре И. Нонешвили, «Аврора» журналының баш редакторы В. Торопыгин, РСФСР Дәүләт премиясе

корт шагыйре Р. Сафин һәм башкалар бар иде.

Әдәбият көннәрендә катнашучылар Иркутск шәһәренең төрле предприятиеләрендә, культура йортларында, завод-фабрикаларында чыгыш ясаганнан соң, биш бригадага бүленеп, өлкә белән җентеклебрәк танышу өчен чыгып киттеләр. Биш бригаданың берсен РСФСР Язучылар союзы секретаре, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов җитәкләде. Группа украин язучысы Иван Гайдаенко, Ленинград шагыйре Сергей Давыдов, Мәскәү шагыйрьләре Сергей Поликарпов, Дмитрий Ковалев, кыргыз шагыйре Омар Солтанов, үзбәк шагыйрәсе Хәлимә Ходайбирдиева, Читада яшәүче балалар язучысы Георгий Граубин иптәшләрдән тора иде. Алар Иркутск өлкәсенең Бурят милли округында, Казачинск-Магистральный-Өлкән поселокларында, ягъни Байкал — Амур магистраленың бер өлешендә булып, атаклы магистральне төзүчеләр, аларның тормышлары, культура-көнкүрешләре белән таныштылар, БАМны төзүчеләр алдында чыгышлар ясадылар.


БАМда башка халык вәкилләре белән бергә безнең якташлар да җиң сызганып эшли. Алар арасында күпер салучылар, урман кисүчеләр, бетончылар, трактор йөртүчеләр, көнкүрештә эшләүчеләр, сәнгать әһелләре һәм яшь шагыйрьләр бар.

## ЛАОС ЦИРКЫ КАЗАНДА

Август аенда Лаос Халык Демократияcе Республикасы циркы Казанга гастрольгә килде. Әле узган ел гына оештырылган һәм күбесе яшьләрдән (18—19 яшь) торган кырык сигез артистны берләштергән бу коллектив башкарган номерларны шәһәребез тамашачылары яратып карады.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ЮБИЛЕЕ УҢАЕ БЕЛӘН

Инде журналыбызда хәбәр ителгәнчә, СССР Язучылар союзы идарәсе шагыйрь Габдулла Тукайның 90 еллыгын бөтен союз күләмендә билгеләп үтү турында карар кабул иткән һәм юбилей комиссиясе төзегән иде. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычны уңышлы итеп башкарып чыкты: шагыйрьнең 90 еллыгы союз күләмендә киң билгеләп үтелде. Юбилей көннәрендә «Советская культура», «Литературная газета», «Литературная Россия», «Советская Россия» газеталарында КПСС өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев, әдипләребез С. Хәким, Г. Ахунов, Н. Юзиевләрнең Тукай иҗатына багышланган мәкаләләре басылды. Шагыйрь иҗаты хакындагы мәкаләләргә илебезнең төрле республикаларында һәм өлкәләрендә басыла торган газета-журналлар да мул урын бирде. Атап әйткәндә, «Волга», «Агыйдел», «Огонёк», «Литературный Азербайджан», «Жулдыз», «Шарк юлдузи», «Гәлстан», «Витчизна», «Мәдәниет және турмыс», «Карогс», «Төрекмәнстанның халык мәгарифе», «Азербайҗан», «Молот», «Ончыко» журналларында һәм күп санлы



*Минзәләдә М. Җәлилгә куелган һәйкәл.*

газеталарда Тукай турында мәкаләләр һәм чыгышлар, шагыйрьнең әсәрләре басылды.

* * *

Мәскәү — Казан — Уфа... Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай исемендәге теплоход әнә шул маршрут буенча йөри. Идел һәм Агыйдел елгалары буйлап туристлар йөртә ул. Теплоход командасы шагыйрь истәлеген бик нык хөрмәт итә. Теплоходта Тукайның тормышын һәм иҗатын чагылдырган махсус стенд бар. Теләгән сәяхәтчеләр, теплоход китапханәсеннән алып, шагыйрьнең татар һәм рус телләрендә басылган әсәрләрен укый алалар.

Габдулла Тукайның 90 еллыгы уңае белән теплоходта шагыйрьнең иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә оештырылды. Ул көнне теплоход Мәскәүнең Химки елга портында тукталган иде. Кичәдә катнашучыларга Мәскәүдә яшәүче шагыйрь-тәрҗемәче һәм тәнкыйтьче Вил Ганиев шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында сөйләде. Соңыннан Мәскәү дәүләт филармониясе артистлары В. М. Солнцева, В. С. Калужский, О. М. Измайловлар катнашында концерт бирелде.

## ЖУРНАЛНЫҢ ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

Республикабызда басыла торган «Азат хатын» журналының чыга башлавына 50 ел тулуын, шул уңай белән һәм Татарстан хатын-кызларын коммунистик тәрбияләү өлкәсендә нәтиҗәле эшләве, аларны хуҗалык төзелеше бурычларын үтәүгә актив туплавы өчен, бу журналның «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнгәнлеген алдагы санда укучыларыбызга хәбәр иткән идек инде. 20 августта Казанның Төзүчеләр культура сараенда «Азат хатын» журналының 50 еллыгына багышланган тантаналы кичә үткәрелде. Журналның күп санлы укучылары һәм язучылар җыйналган кичәдә КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Ә. Табеев, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев, ТАССР Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов, КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, профсоюзларның Татарстан өлкә советы председателе С. Г. Сафин, «Советская женщина» журналының баш редакторы В. И. Федотова, «Крестьянка» журналының баш редакторы И. А. Кобчикова, «Работница» журналының бүлек мөдире Т. Н. Поликарпова иптәшләр дә катнашты. Кичәне КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова ачты. КПСС өлкә Комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы исеменнән юбилярны КПСС өлкә комитетының беренче секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы члены Ф. Ә. Табеев чын күңелдән котлады һәм журнал байрагына «Почет билгесе» орденын беркетте.

«Азат хатын»ның илле еллыгы турындагы докладны журналның баш редакторы А. Ф. Хәсәнова ясады. Аннары республикабызның төрле оешмалары вәкилләре журналны ярты гасырлык юбилее белән тәбрик иттеләр, котлау адреслары, бүләкләр, тапшырдылар.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Тугызынчы бишьеллыкта совет фәнен үстерүдә ирешкән уңышы өчен СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән гыйльми сотрудникы, профессор, СССР Язучылар союзы члены **Мөхәммәт Хәйрулла улы Гайнуллин Хезмәт Кызыл Байрагы** ордены белән бүләкләнде.

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 50 яшь тулу уңае белән, язучы **Хисам Нуретдин улы Камалов КПСС өлкә комитетының һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Почет грамотасы** белән бүләкләнде.

* * *

Совет матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен, «Азат хатын» журналының җаваплы секретаре **Габдулла Шәрәфетдин улы Шәрәфетдиновка**, журналның әдәби хезмәткәрләре **Кояш Закир кызы Тимбикова һәм Мәдинә Габделхак кызы Маликовага Татарстан АССРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет матбугатында актив һәм нәтиҗәле эшләүләре өчен һәм «Азат хатын» журналының илле еллыгы уңае белән, ТАССР Верховный Советы Президиумы әлеге журналның редколлегия членнары **Наилә Закир кызы Закированы, Сәҗидә Гаделша кызы Сөләймановны**, журналның баш редакторы **Асия Фәрит кызы Хәсәнованы Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамоталары** белән бүләкләде.

* * *

Совет матбугатында озак еллар буенча нәтиҗәле эшләүләре өчен һәм «Азат хатын» журналының илле еллыгы уңае белән, журналның әдәби хезмәткәре **Диләрә Гази кызы Зөбәерова, Әлифә Закир кызы Сафина**, техник редакторы **Әлмира Лотфулла кызы Әдиятуллина**, художество редакторы **Илдар Каюм улы Әхмәдиев КПСС өлкә комитетының һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Почет грамоталары** белән бүләкләнделәр.

* * *

Совет хореография сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 50 яшь тулу уңае белән, Казан дәүләт культура институтының хореография кафедрасы мөдире, РСФСРның халык артисткасы **Нинель Даут кызы Юлтыева КПСС өлкә комитетының һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Почет грамотасы** белән бүләкләнде.

* * *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, В. И. Качалов исемендәге Казан дәүләт рус Зур драма театры артисты **Вадим Григорьевич Острополъскийга** ТАССР Верховный Советы Президиумының 19 августта игълан ителгән Указы нигезендә **ТАССРның халык артисты**, шул ук театр артисткасы **Людмила Борисовна Кара-Гяурга ТАССРның атказанган артисткасы** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

* * *

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен, РСФСР художество фондының Татарстан бүлеге директоры **Евгений Александрович Макаровка** һәм, сәнгать кадрлары әзерләүдәге хезмәтләре өчен, Казан театр училищесы директоры **Арнольд Львович Шапирога** ТАССР Верховный Советы Президиумының 11 һәм 19 августта игълан ителгән Указлары белән **ТАССРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

## КОНКУРС ДӘВАМ ИТӘ

РСФСР Министрлар Советының нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре буенча дәүләт комитеты, РСФСР Язучылар союзы, РСФСР Художниклар союзы һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты, Бөек Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгына багышлап, балалар өчен язылган иң яхшы сәнгать әсәрләренә Бөтенроссия конкурсы игълан иткәннәр иде. 1977 елның беренче сентябренә кадәр дәвам итәчәк ул конкурсның шартларын тагын бер кат исегезгә төшерәбез: конкурска проза, поэзия, драма әсәрләре; документаль һәм публицистик әсәрләр; китапларга ясалган иллюстрацияләр тәкъдим ителергә мөмкин. Конкурска советлар иленең тарихын, совет халкының тормышын, коммунистик төзелештәге уңышларыбызны, замандашларыбызның рухи дөньясын дөрес чагылдырган һәм яшь буында илгә мәхәббәт, совет патриотизмы һәм пролетар интернационализм хисе, коммунизм эшенә тугрылык тәрбияләп торган әсәрләр кабул ителә. Конкурс жюрие тарафыннан иң яхшы дип табылган әсәрләргә 1000 әр сумлык ике беренче, 500 әр сумлык биш икенче, 300 әр сумлык биш өченче премияләр биреләчәк. Болардан тыш һәркайсы 100 әр сумлык биш кызыксындыру премиясе дә билгеләнгән. Премия алган әсәрләр авторларына Почетлы дипломнар тапшырылачак.

Кульъязмаларны (машинкада басып һәм ике данә итеп) түбәндәге адрес белән җибәрергә кирәк: Москва, Центр, Малый Черкасский пер., д. 1, издательство «Детская литература» — на конкурс.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Драматург Диас Вәлиев һәм Казанда яшәүче рус язучысы Геннадий Паушкин шәһәрнең вертолет заводы пропагандистлары һәм агитаторлары белән очраштылар. Алар пропагандистларга СССР Язучылары-ның VI съезды йомгаклары, республикабыз әдәбиятындагы яңалыклар хакында сөйләделәр, үз әсәрләрен укыдылар һәм сорауларга җаваплар бирделәр.

* * *

Шагыйрьләребез Зәки Нури белән Рәдиф Гатауллин, ял итүчеләрнең үтенече буенча, Шеланга ял йортына барып поэзия сөючеләр белән очраштылар һәм аларга СССР язучыларының VI съездында каралган мәсьәләләр, «Казан утлары» журналының киләсе елга планнары, бүгенге әдәбиятыбыздагы яңалыклар турында сөйләп, үзләренең шигырьләрен укып кайттылар.

* * *


Прозаик Вакыйф Нуруллин, яшь язучы Марсель Галиев, ТАССРның атказанган артисткасы һәм композитор Сара Садыйкова филармониядән бер төркем башкаручылар белән Октябрь Норлаты районы авылларында әдәби-музыкаль кичәләр үткәрделәр.

* * *

А. М. Горький һәм Г. Тукай премияләре лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким инде күп еллардан бирле җәй айларында ел саен үзенең туган авылына (Арча районының Кулле Киме авылы) кайтып, авылдашлары арасында яшәп, аларның тормыш-көнкүрешләре белән танышып килүне гадәт итте. Быел да шагыйрь шул гадәтенә тугрылык күрсәтеп, якташлары янында булып, үзенә иҗат материалы туплап кайтты.

## ГАСТРОЛЬ УҢЫШЛЫ ҮТТЕ

Ленинградның кече драма театры август аенда Казанда гастрольдә булып китте. Аның спектакльләре В. Качалов исемендәге рус драма театры һәм Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинаһарында күрсәтелде. Кунакларның репертуары кызыклы һәм бай иде. Алар Казан тамашачыларына В. Розовның «Мәңге исәннәр», И. Дворецкийның «Озату», А. Кутерницкийның «Нина», Америка язучысы Николас Е. Баэрның киносценарие буенча эшләнгән «Низаг», А. Островскийның «Ялтыраган һәр нәрсә алтын түгел», атаклы чех драматургы К. Чапекның «Юлбасар», Б. Рацер һәм В. Константиновның «Сәер кешe» исемле әсәрләре буенча куелган спектакльләрне алып килделәр. Ленинградлыларның һәр спектакле уңышлы үтте һәм тамашачыларда зур тәэсир калдырды.




# КУҢЕЛЕМДӘ ИКЕ ЯЗ

**ФАСИЛ ӘХМӘТОВ** музыкасы

**РӘДИФ ГАТАУЛЛИН** сүзләре

Бу көннәрне якты дию генә,
Алтын дию генә аз мәллә?!
Нәрсә булды безгә?
Нәрсә булды күзгә?
Тирә-юньдә яшел яз мәллә?

Бу күңелдә нинди шатлык хисе,
Каян килә җылы май нуры?!
Нәрсә булды безгә?
Нәрсә булды күзгә?
Җанга ява ләйсән яңгыры.

Бу гөлләр, күр, соңгы гөлләрмени?
Күпме матур төсләр, күпме наз!
Нәрсә булды безгә?
Нәрсә булды күзгә?!
Килде җиргә быел ике яз!

*Хөрмәтле укучыбыз!*

«Казан утлары» журналы үзенең берьеллык эшен тәгәлләп килә. Менә инде аның унберенче санын алдыгыз. Елның соңгы аенда Сезне нәрсәләр көтә соң?

Без ул санны Әхсән Баяновның КамАЗ төзелеше, андагы кешеләр тормышын сурәтләгән «Киң урамнар» дигән шигырьләр бәйләме белән ачабыз.

Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» романы шушы санда тәмамлана.

Журнал Сезнең игътибарга ике яшь шагыйрьнең беренче шигырьләрен тәкъдим итә. Аларның берсе — Ренат Хәйри, икенчесе — Рафикъ Юнысов.

Очерклар бүлегендә КамАЗ хроникасы дәвам итә һәм Ф. Хәбибуллинның «Музыка шикелле» дигән очеркы басыла.

1977 елда Галимҗан Ибраһимовның тууына 90 ел тула. Бу зур бәйрәмгә хәзерлек уңаеннан «Казан утлары» журналы яңа рубрика ачты һәм үзенең һәр санында әдипнең иҗатына караган материаллар басып чыгаруны планлаштырды. Ул санда Сез әдипнең яңа табылган хатлары белән танышырсыз.

Татар театрының 70 еллыгына карата басылган төрле характердагы материаллар театр сәнгатебезнең тарихын өлешчә күзаллауга ярдәм итәр.

12 нче санда Сез күренекле татар шагыйре Зыя Мансур архивыннан алынган шигырьләр, яңа китапларга рецензияләр, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары һәм 1976 елда басылган әсәрләрнең исемлеге белән танышырсыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210